ISSN 0206-4189

# КАЗАН УТЛАРЫ

3.2014



2014
мәдәният елы



*Йөз ел элек — татар театры коллективы.*
*Сулдан уңга утырганнар: Мөштәриева, Байкин, Гайшә Терегулова. Басканнар: Кәрим Тинчурин, Гөлсем Болгарская, Нури Сакаев, Габдулла Кариев, Сара Байкина.*
*«Ак чәчәк» бәйрәме. 1914 ел.*

**Казан утлары**

**Qazan utlari** 12+

2014

# 3

**(1097)**

ТМ
татмедиа

*ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ:*
*«ТАТМЕДИА»*
*ачык акционерлык җәмгыяте*

*БАШ МӨХӘРРИР*
**Илфак Мирза улы**
**Ибраһимов**

*ИДАРӘ:*

**Рабит Батулла**
**Нурия Беломоина**
**Разил Вәлиев**
**Рәдиф Гаташ**
**Дания Заһидуллина**
**Дамир Исхаков**
**Рафис Корбан**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Айрат Сибагатуллин**
**Энгель Фаттахов**
**Равил Фәйзуллин**
**Рамил Ханнанов**
*(җаваплы сәркатип)*
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

---

*Мөхәррирләр:* **Айгөл Әхмәтгалиева, Гөлзадә Бәйрәмова, Әлфәт Закирҗанов, Камил Кәримов, Вакыйф Нуриев, Ләйсән Солтанова.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Флёра Сабирова.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Гөлнара Галиева** (баш бухгалтер).

---

✉✉: Редакция һәм нәшер адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Баш мөхәррир — 562-10-62.*
*Җаваплы сәркатип, компьютер үзәге — 222-09-83 (өст.1612).*
*Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге — 222-09-83 (өст.1616).*
*Исәп-хисап бүлеге — 222-09-80 (өст.5).*

**Факс** — (843) *222-09-83 (өст.1612).*

**E-mail:** kazanutlari@yandex.ru

# КАЗАН УТЛАРЫ

www.kazanutlary.ru

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА


## Бу санда


**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Г. Тукай, Р. Мингалим, Р. Гаташ, М. Әгъләм, А. Хәлим, Р. Вәлиев, Р. Миңнуллин, М. Мирза, Г. Морат, Л. Шәех шигырьләре. ....5
АХИР. Таш калада баш кала... *Роман.* ....12
Флёра ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА. Имин тормыш юллап халкыма. *Шигырьләр.* ....50
Гөлинә ГЫЙМАДОВА. Пәрәвез җебе яки кыз әби кыйссасы. *Хикәя.* ....53
Сирень ЯКУПОВА. *Хикәяләр.* ....59
Клара БУЛАТОВА. Гомер аты шундый тиз чапты. *Шигырьләр.* ....73
Нәҗибә САФИНА. Тын кал да, тыңла әле... *Шигырьләр.* ....76
Ләйсән ФӘТХЕТДИНОВА. Сүз кыйммәте бүген — ихлас фикер. *Шигырьләр.* ....113
Рухия АХУНҖАНОВА. Хыяллардан чынбарлыкка кайттык. *Шигырьләр.* ....116

**ДРАМА ӘСӘРЛӘРЕ**

Зөлфәт ХӘКИМ. Җенле күл. *Театраль роман.* ....81

«Казан утлары» архивыннан. ....120, 152

**ТАТАР ХИКӘЯЛӘРЕ ХӘЗИНӘСЕННӘН**

Кояш ТИМБИКОВА. Сөлге булсын бүләгем! ....122

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Нурфия ЮСУПОВА. Татар шигъриятенең үсеш-үзгәреш юллары. ....127

**СӘНГАТЬ**

Милли сәнгатебезнең олы хәзинәсе *(Фәрит Бикчәнтәев белән Илфак Ибраһимов әңгәмәсе).* ....135
Эльвира ҺАДИЕВА. Таң йолдызы эзеннән... ....143
«Җырла, егет, киереп киң күкрәгең...» *(Рафаэль Ильясов белән Филүсә Арслан әңгәмәсе).* ....147

**ФИКЕР**

Ренат ХАРИС. Каш ясыйм дип... *(Рашат Низамига ике хат).* ....154

**МИЛЛИЯТ**

Азат ЗЫЯТДИНОВ. Татарстаным – Идел-йортым! ....160

**ТАРИХ**

Искәндәр ГЫЙЛӘҖЕВ. Беренче Бөтендөнья сугышында Алманиядә мөселман әсирләре. ....167

**ФӘН**

Фаяз ХУҖИН. Вахит Имамов иҗатында татар тарихы. ....173

**АК ҖИЛКӘН**

Руслан РӘҮПОВ. Булганда — кадерен бел, югалткач — елама. *Бәян.* ....181
Сиринә МӨХӘММӘТҖАНОВА. Сиңа килдем бүген кабаттан. *Шигырь.* ....189
Флёра МӘРДӘНОВА. Ике Хәсән хикәясе. ....189

# В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*


«Проза и поэзия»: АХИР. Роман «Город — пожиратель душ» (прод.); рассказы К.ТИМБИКОВОЙ, Г.ГИМАДОВОЙ, С.ЯКУПОВОЙ; стихи Г.ТУКАЯ, Р.МИНГАЛИМА, Р.ГАТАША, М.АГЛЯМА, А.ХАЛИМА, Р.ВАЛИЕВА, Р.МИННУЛЛИНА, М.МИРЗЫ, Г.МУРАТА, Л.ШАЕХА, Ф.ГИЗЗАТУЛЛИНОЙ, Н.САФИНОЙ, К.БУЛАТОВОЙ, Л.ФАТХУТДИНОВОЙ, Р.АХУНЗЯНОВОЙ.

«Драматургия»: З.ХАКИМ. Театральный роман «Чёртово озеро».

«Литературная критика»: Н.ЮСУПОВА. «Пути становления и развития татарской поэзии».

«Искусство»: интервью И.ИБРАГИМОВА с главным режиссёром театра им. Г.Камала Ф.БИКЧАНТАЕВЫМ; статья Э.ХАДИЕВОЙ, посвящённая юбилею актрисы А.ГАЙНУЛЛИНОЙ; интервью Ф.АРСЛАНОВОЙ с народным артистом Татарстана Р.ИЛЬЯСОВЫМ.

«Татарский мир»: Р.ХАРИС. «Два письма Р.Низамиеву».

«История»: И.ГИЛЯЗОВ. «Мусульманские пленные в Германии в Первой Мировой войне».

«Наука»: Ф.ХУЗИН. «История татар в творчестве В.Имамова», Ф.ГАРИПОВА. «История наших деревень».

«Белый парус»: повесть Р.РАУПОВА, стихотворение С.МУХАМЕТЗЯНОВОЙ, рассказ Ф.МАРДАНОВОЙ.

На наших обложках: «Весна»; сцена из спектакля «Голубая шаль» (К.Тинчурин).


# IN THIS ISSUE:

*The magazine edits monthly*


«Prose and poetry»: Akhir. Doman «City as a Soul Eater» (cont.); stories by K.TIMBIKOVA, G.GIMADOVA, S.YAKUPOVA; poems by G.Tukay, R.Mingalim, R.Gatash, M.Aglyam, A.Khalim, R.Valiyev, R.Minnullin, M.Mirza, G.Murat, L.Shayekh, F.Gizzatullina, N.Safina, K.Bulatova, L.Fatkhutdinova, R.Akhunzyanova.

«Dramatic art»: Z.Hakim. Theatrical novel «Devil's Lake».

«Literary criticism»: N.YUSUPOVA. «Ways of formation and development of Tatar poetry».

«Art»: interview of I.IBRAGIMOV with the general director of the theater named after G.Kamal F.BIKCHANTAYEV; article by E.HADIEVA devoted to anniversary of the actress A.GAYNULLINA; interview of F.Arslanova with the national actor of Tatarstan R.Ilyasov.

«Tatar world»: R.Harris. «Two letters to R.Nizamiyev».

«History»: I.GILYAZOV. «Muslim captured in Germany in World War I».

«Science»: F.KHUZIN. «History of Tatars in V. Imamov's creativity», F.GARIPOVA. «History of our villages».

«White sail»: story by R.RAUPOV, poem by S.MUKHAMETZYANOVA, story by F.MARDANOVA.

On our covers: «Spring»; scene from the performance «Blue Shawl» (K.Tinchurin).



★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән житешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 27.02.2014, график буенча 27.02.2014.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108 1/16.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ А-486. Тираж 3107.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсендә 2011 елның 23 мартында теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-44362.
Индекс: 73210 (физик затлар өчен), 16262 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

Тираж сертификацияләнгән.

«ТАТМЕДИА» ААҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2



© «Казан утлары», 2014 ел

Габдулла ТУКАЙ

## Өзелгән өмид

*Күз карашымда хәзер үзгәрде әшьялар төсе,*
*Сизелә: үтте яшь вакытлар, җитте гомрем яртысы.*

*Күз тегеп баксам әгәр дә тормышымның күгенә,*
*Яшь һилал урнында — анда тулган айның яктысы.*

*Нинди дәрт берлән каләм сызсам да кәгазь өстенә,*
*Очмый әүвәлге юләр, саф, яшь мәхәббәт чаткысы.*

*И мокатдәс моңлы сазым! Уйнадың син ник бик аз?*
*Син сынасың, мин сүнәмен, айрылабыз, ахрысы!*

*Очты дөнья читлегеннән тарсынып күңлем кошы.*
*Шат яратса да, җиһанга ят яраткан Раббысы.*

*Күпме моңлансам кунып милли агачлар өстенә,*
*Барсы корган, бер генә юк җанлысы, яфраклысы.*

*Булмадың алтын ярым, салкын ярым син дә минем,*
*Бер тәбәссем берлә дә тормыш юлым яктырткычы!*

*Күз яшең дә кипмичә егълап вафат булган әни!*
*Гаиләсенә җиһанның ник китердең ят кеше?!*

*Үпкәнеңнән бирле, әнкәй, иң ахыргы кәррә син,*
*Һәр ишектән сөрде углыңны мәхәббәт сакчысы.*

*Бар күңелләрдән җылы, йомшак синең кабрең ташы,*
*Шунда тамсын күз яшемнең иң ачы һәм татлысы!*

Рөстәм МИНГАЛИМ

## Кышкы суыкларга кердек исә

*Кышкы суыкларга кердек исә,*
*Хәтеремә төшә үткәннәр.*
*Аякта нык хәзер, өстә калын,*
*Онытылсын иде ул көннәр.*
*Тәрәзләргә салкын урман чикте,*
*Ә ягарга утын юк иде...*
*Шәһәрләр ач иде, авыллар ач,—*
*Сугыш кына ул чак тук иде.*
*Су буенда безнең ач әнкәйләр*
*Су җылыта иде малларга.*

*Башлары боз иде, өсләре боз —*
*Боз хатыннар кебек аналар.*
*Кулларында һаман бозлы чиләк,*
*Юлларына калын боз сарган.*
*Елгасы боз аның, дөньясы боз...*
*Таймас өчен ныграк басарга!*
*Итәкләрен тарта боз чуклары,*
*Бөкләгәндә — җиңнәр сыналар.*
*Өйгә кайтып, безне җылытырга*
*Каян җылы тапкан соң алар?*
*...Бик өшетеп хәтеремә төшә,*
*Йөрәгемә төшә ул көннәр.*
*Күшегеп тора иде, бөгәрләнеп,*
*Моржалардан чыккан төтеннәр...*

**Рәдиф ГАТАШ**

## Хатын–кызларга җыр

*Яратабыз,дибез... Шулай микән?*
*Сүздә һаман әйтеп без аны,*
*Ә гамәлдә сезнең иңгә инде*
*Салмадыкмы... хәтта дөньяны?! —*
*Хатын–кызлар!*
*Әни һәм әбиләр,*
*Апалар, әй ярлар, сеңелләр...*
*Сезгә һаман җыр без багышладык,*
*Бәлки, алар ихлас түгелләр?!*
*Җиңел генә мактыйбыз да һаман,*
*Фәрештә, дип, күккә чөябез.*
*Ә чынлыкта нигә Адәм эшен*
*Сөйгән Хаувабызга өябез?*
*...Көрәк һәм лом тота безнең Муза,*
*Гөлләр, сездә таудай мәшәкать —*
*Вазифалар йөге... Ә нәфислек?*
*Каян вакыт сиңа, мәхәббәт?!*
*Заманалар гаме җаныгызда!*
*Айыйбызмы наз, ямь иясен?!*
*Сакланамы Зөләйхалар? Матур —*
*Ул батыр да бүген, күрәсең...*
*Юккамы ир,ата була белмәс,—*
*Җәмгыятьтә гамьсез кеше өчен*
*Сез янасыз! Нык гаилә, нигез,*
*Җир бәхете, илнең эше өчен*
*Җаваплылык, зур горурлык сездә!*
*Күпләрегез җыр да язалар —*
*Зарланусыз, якты... Кырыс бары!*
*Сез шул — атом чоры музалары,*
*Вазифалар гөле — розалар...*
*Беләбезме кадерегезне сезнең?*
*Күрсәтәбезме чын хөрмәтне?*
*Матурлыкны мактау булды, әмма*
*Онытмадыкмы зур хезмәтне*
*Сезнең, бөек гасыр Хаувалары,*
*Илнең чын каһарман кызлары?!*

*Яратабыз, дидек. Изге сүзне*
*Арзанайттык, ирләр, без аны!*
*Их, ичмасам, саклый белсәк икән,*
*Аңлый, яклый белсәк икән —*
*Инде*
*Сезнең иңдә барган дөньяны!*

**Мөдәррис ӘГЪЛӘМ**

## Бердәнбер

*(Баллада)*

*Иделнең иң гүзәл җирендә*
*Шәм кебек сузылып үскән ул,*
*Борынгы җырларда җырланган*
*Чишмәгә суга дип төшкән ул;*
*Авылның гармунчы егете*
*Аны нәкъ шул чакта күргәндер —*
*Алмадай кызлар күп авылда,*
*Арада ул гына —*
*Бердәнбер.*

*Кичләрен уенга чыкканда,*
*Беркемгә сиздерми чыгарга,*
*Яхшыга киясе күлмәген*
*Чыгарып яшергән чоланга.*
*Үзе дә кичергән әнисе*
*Аның бу хәйләсен белгәндер —*
*Хәйләкәр кызлар күп авылда.*
*Арада ул гына —*
*Бердәнбер.*

*Күбәләк шикелле талпынып*
*Очкан ул, бер чыккач иреккә,*
*Яшьлектә кал шулай*
*Гомерлек уйнап та,*
*Җырлап та, биеп тә.*
*Ул, бәлки, нәкъ шушы уенда*
*Яшьлеген озатып көлгәндер,*
*Һәркемнән узачак ул бәйрәм —*
*Һәркемнең яшьлеге*
*Бердәнбер.*

*Ул кемнән ким әле,*
*Ник әле*
*Яраткан егетенә чыкмасын?!*
*Туй белән биргәннәр аны да,*
*Искечә укытып никахын.*
*Кем белә, ә бәлки,ул чакта*
*Бу безнең туйлар да кергәндер —*
*Ак туймы, кызылмы — барыбер*
*Ул аның туе бит,*
*Бердәнбер.*

*Аннары бу сугыш, озату,*
*Аерылу иреңнән дүрт елга.*

*Дүрт елга барган бу сугышның*
*Газабы барачак күп елга.*
*Үпкәдән килгән бу кара кан:*
*Симәнә ташыган үрдәндер,*
*Ә ире исән—сау кайтачак —*
*Ул аның ире бит,*
*Бердәнбер.*

*Зур сугыш узды ул, тик менә*
*Тын кыса, кимерә үпкәне.*
*...Ире дә исән—сау, янында,*
*Бу сугыш бетсә дә, үтмәде,*
*Тәүлекләп игеннәр урганда,*
*Ул аңа чир булып сеңгәндер —*
*Идәндә сабые үрмәли,*
*Ул аның сабые,*
*Бердәнбер.*

*Идәндә сабые үрмәли,*
*Алырга иде бер кулыңа!*
*Бу соңгы теләге үтәлми,*
*Чем—кара күзләре йомыла.*
*Ә аның шикелле илемдә*
*Меңләгән хатыннар үлгәндер.*
*Онытма, кешелек,*
*Ул минем*
*Әнием иде бит,*
*Бердәнбер!*

***

**Айдар ХӘЛИМ**

*Халык язучысы Фәнис Яруллинның*
*хәләл җефете Нурсөя ханымга*

*Син, Нурсөя, асыл гөл—нисабыз,*
*Рухи зәгыйфьлеген күпләрнең*
*Аклап,*
*Үз иңеңдә*
*Баскычлардан*
*Фәнисне — татарны күтәрдең.*

*Серле кодрәт, сихри көчләр белән*
*Аллаһтан вәхидәй яңардың —*
*Үзебездән мәңгегә киткәнне*
*Титан әдип итеп*
*Кайтардың!..*

*Ирле — ирсез, тәмуг оҗмахында*
*Балаң итеп карап гарипне,*
*Аналык назыннан вазлар кичеп,*
*Таң калдырдың Мәшрикъ—Мәгърибне!..*

*Аһ, Нурсөя!.. Күрелмәгән дастан!*
*Нинди каннан—ханнан туләк син?*

*Без кыйлган гөнаһны гомерең белән*
*Аклатырга төшкән бүләк син!..*

*Таш астында аваз сүнә,диләр,*
*Синең белән сүнми икән ул.*
*Синең белән — кая ди Шигърият?! —*
*Шагыйрь үзе үлми икән ул!..*

*Мин, Нурсөя, халык уянсын дип,*
*Таңда йомшак кына йөткерәм.*
*Илең белән сиңа көн килсен дип,*
*Бер ат йөге гөлләр китерәм...*

**Разил ВӘЛИЕВ**

## Сине озатканда

*Сагынуым басылмады әле,*
*Ачылмады синең йөрәгең;*
*Күзләреңнән яшь тә кипмәгән бит,*
*Елмаюың әле күрмәдем.*

*...Билет юктыр бүген самолётка,*
*Буш урыннар юктыр поездга,*
*Трамвайлар тулы халык белән,*
*...Җил дә әнә моңлы җыр суза.*

*Адашырсың... күктә йолдызлар юк,*
*Юл тапмассың... төн бик караңгы.*
*Тутырыр күк айсыз, йолдызсыз төн*
*Синең белән минем араны.*

*Көз сагышы миңа күчә, дисең...*
*Телисеңме? — Хәзер яз ясыйм!*
*Чәчәк белән күмәм йөрәгеңне —*
*Мәхәббәтнең алсу вазасын.*

*Кирәк түгел чәчәкләрең, дисең,*
*Кирәк түгел сүзең: «Яз ясыйм».*
*Калсам — бары мине табарсың син,*
*Китсәм — сагынып,шигырь язарсың...*

*Ничек итеп җырлар языйм ди мин?*
*Ачалмадым синең йөрәгең...*
*Күзләреңнән яшь тә кипмәгән бит,*
*Елмаюың әле күрмәдем.*

**Роберт МИҢНУЛЛИН**

## Багышлау җыры

*Синең белән узган минутларны*
*Айлар—елларга да алышмыйм.*
*Уем белән мин гел синең янда,*
*Өзгәләнсен әле синең җан да —*
*Бу җырымны сиңа багышлыйм!*

*Сагынулар, саргаюлар белән,*
*Югалтулар белән таныш мин.*
*Син дә мине искә төшерерсең,*
*Мине сөюеңне төшенерсең —*
*Бу җырымны сиңа багышлыйм!*

*Сине уйлап узган гомеремне*
*Сагышларым белән нәкышлыйм.*
*Син дә мине сагынырсың әле,*
*Узганнарга сарылырсың әле —*
*Бу җырымны сиңа багышлыйм!*

*Шатлыкларым күңел тулы иде,*
*Шатлык идем, инде сагыш мин.*
*Сиңа ләкин шатлык кына теләп,*
*Сиңа ләкин аклык кына теләп,*
*Бу җырымны сиңа багышлыйм!*

***

**Мөхәммәт МИРЗА**

*Халык язучысы Рабит Батулланың*
*йөзьяшәр Әнкәсе Мөкәррәмә Анага!*

*Соңарып килгән яз төне,*
*Томан пәрдә япкан күген.*
*Бар да йоклап беткән,димә:*
*Сәҗдәгә оеган түнеп,*
*Йөзьяшәр Әнкәсе бүген.*

*Дисбесенең һәр төймәсе —*
*Хатирәләр хәситәсе...*
*Ил Агасы бүген Улы!..*
*Сәҗдәгә оеган түнеп:*
*— Сузылмыйча яз килсәче?!.*

*Хәтеренең төпкеленнән*
*Актарамы гомер көлен...*
*Утыз сигезенче елның,*
*Зәйдә боз кузгалган мәлдә,*
*Тулгагы тулкыган өнен?*

*— Соңармыйча килсәче яз,*
*Кермичә җәй өлешенә...*
*Томан таралды... Тулганай*
*Челтәрле ак шәлен япты*
*Йөз яшьлек чал көмешенә!*

**Газинур МОРАТ**

## Хәтернең ак дивары

*Хатирәләр хәтеремне*
*Алалар телеп—телеп.*
*Сагынган да кебек булам,*
*Сагынмаган да кебек.*

*Хәтернең ак диварында*
*Сурәтең тора көлеп.*
*Яраткан да кебек булам,*
*Яратмаган да кебек.*

*Сурәтеңне ак диварга*
*Мин үзем куйдым элеп.*
*Табынган да кебек булам,*
*Табынмаган да кебек.*

*Кавышканнар сирәк була —*
*Сөйлиләр бик тә белеп.*
*Яшәгән дә кебек үзем,*
*Яшәмәгән дә кебек.*

*Хәтернең ак диварында*
*Сурәтең тора көлеп.*

**Ленар ШӘЕХ**

## Бары бер кат...

*Дөньяда бәхет мизгелен*
*Бары бер кат кичердем.*
*Бар халәтем белән тойдым,*
*Гомерлеккә исердем.*

*Күзләреңә бары бер кат,*
*Бары бер кат багалдым.*
*Тирән сихер дәрьясында*
*Шул бәхетне табалдым.*

*Бары бер кат кулларыңны*
*Йөрәгемә алалдым.*
*Күктән көлгән ай шикелле*
*Кызардым да агардым.*

*Бары бер кат иреннәрем:*
*— Сөям... —*
*дип пышылдады.*
*Син генә хис дулкынына*
*Нигәдер кушылмадың...*

*Дөньяда бәхет мизгелен*
*Бары бер кат кичердем.*
*Ак томаннарга уралдың,*
*Эредең, очтың, югалдың...—*
*Мин мәңгегә исердем.*



АХИР

# ТАШ КАЛАДА БАШ КАЛА...

РОМАН

## 12

Динә барыбер үз сүзеннән кайтмады. Аның бар булган уе — тизрәк фатир алу иде. Фатир алуга ук, ул эштән китәчәк. Трамвай йөртүдән туйган иде ул. Кызның әти-әнисе дә аңа һаман шул бер сүзне тукыйлар: «Кит син аннан, ирең ашатсын!» Ләкин фатир алмыйча, эштән китеп булмый, беренчел сумманы түләүгә карамастан, фатирны барыбер тиз генә бирмиләр. Беркөнне тулай торакка ашкынып кайтып кергән Динә, ятакта ял итеп яткан иренә:

— Мин кабат Гаврилин катына кердем! — дип оран салды.

— Тагын ресторанга чакырдынмы?

— Әйе, чакырдым.

— Бер чакырдың бит инде, бармады!

— Вакыты булмады.

— Ну, ниемә чакырасың соң син аны?

— Шунда барсы да хәл ителәчәк!

— Киләме?

— Килә!

— Акча кирәк булачак!

— Тап! Фатир сиңа да кирәк бит, бер миңа гына түгел!

— Миннән бигрәк сиңа кирәк ул! Авылда йортым бар! Авылым минем моннан сиксән генә километр! Фатир бирмиләр икән, кайтам да китәм!

— Кайт! Мин сине тотмыйм!

Динәнең уйнап кына әйткәнен яхшы аңлый иде ул. Кайтып китсен әле менә барсын да ташлап, ире артыннан ул икенче көнне үк йөгереп кайтачак. Ләкин Нариманны икенче бер нәрсә сагайтты: Динәнең баласын төшергәненә инде ярты елдан артык вакыт узды, ә икенчегә узарга уйламый да иде...

— Карале, хатын, сине бернәрсә борчымыймы?

— Юк, ә нәрсә?

— Һаман да балага узмыйсың!

— Ә нишләп узарга тиеш соң мин?

*Дәвамы. Башы узган санда*

—Без бит сакланмыйбыз. Сакланмагач, сау-сәламәт хатын балага узарга тиештер бит инде?!

— Сина күпме әйтергә була...

— Беләм, ин элек фатир. Ә аны алганчы, балага узарга ярамыймы? Син бала тапканда безгә как раз фатир булырга да мөмкин.

— Булмаса?

— Булмаса, тулай торакта... авылда үсәр...

— Юк, бала комфортта үсәргә тиеш. Тулай торакта балалар әйберсен юып йөрисем юк әле!

— Комфорт?! Нинди комфорт? Авыл хатыннары алтышар бала таба! Әле син бер балаң белән, тумаган балаң белән комфорт, дип сүләнеп торган буласың! Оят түгелме сина!?

— Алып бир фатир — шундук табам!

— Тфү!

Нариман хатынын танымый торды. Элеккеге Динәме соң бу? Кайчандыр иренә сүз әйтү түгел, аның күзенә күтәрелеп карарга да оялган, тыйнак һәм намуслы авыл кызы калага килеп яши башлау белән үк ниндидер җилбәзәк, усал кала хатынына әверелде дә куйды. Бар булган хыялы: мода артыннан куып, өйдә бот күтәреп яту. Авыл хатыннары сыман, тан тишегеннән торып, сыер саварга барса, аның башында мондый исәр уйлар булмас та иде, бәлкем. Кем белә!? Бәлкем, Динә хаклыдадыр?! Хатын-кызны эш аты итеп күрүдән дә туктарга вакыттыр?! Әгәр дә эшлисе килми икән, бала тапсын, бала карасын, ирен яратсын! Юк, ни генә әйтсәк тә, шәһәр җире хатын-кызны аздыра, аны хәтта акылдан, юлдан яздыра. Ул баш күтәреп ирек даулый, ирен чаптыра, фатир, акча куалый, һәм нәтиҗәдә беркайчан да канәгать булып кала алмый. Таш кала сатылырга теләгәннәрнең җанын тартып ала, алар барысы да шулай кала тормышына яраклаша, ә яраклашырга теләмәгәннәр мондый затсыз тормышка түзә алмый һәм, бернисез калып, авылына, туган нигезенә кайтып егыла...

— Ә мин шикләнәм, синең кабат балага уза алуына ышанып бетмим! — диде ачуы тышка бәреп чыккан Нариман.

— Нишләп алай дисең? — Динә агарынды, аның кинәттән төсе качты.

— Мине тыңламадың, аборт ясаттың!

— Шуннан?!

— Шуннан шул... Беренче мәртәбә балага узгач, аборт ясатырга ярамый. Хатын-кыз бала таба алмаска мөмкин, аңладыңмы?

— Кем әйтте?

— Медицина шулай ди.

— Син нәрсә, мине таба алмас дип уйлыйсыңмы?

— Ие! Уйлыйм! — Нариман Динә каршына буй җитмәслек биек дивар сыман торып басты. Хатын аның янында бер кечкенә генә койма ярыгы булып калды.

— Тапмам, дисеңме!?

— Ие! Кысыр син хәзер! Кысыр сыер!

— Кысыр... — Динәнең күзенә яшь бәреп чыкты. Тавышы бетте: ул ни эндәшә, ни кычкыра алмады.

— Кала харап итте сине, кала! Нәстә дип килдек без бу калага, үзебезне харап итәр өчен килдек! Шул гына!

— Кыс... ыр...

Ачуыннан, шартлардай булып кайнаган Динә кул унында торган табуретканы, күтәреп алып, Нариманга атты. Нариман иелеп калды, урындык

анардан өскәрәк очып, түшәмдәге люстраны коеп төшерде. Бик матур бәллүр люстра иде ул, бик зур чиратлар жинеп, универмагтан сатып алып кайткан иде аны хатыны. Яңа фатир алгач эләргә уйласалар да, беркөнне матурлык өчен юри генә элеп торгач, ул шул килеш түшәмдә эленеп калган иде. Ә шул матурлык, гаилә тормышы белән бергә, әле яңа гына чәлпәрәмә килеп ватылды һәм, шулай итеп, ике арадан кара мәче йөгереп узды...

## 13

Тугызынчы сентябрьдә иртәнге тугызда (ул көнне аның гомердә дә онытасы юк!) бүлмәгә ике милиция кешесе килеп керде. Берсе милиция, икенчесе штатный киемнән. Юк, Нариман алардан куркып калмады, куркак егет түгел иде ул, ләкин тиктомалдан милиция килеп кергәч, шактый гажәпсенде. Ул үзенең бернинди кырын эш кылмаганын белсә дә, каушап калып, озак кына аңышмыйча торды. Бервакытта да нәрсә булып бетәсен белмисең, милициядән теләсә нәрсә көтәргә була. Өйдә ялгызы гына, Динә сменада, ул әле һаман да кайтып житмәгән иде.

Милиция киемендәгесе участковый, ә тегесе тикшерүче булып чыкты. Икесе дә авылныкылар: олырагы, участковый (Нариманның аны бер-ике мәртәбә күргәләгәне дә булды) — бу тирәдә шактый күптәннән бутала, милиция хезмәте авыр хезмәт булса да, беркая да китә алмый, чөнки аңа эшеннән фатир биргәннәр иде. Фатирны үзенә калдырыр өчен милициядә ун ел хезмәт итәргә кирәк. Икенчесе әле яшь егет, күрәсең, югары уку йортын яңа гына бетергән, юрист, аңа да хәзер үзен күрсәтергә кирәк.

— Нариман Жамалов сез буласызмы? — дип сорады ул, ишек төбендә тукталып.

— Ну... — Нариман төртелеп калды.

— Синме Нариман!? — дип усал елмайды участковый. Аның бу елмаюын ике төрле анларга була иде. Ул аның янында иптәшләрчә кыланырга һәм шулай ук, милиция хезмәткәрләре сымак, әзрәк кенә тупас, вәкарь булып калырга тырышты.

— Әйе... мин...

— Жыен, әйдә!

— Кая?

— Отделениегә!

— Ни өчен?

— Анда аңлатырлар...

Урамда аны милиция машинасы көтеп тора иде. Артына тимер челтәр киертелгән зәңгәр «УАЗ»ик. Аста йөгереп йөрүче таныш вахтер, комендант хатын һәм берничә яшәүче кеше милициягә ияреп чыгып барган Нариманга сәерсенеп карап калдылар. Әле ярый кулына богау салмадылар, оятыннан кая кереп качарга да белмәссең! Чөнки эчмәгән, тартмаган, беркайчан да тәртип бозмаган, үзен һәрчак әдәпле тоткан, кирәк вакытта кешеләргә һәрвакыт ярдәм итәргә торган Нариманның әлеге тулай торакта абруе зур иде. Шуны аңлаган участковый «УАЗ»икның арткы ишеген ачтырып тормады, Нариманны тиз генә алга утыртты...

Милиция бүлегендә аны аерым бүлмәгә алып керделәр. Бер зур өстәл, ике урындык һәм башка берни дә күренми, хәтта гадәттә диварларга эленә торган совет плакатлары да юк. Сорау алу бүлмәсе булып чыкты бу. Бераздан бүлмәгә, салмак адымнар белән генә атлап, Нариманнарга килгән баягы юрист малай керде. Ул аның каршысына утырды, кызыл папкасын ачып, аннан нindидер кәгазьләр, әйберләр чыгарды. Карап торышка гади бер авыл баласы инде, ләкин

авыллыгын, татарлыгын яшергән булып, үзе кебек үк авыл егете белән урысча сөйләшкән була. Кара юка костюм, зәңгәр күлмәк, кызыл галстук — бар да тәртип, бар да үз урынында. Тик менә буе гына кыска, шуның аркасында аның кигән кәчтүме олырак булып күренә һәм ул тоткын каршында нindидер вак бер ипи валчыгы кебегрәк шәйләнә...

—Нариман Халикович, — диде ул, ниһаять (әтисе исеме белән ана әле беренче мәртәбә эндәшәләр иде, ул әллә нишләп китте!), — сез кеше үтерүдә гаепләнәсез!

Бу коточкыч сүзләрдән соң, Нариманга берьюлы кызык та һәм куркыныч та булып китте. Каян килеп? Бар кызыгы шунда! Ә куркырлык берни дә юк кебек, аның кеше үтергәне юк. Ләкин органнарның бер гаепсезгә кешеләрне утырткannарын һәм хәтта үлем җәзасы биргәннәрен ишеткәне бар иде аның. Менә шуңа күрә дә ана куркыныч булып китте. Ләкин җебеп тә төшмәде, үзүзен кулга алырга тырышты.

— Бр-р-рат! — дип кинәт кенә дустанә дәште ул тикшерүчегә. — Син кайсы авылдан?

— Ничек кайсы? — Юрист малай (мондый кучешкә әзер булмаган, күрәсең!) аптырап, каушап калды. Ләкин гакылын җуймады, ике араны тигез тотты, дилбегәне ычкындырмады.

— Биргән сорауга төгәл генә җавап бирегез, пажалысты!

— Ә җавабым шул! Карале мина...

— Әйе...

— Мин кеше үтерүчегә охшаганмы, юкмы!?

Нариман егетнең күзләренә ихлас итеп, туп-туры карады. Мондый караштан соң юрист малай, анар кыенсынып кына: «Гафу итегез, ялгышканбыз!» —дип әйтергә тиеш кебек иде. Ләкин юрист малайның авызыннан андый сүзләр яңгырамады. Тикшерүченең монда карата үз фикере һәм, иң гаҗәбе, үз дәлилләре дә бар икән ләбаса...

—Сез бу кешене беләсезме? — Тикшерүче олы яшьтәге бер ир кешенең фотосурәтен чыгарып күрсәтте.

— Юк! Кем соң ул?

— Корбан... Аны кич өендә үтерделәр. Казан кешесе ул. Гомере буе калада яшәгән. Сезнең кайчан да булса Карбышев урамындагы унынчы йорт, сиксән беренче номерлы фатирда булганыгыз бармы?

— Юктыр... дип уйлыйм...

— Нариман Халикович, бу уен эш түгел, монда шаяру урынсыз. Төгәл итеп җавап бирегез: булдыгызмы сез ул фатирда, юкмы?

— Юк, кәнишне.

— Яхшы. Ә менә бу нәрсә сезнекеме? — Тикшерүче юка гына бер документ кисәге чыгарып күрсәтте.

— Нәрсә соң ул?

— Профсоюз билеты.

— Тотып карарга ярыймы?

— Юк, ярамый, — дип кырт кисте юрист. — Мин аны сезнеке дип уйлыйм. Чөнки монда сезнең исем-фамилиягез язылган. Сезгә аны Казан сөт комбинатыннан, профсоюздан биргәннәр...

Нариман әле яшь, ул үз гомерендә бер генә мәртәбә дә күзлек киеп карамаган, аның күзләре әйбәт күрәләр иде. Ул үзенең профсоюз билетын бик тиз таныды һәм ул аның тышында әзрәк кан таплары да шәйләп алды. Шундук аның башыннан: «Әй, абый, абый нишләдең син!» — дигән үкенечле уйлар йөгерде. Исенә төште: ул үзенең профсоюз билетын Назыймга бүләк иткән иде. Дөресрәге,

ул үзе аны Нариманнан сорап алды. «Эчкән вакытларымда кесәгә паспорт тыгып йөрергә куркам, югалтуым бар, әгәр ул сиңа кирәкмәсә, бир миңа, мин аны үземә яраклаштырып, ясап куям!» — дип сорагач, Нариман авылдашының сүзенә каршы килә алмаган иде. Профсоюз билетын ул бигүк кирәк нәрсә дип тапмады, шунар күрә ул аны, бер дә кызганмыйча, Назыймда калдырып чыкты. Тә-ә-әк! Ничек булып чыга соң бу хәзер? Димәк, Назыйм абыйсы шаяртмаган, Назыйм сүзендә торган: Шәмсыгаян апайны харап иткән адәмнең башына житкән, ул аны үтергән. Үтерүченең: « Әле аның краны ябылып бетмәгән. Өч көннән бәреп чыгачак ул... менә күрерсең... су... кып-кызыл... су... » — дигән сүзләре, жанны өшетеп, баш миен тагын бер кат чыбыркылап алды...

—Үтерелгән кешенең исеме ничек соң? — дип сорады Нариман.

— Сез белмисезме? — дип сынаулы караш ташлады аңа юрист.

— Юк, белмим.

— Белмәсәгез, әйтәм. Сәлим.

— Сәлим!?

— Беләсез... димәк...

Нариман бер сүз дә әйтмәде. Әйе, ул Сәлим атлы иде. Димәк, Назыйм аңардан үзенең үчен алган, ул аны үтергән. Нигәдер ул үтерелгән кешене түгел, ә Назыймның үзен жәлләде. Чынында исә аңар бу минутларда үзен кызганырга кирәк иде, ул үзе дә авыр хәлдә калды. Тикшерүчегә дөресен сөйләп бирсә, гаепне аңардан алып атачаклар, ә Назыймны шундук кулга алачаклар. Дустын, авылдашын сату булып чыга түгелме соң бу? Ләкин мәсьәләнең икенче ягы да бар иде. Нишләп ул профсоюз билетына үз исем-фамилиясен язып, фотосын ябыштырмаган соң? Жавап шундый: йә теләмәгән, йә инде өлгермәгән. Әгәр дә ул үзенең жинаятен башка кешегә (бу очракта Нариман!) аударыр өчен махсус шулай эшләгән булса? Юк, юк... Назыйм андый юлга бармас... Назыйм андый кабахәтлекне эшләмәс... беркайчан да...

— Мин сиңа шуны гына әйтә алам, брат, мин аны үтермәдем.

— Моны ни белән дәлилли аласыз?

— Кичә кич мин өйдә булдым. — Тикшерүче аңардан иң элек шуны сорарга тиеш иде. Ләкин тикшерү эшендә тәжрибәсе житмәгәнгәме, әллә һаман да шул профсоюз билеты белән болгангангамы, ул Нариманның кичә кайда булганын сорап тикшерергә дә оныткан иде.

— Димәк, сезнең алибиегез бар! — диде ул Нариманның күзләренә туры карап. Авыл мужигының андый чит сүзләрне бигүк аңлап бетермәгәнен аңлап алган юрист малай тиз генә гади телгә күчте. — Моны кем раслый ала? Кем күрде сезне?

— Минем хатыным.

— Исеме?

— Динә.

— Кая эшли?

— Трамвай йортта. Өченче маршрутта...

— Кичә ул өйдә идеме?

— Без кичә кич аның белән өйдә идек.

—Ә үтерү кич белән түгел, көндез булган! — дип башын бутады аның тикшерүче.

— Без көндез дә өйдә идек...

— Тагын кем күрде сезне?

— Кем?! Комендант...

— Тагын?

—Күрше бар безнең... Рәхим исемле... әйбәт мужик. Кергән саен: «Рәхим итегез!» — дип елмаеп тора...

Тикшерүче Нариманнан күзен алмады, ул ана сөзеп, сынап карады. Каршылыклы уйлар эчендә бөтерелгән мужикның анардан нидер яшергәнен һәм шуны әйтеп, ачып салырга теләмәгәнен сизенгән юрист малай аллагы тактикасын үзгәртеп, ана берникадәр якынаерга тырышты. Тикшерүче әле ул гади тикшерүче генә түгел, ә кеше җанын аңлаучы психолог булып та калырга тиеш. Кыскасы, тикшерүче малай башкача сайрый башлады...

— Беләсенме, абый, эш нәрсәдә...

— Нәрсә?

— Мин сине кеше үтергәнсен дип уйламыйм...

— Во! Ниһаять, син дә кешечә сүләшә башладың...

— Кеше үтерүчегә охшамаган син, анысы шулай, ләкин безнең хезмәт шундый, без барсын да тикшерергә тиеш, — дип сайрады ул, кан тапларына манчылган профоюз билетын селкеп. — Монда икенче нәрсә бар...

— Нәрсә ул?

— Минемчә, син үтерүчене беләсен, тик аның исемен әйтергә теләмисен. Ни өчен икәнен дә аңлыйм: ул синең танышың, йә бик якын дустың булырга мөмкин. Беләм, син аны сатырга теләмисен. Авыллар шундый инде алар, чиста күңелле булалар, мин үзем дә, беләсен килсә, авыл баласы. Тик син шуны аңла, аны яклап, син үзенә начарлык кына ясыйсын, күрә торып, үзенә бер кирәкмәгән проблема гына ясыйсын. Син бу профсоюз билетын да ана, әгәр дә ул аны урламаган, алмаган булса, аның алдында яхшы булырга тырышып бүләк иткәнсен. Ләкин шушы профсоюз билеты, абый, сине харап итәргә мөмкин, бик тә мөмкин...

— Нигә?

— Чөнки ул җинаять урынында табылган бердәнбер табылдык дәлил, аңлыйсынмы...

Нариман берни дә аңларга теләмәде. Ул бүтән бернәрсә дә сөйләмәде, бернинди сорауга да җавап бирмәде. Аны кулга алдылар һәм аерым камерага кертеп яптылар. Закон буенча, ягъни суд карары чыкканчы, аны әле монда тагын бер өч тәүлек тота алалар иде.

### 14

Динә үз-үзенә урын табалмады.

Нариманның өйдә юклыгын күргәч тә, ул иң элек күршеләренә керде. Әле яна гына өйләнгән Рәхим, аны, гадәттәгечә, матур елмаеп: «Рәхим итегез!» — дип каршылады. Ире турында сорашкач, ул, бик тәмләп, Динәгә Нариманны милиция алып китүе турында сөйләде. Динә берни дә аңламады, мескен хатынның куркуы эченә үтте. Рәхимнең: «Карбыш урамындагы фатирда бер кешене үтергәннәр, бик каты тикшерү бара, иреңне дә шунын өчен алып киттеләр, ышанмасагыз, безнең комендантттан сорый аласыз!» — дип сөйләнүе болай да куркуы ботына төшкән Динәнең йөрәгенә кабат шом салды.

Ул ни өчендер комендант хатын янына төшмәде, ә авылдашы Назыйм янына керергә булды. Ире (гел шунда утыргач) милициядә түгел, ә аның янында, аның белән сөйләшеп утыра кебек тоелды ана. Динә, ишекне дә (ул ачык иде!) шакып тормыйча, бүлмәгә атылып керде. Нариман бүлмәдә күренмәде, ә Назыйм, чалкан яткан килеш, тимер караватында аунап ята иде. Динә килеп кергәч, ул саташып аз гына башын күтәрде, һәм шаккаткандай, күзләрен акайтып, Динәгә төбәлде. Инде ничә көннәр кырынмаган, юынмаган, исереклек юлында әшәкеләнеп йөргән ялгызак абзый бу юлы Динәдә шактый авыр тәэсир калдырды. Эчүе генә бер хәл, ул әле икенче чирдән — җан чиреннән газаплана кебек тоелды ана...

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МИЛЛИ КИТАПХАНӘСЕ
НАЦИОНАЛЬНАЯ БИБЛИОТЕКА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

— Назыйм абый, — дип куркып кына эндәште хатын, — мин иремне, Нариманны эзлим, аны нигәдер милициягә алып киткәннәр, син берни дә белмисеңме?

—Карбыш урамында бер адәмне үтергәннәр, шуның өчен аны алып киткәннәр, — дип бик теләмичә генә аңлатты ул.

— Каян беләсез?

— Суң... бөтен общага күреп калган! Миңа кереп әйттеләр!

— Нәрсә... Нариман кеше үтергән булып чыгамыни инде!?

— Белмим... әйтә алмыйм, — диде ул, башын аска иеп. — Булырга да мөмкин...

— Син нәрсә, Назыйм абый, ни сөйлисең син!?

— Мин беркайчан да ялган сүләмим, сеңлем...

Кинәт исерек абзый караваттан шуып төште дә, шаркылдап көләргә тотынды. Аның көлүе Динәне өнсез итте, әйтерсең лә аның каршында иблис көлеп утыра.

— Борчылма... утыртмыйлар аны! — дип сөйләнде исерек. — Үтерүче иректә... Тиздән кулга алачаклар...

— Кайчан?

— Берәр сәгатьтән...

— Ничек?

— Бәлкем, ярты сәгатьтән булыр. Килүдән тора инде...

— Каян беләсең!?

— Ә мин үзем чакырдым!

— Кемне?

— Милицияне!

— Кайчан?

— Аска төшеп... автоматтан шалтыраттым...

— Автоматтан!?

— Әйе... 02... беләсең ич инде...

— Нигә?

— Син мине нәрсә, шундый свулыч, кабахәт дип уйлыйсыңмы!? Яраткан иреңне, күрәләтә торып, төрмәгә утырта алмыйм бит инде! Кешене бер гаепсезгә...

Җавап гаҗәеп килеп чыкты. Динә берни дә аңламады, ул һаман буталды, чөнки Назыйм абыйсы аның башын әйләндереп маташа иде. Алар, бер-берсенә карашып, озак кына тын тордылар. Шуннан соң абзый, ауган җиреннән кисәк кенә күтәрелде дә, караваг башыннан рюкзакка охшаган бер нәрсә тартып чыгарды. Яшел төстәге рюкзак кап-кара тузанга баткан. Назыйм аны ашыгып селкергә тотынды, бүлмәдә тузан бураны күтәрелде...

— Нишлисең син?

— Җыенырга кирәк! Минем бит хатын юк! Передача ташырга да кешем юк!

— Кая?

— Төрмәгә...

— Кая!?

— Сухари надо сушить! — Теге иләмсез көлү дәвам итте.. Көлә-көлә ул (әллә алышынган да инде!), үткен пычак эзләре төшкән аш өстәлендә яткан калдык-постыкларны, каткан сыныкларны берәм-берәм рюкзагына тутыра башлады. Өстәлдән алырлык әйберсе калмагач, караваг каршысында торган агач тумбочканы актарырга тотынды. Аннан ике-өч теш щеткасы, кырыну приборлары, сабын калдыклары тартып чыгарды һәм аларның барсын да тиз арада рюкзак эченә шудырды...

Әллә акылдан чыга инде бу Алла бәндәсе! Болай да куркып калган хатынның йөрәгенә кабат шом бәреп керде. Шулчак бу исәр кулындагы рюкзагын, шап итеп, идәнгә ташлады да, хатын ягына борылып, аны аяктан егардай сүз әйтте. Динә чак кына артына утырмады...

— Аны мин үтердем!

— Кемне?

— Карбыш урамындагы кабахәтне...

Назыймның әлеге сүзләрен раслагандай, кинәт кенә бүлмәгә милиция формасыннан дүрт-биш кеше килеп керде. Алар арасында Нариманны кулга алырга килгән, без белгән участковый да бар иде.

— Шушы ул! — дип кычкырды участковый милиционерларга.

— Назыйммы син? — дип сорады анардан берсе. Погонына караганда ул капитан булып чыкты. Назыйм дәшмәде, юләр сымак елмаеп, бер урында басып тора бирде.

— Әйе! Назыйм! — диде аның өчен Динә.

— Иренме? — дип сорады мент.

— Юк, ирем түгел! — диде коты очкан хатын.

— Нишлисең монда?

— Иремне эзләп кердем!

— Ирең кем?

— Нариман... аны алганнар...

— Аңлашылды, без аны кичә кулга алдык! — диде участковый капитанга. — Бар әле, чыгып тор моннан! — Динә тиз генә ишек ягына атылды, ләкин ишек төбендә туктап, катып калды...

—Алыгыз! — дип әмер бирде капитан, җинаятьче ягына таба ишарә ясап. Рядовойлар Назыймга атылдылар, ләкин Назыйм һаваланып, баш очында үз кулы белән ясаган тимер урындык күтәргәч, тегеләр шундук туктап калдылар.

— Менты поганые! — дип сүгенде Назыйм. — Живым я вам не сдамся!

— Назыйм! Тынычлан! — диде участковый. — Без сина тимибез! Синен гаебең әле ачыкланмаган...

— Ачыклыйсы юк: мин үтердем ул кабахәтне, мин! Ул адәм минем анамны мыскыл итте, безнең нәселне авыл халкы алдында мәсхәрә итте, безне авылдан качырды, минем, апай-абыйларның тормышын җимерде, атамны бауга менгерде! Мин шунар түзеп торырга тиешме, ә?! Юк! Аны үтергәнемә мин грамм да үкенмим! Мин хаклы, халык мине аклар... аңлар...

Назыймның әлеге чын күңелдән сөйләгән сүзләре бары тик бер участковыйга гына тәэсир итте булса кирәк. Капитан һәм анар ияреп килгән рядовойлар да, җинаятьчене эләктерү өчен, җайлы вакытны көтеп кенә торалар иде.

— Синең аркада бер гаепсезгә кеше утыра, — диде участковый, Динә ягына ишарәләп.— Менә бу хатынның ире, минем аңлавымча, ул синең авылдашың, дустың...

— Беләм... — Назыйм, сизгерлеген югалтып, кинәт йомшап китте. Һәм шуны көткән, янда гына басып торган куркә кыяфәтле рядовой, һөнәри үткенлек күрсәтеп, аягы белән Назыймның тезенә китереп типте. Кай җиргә тибәргә кирәклеген белә, каһәр! Назыйм, үкереп, идәнгә тезләнде һәм башы белән алга сыгылып төште. Күз ачып йомганчы, җинаятьченең кулына тимер богау кигезделәр...

— Падлы! — дип сүгенде мужик. — Ненавижу!

— Торгызыгыз! — дип команда бирде капитан. — Алып китегез!

Милиционерлар, Назыймның кулын каты итеп каерып, ишек ягына сөйрәделәр. Назыйм, ярсуланып, участковыйга усал гына карап куйды. Тегесе, башын аска иеп, күзләрен читкә алды...

— Мин кеше үтермәдем, явыз убырның үзен үтердем! — дип кычкырды Назыйм. — Мин авыл мужигы, ишетәсезме, авылныкы...

— Ә без сине Казанныкы дип уйлаган идек! — дип елмаештылар аны алырга килгән милиционерлар.

— Мин авылымны якладым, таш калагызны тар-мар иттем! Ха-ха-ха!

— Син нәрсә, Иван Грозный мәллә!? — дип көлештеләр алырга килүчеләр...

Назыймны бөтен тулай торак халкы озатып калды. Нариманны шул ук көнне һәм шул ук сәгатьтә тоткынлыктан азат иттеләр.

## 15

Ә үтерүчене барыбер утыртмадылар. Тикшерү барышында төрле экспертизалар ясап, суд аны җүләргә чыгарды. Төрмәдә түгел, ә ябылулы җүләрләр йортында дәвалана икән, дип ишетте Нариман аның турында. Аның янына хәзер барып та, кереп тә булмый. Анда утырганчы, төрмәдә утыруың яхшырак, дигән сүзләр дә йөри. Җүләрләнгән авылдашы турында яңа төрле легендалар да туды. Тикшерүче анардан, Карбышев урамында торучы ялгыз ирне ничек һәм ни өчен үтерүе турында сораша башлагач, җинаятьче шәхес тиктомалдан гына туган авылының гүзәллеге һәм аның матурлыгы турында дастан сөйләргә тотынган. Үтерелгән Сәлимне ул сугыш вакытында гаепсез авыл кешеләрен атып йөргән явыз фашистка тиңләп, аны колхозның үләксә базыннан сасыган терлек ите һәм терлек сөяге ташучы кызыл авызлы кара козгын белән чагыштырган.

Корбанын ул кыйнамаган, имгәтмәгән. Сәлимнең башына разводной ачкыч белән томырып, анын чигәсен ярган һәм ул секунд эчендә җан биргән. Фатирдан берни дә урламаган, бернәрсә дә алып чыкмаган. Ә эзләнсәң, урларлык нәрсәләр күп булган анда. Байлык зур. Ләкин ни хикмәт, ничәмә хатынга өйләнеп, ничәмә хатын белән яшәп тә, бу адәмнең үз баласы булмаган. «Кысыр» булган, күрәсең ( хәер, дөньяда андый ирләр дә булгалый!), шулай булмаса, хатыннарның берәрсе булса да аңардан бала тапкан булыр иде. Шунар охшашлы нәрсә Нариманнар авылында да булды: каенанасы белән ире, ничә еллар буе, син имгәк, син бала табалмыйсың, дип бер яшь киленне кыерсытып яшәделәр. Баксаң, гаеп хатында түгел, ә ирдә икән. Тикшерә торгач, шундый нәрсә ачыкланды: ирнең орлыгы хатын-кызны орлыкландырырга сәләтсез икән. Сыек, димәк. Шуннан соң теге кысыр ир башын иеп кенә йөри башлады, ә киленнәре, Берлинны алгандай, күкрәк киереп йөрде.

Тикшерүчеләрнең: «Ни өчен үтердең?» — дигән сөаленә дә Назыйм: «Мин аны үтермәдем, ул үз-үзен үтерде!» — дип җавап кайтарган. Һәм соныннан: «Дөресрәге — ул үз-үзен үтерә алмыйча интекте, мин аңа ярдәм генә иттем. Андый кабахәт җир йөзендә яшәргә тиеш түгел!» — дип тә өстәгән.

Мәгълүм ки, тикшерү барышында үтерелүченең дә каршылыклы шәхес булганлыгы ачыкланды. Ләкин ул Сәлим дигәннәре ничек итеп Назыймның анасын мыскыл итсә дә, ничәмә хатыннын тормышын бозса да, аларны ярык тагарак каршында утыртып калдырса да һәм ул нинди генә кабахәт булса да Назыймның кеше үтерергә хакы юк иде, билгеле.

Шулай ук аның җинаять урынында профсоюз билетын калдыруын аңлап бетермәде Нариман. Юк, ул аны махсус, авылдашына шик төшсен дип ташлап калдырмаган, билгеле. Юк, юк, Назыйм андый кабахәтлеккә бармас! Бәлкем, ул аны, уыгып, кесәсеннән ялгыш төшереп калдыргандыр?! Ул бит билеттагы

исем-фамилияне үзгәртеп, шунар үзенен фотосын ябыштырып куярга да өлгерми калган. Анын: «Мин теләсә нинди документны үзгәртеп ясый алам, миндә, дустым, каллиграфический почерк!» — дип мактанганын да Нариман яхшы хәтерли...

Әллә инде авылдашынын язмышына битараф булмаганга, әллә үзенә үк шушы жинаять процессы аша узарга туры килгәнгәме, Нариман, йоклар алдыннан, көн саен диярлек, Динәдән Назыймны ничек итеп кулга алуларын сөйләтте. Баштарак шунын турында бик нык дулкынланып, тәфсилләп сөйләгән Динә сонрак бу нәрсәдән туя башлады һәм бөтенләй сөйләүдән туктады. Нариманны кулга алгач, милиция бүлеге каршында елап басып торганнарын, ирен азат иткәч, анын муенына асылынып: «Яратам сине, жаным, яратам!» — дип назлануларын ул инде хәзер онытты булса кирәк.

— Син нәрсә, башка проблеман юк мәллә?! — дип кычкырды ул ана беркөнне. — Һаман шул шизик турында сөйләтмәсән... Булган, узган, ятсын хәзер психушкасында!

— Теләмәсән, сүләмә, көчләмим...

— Үзен турында уйла син, фатир турында!

— Гаврилинга бармадынмыни? — дип сорады Нариман. Анын соравы, билгеле ки, һәрвакыттагыча кинаяле янгырады.

— Бардым, ләкин ул ысвиданиягә чыкмады! — дип шаярткан булды тегесе.

— Булмаган, димәк...

— Фатир тиздән булачак!

— Ничек?

— Әти сөйләште.

— Кем белән?

— Бер зур кеше. Ул безнен директорга чыккан. Шулай булгач... шитыкрыты, жаным!

— Синен әтиен!? — дип шаккатты ир.

— Ә ни булган минем әтигә!?

— Атаннын шундый свәзләре бар дип һич кенә дә уйламаган идем!

— Син аны шундый төшеп калган кеше дип уйлыйсынмы?

— Уйлый идем! Хәзер фикерем үзгәрде...

Фикерләр әкренләп үзгәрә торды. Тормыш һаман да алга чаба, тик менә Нариман гына бер дә үзгәрергә теләми. Илдә комсомол төзелешләре колач алды: Чаллыда «КамАЗ» заводы, Түбән Камада химия комплекслары калкып чыкты. Яшьләр һәм хәтта карт-корылар, туган авылларын ташлап, шул гасыр төзелешләренә агылдылар, киләчәктә исә шәһәр кешесе булып калу турында хыялландылар. Күпме авыллар, колхозлар таралды, күпме йортлар бушап калды, күперләр ватылды. Татарстан-Төтенстан — сәлам сина, сәлам! Ура! Шәһәр жинде: өч башлы комсыз аждаһа сыман, авылны ул бер кабуда йотты...

Нариман гел авылын сагынып яшәде. Авылны сагыну озакка бармый, бер ике-өч елдан ул бетә, сүнә, кеше әкренләп шәһәр тормышына иялэнә һәм шул баштагы сагынуына сонынннан хәтта көлеп карый башлый, диләр. Ә юк, шәһәрдә тора башлаганына инде дүрт елга якын вакыт узды, ә Нариман туган авылын һич кенә дә оныта алмады. Онытып була димени сон аны! Беренчедән, анын авылда бергә укыган, бергә үскән дус-ишләре калды, икенчедән, анын ялгыз әнисе анда, ул улын һәрчак сагынып, көтеп тора. Пенсиягә чыгуга ук, укытуын ташлыйм дип йөргән әнисе, лаеклы ялга чыккач та, мәктәптә укытырга калды. «Өйдә ялгызым гына утырып нишлим, мәктәптә балалар арасында көнем үтә, ичмасам!» — дип акланып маташкан иде башта. Ләкин артык озак укытырга туры килмәде

ана, чөнки Хәлимә чирләп китте, кан басымы белән интекте. Авылның надан балаларын укытып, нервыларын бетергән укытучы хатынга, теләсә-теләмәсә дә, яраткан мәктәбеннән китәргә туры килде. Билгеле, ул коллективтан бөтенләй үк аерылып бетмәде, аның анда дәресләре калды. Чөнки аны коллективта хөрмәт итәләр һәм аның белән һәрчак киңәшәләр иде. Ләкин бу ярым чара, ягъни балага еламас өчен имезлек каптыру кебек нәрсә генә булып калды. Ул хәзер күбрәк өйдә утырды, өй хезмәтен алып баруы җиңелрәк булсын өчен, терлекләрен бетереп, кош-корт кына калдырды. Ләкин ялгызлык газабы барыбер үзенекен сиздерде, пенсионерның көне үтми башлады. Моңа тиклем улында әллә ни зур нужа күрмәгән ана кеше улын сагына башлады, улы юлга кузгалганда да бик нык монсуланып озата торган булып китте. Ялгыз көннәрен гел чирләп, дару эчеп кенә уздырган, инде үлем турында сөйләнә башлаган Хәлимә Нариман авылдан киткәндә: «Тагын кайчан кайтасың? Япа-ялгыз кинәт кенә үлеп китүдән куркам!» — дип улының йөрәгенә шом салып куя торган иде...

Бу очракта Нариманның үзендә дә гаеп бар сыман: әгәр дә ул әнисенә катырак торса, авылга беркайчан да кайтмыйм, калада калам, дисә, авылны сагындым, авылсыз яши алмыйм, дип сөйләнмәсә, аңар күңел серләрен чишмәсә, әнисе дә, язмышына разый булып, артык эремичә, хисләнмичә генә, улын авылга кайтыру турында, бәлкем, сүз дә кузгатмас иде.

Беркөнне Нариман искиткеч бер сәер төш күрде. Каядыр сәфәргә чыккан икән ул, печән төялгән йөк машинасында баш очында хәтсез кыздырган кояштан күзләрен яшереп, каядыр бара да бара икән. Яңа гына чапкан ямь-яшел үлән, люцерна! Ах, аның хуш исле тәме, тәмле исләре! Андый хуш исле төшне аның үз гомерендә беренче генә күрүе иде. Рәхәт шундый... җан рәхәте... Ләкин бу рәхәтлек нигәдер озакка бармады. Менә машина кисәк кенә туктады, аннан ике әзмәвер егет йөгереп чыкты да, Нариманны, аягыннан тотып, җиргә тартып төшерде. Ни хикмәт, боларның икесе дә таныш кешеләр булып чыкты. Кала хулиганнары: берсе Альфред, икенчесе Хамис. Альфредның ул кайчандыр тезен ярды, Хамисның аркасына таш томырды. Хәер, анда аның гаебе юк, алар сугышны үзләре башладылар. Нариман чын мужик иде. Әгәр дә аның үзенә бәйләнмәсәләр, аны мыскыл итмәсәләр, ул беркемгә дә тими, ә инде бәйләнеп, теңкәсенә тисәләр, йә инде аның каршында әллә кем булып кылансалар, ул аларны изеп атып, җир белән тигезләп куярга да күп сорап тормый иде. Бу юлы исә ул үзен гаепле итеп сизде, ул аларга хәтта ялынып, ялварып та карады. Тик файдасы тимәде. Алар әрсез сәяхәтчене, арт ягына тибеп, тузанлы юлда бәреп калдырдылар. Җәй, эссе, гаять каты кыздыра. Шулчак давыллы җил чыкты, кара тузаннар туздырды, күзләргә чүп кереп тулды. Җил тынгач, ул әкрен генә күзен ачты. Бер кызыкай, чиләк-көянтәләрен асып, чишмәгә су алырга төшеп бара. Чырае ап-ак кызның, монсу, ул әзрәк чирле кешегә дә охшаган. Менә алар икесе дә чишмә буенда. Нариманның бик каты су эчәсе килә, ул кыздан су сорый. Кыз аның авызына чиләк кырын китерә. Нариман йотылып су эчә һәм, күтәрелеп, кызга карый. Ялгышкан икән бит! Суны ана хатыны Динә бирә дип уйлаган иде, ә ул бөтенләй башка кеше, башка кыз булып чыкты. Кыяфәтенә караганда, ул ничектер авыл кызына охшаган иде.

Бу төш берничә мәртәбә кабатланды. Нинди төш ул? Нишләп керә соң ул ана? Төшләр юраучы авыл карчыгына да сөйләп күрсәтте ул аны, ә җавабында багучы хатын ана: «Бик зур төш, олан, тормышыңда олы үзгәрешләр көтелә, мөгаен, авылыңа кайтырсың, туган йортыңда яши башларсың, ләкин ул җиңел генә бирелмәс!» — диде. «Минем Динәм гомердә дә кайтмый авылга!» — дигән сүзгә исә ул (аны бик нык гаҗәпкә калдырып!): «Мин анда Динәнне күрмим, ә башка кешене күрәм!» — дип әйтеп куйды.

Динә белән кайчан да булса аралары өзелер дип аның башына да, уена да килмәде. Алар бит бер-берсен яратышып өйләнештеләр. Алар хәзер дә бер-берсен ярата кебек. Ләкин Динәнең сәер холкы, көймәне һәрчак үз унаена ишәргә тырышуы, Нариманның исә һаман да икенче якка ыргылуы, авылга тартылуы, авылны оныта алмавы аларны күптән бербөтен итә алмыйча, гаиләнең тотрыклыгын җимерә башлаган иде.

Ә бәхетсезлек, ни гаҗәп, бәхеттән башланды. Ниһаять, алар фатир алдылар. Фатирны аларга яңа ел алдыннан бирделәр. Ике бүлмәле, лоджийлы. Ленинградка. Динә сөенеченнән ике көн кунак җыйды. Кемнәр генә килмәде дә, кемнәр генә котламады аларны. Авылдан Динәнең ата-анасы да килде, бары тик Нариманның анасы Хәлимә генә килә алмады. Авырды... Хәер, өй туе ике көн белән генә чикләнмәде, фатирны атна буе юдылар. Яңа елны яңа фатирда каршы алдылар. Фатир алырга хыялланган Динә, Нариманга белгертмичә генә, берникадәр акча җыйган булган икән. Шунар зал ягына зур стенка, йоклар өчен яңа диван-кровать алдылар. Ә менә ире (үз акчасына) балалар караваты алып кайткач, Динә әллә нишләп китте, ул сөенә дә, көенә дә алмады. Утырып бер елады. Нариман шул вакытта ук нидер сизенгән иде инде. Соңыннан әлеге уенын юш килгәнлеге, бәхетсезлегенә каршы, бөтен хаклыгы белән ачыкланды.

Нариман кеше әйберсендә актарынырга яратмый. Ул куркыныч кәгазь дә аның кулына очраклы рәвештә генә килеп керде. Беркөнне кадрлар бүлеге аның паспортын сораттты, ул аны стенканың бер кечкенә тартмасына тыгып куйган иде. Шунда актарынган чагында тартмадан, аллап-артлап мөһер сугылган, төрле медицина белешмәләре, анализ кәгазьләре килеп чыкты. Динә, иренә әйтмичә генә, сырхауханәдә тикшеренеп йөргән икән. Бу анализларның (медицинада әллә ни аңламаса да!) бала белән бәйле булганлыгын сизенгән Нариман, боларны күче белән җыйнап алып, элеккеге классташы, хәзер инде калада хирург булып эшләгән тиңдәшенә күрсәтте. Кабинетта берничә табиб җыйналды, араларында гинеколог хатын-кыз да бар иде. Олырак яшьтә, тәҗрибәле. Менә шул хатын ир җыйнап килгән кәгазьләрне карап чыккач, озак кына бер сүз дә эндәшми торды. Барсы да анардан сүз көтте. «Дөресен әйтергә ярыймы!?» — дип сорады ул башта Нариманнан. Тегесе, ярый дип, баш селекте. «Синең хатының беркайчан да бала тапмаячак!». «Нишләп?!» — Нариманның тавышы калтыранып чыкты. «Хатының аборт ясаткан идеме? Булдымы шундый хәл?» — дип сорады анардан гинеколог. Нариман моңа каршы бер сүз дә әйтә алмады, әйе, дип, башын түбән иде...

Күпме әйтте — ясатма, йөрмә, тап, үстербез, дип! Юк, тыңламады! Кеше әйткәнне тыңлый белә димени соң ул? Чат атасы — киреннең киресе! Бер нәрсә уйлады икән, үзенекен итмичә калмый. Инде хәзер нишләргә? Әйтергәме үзенә, юкмы? Баласыз нинди гаилә була ала? Кала хатыннары бала санын икедән уздырырга тырышмыйлар, күбрәк үзләрен карап, үзләрен көйләтергә яраталар. Ә монда хәзер ике түгел, бер дә булмаячак! Гаиләдә бер генә бала булып үскәч, ул гомер буе ишле гаилә турында хыялланды, апа-сеңелләрнең, абый-энеләрнең булуын теләде. Каршы якта гына атаклы комбайнчы Сабир абзый яшәде, аның хатыны алты бала тапты. Өч ир, өч кыз. Алтысы да исән-сау, алтысы да тап-таза булып үстеләр. Ишле гаилә авыр яши, балаларның киярләренә җитми, ашау яклары да такыр була, диләр. Шулайдыр, төрле чагы буладыр, тик нигәдер Нариман бала чагында алардан гел көнләшеп яшәде. Бер-берсен карашып, бер-беренә ярдәм итеп үскән күрше балалары гел бердәм булып яшәделәр, матур итеп хезмәт итәләр, күңелле итеп уйный да белә торганнар иде алар. Ә ул һаман да үзе генә, ялгызы гына уйнап үсте. Ни өчен аның анасы бер генә

бала белән калган? Менә бу нәрсә аның өчен әле дә зур сорау булып кала килә. Шуны белеп, шунын бер очына чыгасы килсә дә, нигәдер анасыннан сорарга яхшысынмый торган иде.

Ә менә Динә белән нишләргә? Әйтсән, билгеле, тавыш чыгачак, минем арттан эш йөртәсен, дип үпкәләячәк! Табибларга да тулысынча ышанып җитеп булмый, бала язмышы ул барыбер Ходай кулында, баланың ничек һәм кайчан туасын бер Ходай гына белә. Юк, ул әлегә хатынына берни дә әйтмәскә, әзрәк көтәргә булды. Бер җае чыгар, бәлкем.

## 16

Динә трамваен ташлады.

Озак та үтмәде — ресторанга урнашты. Официант булып. Башта иреннән рөхсәт сораган булып кыланды, ә инде рөхсәт алгач, юри генә сорадым, дип шаярткан булды. Каршы килеп кая барсын инде Нариман!? Динә барыбер үзенекен итәчәк! Хатынының бала таба алмаячагын аңлаган көннән үк, аңа карата бик нык үзгәрде ул. Тиктомалдан гына кешене йокы череме ничек басса, аны да шундый ук битарафлык хисе басты. Хатыны кая гына барса да, нәрсә белән шөгыльләнсә дә, аңа хәзер барыбер иде. Яратып яшәгән изге, кадерле еллар үтте, тормышның да кызыгы бетте кебек. Кыскасы: «хәлләр изге, тегеләр бизде!».

Динә башта көндезгедә йөрде, аннан кичкегә күчте. Азрак вакыт узу белән аңа җүләр акча, ягъни чумара җене кагылды. Ул бертуктаусыз: «Хезмәт хакына гына баеп булмас, алдау хакына баеп карарга кирәк!» — дип сөйләнде. Алдау сүзе монда бигүк аңлашып та бетми, чөнки ресторанда «чәйлек» дигән нәрсә бар. Әзрәк баерак, кыланчыграк адәмнәр официантлардан сдача-мазар сорап тормыйлар, тоташ акчалар калдырып чыгалар. Билгеле, андый зур акчалар атканда алар шактый кызмача булалар, икенче көн акчаны артык күп тамызганнарына, бәлкем, үкенә дә торганнардыр, ләкин көн инде үткән, вакыт та башка чорга авышкан була.

Динәнең рестораннан кайтканын көтеп җаны чыга иде Нариманның. Вакыт узмый да узмый. Аптырагач, телевизор кушып карый. Анда да әллә нәрсә юк. Яхшы фильм булса әле бер хәл, юк шул, зәңгәр экраннарда һаман да шул партия функционерларының карт, иләмсез чырайлары гына чагыла. Шуларның ялган һәм эчпошыргыч сүзләрен тыңлап утыру саруны кайната. Ә ил хуҗасы, ягъни генсек бөтенләй картайды, аның хәзер нәрсә сөйләгәнен дә аңларлык түгел. Ияге чалшайды, күзләре акайды. Буш сүз сөйләгән кешене яратмый иде Нариман, ә бу илнең сәясәте фәкать шуңа, буш сүзгә корылган. Өстәгеләр чүбек чәйниләр, ә халык шуларга кул чабып тора. Ә инде ялганга корылган, буш сәясәт алып барган илнең беркайчан да киләчәге булмый...

Көз айлары. Әбиләр чуагы. Көндез кояш кыздыра, рәхәт, хәтта төнлә дә җылы була. Шундый матур төннәрнең берендә Динә эштән кайтмады. Хатыны әзрәк сонгарак калса, ресторанга барып, аны каршы алгалаган чаклары күп булды аның. Ә бүген ул бармады. Такси белән кайтыр дип уйлады. Телевизордан бер яхшы кино карый-карый, йокыга киткәнен сизми дә калды. Ул уянганда иртәнге бишләр иде инде. Телевизор һаман да янып тора, программа беткән, экраннан, шытыр-пытыр килеп, «ак кар» сибәләп тора иде...

Динә Бауман (Казанның иң данлыклы урамы!) стритында урнашкан «Восток» ресторанында эшли иде. Нариман кран астына иелеп, башын салкын су белән койды да, фатир ишеген бикләп, урамга чыгып йөгерде. Инде таң атып килә, анда-санда җинел машиналар күренә. Кольцога бик тиз төшеп җитте ул. «Волга» хуҗасы акчаны шактый күп каерды, ләкин бу очракта акча белән хисаплашып тора

торган чак түгел иде. Ресторан ишекләре ябык (ул шуны көткән дә иде!), утлары сүнгән. Ул хәтта, көч белән, арткы ишекләрне дә тартып карады, ләкин файдасыз. Хатыны ресторанда кунып ята дигән уйны ул бик тиз башыннан чыгарып атты. Һәм шулчакны аның күзе юлның икенче ягына, ягъни «Кольцо»ның икенче башына төште — «Татарстан» кунакханәсеннән аның сөекле хатыны чыгып килә иде. Ул өстенә ал төстәге ветровка ( ул аны бик зур бәягә бер Мәскәү спекулянтыннан сатып алды) кигән, ана кара озын плащлы бер олы яшьләрдәге ир кеше дә ияргән иде. Боларны бергә күргәч, Нариман иманеп китте. Икенче якка жир асты юлыннан һәм шулай ук турыдан — трамвай юлы аркылы да чыгып була. Нариман жир асларына төшеп, вакыт уздырып тормады, ул кунакханәгә туп-туры бәреп чыкты. Алар кунакханә каршында бер-берсенә бик нык якынаеп, сыенышып, күнелле генә чөкердәшеп торалар иде. Нариман Динәне тупас кына кырыйга бәреп, плащлы ирнең муенына ябышты. Әгәр дә Динәсе: «Нариман, тукта!» — дип чәрелдәп кычкырмаган булса, ул, бәлкем, үзенең көндәшен буып та аткан булыр иде. Динәнең кычкыруы көндәшенең муенына сузылган кулын бушатты. Шулай да кирәгеннән артык ярсыган Нариман, берни белештермичә, тезе белән тегенең корсагына китереп төртте — плащлы ир шундук сыгылып төште һәм асфальтка тезләнде. Анар шактый каты эләкте, күрәсең — ни эндәшә, ни хәрәкәтләнә алмады...

Нариман Динәне, жилтерәтеп алып, универмаг каршында басып торган «яшел күзле» сары таксига кертеп тыкты. Өйгә кайтып житкәнче, алар бер сүз дә дәшмәделәр. Ә өйгә кайтып керүгә үк... башланды! Ир түгел, ә хатын башлады:

— Нишләден син, ә!

— Нишләдем! Уйнашчыны тоттым!

— Нишлә-ә-ден! Бөтен эшне боздың!

— Комачауладым, име!?

— Кемгә суктын син! Кемгә!

— Кемгә... сөяркәнә!

— Нинди сөяркә! Ул зав бит безнен!

— Нәрсә... зав булгач, аның белән йокларга да ярыймы!

— Нинди йоклау!?

— Син тан алдыннан, чит ир белән кочаклашып, гостиницадан чыгып киләсен, шулай булгач, мин ни уйларга тиеш!?

— Колхоз булудан туктарга вакыт сина, жаным! Сон шул зав аркылы бөтен чумара ясала да бит инде! Шунын акчасына яшибез ләса! Биш ай эшләп, күпме әйбер генә алдык, машинага акча салдык! Синен акчаң ашарга да житми! Мин аның белән йокламадым, без аның белән акча бүлештек! Мә, менә кара!

Хатын крокодил тиресеннән тегелгән затлы сумкасыннан бер күч совет акчасы тартып чыгарды. Бөгәрләнгән акчаларны таслап, жыеп санаганнар иде...

— Динә ! — дип ярсыды Нариман.

— Нәрсә?

— Кит син рестораннан! Әгәр китмәсән...

— Нишләтәсен?

— Атап әйтәм: бу акча уеныгыз сезнен яхшылык белән бетмәячәк! Акча кешене боза, кеше акча колына әйләнә. ОБХСС жибәртеп, рестораныгызны яптырам, ыслушай! Завынны утырттырам! Аңладыңмы?!

— Ай-хай... мине дәме?

— Әйт дөресен, яшермә, әйт! Юкса мин сине!

Нариман, Динәнен кулыннан каерып, хатынын маңгайга маңгай терәде.

Кулын иркен тоткан ир белән шаярырга ярамаганын аңлаган Динә бераздан башкачарак сөйләргә тотынды:

— Ипи тотып ант итәм, мин аның белән йокламадым. Без, чынлап та, номер снимать итеп, шунда булган акчаларны бүлештек. Ресторанда, кеше алдында ярамый, аңлыйсыңмы! Зав минем аркылы эш итә! Акчаны минем аркылы ясый! Яшермим, мин аңа ошыйм... ул үзе дә шулай ди...

— Үзе дә!

— Ләкин мин аны үземә якын китермим! Мин сиңа тугры, Нариман!

— Хе! Гостиницада чит кеше белән кунып ята, ә ул миңа тугры, имеш! Булды! Житте! Мин авылга кайтам! Атап әйтәм: авылдан китмәгән булсак, бу яман хәлләрнең берсе дә булмаган булыр иде! Янында чит ирләр дә иснәнеп йөрмәс иде! Син дә иләс-миләс йөрмәс идең! Күралмыйм!

— Ә мин нишләгән соң әле? Минем бернинди дә гаебем юк, чөнки гаебем ачыкланмаган. Калага килеп без, җаным, берни дә югалтмадык. Киресенчә. Без монда кеше булдык. Эш бар, акча бар, фатир алдык. Тагын ни кирәк!? Ни житми сиңа!?

— Бала!

— Нәрсә!?

— Бала житми!

Хатын һәм ир беркайчан да тавышланмыйча тормый, ләкин Динә белән Нариманның тавышсыз яшәгән чаклары сирәк булды. «Авылда калсак, тавыш-гаугалар азрак чыгар, хатын да үзен башкачарак тотар иде!» — дигән уй Нариманның һич кенә дә башыннан чыкмады. Иң кызыгы шул, тавыштан хатыны нигәдер гел коры чыга һәм һәрвакыт җиңүче булып кала иде. Гаилә хуҗасы никадәр генә кызса да, тамагын ертып акырса да, тормыш барыбер хатын-кыз сүзе белән, ягъни хатын дигәнчә бара иде. Бу юлы ул хатынынннан өстен чыгарга, ноктаны зур итеп, калын итеп куярга теләде. Ул ачудан стенка шүрлеген алып атып, аннан анализ кәгазьләрен тартып чыгарды. Бөтен бүлмә кәгазь белән тулды...

— Нәрсә бу? — дип акырды коты очкан Динә. Хәер, ул җуләр түгел иде, барсын да бик тиз аңлап алды, ләкин белмәмешкә сабышып, уенны әзрәк кенә суздь.

— Дәлилләр!

— Нинди?

— Син беркайчан да бала табалмаячак! Беркайчан да ана булу бәхетен татымаячак!

— Ни өчен?

— Язмыш! Язмыш каргады безне!

— Язмыш... нигә...

Динә үкереп еларга тотынды. Елау акрынлап истерикага күчте — ул ярсып стенка кырында торган, туйга бүләк иткән чәчәкле зәңгәр вазаны бәреп ватты. Аннан вазадан өстәрәк торган бәллүр савытларга ябышты. Күп итеп җыйган иде ул аларны. Бөтен ил — бәллүр савыт җыйный. Шуларның берсе белән ул иренә кизәнде, бәхеткә Нариман аның кулыннан тотып калды. Хатынны тынычландыру рәвеше шактый озакка сузылды. Хатыны тәмам тынычланып беткәч кенә, Нариман аңа үзенең ниятен ирештерде:

— Динә, мин синнән китәргә булдым! Синнән генә түгел, каласыннан качарга булдым!

— Ярар, — дип килеште хатын, — әгәр китәргә уйлагансың икән, мин сине көчләп тоталмыйм...

Ул әле, бәлкем, калган да булыр иде, ләкин хатынының соңгы сүзләре аны

тәмам үтерде, аның битарафлыгына шаклар катты. Җүнле хатын-кыз ирен янында калдыру өчен ни генә эшләмәс — ялынып да, ялварып да, җаен табар иде. Ә юк, Динә андый кеше түгел, ул бөтенләй башка, ул артык горур иде. Нариман бар булган кием-салымнарын, кирәк-яракларын чемоданга тутырган вакытта да, хатынының бер кылы да селкенеп карамады. Хатын да җүләр түгел, ул барсын да аңлый: бер китүдә генә бар нәрсәне җыеп бетереп булмый, димәк, аның ире әле тагын кайтачак, алар кабат күрешәчәкләр. Динә, теләсәң нишлә, дигән сыман, кулын селтәп, урынга барып ауды. Чемоданын җыеп бетергән Нариман, ишекне бик каты бәреп, өйдән чыгып китте. Ә киткәндә ишекне каты итеп бәреп китү ул начар фал һәм аның ахыры аянычлы булырга да мөмкин...

## 17

Юлсызлык — авылның иң зур михнәте. Бөтен СССР юлсызлыктан интегә. Авыллар арасында кыр юлларын, ат сукмакларын бетереп, дамбалар өеп, шунар таш салган шосселар да төзеп карадылар, ләкин юллар аңа карап кына яхшырмады. Юллар яз-көз кардан, яңгырдан изелде, кышын аларны кар басты. Җәен, күбәләк очкан вакытта әзрәк йөреп алганнан соң, көзен тагын чын газап, михнәт башлана. Юл булмау аркасында шәһәр белән авыллар арасында автобуслар йөрми, кайтсаң шул йә су юлы, йә тимер юл аша гына кайтырга була.

Нариман шәһәрара поездга төшеп утырды. Халыкта аны «кызыл поезд» дип йөртәләр иде. Ни өчен шулай атаулары яхшы аңлашыла, поездның үзе дә, вагоннары да кызылсу төстә. Ул кассада сатып алган билетын таслап, кәчтүм кесәсенә салып куйды, киң вагон тәрәзәсеннән тышка, урам ягына күз салды. Ул бүген иртә төште, поезд кузгалырга шактый вакыт бар, вагоннар буш, әле халык та кереп, утырып бетмәгән иде. Перрон буйлап чабыша-чабыша кешеләр йөгерешә: кайсы чемодан, кайсы капчык күтәргән, кайсылары кечкенә кибет «арбалары» тартып бара. Бераздан ул перронда ике таныш адәмне күреп алды, болар Нариман авылында дискотека ясап яткан, соңыннан аны кыйнарга йөргән Альфред белән Хамис иделәр. Ул аларны инде күптән күргәне юк, чөнки ни хәтле гомер үтте. Алар анардан үч алырга йөргәннәрен дә ишеттерделәр, аның калада, тулай торакта яшәгәнен белеп, берничә мәртәбә хәтта Нариманны эзләп тә килгәннәр. Ул вакытта аларга очрашу насыйп булмаган, ә менә хәзер аларны язмыш һич көтмәгәндә кабат очраштырды. Нариман аларны күрмәмешкә сабышты, ләкин алар аны бик тиз танып алдылар. Юк, ул алардан курыкмады, ләкин күрергә дә ашкынып тормады. Менә шул ике кала эте тиз арада поезд эченә үтеп, Нариманның каршысына ук килеп утырдылар. Икесе дә шактый кызмача, икесе дә күңелле сөйләшә. Ябыгы, Альфреды (авырый, күрәсең) бөтенләй ябыккан, чырае көл сымак ап-ак, ияк астындагы җирән сакалы гына тырпаеп калган. Ә Хамис, киресенчә, тагын да тазара төшкән, куллары, беләкләре юанайган, өйләнгән мужик сымак, зур корсак үстергән...

— Сәлам, друган!

— Как хяллар?!

Шаярышып кына, алар аңа кул суздылар. Тик Нариман аларга кул бирмәде, бер сүз дә дәшмәде.

— Авылга мәллә? — дип сорады Альфред.

— Авылга! — дип төксе генә җавап бирде юлчы.

— Вижу, кәефың юк! — дип Хамисы сүзгә кушылды.

— Әйе, юк...

— Поезд кайчан китә? — дип сорады Альфред.

— Ярты сәгатьтән!

— Да! Вакыт бар икән әле!

—Айда, пивнушкага кереп чыгабыз, — дип тәкъдим ясады Хамис. — Каефың да күтәрелер!

— Керегез! Тик миннән башка!

— Акча ягы такыр, братан! — дип моңсуланды тегесе. — Синдә юкмы соң?

— Миндә бар, ләкин мин кулга акча бирмим!

— За падло што-ли!?

— Бәлкем... сыйларсың... Күрәсең... хәл начар... Жиденче көн эчәбез... Запойда... слушай... Может... угостишь... а...

Авыл егетләрендә шундый бер сәер гадәт бар: кеше ярдәм сораса, алар ярдәм итмичә калмыйлар. Бу гадәт авыл кешесенең канына сеңгән һәм ул аңарда гасырлар буена тәрбияләнгән. Авыр вакытта бер-береңә ярдәм итү, бер-береңнең хәлен белү авыл кешесе өчен зарур нәрсә. Бу очракта исә моны куркаклык түгел, ә йомшаклык итеп кабул итәргә була иде. Соңыннан бәлагә таргач, үлем белән яшәү арасында калып, Газраил белән көрәшеп ятканда ул шушы йомшаклыгы өчен, бәлкем, үз-үзен битәрләгәндер дә һәм үкенгәндер дә... Тик киләчәкне белеп булмый шул: шулай аянычлы килеп чыгасын белсә, ул, бәлкем, урыныннан да кузгалмаган булыр иде...

Кала этләре, күрми-күрмәгәндәй, вокзал сыраханәсендә сыра чөмерделәр. Нариман аракы белән дус булмаса да, әзрәк сыра капкалый башлаган иде. Компания өчен дигән булып, үзенә дә бер ярты кружка сыра алды. Тик шуның яртысын да эчеп бетермәде. Ул бертуктаусыз кулындагы сәгатенә карады, поезд китәргә унбиш минут кына вакыт калган иде. Тегеләр дә аңар ияреп чыктылар. Пивнушка янында гына урыс каены белән Америка чаганы аралашып үскән агачлык урыны бар, Хамис та, Альфред та тәмәке кабызып, шуның эченә кереп бастылар. Ни өчен алар артыннан ияргәнен ул әле дә ахырына хәтле аңлап бетерә алмый. Тиз генә хушлашып, поездга кереп утырасы иде инде, юкса! Юк, аяклары аны нигәдер әнә шул якка, шул урыс каены белән Америка чаганы астына тартты. Альфред агач төбенә иелеп кечкенә йомышын башкарды, Хамис, ярсуланып, дәү агачлар тирәсендә үскән яшь, кечкенә үсентеләргә типкәләп алды...

— Рәхмәт, братан! — дигән булды агач төбендә эшен бетереп яткан Альфред.

— Ни өчен?

— Сыйладың...

Альфредның сөйләвендә киная юк түгел иде, билгеле, ул рәхмәтен ничектер төрттереп, астыртын рәвешле әйтте. Нариман инде монда үзенең артык кеше икәнен аңлап, тизрәк китәргә ашыкты. Ләкин аны Хамисның бер төртке сүзе туктатты һәм шул сүзе белән ул Нариманны бик нык кечерәйтеп, мыскыл итеп әйтте кебек:

— Курыктың, а, друган, куркып сыйладың!

— Минме!?

— Да... син... по ходу...

— Әгәр курыксам, поездан да чыкмаган булыр идем...

—Курыктың! — дип каныкты Хамис. — Авылында герой булып йөрдең, ә монда... ыштанына җибәрдең!

— Кабатла! — дип кычкырды аңа Нариман.

— Нәрсә?

— Сүзенне кабатла!

Шулчак Хамис ветровка кесәсеннән пычак тартып чыгарды. Вакыйгалар зурга китүдән курыккан Альфред Хамисны бу эшеннән туктатмакчы булды,

ләкин тегесе аны тыңларга теләмәде, пычак күтәреп, Нариманга ташланды. Ләкин Нариман да куркып калмады — ыжгырып, Хамиска каршы китте. Ярсыган чагында Нариманның теләсә кемне ботарлап атканын яхшы белгән Хамис, шүрләп, арты белән артка чигенде...

— Лады... пошутили, хватит...

Дошманының кулына пычак тотып та, коралсыз кеше алдында куркып калганын күргән Нариман, мыскыллы елмаеп, анар кул селтәде дә, борылып, перронга таба китте. Сизде ул, сизде теге бәдбәхетнең артыннан йөгереп килгәнен, бик яхшы сизде! Аяк астында черегән, корыган яфракларның шыштырдаганына хәтле ишетте, ләкин борылып, саклану чарасын күрмәде. Бу очрашу шулай җинелчә генә үтеп китәр, бу бәдбәхет явызлык кылырга кыймас дип уйлады ул...

Аркага тимер кадак белән суккан кебек булды — пычак тәнне ярып керде. Бик иләмсез каты авырту тойган Нариманның күз аллары караңгыланып китте, күз алдында ап-ак очкыннар уйнады, кечкенә көмеш тайның — Ак маңгайның кушаяклап җәйләү буйлап чабып үткәнен күреп калды... Аннан ул хәле бетеп, аңын җуйды...

Ул өч көннән соң гына аңына килде. Ул үзенә хастаханәдә операция ясаганнарын белми дә, сизми дә калды. Кан эчендә яткан Нариманны перрондагы пассажирлар күреп алганнар. «Ашыгыч ярдәм» машинасы вакытында килеп җиткән, бәхетенә ул Казан вокзалы тирәсендә генә туктаган булган. Шактый кан югалткан Нариман искитмәле хәлдә исән калды.

Ул уянганда аның каршында әнисе Хәлимә һәм палатаның бер читында боегып Динәсе утыра иде. Авыру уянгач, әзрәк аңына килгәч, бүлмәдәгеләр кауталанышырга тотындылар. Каяндыр ак халатлы шәфкать туташы атылып керде, ул авыруга куелган системаны төрлечә тарткалап, төзәтергә тотынды. Аннан табиблар җыелды. Алар авыруның хәлен белгәч, үзара нидер сөйләшеп, Нариманга уңышлар теләп, палатадан чыгып киттеләр. Медперсоналдан бушап калган бүлмәдә әнисе белән хатыны гына утырып калды.

— Җә, улым, нихәл хәлең? — дип сорады кайгыдан күз яшьләрен сыгып туйган анасы. Кала якларына сирәк йөргән, һаман да шул авылда, өйдә утырырга күнеккән, инде шактый олыгаеп барган анасы, калага барырга булгач, әзрәк киенгән-ясанган, һәм шуның бәрабәренә берникадәр матурланып та киткән иде...

— Нариман! Нариман! — Шатлыгын яшерә алмаган Динә чаттан ире янына күчеп утырды һәм аның кулыннан алды. Нариман Динәнең кулын читкә алып, аны бөтенләй күрмәмешкә сабышты. Хатын аңлады: Нариманның ана булган рәнҗеше бик тә тирәнгә киткән иде...

— Менә, әни, — дип бик зур авырлык белән генә эндәште улы, —авылга кайтырга дип чыккан идем...

— Ие, улым, ие...

— ... кайтып житә алмадым...

— Кайтырсың, улым, кайтырсың, терелеп бетүгә үк авылга кайтырсың, рәхәтләнеп туган нигезеңдә яшәрсең...

Хәлимә сөйләнә-сөйләнә, кырын күз белән генә килен ягына карап алды. Янәсе, килен ничек уйлый, ничек карый аның бу сүзләренә!? Ә килен дәшми, чөнки ул үзенең гаебен белә, каенанасы ни әйтсә, шунар риза булып утыра. Риза булмас иде дә, ул ананың сүзләрендә хаклык барлыгын сизә. Нариман калага китсә дә, кала кешесе була алмады, ул каланы, ә кала аны кабул итмәде. Шуның аркасында ул зур җәфалар күрде, кыенлыклар кичерде. Ә бәлкем, җәфаламаска, җибәрергәдер аны иреккә!? Китсен, әгәр дә авылда яшисе килә икән, китсен,

яшәсен шунда. Динә дә үлмәс, ничек тә яшәр әле! Матурлыгы, житешлеге бар, ялгызы калмас, әлбәттә! Шулаен шулай да, ләкин нинди хатынның яраткан ирен иреккә чыгарасы, чит кешегә бүләк итәсе килсен икән?! Әйтүе, уйлавы гына җиңел, ә булганны югалтасы, кулдан ычкындырасы килми бер дә...

Авыру Нариман исә анасы янында, иркәләнеп, бала сыманрак кыланды:

— Әни, алып кит мине моннан...

— Ярый, улым, ярый...

— Калдырма мине монда...

— Юк, улым, калдырмам...

**18**

Хастаханәдән чыккач, аны авылга кайтардылар. Авыл һавасы аңа яхшы тәэсир итте: сәламәтлеге күзгә күренеп алга китте. Баласының авылга кайтып, туган өендә яшәгәненә сөенгән ана аның янында чабып, биеп кенә йөрде. Улына, ул ни теләсә, шуны ашатты, шуны эчертте. Бөтенләй аягына баскач, Нариман буага төшеп су коенды, көн аралаш мунча чабынды. Авыруыннан терелгән арада ул авылда бик күп кешеләр белән очрашты. Аны киләчәктә колхозның язмышы борчый иде. Чөнки ул авылда калачак, ул шушында яшәячәк, хезмәт итәчәк. Бармы бу колхозның киләчәге, юкмы? Аны менә шул нәрсә бик нык борчый иде.

Аларның колхозы районда иң көчле колхозларның берсе, моннан ике-өч ел элек кенә ул әле миллионер булып санала иде. Аны шул дәрәҗәгә элеккеге колхоз рәисе Кадыйр абзый күтәрде. Революциягә хәтле туган, Герман сугышында атасын югалтып, яшьли ятим калган, егерме беренче елгы ачлык заманнарын күргән, колхозлашу, репрессияләр чорын узган, нахакка суд һәм төрмә юлларын таптаган, немец-фашистларына каршы фронтта сугышкан, берничә мәртәбә яраланган, орден-медальләр алган Кадыйр абзый хәзерге көндә лаеклы ялга чыккан иде. Әйе, үзенең тормышы турында (үзе әйтмешли): «Мин иң гад заманда яшәдем!» — дип әйтергә хакы бар иде аның. Егерме беренче елгы ачлык елларында ничек итеп исән кала алганлыгына ул әле дә ышанып бетә алмый. Аның уенча, моңа совет властеның азык-төлек отрядлары (продразверстка) гаепле булды. Мылтыклы адәмнәр, өйдән-өйгә йөреп, амбарларны, базларны, сайгакларны актардылар. Запаска калдырылган ашлыкны каерып алдылар. Ул елны җәй дә бик коры килде. Август аена хәтле, бер тамчы явым-төшем булмаганлыктан, басудагы игеннәр дә көйде. Шуннан соң, яңгыр ишелеп яугач, алабута үләне котырып үсте. Аны кем җыйды — шул исән калды. Ачлык коры сөяккә калдыргач, ашарга алабута оны да булмагач, заманалар яхшырганчы авылдан югалып торуны хәерлегә санап, кайберәүләр атларына утырып, Себер ягына таба кузгалдылар. Күрше Бишмунча авылында, Габдуллаҗан бай йортында приют ачылды. Әти-әнисез калган ятимнәрне шунда урнаштырдылар. Кадыйр абзыйның әнисе Сәрбиҗиһан аларга нәрсә бар, шуны пешереп торды. Аерым йортта аеруча хәлсезләрне ашатуны оештырдылар. Этләрне, мәчеләрне суеп ашадылар. Күрше Бишбалта авылында берәү ике баласын ашаган икән, дигән сүзләр дә таралды. Бераздан авылга Америка паегы да килеп житте. Кофе, какао тараттылар. Бары тик егерме дүртенче елда, дәүләт тараткан тарыны чәчеп, аның мул уңышын тегермәндә ярмага, онга әйләндергәч кенә, халык, ниһаять, боткалы, кыстыбыйлы, ипиле булды. Ул вакытта җан башына бер ярым гектар җир туры килде. Алар гаиләдә сигез кеше иделәр. Җәмгысына уникe гектар җирләре бар. Басу, арбалы ат белән йөрү өчен юл калдырылып, ел саен бүленә. Гадәттә, бер кардада — алты хуҗалык. Һәр кишәрлекнең үз тамгасы. Аларныкы — озынча алка. Аны көрәк белән

жир өеп ясыйлар. Ул шәһәр урамын күрсәткән язу сыман, ерактан күренеп, адаштырмас маяк кебек, кишәрлеккә әллә каян ук чакырып тора. Жирләр ат белән сукаланды. Әле балигъ булырга да өлгермәгән яшь егет немецларның «Зингер» ширкәтеннән алынган өч көпчәкле сабаны белән төшкә хәтле утыз, аннары утыз өч сутый мәйданны сөреп чыга торган иде. Әйе, бу хәзерге колхозчылар сымак эленке-салынкы йөрү түгел инде, бу чын хезмәт иде!

Кадыйр абзыйга утызынчы елларда колхозлар оештырып йөрергә дә туры килде. Егерме тугызынчы елның ахырында волостьтан килгән вәкилләр: «Син колхозга керәсенме, юкмы?!» — дип авыл халкыннан сорап тормадылар. Бер волость вәкиле: «Йөз процент колхозчы булмаса, мин Бишкүлдән китмим!» — дигән таләп куйды. Бишкүлдә ул вакыт бик зур аерым хуҗалык булган, Миңлебай Фарукшин хуҗалыгы. Волость вәкиле тарафыннан әнә шундый катгый таләпләр булуга да карамастан, Миңлебай хуҗалыгы гаризага имза сыпларга ашыкмады. Шуннан ул яшәгән өйгә «Партизан» кушаматлы Гайфетдин абзыйны җибәрделәр. Ул туганы Миңлебай белән күп сөйләшеп тормады, кулыннан кысып тотып, кулны көчләп куйдырды. Бераздан мәҗбүри төстә колхоз оештыру тәҗрибәсе Мәскәү тарафыннан тәнкыйтьләнгәч, дилбегә әзрәк бушады бушавын. Шуны гына көткәндәй, өч авылны берләштергән колхоз тарала да башлады. Ике йөз ун йортның илле бише генә күмәк хуҗалыкта калды. Алары да җирне ничек эшкәртергә белмәүче атсызлар һәм кулаклыкта гаепләнүдән шикләнүче берничә баш терлекле «байлар» иде. Шунысы кызганыч, колхоздан чыгучыларны хөкүмәт барыбер тынычлыкта калдырмады. Хөкүмәт нишләде? Аерым хуҗалыкларның амбарларыннан икмәкне җыя башладылар, ә колхозчыларга кагылмадылар. Шуннан бөтен кеше диярлек янадан колхозга кереп бетте. Шулай итеп, барсын да әкертенләп алдадылар. Билгеле, колхозга кермәүчеләр дә күп булды. Башкаларга сабак булсын дип, андыйларны авылда калдырмадылар. Аларга «кулак» кушаматы тагып, барсын да читкә сөрделәр. Ике жил тегермәне хуҗасы Хөснетдин Хәстиев, тегермәнче Әкрам Шиһапов, җир җимертеп хезмәт итүче чын крестьян, колхозлашуга каршы үз сүзен әйтергә батырчылыгы җиткән Вәлиәхмәт Тимерханов, аты булмаган кешеләрнең җирләрен алып эшкәртүче һәм аларга аренда хакы түләүче Сафиулла Сәйфуллин, аның башка чыккан улы Хафизулла совет хөкүмәте тарафыннан шулай эзәрлекләнделәр. Шинельле-галәфиле вәкилләр аларны кичтән кисәтеп куйдылар, юлга җитәрлек ризыкларын, вак-төяк кием-салымнарын җыйдырып, иртән атларын җиктереп, алып чыгып киттеләр. Ата хөрәсәннәрдән, ялкаулардан кала, башкалар алар белән хушлашуны бик авыр кичерделәр. Чөнки ул киткән кешеләрнең барсы да Бишкүл авылының иң уңган эшсөярләре иде. Аларның авылда яшәгәндә дә йомшак урынга ятып, туйганчы йокларлык вакытлары да булмады. Алар чын хезмәт кешеләре иде. Тирләре тамганчы, куллары яргаланып беткәнче хезмәт иттеләр. Боларны халык җилкәсен кимергән кулаклар, дип әйтергә кемнең намусы җитәр икән? Үз көчләре белән тапкан малларыннан иреклe рәвештә баш тартырга теләмәгәч, малларын суеп кар астына яшергәч, аларны сыйнфый дошманга әйләндерде дә куйды Сталин. Әшәке, кабахәт заман! Ул вакытта акыллы кешенең авызын да ачтырмадылар, авызын ачканнарны, син дә «кулак тегермәненә су салучыга әйләндең» дип, шундук кулга ала тордылар. Күпме эшчән крестьян, чын җир хуҗалары әнә шулай чит җирләргә озатылып, юлда харап булдылар...

Кадыйр абзый үзе коммунист кеше булса да, коммунистларны бигүк өнәп бетерми иде. Билгеле, аның турында бик ачылып сөйләргә ярамый, ләкин совет системасын өнәп бетермәү барыбер сизелә иде анарда. Нариманга чыбык очы гына булса да, атасы ягыннан туган тиешле кеше иде ул. Калага киткәндә дә, каладан кайтканда да ул абзый янына кереп, аның хәл-әхвәлләрен

белмичә калмый торган иде. Абзый да тырыш егетне үзенчә якын итә, керсә, карчыгыннан табын әзерләтеп, кунак итеп чыгара иде. Бу юлы исә, Нариман хастаханәдә ятып чыкканнан соң, ул үзе аның янына килде. Чәй артында колхоз турында сөйләшеп алдылар. Нариманның авылга кайтырга теләгәнен ишеткәч, абзый бераз сәерсенеп калды. Кадыйр абзый хәзер колхозны мактарга тотынып, кайт, энекәш, һичшиксез авылда кал, дип өндәр төсле тоелган иде аңа. Ләкин абзый аны шаккатырды, ул сүзен бөтенләй икенче төрле сукалый башлады һәм киләчәктә колхозларның яши алу-алмауларына шик салды...

— Мин бит элек сәүдәгәр идем, сельпода хезмәт иттем, — диде ул. — Менә шул партия хуҗалары көчләп китереп тыктылар мине шушы колхозга. Синең дә, барып урнашкан жиренне ташлап, кире колхозга кайтуыңны бик артык хупламыйм мин, энекәш!

— Тугани абый, минем кайтуыма син сөенгәнсең дип уйлаган идем тагын. Колхозны яратмавыңны да аңлап бетермәдем?

— Синнән сүз чыкмый, улым, шуңа күрә дә мин сиңа курыкмыйча сүли алам. Колхозны аны халык түгел, ә дәүләт уйлап чыгарды. Дәүләткә крестьяннарны иң элек кулда тотарга кирәк иде. Ярлы-ябагайны гына түгел, ә чын тир түгеп хезмәт итүчеләрне. Ләкин дәүләт житәкчелеге бик зур ялгыш жибәрде...

— Нинди ялгыш?

— Алар колхозлаштыруның асылына, төбенә төшеп фикерли алмадылар. Ә моның нигезендә, әзрәк уйлансаң, бик зур бер каршылык ята. Аның асылы «минеке» һәм «безнеке» дигән төшенчәләргә барып тоташа. Тормыш раслаганча, «минеке» бетми, жимерелми. «Безнеке» исә югала һәм ватыла.

— Бигүк аңлап бетермим әле мин сине, тугани абый! — диде үзенең берни дә аңламаганына ояла башлаган Нариман.

— Аңлатам, әгәр дә аңламасаң. Мәсәлән, авылда бер кешенең сыеры үлсә, моның турында бөтен авыл халкы сүли. Ә менә колхоз фермасындагы терлекләрнең күпләп үләт базына китүенә беркемнең дә исе китми, шулаймы!?

— Шулай...

— Әйтерсең ул шулай булырга тиеш! Менә мисалга бәрәңге бакчасын гына алыйк. Шәхси хуҗалыкның егерме биш сутыйлы жиреннән чыккан уңыш аның хуҗасына да, мал-туарына да, каладагы туганнарына да житә. Әгәр өч бакчаны берләштереп, аны өч кешегә беркетеп «безнеке» ясасаң, ышанып әйтә алам, чыкмаячак шул хәтле уңыш! Монда төп хикмәт жирнең «минеке» дигән хуҗасы булуында. Чөнки ул маллар астыннан чыккан тиресне черетеп, шуны ашлама итеп, ел саен кишәрлегенә тарата. Монда абзар — жиргә, жир абзарга эшли. Ә колхозда? Ферма тирескә күмелсә күмелә, әмма мондый әйләнеш ясалмый...

— Сәбәбе нидән, тугани абый?

— Сәбәбе бик гади: «минеке» дигән хис булмагач, гомумигә исе китми кешенең. Шунар күрә дә крестьян психологиясен кичекмәстән дәвалау сорала: жиргә дача-бакча хуҗалары кебек эшкуарларны янадан кайтарырга кирәк булыр...

— Тугани абый, мин сине бөтенләй аңламыйм...

— Нәрсә аңламыйсың?

— Колхозны бетерергә дисеңме?

— Хе! — дип елмайды карт төлке. — Син бик шаулама, яме, хәер, синнән сүз чыкмый, шунар сиңа сүлим дә. Гомер буе куркып яшәдек, колхоз рәисе булганда да өстән шикаять язып үтерделәр. Кемнәр генә язмады, хәтта туганнарга хәтле язды. Берсе, безнең рәис «хором»да яши дип шикаять язгач, өйне килеп, санап-үлчәп киттеләр. Бу илдә чын хезмәт белән яшәүчене күралмыйлар, күрәсең, иле үк шундый, ахрысы...

— Тугани абый...
— Нәрсә, энекәш?
— Син сорауга җавап бирмәден бит...
— Нинди сорау иде ул, кабатла?!
— Колхозлар турында...
— Ә... әйе... шунсыз булмый, энекәш. Чөнки колхозда берәүләр йөкне җигелеп тартканда, икенчеләре арттан сөйрәлә. Гомуми көчтән алучы бик күп, тик салучы гына юк...
— Нәрсә, киләчәктә колхозлар бетәр дисенме?
—Шунар таба бара, энекәш, шунар таба... Ләкин колхозлар бетсә дә, авыл бетмәс инде ул. Авыл бетү татар өчен тагын да аяныч хәл. Урыс ул кая да урыс, калада да урыс, салада да. Авылны бетерергә ярамый, чөнки авыл бетсә милләт тә бетә. Колхозлар яшәсен, без хәзер колхозсыз яши алмыйбыз, без шуңа ияләштек... Менә синең кебек тырыш ир-егетләр булганда колхозы да, авылы да бетми әле аның, бетми, кәнишне. Әгәр дә кайтырга уйлагансың икән, син кайт, энекәш, кайт... ташлама авылыңны...

**19**

Күнел дигән нәрсә бер сүрелгәч, сүрелә икән, ә аралар бер өзелгәч, өзелә икән шул. Нариман, терелеп беткәч, берничә тапкыр калага хатыны янына барып карады. Ләкин хатынын инде иркәләп, кочаклап йоклый алмады. Чын авыл мужигы, чын крестьян булып тәрбияләнгән, гомерлек юлдашы — хәләл җефетен, яратудан битәр, үзенең милке итеп санаган хатынын Нариман кабат үз итә һәм аның хыянәтен берничек тә кичерә алмады. Ярты елдан сон алар аерылыштылар. Ул бөтенләйгә авылга кайтты, ә Динә калада калды. Ул, ниһаять, үз теләгенә иреште, Динәсе дә аның теләге белән килеште. Аның авылдаш дуслары Һади белән Зиннур-Зимагур да, инде өйләнеп, авылда төпләнеп калдылар. Алар икесе дә урып-җыю вакытында ындырда каладан икмәк чистартырга кайткан кызларны алып калдылар. Дөресрәге, алар башка районнан килгән авыл кызлары иде, ә завод (шунда хезмәт иткәч) аларны авылга ярдәм йөзеннән җибәрде. Заводка һәм кызларга зур рәхмәт, чөнки алар колхозга гына ярдәм итеп калмадылар, ә Һади белән Зиннур-Зимагурны да бәхетле иттеләр.

Кала белән ике арада йөргән арада, Нариман тимер юл вокзалы перронында Шәмсыгаянның улы Минненазыймны да очратты. Дустын әле дә җүләрләр йортында ята дип уйлаган Нариман бик каты ялгышкан икән бит! Башта ул Назыймны танымыйча торды, аны күзенә күренә дип кенә уйлады. Чөнки кайчандыр кеше үтереп, шундый җинаять кылган кешене кабат иректә күрермен дип аның уена да кереп карамады. Дөреслектә, ул Назыймны түгел, ә Назыйм аны танып алды. Танымаслык булып үзгәргән үзе. Матур кепка, модный кәчтүм киеп куйган. Күнеле дә, кәефе дә күтәренке иде үзенең. Алар кочаклашып күрештеләр.
— Син кайда сон хәзер? — дип сорады анардан Нариман.
— Себердә.
— Ничек барып чыктың анда?
— Олы апам, Айсылу апам шунда, кияүдә. Нефтьтә мин хәзер, нефтьтә...
— Тегеннән ничек котыла алдың?
— Котылдым, ә нигә котылмаска! Алар авыл кешесен җүләргә саныйлар, ахрысы, үзләрен бик тә акыллы дип уйлыйлар! Ә бездән дә акыллы, хәйләкәр кеше юк бу дөньяда. Кирәк икән ул тиешле сүзен дә әйтә, кирәк икән башын

җуләргә дә сала беләә. Кыстати... бөтен җүнле, акыллы кеше авылдан чыккан, авыл үстерә баһадирларны, авыл... Ә син кая?

— Мин Динәдән аерылдым, авылга кайтам... бөтенләйгә...

— Син кайта тор, бер биш-алты елдан мин үзем дә кайтып җитәм, менә әйтте диярсең! Атам нигезенә яңа йорт салып куям! Менә бераз гына акча эшләп алыйм, ә Себердә әйбәт түлиләр, туган, яхшы түлиләр...

Шулай итеп, Назыйм Себер якларына китеп барды, ә Нариман авылга әйләнеп кайтты. Әни янында булырмын, яраткан тракторымда хезмәт итәрмен, дип, авылына шатланып, сөенеп кайткан Нариманның бераздан кабат эче поша башлады. Кайчандыр яраткан хатыны белән яшәгән, хатын назына өйрәнгән һәм инде хәзер аерылган буйдак дәрәҗәсендә йөргән егетнең күңеле барыбер китек калды. Әнә шул эч пошуын басар өчен, күңел китеклегеннән арыныр өчен Нариман да, бик күпләрнең ачы язмышын кабатлагандай, әкренләп эчүгә сабышты. Улы өчен ут йоткан һәм аны кабат өйләндерергә хыялланган Хәлимә әлеге читен хәлдән чыгу юлын эзләде. Әйе, авылда кызлар азая, ләкин ел саен барсы да китеп бетми, калганы кала. Нариманны димләргә тотындылар. Димчесе дә, өйләндерүчесе дә Хәлимә үзе булды. Бик күп кызларны тәкъдим иттеләр аңа, ләкин егет кире бетеп, һаман да үз турысын сукалады. «Яратмыйча өйләнә алмыйм, әни, аңла!». Бу бәргәләнүләр шактый озакка сузылды. Ләкин Динәнең янә кияүгә чыгып, бергә яшәгән фатирга чит кеше кайтарып утыртуын ишеткәч үк, Нариман күрше урамдагы Кәримә апаларның Зөмәрәсенә әнисен яучы итеп җибәрде. Үзе бармады, үзе кырыйда калды. Әнисе Хәлимә Зөмәрәнең йөрәк белән чирле икәнен, аның «группа»да утырганын белә иде. Әнисе: «Нишлисең син, улым, син бит аны яратмыйсың!? — дигәч, җавабында улы: «Бу дөньяда хет бер кешене булса да бәхетле итәрмен!» — диде. Укуны бетергәч, әнисе янында авылда калган, авыру сәбәпле, җинел эштә генә йөргән Зөмәрә, тәкъдим ясалуга ук, аңар йөгереп чыкмады. Кыз (үзенә күрә түгел!) шактый тәкәббер, нәзберек булып чыкты. Ә бу үҗәтлек егеттә кызга карата ачу түгел, нииндидер кызыксыну хисе дә уятты. Ул үзе берничә мәртәбә кызның өенә төште. Яп-ябык, арык кыз, ни арты, ни яны, ә үзен менә ничек зур итеп куя! Иң элек кыз: «Мина кызганудан гына өйләнергә булсаң, вакытың әрәм итеп йөрмә!» — дигән таләп куйды. Ә егет җавабында: «Яратам, дип әйтә алмыйм, әмма терәгең, тугры ирең булырга ант итәм!» — дигәч, кыз эреде дә төште һәм бер-ике көннән ризалыгын да бирде. Әллә ни зурдан купмадылар, комсомол туе гына ясадылар. Ә ярату соңыннан килде: ни арты, ни яны юк кыз, кияүгә чыгуга ук, кинәт кенә чибәрләнеп, тулып китте, йөзгә дә матурайды. Ни гаҗәп, төрле кунакларда, мәҗлесләрдә бөтен кешенең күзе Зөмәрәдә була торган иде. Тышкы матурлык кына аз, эчке ягы да бәһале бит аның. Ә яшь хатынның күңеле чиста һәм ул хискә дә бай иде. Хатын башта кыз бала тапты, ләкин ул өч ай да тормады, үлде. Күз тигән, диделәр. Табиблар аңа бүтән бала тапмаска киңәш бирсәләр дә, хатыны беркемне дә тыңламады, тап-таза ир бала тапты. Аңа Инсаф дип исем куштылар.

***

...Нариман Зөмәрәнең үлемен бик авыр кичерде. Тормышлар рәтләнеп, Инсаф үсеп җиткәч килеп чыкты бу аяныч хәл. Табиблар хатынының озын гомерле түгеллеген инде аңа күптәннән әйтеп, аңлатып килделәр, тик Нариманның моңа һич кенә дә ышанасы килмәде. Әле генә яхшы хәле, әле генә начар. Гел шул халәттә яшәде ул. Унсигез яшьлек Инсафы төрмәгә утырганнан соң, Зөмәрә бөтенләй бетерешәте. Нариман шулай итеп ике газиз кешесен югалтты: хатынын җирләп кайтканда, малае Инсаф инде икенче ел төрмәдә утыра иде...

## ИКЕНЧЕ КИСӘК

## Туган нигез

### 1

Туган нигез...

Өй ябык: тәрәзәләре калакланган. Ян-яклары ашалган имән ишеккә зур амбар йозагы эленгән. Өй эченә шыксыз карангылык ингән. Әйтерсең лә монда тормыш (вакыт) туктап калган. Тик ни гаҗәп: озак еллар кеше яшәмәгән йортта гаҗәеп чисталык вә пөхтәлек хөкем сөрә. Бер генә әйбер дә чәч тә баш ятмый: миче акшарланган, өстәл өсләре сөртелгән, табак-савытлар юылган. Туган йорт, туган нигез бүген әнә шундый халәттә, гүя, ул хуҗасын көтә кебек...

Тынлык. Монсу тынлык.

Каяндыр адашып кергән канатлы бөҗәк, бик каты гына безелдәп, өстәл тирәсендә очып алды да, кабат тынып калды. Әлеге тынлыкта ниндидер серле пышылдаулар — йортияләренең үзара эндәшүләре вә сөйләшүләре ишетелеп алды.

Кинәт! Ах, шул кинәт! Агач чыртлап сынган кискен каты тавыш ишетелде. Кемдер тышта тәрәзәгә калакланган агач такталарны каерып ташлады һәм тәрәзә ачылып китте. Өй эченә кояш яктысы бәреп керде, өйгә нур инде. Ниһаять, нигез уянды, терелде һәм ул үз тормышы белән яши башлады. «Исәнме, туган йорт!»

Аркасына биштәр аскан Инсафның, тәрәзә аша кереп, беренче эндәшкән сүзе әнә шул булды. Аны туган йортыннан башка беркем дә ишетмәде, чөнки бу өйдә ул әлегә үзе генә иде. Әллә кайтаваз, әллә йорт ияләре телгә килде, һәр тарафтан бердәм булып: «Исән-ме...и-сән-ме...и-сән-ме...» — дигән сүзләр, авазлар яңгырады. Биштәр карават өстенә очты. Инсаф өстәл өстендә торган дәү калай чәйнекне кулына алып, аның капкачын ачты. Су бармы?! Ул бик нык сусаган, кайрәгән иде. Башта ул суны чәйнекнең борыныннан гына эчмәкче булды. Аннан кире уйлап, аны урынына куйды. Бер учка җыелган җиләк төсендәге вак чәшкәләрне тиз-тиз генә өстәл өстенә тезеп чыкты. Бер, ике, өч... Шуларның һәркайсына, кырыена хәтле ташытып, су салып чыкты...

— Исәнме, әнкәй! Исәнме, әткәй!

Авазлар, ир-ат һәм хатын-кыз тавышы белән чиратлашып, янә кабатланды:

— Исәнме, улым... Исәнме, улым...Кайттыңмы...

Инсаф барлык чәшкәләргә дә салынган суларны эчеп бетереп, өстәл янындагы урындыкка утырды. Учлары белән маңгай тирләрен сөртеп, башын аска иде һәм тын гына елады...

— Исәнмесез... җаннарым...

— Исәнме... исәнме! — диеште йорт ияләре.

— Кайттым... ә сез юк...

— Без юк, юк, — диештеләр алар, — ә син бар, бар...

— Юк!!!

Инсаф бар көченә йодрыгы белән өстәлгә китереп сукты. Өстәл дер селкенеп куйды. Бераздан өйне тагын тынлык камап алды. Егет күңелен авыр уйлар биләде. Ниһаять, аны төрмәдән чыгардылар. Унике ел биргәннәр иде, җиде елын утырды. Җиде ел — җиде гомер кебек ул! Ниһаять, ул иректә, тик бу азатлык аны нигәдер сөендермәде. Әтисе дә, әнисе дә юк, икесе дә күптән мәрхүм. Шып-шыр өйгә кайтып утырды ул, шып-шыр өйгә! Олы юлдан попуткага утырып кайткан егет, соңыннан төшеп калып, соңгы ун чакрымын җәяүләп кенә тәпиләде. Нигәдер аның кешеләргә күренәсе килмәде һәм ул үзе

дә кешеләрне күрергә теләмәде. Чөнки шактый гомер үткән: авыл аңардан һәм ул да авылдан читләшкән иде. Арыганлык үзен нык сиздерде, Инсаф башын өстәлгә куйган килеш, изрәп йокыга китте...

Шулчак кемдер тышта ишек йозагын каерды. Егет тиз генә сикереп торды, ләкин нидер уйлап, кире урынына утырды. Яман төрле авазлар чыгарып, бик зур авырлык белән генә өй ишеге ачылды. Ишектән, бертуктаусыз йөткерә-йөткерә, кемдер атлап керде. Инсаф ул якка борылып та карамады. Ул болай да аның кем икәнен аңлады. Бу аның дәү әнисе Кәримә апай иде. Ул ишек йозагын өйгә хәтле үк күтәреп кергән, чөнки ачкыч йозакка кереп калган, ә ул шуны кире чыгара алмыйча интегә иде...

—Кулым! — дип зарланды ул. — Шушы йозак тәресен! Газаплый да соң инде алай да!

Шулчак Инсаф тамак кырып куйды. Кәримә сискәнеп шул якка борылды.

— Абау! Кем син!?

—Исәнме, дәвәни! — Егет урыныннан торып басты. Кәримә дулкынланып йөрәген тотты.

— Инсаф... улым... синмени?!

— Мин, дәвәни, мин!

— И... жаным...

Инсаф дәү әнисен кочаклады. Жиде ел эчендә шактый ук кинәергә өлгергән әбисен ул кысып коча алмады. Бу очрашуны төрмәдән чыккан егет башкачарак көткән иде, билгеле! Дәү әнисеннән дә якын кешесе калмады аның авылда. Ул дәү әнисен аркасыннан сөеп, жилкәсеннән чәбәкләде...

— Их, дәвәни, дәвәни, әле дә ярый син бар! Исән...

— Исән...исән...әле дә ярый Дания апаң...

— Ни булган аңа?

—Өй янында бер чит кеше йөри дигәч, тиз генә монда чаптым. Кем белә! Кемнәр генә йөрми хәзер авылда!

— Кемнәр?

— Әллә кемнәр... тавар сатучылар, чегәннәр, хулиганнар...

— Ачуланма, дәвәни, — дип акланды онык. Ул тәрәзәне барып япты. — Ишектән кермәдем, тәрәзәдән кердем!

— Нишләп соң туп-туры миңа кайтмадың!?

— Нигәдер туп-туры шушында, үз өемә кайтып керәсем килде. Йортым төрмәдә утырганда да төшләремә кереп йөдәтте...

Оныгы төрмәгә утыргач, Кәримәгә шактый авырга туры килде. Башта йөрәк өянәге белән аның кызы, Инсафның анасы Зөмәрә үлеп китте. Приступ арты приступ — бик каты авырды кызы! Операциядән нигәдер баш тартты, соңыннан риза булды булуын, ләкин ясарга өлгерми калдылар. Өч елдан соң язгы ташу вакытында кияве Нариман батып үлде. Гомер аракы эчмәгән, авызына грамм хәмер капмаган кияве Зөмәрәнең үлемен күтәрә алмады, ул үлгәч, бик нык эчте. Алар бер-берсен бик нык яраттылар, алар бер бөтен иделәр. Хатыны чарасыз авыру, ә Нариман, чәчү аппаратында кулын имгәткәннән соң, бер кулга гарип булып калды. Билгеле, менә бер хатынының үлеме генә түгел, ә колхозларның таркалуы, халыкның эшсез, акчасыз калуы да сәбәпче булгандыр. Колхозның таркалуын, аның талануын бик авыр кичерде Нариман. Авыл явызы Латыйп башына житте аның, дигән сүзләр дә шактый йөрде йөрүен, ләкин бу факт расланмагач, гаебе исбатланмаган кешегә яла ягудан ни файда. Кияве әйбәт кеше иде Кәриманең. Булсын, тормыш барсын дип тырышты. Булдыра алмагач, пар канаты сынгач, сүнде бахыр. Ире үлгәннән соң, үз өендә ялгызы

гына гомер кичергән Кәримә кызы белән киявенең йортын да ташламады, атна саен килеп йөрде, жыештыргандай итте, үзенчә карады. Өй эчендә чынлап та тәртип иде. Аллага шөкер, инде ниһаять, оныгы да кайтты. Ул кайткач, бу аулак өйгә тагын да ямь керер, иншалла! Инсаф дәү әнисенең тырышлыгын күрде, бәясен бирде, әмма әбисенең тәрәзәләрне такта белән кактырып яптыруын гына ошатмады. Тәрәзәләре калакланган йортны күргәч үк, аның йөрәге өшеп китте. Кешенең күзен бәйләгән кебек инде бу. Борылып кире китәрдәй булды. Ләкин (дәү әнисе әйткәнчә) кактырмыйча да булмый, яшьләр бик әрсез хәзер, иясез йорттан нәжесле урын ясарга да мөмкиннәр. Болай да инде әнә бер тәрәзәне ватып киткәннәр...

— Улым, сругың бик зур иде ләбаса! Иртәрәк чыгардылармыни?

— УДО белән чыктым.

— Нәстә белән?

— Условно-досрочное освобождение.

— Нәстә соң ул?

— Тәртибем яхшы булды. Шуңар күрә алданрак чыгардылар.

— Ярар, әйбәт булган, — диде Кәримә өстәл янына чүмәшеп. Ул хәтле зур гәүдәне, баскан килеш, тотып тору жинел нәрсә түгел иде. Житмәсә, соңгы вакытта аяклары, буыннары да сызлый башлады. — Кайтуын турында хәбәр дә бирмәдең?

— Мин бит армиядән түгел, төрмәдән кайттым. Кемгә әйтим? Ничек хәбәр итим? Аннан... чыгарачакларына актык көнгә хәтле ышанмадым.

— Ярар, ярар, исән-сау гына әйләнеп кайттың, шуңар сөенергә кирәк. Тик... атаң-анаң гына...

— Сүз дә юк... Ничек күнелле булыр иде, әгәр дә мине хәзер әти-әни каршы алса!

— Көттеләр, бик тә көттеләр алар сине! Башта әниең... аннан... атаң...

— Әйе...

— ...гүр иясе булдылар...

Кәримә яшьләрнең үлемен авыр кичерсә дә, хисләрен кешегә күрсәтергә яратмый иде. Елаганда да күз яшьләрен яшереп елый, сөйләгәндә дә сак кылана — кемгә сөйләгәнен белеп сөйли иде. Гомумән, алар нәселләре белән шундый иделәр, әзрәк кенә ордым-бәрдемнәр, каты күнеллеләр. Авылда Фарих бабаларының нәселе атаклы нәсел иде. Инсаф моны яхшы белә, аның авыру анасы да һәрчак көчле рухлы булды, беркайчан да юкка жебеп төшмәде.

Өйнең түр ягында, чаттарак, диварда кечкендик пыяла рамнарда әти-әнисенең, туганнарының фотосурәтләре эленгән. Көзен-кышын ягылмаган йортта фотоларның күбесе саргаерга да өлгергән. Ләкин исән калганнарыннан да ата-анасының йөз чалымнарын абайларга, аларны тулы итеп күз алдына китерергә булыр иде. Ул нәкъ жиде ел утырды һәм шул жиде ел эчендә аның әнисе дә, әтисе дә китеп барды. Ни аяныч, ул аларны күмәргә дә кайта алмады...

— Синең өчен ничек борчылганнарын белсәң икән син атаң белән ананның! — дип тезеп китте карчык. — Син утырганнан соң, кара кайгыга баттылар. Гаебең юк икәнен белсәләр дә, бик нык хурландылар халык алдында... Нәселдә булмаган нәрсә, нәселдә, шуңар бик нык хурландылар. Бала кайгысы! Ай, бу бала кайгысы! Дошманына да теләмә икән шуны! Анаң тумыштан авыру булды, сине утырткannан соң да авыруы отыры көчәйде. Көнгә икешәр, өчәр приступ... май кояшымның...

— Беләм! Әти язды ул турыда...

— Белсәң... шул...

— Әтигә ни булды?

— Анаң үлгәч, атаң да бетерәште.

— Эчтемени? Гомер әтинең эчкәнен күрмәдем!

— Ансы аның бер хәл...

Кәримә шактый вакыт дәшмичә торды. Инсаф белә, берәр сер ирештерәсе килсә, ул шулай озак кына эндәшмичә тора иде. Моны чит кешегә сөйләп тә, аңлатып та булмый, бары тик онығына гына ирештереп була иде.

—Яшерен-батырын түгел, кыйнадылар атаңны! Завфирмы булып эшләгәндә...

— Кем?

— Белсәк икән...

— Яшермә, әйт...

— Юк, әйтмим...

— Нишләп?

— Ул адәмнең исемен атарга да ярамый.

— Нигә? Куркасыңмы?

— Ансы да бар...

— Ну!?

— Гаебе исбатланмаган...

— Ни өчен кыйнаганнар соң? Әти миңа ул турыда язмады да...

— Атаң шундый кеше иде...

— Шулай да...

Кәримә сөйләргә мәҗбүр булды. Нариман тракторда йөргәндә гарипләнеп, кул һәм беләк сеңерләрен өздергәннән соң, озак кына эшсез ятты. Бераздан аны колхоз фермасына җитәкче итеп куйдылар. Алдау-йолдауны белмәгән, фәкать эш-хезмәтне генә сөйгән мужик бер ел эчендә таркалып барган ферманы аякка бастырды. Биналарга ремонт ясатып, акчасын таптырды, терлекнең баш санын арттыруга иреште. Сөт, ит җитештерү артты. Шуның исәбенә колхоз яхшы табыш ала башлады. Ләкин колхоз барыбер мантый алмады: үзгәртеп кору чоры башлангач, ул бөтенләй таралды. Нариман фермасы гына аягында нык торды. Бандитлар каланы гына түгел, авылларны да басып алдылар. Авылныкылар бит үзләре җитмәсә! Шул адәмнәр Нариманнан ярты бәягә генә ике тана килеп сорадылар, ә ул аларга каршы чыкты, бирмәде. Гадел кеше чөнки, беркайчан да хәрәмгә бармады. Шуннан соң аны бик каты кыйнап, таналарын урлап алып киттеләр. Хастаханәдә ятып чыкканнан соң, ул кабат фермага кайтмады. Ул үзен бик начар хис итте, аның бөтенләй яшисе килмәде. Кешеләрне яраткан, кешеләр белән ачылып сөйләшергә күнеккән мужик үз-үзенә кереп бикләнде, беркем белән аралашмас, көрешмәс булды. Шул кайгыдан Зөмәрә дә чирләп үлеп китте. Нариман язгы ташуда батып үлде. Кулсыз иде ул, бер кулы бөтенләй йөрми, хуҗасын тыңламый, бауга эленгән кер сыман, эленеп, салынып кына тора иде. Шул кулы таза булса, исән дә каласы икән. Ул суга егылган, ә сау кулы аста калган, шуңар күрә дә ул яр кырыннан чыгып торган юан агач тамырына тотынып кала алмаган...

—Әй, кияү, кияү, җәллим дә соң үзеңне! — дип сыкранды Кәримә. — Җәллим...

—Мин! Мин гаепле монда, дәвәни! Әгәр мин утырмаган булсам, әни дә, әти дә исән калган булырлар иде!

—Кем белә инде, балам, кем белә. Язмыш инде ул, язмыш... гомер узган...

Әйе, гомер узган, тик аның менә хәзергесе кадерле. Төрмәдән чыгуга ук, ул туп-туры авылга кайтты, калада бер генә көн дә кунмады. Кайчандыр

бергә утырган, инде хәзер ireккә чыккан «корешлар»ы, ягъни дуслары аны калада калырга үгетләделәр. Аны анда барсы да хөрмәт иттеләр. Үзенең бер гаепсезгә утырганын белсә дә, Инсаф төрмәдәгеләргә кирәкмәгәнгә зарланып, үзен кызгандырып маташмады. Төрмәгә эләккәч үк, ул зарлану дигән нәрсәне онытты. Юк-барны сөйләмәде, сөйләргә ярамаганны яшерә белде. Юк, ул «сладкий» чувак түгел иде. Чөнки камерадагы бай малайларына көче-көче белән передачалар, күчтәнәчләр ташыган кебек, аңа анда андый нәрсәләр ташучы булмады. Әнисе исән чагында килмәде түгел, килде, атасы, ара-тирә, акча җибәргәли торган иде. Әтисе дә, анасы да үлгәч, өч айга бер булса да, пенсиясеннән өлеш чыгарып, дәү әнисе акча җибәрде. Передачаны өч айга бер генә мәртәбә алып була, артыгын ала алмыйсың. Дәү әнисе оныгы утырган төрмәнең кайда икәнлеген дә, калага ничек барырга кирәклеген дә белми. Передачаларны, акчаларны аңа Раушаниясе китерә торган иде. Ул хәзер дә күрше авылда гына яши, балалар бакчасында тәрбияче булып эшли. Инсафка егерме тугыз, кызга егерме җиде яшь. Инсаф аның белән күрше авылга клубка дискотекага төшкәч, танышып калган иде. Юк, ул Раушаниягә үлеп гашыйк булмады, аның артыннан да чапмады. Аларның чын сөю мөнәсәбәтләре (хат һәм телефон аша) Инсаф төрмәгә утыргач кына башланды...

— Авыл халкы ни сөйли, дәвәни?

— Кем турында?

— Минем турында?

— Начар сүләми. Барсы да сине кызгана. Инсафның бернинди гаебе юк, ул бары Әпти малае аркасында гына утырды, диләр. Кем турында сүләгәнемне аңлыйсыңдыр, шәт!?

— Аңлыйм. Халык шулай ди алайса?

— Чын шулай! Шулай булгач, курыкма, балам, башыңны югары күтәреп йөр!

Кәримә бик зур авырлык белән урыныннан кузгалды. Инсаф аны тартып ук торгызды. Әйе, дәү әнисе шактый картайган, шуның өстенә яна авырулар да өстәлгән үзенә.

— Әйдә, киттек!

— Кая?

— Миңа! — диде Кәримә. — Чәйләп алырбыз!

— Килермен, дәвәни, килермен, кичкә яме! Әзрәк өйдә булыйм инде! — диде оныгы һәм диварда элеңгән радионы кушты. Озак сөйләми яткан радио исә, шытыр-пытыр килеп, сөйләргә тотынды. Ул тиз генә аның тавышын басты...

— Ярар, үзеңә кара! — дип килеште дәү әнисе. — Мә, ал йозакны! Ачкычы да шунда! Тәрәзәдән йөрмә бүтән, ишетсен колагын!

— Ай-яй, авыр йозак! — диде ул кулына йозакны алгач. — Төрмә йозаклары да бу кадәр үк авыр түгел!

— Хәзер син хуҗа монда! Теләсәң нишлә! Ярар, киттем, кичкә килерсең. Пилмән куеп җибәрәм...

— Дәвәни! — дип эндәште ул Кәримәне туктатып. — Бәлкем, монда күчеп килерсең, ә!? Безнең өй яңарак бит.

— Юк, балам, мин үз өемне ташлый алмыйм, анда минем барсы да көйләнгән...

— Берүземә күңелсез булачак инде, сөйләшергә кеше дә юк...

— Өйлән! Өйләнгәч, сөйләшеп, сөешеп туя алмассың!

— Кем чыгар соң миңа? Төрмә кошына?!

— Чыгарлар, ник чыкмасыннар. Күнелең әйбәт синең. Корпусың да яхшы. Мин үзем генә торырга иятләшкән инде, улым. Һәркемгә үз өе якын. Әлегә

аягымда йөрим, Аллага шөкер! Миңа үпкәли алмыйсың: йортыгызны карадым. Барсы да үз урынында...

— Бер генә әйбер житми! — дип искәртте шулчак егет.

— Нәстә?

— Тальянны күрмим. Гармунны.

— Нәстәмә ул сиңа?

— Бер уйнап карыйсы килә.

— Борчылма, гармунын исән, югалмаган.

— Кая соң ул?

— Әбиеннең сандыгын ач әле!

Сандык икенче бүлмәдә, йокы бүлмәсендә иде. Ул Хәлимә әбидән калган иде. Иске, затлы сандык. Яшьләр хәзер сандык-мандыкларга артык исләре китми. Инсафның әнисе шушы йортка килен булып төшкәч тә, каенанасының сандыгын яратты, үз итте. Нариман белән өйләнешкәч, алар матур кием шкафлары, гарнитурлар да алдылар. Ләкин Зөмәрә шушы сандыкны башка әйбердән якынрак күрде, аңа хыянәт итмәде. Ул кыйммәтле, затлы әйберләрне һәрчак шушы сандыкта саклады. Чагыштырмача яшь кеше булса да, яшьли дөньядан китсә дә, ул хәтта (әллә сизенеп!) үзенә үлемтекләр дә әзерләп куйган булган һәм аларны да шушының эчендә саклаган. Үз-үзенә үлемтек әзерләгән кешене озак яши, диләр, тик менә әнисенең генә гомере әлләни озын булмады.

Тальян гармун да шушында саклана иде. Инсаф сандык капкачын зур авырлык белән ачты. Борынына ят ис, нафталин исе килеп керде һәм ул бөтен бүлмәгә таралды. Ул сандыкның чатында чәчәкле сөлгегә төрелгән гармунны тартып чыгарды, аның тузанын сөрткәндәй итте, тик, ни гаҗәп, гармунга хәтта тузан да кунмаган иде. Бу тальянда аның атасы да уйнаштыргалады, ләкин ул барыбер Инсаф кебек оста итеп уйнарга өйрәнә алмады...

— Менә бит ул! — ди чиксез сөенде егет, яраткан гармунының телләренә баскалап. — Таш сондыкта кандала сытып ятканда, авылга кайткач, рәхәтләнеп бер гармунда уйнармын, дип хыялланган идем. Менә бит ул! Менә ул минем гармун! Әйдә, сытыйк әле шуны бер!

— Уйна, әйдә, — диде дәү әнисе, — авылда синнән дә яхшы уйнаучы бар микән хәзер!? Әхмәт тә, өйләнеп, авылдан китеп барды...

— Теге гармунчы абзыймы? Кая ул хәзер?

— Калага күчте. Бер хатынга йортка кергән, диләр.

— Их! Шәп уйный иде!

— Уйна, әйдә!

— Уйнарга, дисең инде!?

— Уйна, балам, уйна! Син кайткач, өйгә жан керде... жан...

Тальянын күкрәгенә кочып, Инсаф урындыкка утырды. Кәримә оныгының алдына кызыл төстәге жәймә китереп салды, оныкгармунын шунын өстенә утыртып, әкрен генә уйнарга тотынды. Уен көе бераздан соң жырга күчте, егет жаны ни сораса, шуны уйнады һәм шуны жырлады, чөнки аның бүген күңеле жыр сорый иде...

Без авылдан чыккан чакта
Күтәрелде томаннар.
Йә кайтабыз, йә кайтмыйбыз,
Сау булыгыз, туганнар!
Йә кайтабыз, йә кайтмыйбыз,
Сау булыгыз, ту-у-ганнар...

## 2

Көннәр ничектер бертөрле, ялыктыргыч булып узды. Инсаф, билгеле, кул кушырып, тик кенә утырмады. Кул эшенә оста иде ул. Әнә агач чолан бурадан авышкан, ул шуны урынына тарттырып, өр-яңа такта белән тышлап чыкты. Тактасын сарайдан тапты. Атасы ышкылап, ясап калдырган булган. Чолан ишегенә яна йозак элеп куйды. Мунчаның бусагалары черек иде, аларны да алыштырды. Ике-өч көн рәттән мунча якты. Төрмәдә чакта мунча керүләр сирәк эләгә иде, исән-сау чыккач, авылга кайтып бер мунча керү аның өчен чиксез зур бер хыял булып тоелды. Аллага шөкер, бусы да тормышка ашты! Ашау-эчү әлегә дәү әнисендә булды. Аралар ерак түгел, ике тыкрык кына, тиз генә бара да килә. Эч пошканда ул бергә укыган дуслары, классташлары белән очрашкалап алды, алар белән дә аралашты. Ниһаять, ул Раушаниясе белән дә күреште. Күрше Багыш авылына төшеп, аны үзенә кунакка алып менде. Кочышып, сөешеп, хисләр янартырбыз, дип өметләнгән Инсаф монда да ялгышты. Бигүк ачылып китәргә, серен чишәргә яратмый торган кыз булып чыкты ул. Әзрәк кыргыйрак, кырысрак та иде. Жиде ел буе күрешмәгән егетен кочаклап, кысып үбәсе урынга, ул, килүгә үк, юеш чүпрәк белән сулы чиләккә ябышты, өйнең тузанга, пычракка каткан идәннәрен, бусагаларын юып чыгарды. Эш авырга китте, ахрысы, кыз сонрак (ул Инсафның әнисе кебек үк йөрәк авырулы иде!) әзрәк тыны кысылганын тоеп, карават чатында йөрәк ягын тотып, уып утырды. Инсаф аны кочагына алды. Раушания карышмады, башын Инсафның муен астына төртеп, тын гына елады. Елый, димәк, ярата, елый, димәк, сагынган. Егет шулай дип уйлады. Ләкин егетнең күнеле инде күптән сагыштан, моннан туйган, ана хәзерге минутта дөнья шатлыгы, яшәү дәрте кирәк иде. Ни кызганыч, Раушания ана әлегә ул теләгән нәрсәне бирә алмый иде.

***

Әбиләр чуагы. Матур көннәр тора. Кояш, кыздырмый гына, тәнне, жанны эретеп кенә жылыта. Шундый матур, аяз көннәрнен берсендә Инсаф сарайга утын ярырга дип чыкты. Шактый озак ярды ул утынны, арыды, шуннан бик нык эчәсе килүен сизеп, өйгә керергә булды. Керсә — өендә бер чибәр хатын киштәдән китаплар актарып тора иде. Хужа кергәч, ул актаруыннан туктап, борылып, егеткә карап куйды. Юк, ул башын аска иеп, иреннәрен турсайтмады, йөзен дә яшермәде, ул кояштай балкып, ана карап, матур итеп бер елмайды. Аны күргәч үк, Инсафның йөзләре яктырып китте. Менә бит ул, менә кем кирәк ана! Юк, аны чибәрләрнен чибәре дип тә әйтеп булмый, алай дип әйтергә никтер тел дә бармый, ләкин ул шул хәтле сөйкемле иде, каһәр, ягымлы, аны менә хәзер үк кочып алып, шашып үбәсе, иркәлисе килә иде! Озын чәчләре кара төстә булган, күрәсен, ләкин ул, заман шаукымына ияреп, аны жирән төскә буяткан, гомумән, ул төсе-кыяфәте белән бер генә дә авыл кызына охшамаган, ул кала кызына тартым иде. Аның кайчандыр калада яшәгәнлеге, авылга мәжбүри хәлдә генә кайтканлыгы әллә каян беленеп, сизелеп тора. Кайбер авыл кызларына син хет әллә нәрсә кидер, ясат, буят, ләкин алар барыбер авыл кызы булып калалар. Ә бу кыз, бу ханым исә бөтенләй үзгә кеше иде! Инсаф белән хатын бер-берсенә жылы гына карашып куйдылар, аларның күз карашларында бер-берсен ярату, ошату сизелде һәм аларда: «Син минеке бит, наным, мин синеке бит, жаным!» — дип язылган сыман иде...

— Инсаф! — дип дәште аңа хатын. Кара, ул инде аның исемен дә белә. — Бу хатын синең янга ни өчен килгән, дип уйлыйсыңдыр инде, име?

— Син...

— Нәрсә?

— Кияүдәмени?

— Ә нишләп әле мин кияүдә булмаска тиеш ди!?

— Димәк, ялгышмаганмын. Син килгән кеше. Хатын-кыз кинәт кенә чит авылга кайтып төшми. Аны алып кайталар.

— Килмешәк, димәкче буласыңмы?

— Юк, алай димим. Син минем исемне беләсең, ә мин синекен белмим. Исемең ничек?

— Белмәвең әйбәтрәк булыр...

— Шулай да?

— Ландыш.

— Ландыш, син кем хатыны соң?

— Латыйп хатыны.

— Латыйп!? Әпти Латыйбымы?

— Кушаматын белмим. Фатхуллин Латыйп хатыны мин.

— А... а...

Инсаф агарынып китте, аның чырае качты. Нәрсә, нәрсә, ләкин шушы чибәр хатын авызыннан шул адәмнең исемен ишетәсе килмәгән иде аның. Хәер, Әпти хатынына барыбер, күрәсең, аңа кем хатыны булса да килешә һәм беренче карашка ул Инсафка әзрәк җинел акыллы булып күренде.

— Ни булды? — дип сорады Ландыш.

— Юк, берни дә юк, — дип җавап бирде Инсаф, ниятен яшерергә тырышып. — Бар да тәртип...

— Күреп торам! — Хатын шактый сизгер җан булып чыкты.

— Нәрсә күрәсең?

— Латыйпның исемен ишетүгә үк, чыраең коелды. Дошманың мәллә?

— Юк, дустым, — диде Инсаф, киная белән.

— Әйт дөресен, мин туры сөйләгәнне яратам!

— Юк, мин...прусты көнләштем!

— Нидән?

— Шундый чибәр, акыллы кызны Әпти малае ничек итеп каптыра алды икән? Маладис Латыйп, булдырган! Башка сүзем юк!

Инсаф моны чын-чынлап әйтте. Ләкин Ландыш аның соклануын уртаклаша алмады. Ул башта сүзсез калды, озак кына эндәшмичә торды. Аннан китте, китте: беренче генә күрешкән егет кешегә барсын да ачып, сөйләп бирде. Ачылып сөйләде, эчендәгеен бушатты: туры сүзле иде ул, күрәсең, ихлас җанлы...

— Чын дөресен әйтимме?

— Әйт.

— Бишкүлгә мин үз теләгем белән кайтмадым. Латыйп мине алдап алып кайтты.

— Алдап!?

— Әйе...

Ландыш Карасудан булып чыкты. Башта ул Алабугада укыган, аннан Казанга киткән. Казанда ул бергә укыган Асия исемле бер иптәш кызын очраткан. Ул шуна кунакка кайта. Өч көн Бишкүлдә яши. Латыйп белән таныша. Ул Асиянең туганы булып чыга. Өченче көнне Асия каядыр югала. Өйдә беркем дә калмый. Латыйп аны үзенә алып кайта. Җибәрми. Кызны урлаган кебегрәк килеп чыга.

Соныннан ачыклана: Латыйп Асия белән алдан ук сөйләшеп куйган икән. Ул Латыйпка каршы килә алмый, язмышына буйсынырга мәҗбүр була...

— Менә шулай итеп мин сезнең авылда калдым! — дип нәтиҗә чыгаргандай итте Ландыш. — Туктале! Нишләп соң мин боларның барсын да сиңа сөйлим!? Мин бит бу йортка бөтенләй башка йомыш белән кердем...

— Нинди йомыш?

— Мин китапханәдә эшлим. Миңа китап кирәк.

— Нинди китап?

— «Ак чәчәкләр». — Инсаф Ландышның янына ук килеп басты һәм аның кулыннан алып, аны чак кына битеннән үпмичә калды.

— Нәрсә?

— Әпсәләмов...

— Ә?!

— ...китабы...

— Әпсәләмов... бармы соң ул бездә?

— Бар...мин аны күрдем...

Хатын кулы белән киштә ягына ишарә ясады һәм инде үзен кочакларга торган егеттән җиңел генә качып, киштәдән Әпсәләмов томын тартып чыгарды. Китапханә китабы кулдан-кулга йөреп шактый таушалган, битләре саргаеп, мунчалага әйләнгән, тышындагы хатын-кыз сурәтен танырлык түгел иде. Инсафның хәтере ялгышмаса, китапның тышына ак халатлы шәфкать туташы сурәте төшерелгән иде...

— Китапханә китабы. Унҗиденче битендә мөһере дә бар...

— Мөһере булгач, аласың инде...

— Нариман абый... әтиең име?

— Әйе, әтием.

— Күптән укырга дип алды. Тик кертеп кенә бирергә өлгерә алмады.

— Үлде әти...

— Әйе... Йорт бикле, китапны кайтаручы юк. Ә ул һаман да минем өстә тора.

— Кем? — дип сорады Инсаф һәм, ниһаять, ул Ландышның кулыннан тотты. Күп тә узмас, ул, ханымны кочагына алып, аны күкрәгенә кысар төсле иде.

— Әпсәләмов. — Ландыш, Инсафтан ычкынып, ишек ягына атылды.

— Туктале! — дип кычкырды аңа егет.

— Әйе!?

— Аны озынайтып булмыймы?

— Нигә?

— Минем дә укыйсым килә!

— Була, — дип килеште хатын, — тик аның өчен китапханәгә килергә кирәк...

Китапханәче чыгып киткәч, ул озак кына үз-үзенә урын таба алмады. «Шайтан! Ни булды соң аңа? Ни булды!?» Ул котырынып китеп урындыкка типте. Каты типте — урындыкның арткы аягы очып ук чыкты һәм ул шундук күтенә утырды. «Латыйп... Латыйп... килсә дә килә бит кешегә бәхет, килә! Тыныч тормыш, чибәр, акыллы хатын...» Акчаны эшли белсә дә, шабашниклар бригадасы белән җитәкчелек итсә дә, нигездә, ул бер авыл наданы иде, ул бит мәктәптә укыганда да бер елын утырып калды. Ә хәзер әнә кем булган! Нинди хатын алган! Көрешеп, аңлашып аласылары бар әле аның Латыйп белән, бар! Аның турында күп нәрсә белми шул әле Ландыш, белми һәм ул үзенең кем белән яшәгәнен аңлап та бетерми шул. Белер тиздән, белер, иншалла!

### 3

Ландышның Инсафка керүен дәү әнисе дә күреп калган икән. Күрмәсә дә, житкергәннәрдер, күрәсең. Икенче көнне килүгә үк, ул шуның турыда чәйнәргә тотынды. Инсаф кебек үк, Кәримә дә Латыйпны өнәп бетерми, алай гына да түгел, ул аны бөтенләй күралмый икән.

— Әптиләр килене нишләп керде? — дип сорады ул.

— Әпсәләмовка кергән! — дип шаяртқан булды Инсаф.

— Кемгә?

— Әти кайчандыр китап алган булган. Әпсәләмовны. Китапханәче шуны сорап кергән.

— Ул аны миннән бер сораган иде инде.

— Нигә бирмәдең?

— Жаны чыксын! — дип акырды Кәримә. — Әптиләр белән кушылган кеше жүнле була димени!

— Латыйп хатыны булып чыкты ул.

— Нәрсә тапкандыр ул шунарда, белмим. Кунакка кайткан жиреннән алып калды ул аны. Хәер, Латыйпка чыккач, үзе дә әллә кем түгелдер инде. Байлыгына кызыккан, күрәсең.

— Матур хатын — сүз дә юк. Баласы бармы?

— Бар, малай тапты.

— Да! Бәхете ташыган икән Латыйпның!

— Син төрмәдә сөяк череттең, ә ул яхшы тормышта чибәр хатын белән чөкердәште. Шул кабахәт аркасында... сине...

— Дәвәни, кирәкми! — дип кычкырды Инсаф.

— Нәстә акырасың?

— Үткәннәрдә казынмыйк! Булган — беткән!

— Ачуым чыга бит, балам! Атаңны да ул гына кыйнатты...

Ниһаять, дәү әнисе күңел эчендә йөрткән серен ачты. Хәер, Инсаф өчен ул инде зур сер түгел иде. Латыйпның кансызлыгы хакында аңа берничә кеше килеп сөйләде. Беркемгә дә сөйләмәскә ант итеп, ул алардан үзенә бөтен мәгълүматны да ала алды. Яшьләр арасында Инсафка карата хөрмәт тә, ышаныч та зур иде.

— Менә ансы башка разгавур! — диде ул нидер ниятләп. — Бу эш буенча Латыйпны күрәсем бар әле!

— Зинһар, суга күрмә! — дип борчылды дәү әнисе. — Утыртып куймасын!

— Мин ул Латыйпны узачак әле, дәвәни, бер узачак! — дип өзгәләнде ул.

— Ничек? Нәстән белән?

— Тракторга утырырга хыялланам. Немец машинасына. Инвестыр белән сөйләшергә уйлыйм. Төшемле эш. Ә көзгә... көзгә мин өйләнәм...

— Кемгә?

— Раушаниягә.

— Раушаниягә?

— Ие. Багыш кызына.

— Ай! — Кәримә ухылдап йөрәген тотты һәм шул килеш, артык кабаланмыйча, акрын гына караватт кырына чүмеште.

— Ни булды, дәвәни?

— Юк, берни дә юк, улым...

— Әйтеп бетер... дәвәни!

— Яшьтән... чирле кыз бит ул. Әниеннеке күк... йөрәк паругы анарда. Ничек шулай кабатлана сун бу язмышлар, ә!?

— Әйбәт кыз ул. Күнеле яхшы.

— Яхшыдыр... әйтмим...

Раушаниянең йөрәк авыртулы икәнен Инсаф күптән белә иде. Ләкин аның анар бервакытта да исе китмәде. Раушания бармы — бар, исәнме — исән! Яшь кешегә тагын ни кирәк!

— Төрмәдә утырганда ул гына килде минем янга, дәвәни! — дип ни өчендер аклангандай әйтте ул. — Ул гына йөрде свиданиягә, ул гына передача ташыды. Андый кешене мин хәзер, ничек итеп, читкә этәрә алыйм соң!?

— Ансы шулай инде...

— Ярата ул мине, дәвәни!

— Ә син үзең?

Инсаф җавап бирмәде: «әйе», дип, баш кына селекте. Кәримә башын чайкап, авыр сулдап куйды. Билгеле, ул оныгына каршылык ясарга омтылмый, ә бары тик аңа бәхет кенә тели иде. Ләкин андый хәтәр чирнең ахыры ни белән бетәчәген ул, авыру бала үстергән ана буларак, яхшы белә иде. Алар нәселендә гомерендә (ире ягыннан да!) йөрәк авыруы белән интегүчеләр булмады. Зөмәрә исә туганда ук йөрәк өянәге белән туган. Башта аны авырый дип, беркем дә уйламады, бары тик сабыйга биш-алты яшьләр тулгач кына, йөрәк үзен сиздерә башлады. Приступлары башлангач, кызның тыны бетә, йөрәге кага башлый, йөзе агарынып, соңрак зәңгәрләнеп тә чыга иде. Андый авыруга операцияне яшь чактан ук ясыйлар, ләкин Кәримә кызына нигәдер ясаттырмады, курыкты. Каладан кайткан бер туганы, авыруларның сиксән проценты пычак астында үлә икән, дип сөйләп куркыткач, алар операциядән баш тарттылар. Соныннан үкенде үкенүен, ләкин соң булды. Зөмәрә гомере буе дару эчеп яшәде. Әле шул килеш тә ике бала тапты. Берсе үле туды, икенчесе, Аллага шөкер, исән, ләкин аның яшьтән бәхете генә булмады. Ә язмышлар, үч иткән сымак, кабатланып тора: инде менә Инсафның яраткан кызы да, Зөмәрә кебек үк, йөрәк белән авыртулы икән...

Хикмәт Раушаниянең бер үзендә генә түгел, билгеле, кызын төрмәдән кайткан егеткә кияүгә бирергә кызның әти-әнисе дә каршы иделәр. Алар ана әле һаман да кырын карыйлар иде. Әйе, ул армиядән кайтмады, төрмәдән кайтты. Авыл халкы нигәдер шикләнә андый кешеләрдән. Ә бит төрмәдә утырып, Инсаф начар якка үзгәрмәде. Начарлыкка, әшәкелеккә өйрәнмәде. Ул анда да чын ир-егет, мужик булып калды. «Блатной»лар арасында анардан көлеп, анар мыскыл итеп караучылар да табылды. Янәсе, чын «зык» бил бөгәргә тиеш түгел. Ләкин ул беркемгә дә һәм бернигә дә карамады. Кая куйсалар, шунда хезмәт итте. Цехта тимер койды, сетка бәйләде. Тагын шунысы да бар, хезмәт иткәч, вакыт та тиз узы. Әгәр дә үзенне төрмәдә беренче көнне үк шулай куймасаң, анда яшәве икеләтә, өчләтә авырая. Билгеле, провокация ясаучылар булды: тоткыннар арасында гына түгел, конвоирлар арасында да. Авыр булса да түзде, күз яшен түкмәде, өметен өзмәде. Аны өмет яшәтте, авылга кайтып, кешечә яшәү өмете яшәтте. Төрмәгә эләккәндә ул әле борыны астына мыегы да чыкмаган бер нәүмиз яшүсмер генә иде, ә ул аннан чын ир, чын мужик булып чыкты.

— Раушания өчен борчылма син, — дип тынычландырды ул дәү әнисен, — әнкәйгә операцияне вакытында ясаткан булсак, ул бүген дә безнең янда утырган булыр иде. Мин Раушаниягә операция ясатам. Калада бер шәп профессор бар минем. Мин аның малае белән утырдым. Эдик исемле. Йомшак кына, слабый гына бер малай иде...

— Пырафисыр малайлары да утырамыни анда, жаным?

— Профессор гына түгел, банкир малайлары да утыра анда, дәвәни, банкирлар хәтта үзләре дә утыра. Закон һәркемгә дә бер...

— Ни булды пырафисыр малаена?

— Наркотик белән. Хәзер бөтен төрмә шулар белән тулган бит инде. Иң мәгънәсез, иң әшәке статья. Башта бик кыерсыттылар аны. Мин аны берничә мәртәбә яклап чыктым. Шунын аркылы анын атасы белән танышырга туры килде. Ул мина телефон аша рәхмәтләрен житкереп торды. Эдик әллә ни озак утырмады, атасы аны тартып чыгарды. Зур кеше чөнки. Профессорның әйтүе буенча, операция артык катлаулы булмаячак. Хәзер технология югары. Әзрәк кенә акча эшләп алам да, Казанга, клиникага алып барам жаныемны! Ярты бәягә генә ясаячаклар! Менә шуннан сон берәр сүз әйтеп карасын мина анын әти-әнисе! Авызларын да ачалмаслар!

—Ярар, әйдә, без дә авыз ачыйк! — дип көлде Кәримә һәм оныгына дип алып килгән ашамлыгын өстәлгә чыгарып куйды. Дәү әнисе яшь бәрәнгедән, тәмле иттереп табикмәк пешереп килгән.

—О! Табикмәк! — дип шаклар катты Инсаф һәм шундук ашауга да ябышты. — Камыр азыгы, бәрәңге валюта иде анда...

— Жылытып аша инде, ашыкма!

— Жылытмыйча да тәмле ул!

— Яна тормышка өйрәнеп буламы сун, улым?

— Авырлык белән... һәркөн иртәнге жидедә торам да утырам...

— Нишләп?

— Тегендә гел жидедә торгызалар иде...

4

Раушаниянен атасы бүген ат жикте һәм ул шунар утырып менде. Колхоз таралгач, атлар кимеде, ләкин Гариф абзый, атсыз калудан куркып, ат асрый башлады. Ат эшкә дә, иткә дә бара. Атларны картайганчы тотмый, вакытында суя торган иде. «Ат тотмаган ир ирмени инде ул, атсыз калган колхозны колхоз дип әйтеп буламы!?» — дия торган иде ул, авыл хужалыгы турында берәр төрле сүз фәлән чыккаласа.

Бишкүлдә он тегермәне әле дә бар. Совет чорында төзелгән күп кенә тегермәннәр, икмәк пешерү цехлары тирә-якларда инде күптән таркалып бетте, ә менә бу авылда он тегермәне әле дә сакланып калган иде. Билгеле, хәзер анда югары сортлы он тарттырмыйлар, шулай да фуражга булса да ярап куя иде.

Алтын көз. Инде өченче көн янгыр яуганы юк. Аяз, кояшлы көн. Кырлары бушап калган такыр юлда янгыр эзләре күзгә чалына, су жыелган урыннарда бөжәкләр, комбайннан киселеп калган үлән бөртекләре йөзеп йөри. Урып-жыю эшләре инде бетеп бара, тракторлар көзгә басуларны сөрә башлады.

Ата белән кыз юл буе сөйләшмичә бардылар. Гариф абзый кызынын кияүгә чыгар вакыты житкәнен яхшы анласа да, анын төрмәдән кайткан зимагур белән кушылырга теләвен бигүк өнәп бетерми иде. Кызы өчен борчылудан битәр, ул халык алдында хурлана иде. Кемнен төрмәдән чыккан кешегә газиз баласын бирәсе, аны гомерлеккә төрмәче белән бәйлисе килсен ди. Бу турыда өйдә сүз күп булды, алар кызларына тегеләй дә, болай да анлатып карадылар. Ә Раушания барыбер үзенекен сукалады. Кызынын шундый үзсүзле һәм кире бала булуына шаклар катты абзый. Әйе, ул чирле, йөрәге чирле, шунын аркасында читкә чыгып китәргә дә жөрьәт итмәде. Авылда өйләнмәгән, акыллы егетләр шактый, житмәсә. Әнә Жәмәли малаен гына ал! Газда эшли. Акчалы. Кыз артыннан килеп тә, йөреп тә карады, юкса. Юк, яратмады шуны. Ә шул төрмә кошын нигәдер үз итте. Жүләр! Жиде ел көтте бит шуны! Ничә тапкырлар янына барды, качып барды! Апаларына кунакка барам, дип, калага чыгып китә дә, атналар буе шунда ята, төрмәгә свиданиегә йөри. Ярата, имеш! Ярату шундый була микәнни сон!?

Гарифнын аты тегермән янына барып туктады. Кызы: «Әти, мин озак

тормыйм!» — дип сарык тиресе җәелгән арбадан шуып төште дә, урам аша, иң беренче тыкрыкка кереп китте. Атның тезгенен рәшәткә баганасына бәйләп торган Гариф абзый, авыр сулап, кызның артыннан карап калды...

Нигәдер ашыгып барды ул. Алар инде өч көн күрешмәгәннәр иде. Уксты, кабаланды. Ә аңа ашыгырга да, чабарга да ярамый. Өйнең бусагасыннан атлап кергәндә аның бик нык йөрәге какты, тыны кысылды. Ул кергәндә, Кәримә әле һаман да онығы янында тәмләп чәй эчеп утыра иде. Кыз аны күргәчтен бер мәлгә югалып калды, кызарынды, бузарды...

— Ой...исәнмесез...

— Раушания! Кер! — Инсаф аны күргәч, исе китте һәм тиз генә ашаган урыныннан сикереп торды. Киләсен белдереп, хәтта кәрәзле телефоннан да шалтыратмады.

— Кер, әйдә! — дип кыстаган булды аны Кәримә. — Мактап йөрисең икән! Күчтәнәчтән авыз ит!

— Рәхмәт! Мин...бүген килергә дә уйламаган идем. Әти тирмәнгә он тарттырырга бодай алып мендe. Нигәдер анардан каласым килмәде. Килмәскә иде...име...

— Юк, син нәрсә! — диде Инсаф, аның кулыннан алып. — Бүген мин болай да синең артыңнан төшәргә дип тора идем әле. Шалтыратам, телефоның недоступен. Бүген миндә, беләсең килсә, аулак өй, яшьләр җыела...

Төрмәдән кайтканнан соң, дусларын, туганнарын, танышларын җыйнап өендә кунак итү уен Инсаф күптән башына киртеп куйган иде. Кайтуга ук кунак җыя алмады, ничектер килеп чыкмады. Аннан әлегә эшләми дә, акча яклары да такыр. Дәү әнисеннән мәҗлескә акча сорарга яхшысынмады, ашарлык-эчәрлек кенә ул аңа болай да биргәләп тора иде. Шуны аңлаган авыл яшьләре мәҗлесне, ягъни аулак өйне үзләре оештырырга булдылар. Хәзер яшьләр бер җыелып сыйлануны аулак өй дип атыйлар. Элеккеге заманнарда аулак өй ул яшь кешенең ата-анасы каядыр китеп, өйдә үзе генә калгач уздырыла торган бер күңелле чара булган. Борынгыдан шулай килгән. Тик заманнар алышына, заман белән кеше генә түгел, гореф-гадәтләр дә үзгәрә, йә ул янара, йә бөтенләй онытыла, бетә.

— Әйбәт кенә утырыгыз инде! — Кәримә шул сүзләрне әйтеп, әкрен генә урыныннан кузгалды. Инсаф ашыгып Раушанияне дәү әнисе белән таныштыра башлады. Алар бер-берсен кеше аркылы гына белсәләр дә, аларның әлегә кадәр очрашып күрешкәннәре булмады.

— Минем сезгә Кәримә апа дип түгел, ә нигәдер дәвәни дип эндәшәсем килә! — диде кыз. Монда ниндидер юмалану, яраклашу кебегрәк нәрсә сизгән, табигате белән шундый нәрсәне, төчеләнүне кабул итмәгән карчык:

— Вакыты житкәч, эндәшерсең! — дип коры гына җавап бирде.

— Дәвәни, китмә әле! — дип каршына төште ана онығы.

— Нишлим монда? Сезгә комачауламыйм, сөйләшегез рәхәтләнеп!

— Дәвәни!

Инсаф Раушанияне, кулыннан борып алды да, Кәримәнең каршына китереп бастырды. Кызның иплəп кенә биленнән каптырып, аны кочагына алды.

— Дәвәни, мин бит инде сиңа әйткән идем, — дип дәвам итте ул сүзен. — Без Раушания белән вәгъдәләшкән идек. Тиздән без аның белән өйләнешәчәкбез!

Кәримә: «Дөресме бу?» — дигән сыман булачак киләшкә карап куйды. Раушания, «әйе», дип башын аска иде. Карчыкның чытык чыраенда: «Миннән сезгә ни кирәк суң?» — дигән сөаль чагылды.

— Хәер-фатихаң, дәвәни! — диде шуны бик тиз аңлап алган егет. — Син бит минем әти белән әни урынына калган кеше!

— Капылт кына... Башка бәргән кебек булды. Әгәр мин булмасам, кемнән сорар идегез?

— Нәрсәне, дәвани?

— Фатыйханы?

— Ходайдан! — диде Инсаф.

Кәримә яшьләргә сәер генә карап-карап торды да, болай диде:

— Әй, балалар, ничек каршы килә алам ди мин сезгә! Риза мин, риза... тик... —Яшьләр бер мәлгә сагайдылар: карт кеше ни генә әйтмәс! — Бер-берегезне хөрмәт итегез, рәнжетмәгез! Рәнжеш һәрчак каргыш булып төшә, шуңардан сак булыгыз! Сәламәт йөрегез! Хәер-фатихам шул сезгә, балалар! — Соңгы сүзләрен карчык Раушаниягә адреслап әйтте, кыз аны аңлады, үпкәләмәде һәм карчыкның сүзләрен кирәк нәрсә, хак вә дөрес нәрсә итеп кабул итте.

— Менә күрәсеңме, барсы да җиңел хәл ителде! — диде Инсаф, дәү әнисе, аларга хәер-хак теләп, өйдән чыгып киткәч.

— Ә мин ышанмыйм, — диде аңа Раушания.

— Ышанмыйсың? Кемгә?

— Сина.

— Миңа?

— Син мине яратмыйсың. Син минем белән уйныйсың кебек.

— Мин? Уйныйм?

— Инсаф!

— Әү, җаным?!

— Үзеңне көчләргә кирәкми. Сөю йә ул бар, йә юк...

— Җаным, син нәрсә инде!? — Әйе, ул йөргән кызының холкын яхшы белә иде. Болай карап торырга гына гади, сабыр кеше кебек тоела ул, ә эчендә аның әллә нинди давыллар, җен-пәриләр уйный. Шул хәтле сизгер, ихлас һәм нечкә күңелле ул, аның белән уйнап, аңа ялган сүз сөйләп тә булмый. — Дәү әнидән кала, син минем бердәнбер якын кешем. Син — чын кеше. Син мине ташламадың, миңа хыянәт итмәдең. Төрмәдә утырганда мин үз-үземә сүз бирдем: исән-сау котыла алсам, чыгуга ук Раушаниямә өйләнәм, дидем...

— Үз сүзләреңне үзең үк раслыйсың түгелме? Мин синнән аерылмаган, мин сине ташламаган өчен генә үз-үзеңә сүз биргәнсең, антлар эчкәнсең. Бу бит әле чын ярату дигән сүз түгел, Инсаф!?

— Юләрем! — диде ул сөйгәнен кабат кочып. — Сине яратмыйча мөмкин түгел.

— Син мине кызганасың гына кебек. Ә кызгану белән ярату, ул икесе ике нәрсә. Мин бит сәламәт кеше түгел, син беләсең... Моны хәтта дәү әниең дә белә...

— Белсә нәрсә?

— Җәфаланма минем белән, тап үзеңә тиң кешене! — Раушания, Инсафның кочагыннан ычкынып, читкә тайпылды һәм нәрсә белән бетәр бу дигәндәй, тынып калды...

— Ә мин таптым инде!

— Кем ул?

Инсаф озак кына дәшмәде. Ул уйнады, билгеле. Раушания аңардан җавап көтте, куркып, сагаеп көтте. «Син!» — дип кычкырды егет һәм шундук кызны күтәреп тә алды. Раушаниянең кинәт кенә чырае агарды, сулышы капты. Егет аны тиз генә караватка утыртты.

— Бүтән алай эшләмә, яме! — диде кыз.

— Ни булды?

— Йөрәгем урыныннан куба дип торам...

— Гафу ит, чамаламадым.

— Зыян юк... ой... тәмам башым әйләнде минем...

— Мин сине анламыйм! — Инсаф кызның алдына тезләнде. — Кем син? Минем өчен кем син? Таш камерада утырганда гел сине генә уйладым, синең белән тизрәк күрешү турында хыялландым. Син миннән ерак булдың, ләкин син шундый якын идең. Менә хәзер син минем янымда, тик син миннән нигәдер еракта, каядыр бик еракта сыман...

— Әйе, бер еракта, бер якында... Нишләп шулай соң ул, Инсаф, нишләп?

— Белмим шул, җаным, әгәр белсәм икән...

Раушания, ашыгып, диварда текелдәгән күкеле сәгатькә карап алды. Әле генә учын йөрәгенә кысып торган кыз, тиз генә торып басты да, егет белән хушлаша башлады.

— Раушания...

— Әү?

— Каласыңмы бүген?

— Кая?

— Миндә.

— Синдә?

— Әйе, бүген миндә кич яшьләр җыйнала.

— Нигә?

— Аулак өй...

— Аулак өй!? — диде ул, елмаеп. — Бу йорт болай да аулак бит инде, син үзең генә торасың.

— Каласыңмы?

— Юк! — Кыз каты иде: уйнап, көлеп сөйләшергә яратмый. — Никахсызмы!?

— Аңладым...

— Аннан...

— Әйе...

— Мин андый күңел ачу чараларын яратмыйм. Чит кешеләр арасында читен миңа. Шау-шу, чыр-чуны сөймим!

— Кыргый, димәк...

— Әйе...кыргый, — дип килеште ул. — Дөрес әйттең, мин кыргый кеше. Мин кешеләр яратмыйм. Миңа син дә бик житкән. Мин...

— Калмыйсың, димәк?

— Юк, мине әти көтә... Ярый, миңа вакыт...

— Яхшы, мин сине төшеп алырмын!

— Кирәкми, йөрмә!

— Нигә?

— Әти мине барыбер җибәрмәячәк...төнгә...

— Син бит бала-чага түгел инде. Төшимме артыннан?

— Юк, мин үзем дә теләмим.

— Ну, ярар, үзенә кара, тик соңыннан үкенерлек булмасын...

Инсаф бу сүзләрне кызга берникадәр үпкәләбрәк әйтте. Кызның үзсүзлеге, тәкәбберлеге аның ачуын чыгарды. Раушания кабат-кабат: «Юк, килмим!» — дип әйтеп чыгып киткәч тә, бу юлы ул нигәдер аның артыннан чыгып йөгермәде, аны, гадәттәгечә, озата да бармады. Беренчедән, аның кырыс атасын күрәсе килмәде, икенчедән, ул шулай итеп яраткан кызын, ягъни булачак кәләшен тәрбияли алырмын дип уйлады...

*Ахыры киләсе санда*



Флёра
Гыйззәтуллина

# ИМИН ТОРМЫШ ЮЛЛАП ХАЛКЫМА

## Ачыла хәтер

*Милләтем — сөю ширбәтем.*
*Яралы маңгай сырым!*
*Миндәй чал шагыйрьләреңә*
*Карама, берүк, кырын!*
*Юнәлтә күрмә юлыңны*
*Денсезлек дәверенә...*
*Денсезләр, телсез, моңсызлар*
*Өрәккә әверелә.*
*Өрәкле зиндан түрендә*
*Тибрәлми милли бишек...*
*Йөрәкне үксез—моң телә:*
*Оныклар килә үсеп.*
*Ачыла хәтер: оныгың*
*Күкрәккә кысып сөйсәң...*
*...Оныклар түреннән калкып:*
*— Без — исән!!! — дибез... — исән!!!*
*Милләтем!.. Исәнлек белән*
*Бак хәтер чыганагың!?.*
*Куй башың, минем күкрәккә:*
*Җыр булсын сулаганың...*

## Бөре фалы

*Яз хөрлеге бит ул*
*Җир—Анага*
*Багышланып ачкан фалларда,*
*Җәйге таңда сары сандугачлар*
*Кунып сайрый торган талларда.*

Флёра ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА — *шагыйрә; Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. «Татнефть» һәм Татарстан Язучылар берлегенең С. Сөләйманова исемендәге әдәби премиясе лауреаты. «Йөрәгемдә шаулый карурман», «Башкаемда дөнья исәпләре», «Яну дәверләрендә» исемле китаплар авторы. Казанда яши.*

*Ил кодрәте — кылган догабызда —*
*Кыйбла тарафына йөз тотып...*
*Изге дога... намаз вакытында*
*Эри йөрәктәге мең котып.*

*Язгы якта һәр тереклек сакта!*
*Җан Кояшка таба талпына.*
*...Мин фал ачам бүген,*
*кодрәт юллап,*
*Имин тормыш юллап халкыма.*

*Мин фал ачам бүген киләчәккә,*
*Учта тотып җирнең күчәрен...*
*Башым куйган намазлыкка тиеп*
*Бәргәләнә бәгырь кисәгем.*

*Җир искәртә безгә яз килүен,*
*Назлап язның бөдрә бөресен.*
*Яздай эреп бер тыңлагыз әле —*
*Бөре фалы сөйли дөресен.*

*Бөре фалы: «Сөям... яратам...» — ди,*
*Яз түрендә дөрли-дөрли дә,*
*...Мин фал ачам...*
*ләкин үзем өчен*
*Кирәк түгел инде — берни дә.*

*Мин бит инде Җир кешесе түгел! —*
*«Яратам!!!» — дип артык өзелмәм.*
*Еллар узгач, бер багармын язга,*
*Тамчы булып шигырь күзеннән.*

## Чиксезлек

*Иреккә тугрылык — Ватанга тугрылык! —*
*Юл яру киләме көчеңнән?*
*Мәйданда: «Ирек!!!» — дип*
*Тилмергән көннәрнең*
*Минуты чыкмады исемнән.*

*Милләткә тугрылык — вөҗданга тугрылык! —*
*Онытмый яшәрбез йөзгәчә...*
*...Бер милләт кенәме?*
*— Вөҗданың барла! — дип,*
*Безгә бит күк дәшә, җир дәшә.*

*Безгә Хак Тәгалә, ышанып, тумыштан*
*Чәчәнлек хикмәтен йөкләгән.*
*Шигырьгә тугрылык — газапка тугрылык!*
*Кем безнең газапны чикләгән?*

## Могҗиза

*Сөю — сер... Ачсаң, —*
*Сындырып*
*сынарга риза бар да...*

*Ачкычы йөрәк серемнең*
*Туар могҗизаларда.*
*Сердә килешкән парларның*
*Булмыйдыр бәхетсезе...*
*«Сөйгән яр», — ди дә,*
*мөлдери —*
*Мәхәббәт — дәрья күзе.*
*...Күктәме, агымсудамы*
*Мәхәббәтемә дәвам?*
*Мин җиде катлы күкләргә*
*Дәрья күзеннән багам.*
*Давыллы дәрьяда ага*
*Мәхәббәт бизәкләрем.*
*Агымга каршы йөзгәндә*
*Өзелде үзәкләрем.*
*Серле могҗиза тудырдым,*
*Давыллар кочып ярда.*
*Кирәкми, мине,*
*кирәкми*
*Давылдан ышыкларга.*

## Ялвару

*Гөнаһ кылсаң, башкаеңны*
*Кайгы—хәсрәт баса икән!*
*Гөнаһлының чыраеннан*
*Иман нуры кача икән...*
*Хак Тәгаләм!*
*Мәслихәт кыл —*
*Иманымның көч—ныклыгын.*
*Бәндәләргә җитми бүген*
*Хәләл гамәл, хәләл белем.*
*Хак Тәгаләм!*
*Яшел юл ач*
*Туктап калган хакыйкатькә! —*
*Милли кыйбла сугарганда*
*Сарылмасын ят итәккә...*
*Раббым Аллам!*
*Көч—кодрәт бир*
*Яшь буынга яшәр өчен...*
*Игелекле иген кырын*
*Сөрер өчен, чәчәр өчен!*
*...Ил—көнемә иминлек бир!?*
*Бир илһамның гомерлеген...*
*«Ил!» — дип, үзәк өзелсә дә,*
*Өзелмәсен шигырь гөлем.*

*Бөек Тәңрем! Сакла безне!? —*
*Гөнаһ шомлыгыннан сакла!*
*Суд газапларыннан сакла,*
*Ут казаларыннан сакла,*
*Бакыйлыгыбызны хакла.*



Гөлинә
Гыймадова

# ПӘРӘВЕЗ ҖЕБЕ
## яки
# КЫЗ ӘБИ КЫЙССАСЫ

– А-а-а...

Нишли ул, нишли ул, йә? Дивана түгел, диген син аны! Акыл йөрәкне шулай сугә, ә йөрәк кысылганнан кысыла бара. Ул шулкадәр авырта ки, хәтта сулыш алулары читен. Бетәм дигәндә генә ачыргаланып кычкырып җибәргәч, тын юллары ачылып киткәндәй була.

Болай түгел иде бит әле. Намаз укыгач, җибәрә торган иде. Ә бүген... Бүген кышның кыл уртасында тәрәзәләрне киереп ачып һава алмаштыру да, хәтта өйалдыннан йомшак карга яланаяк йөгереп чыгу да булышмады. Хәмдиянен, кара төн житеп, авыл йокыга талгач, яланаякка гына кизитекләрен элеп, кырга чыгудан һәм өскә менә-менә авам дип торган йолдызларга карап, тавышы карлыкканчы илереп елаудан башка чарасы калмады.

– Нур-ис-л-а-а-а-м!

Яшьлегендә ләззәт белән пышылдаган бу исемгә бүген бер тамчы хәсрәт, бер тамчы үкенү хисе кушылган инде. Тып-тып-тып... Күз яшьләре түгел, гүя хәтер күзәнәкләре тама. Менә ул яргаланып беткән кулларындагы хәтер тамчыларына бага. Ә алар йолдызларнын саран нурларында берничә тәлгәш бәхет мизгелен искә төшерә. Хатынга шул берничә тәлгәш тә бик җиткән, ул инде тынычланган иде. Хәзер кар ерып, авыл читендәге йортына кайтасы да, ястык-мендәрләре өстенә авасы. Ул инде орлыгын койган башак сыман буш иде.

Тукта. Чү, ни бу? Хәмдиягә бер мизгелгә дөнья тавышлары тынып калган сыман тоелды. Ул төсе унган шәле астыннан бөселеп чыккан чәчен рәтләштергәләп куйды да, елаудан шешенеп авырайган күз кабакларын күтәреп, күккә бакты. Аннан тирән сулыш алып елмаеп җибәрде. Җаны күкләрдә, Нурисламы белән кавышырга томырылганда да, тәне рәхәт кенә оеп, йөзендә елмаю эленеп калган иде инде анын. Хатыннын иреннәре ул исемне пышылдарлык хәлдә түгел, аны җаны кабатлый һәм бөтерелә-бөтерелә күккә аша иде. Ул белә: Нурисламы да шул ук халәттә, ул да, күккә багып, аңа исеме белән дәшә, аңа ялвара иде.

***

— Кире!

Ноутының экранына төбәлгән кыз шул сүзне генә кысып чыгара алды. Аның йөзе чытылган, кечкенә генә куллары йодрыкка төйнәлгән иде.

— Кара инде моны! Үзе онлайнда, үзе ник бер сүз язсын!

Аһ, бу социаль челтәрләр! Дөньяның төрле почмакларында яшәгән адәм балаларын, тоткан да интернет пәрәвезе белән чолгап алып, компьютер экраннарына беректереп куйган. Күпме гашыйк җан бер җылы сүз, һич югы бер смайлик килеп төшкәнен көтеп таң аттыра. Бу Хәмдияләр чорындагы кебек капка төпләрендә утыру, йолдызлар янгыры астында күзгә багып аңлашу түгел шул инде. Хәмдияләр белән бергә аларның чоры да, зиратка карап, соңгы көннәрен үткәрә. Аннан өч аршын җир, тар ләхет, бәләкәй генә туфрак өеме кала.

Айзирәкне интернет белән чирлеләр рәтенә кертеп булмый үзе. Киресенчә, ул шундый сырхауларга ярдәм итүчеләр сафында. Коллегасы Витёк белән суицид дип шашканнарның төркемнәрен ачыклап, тормыш мәгънәсен җуйган кешеләргә ярдәм итә ул. Ә бит тормыш чыннан да ямьле! Чөнки аның Булаты бар. Тик менә ничәнче көн инде киребеткән Булат ник бер сүз язсын! Ичмасам, телефон трубкасын да алмый.

— Ярар, син дә бер кайтып төшәрсең әле. Тик ул чагында мин булмам!

Кыз шулай диде дә ноутын шапылдатып ябып куйды.

— Йокларга кирәк. Иртәгә яфрак бәйрәме түгел.

Әнисеннән кечкенәдән ишетеп үскән шул сүзләрне кабатлап, кыз юыну бүлмәсенә кереп китте. Иртәгә тагын җитәкчесе белән тарткалашасы була. Аны тарихчы дуслары Алтайга экспедициягә чакыра. Тик менә мөхәррире җибәрми. Янәсе, журналны озакка фотографсыз калдырып булмый. Харап икән, хәзер этендә дә, бетендә дә фотоаппарат. Айзирәк юк дип журнал чыкмыйча калмас иде әле.

Айзирәк яткач та күңеленнән җитәкчесе белән бәхәсләште әле.

***

— Нур-ис-л-а-а-м!

Таң әтәче кычкырып, җаннары тәннәренә атылганда, күктә хатынның инрәве эленеп калды...

Тагын шул төш! Онытылган иде бит инде. Айзирәк бу төшне беренче тапкыр күргәндә, әллә ни әһәмият бирмәде. Изге урыннар, космик энергия турында әллә ничә фәнни хезмәт укыган кешенең төшенә ни кермәс?! Менә хәзер генә ул аның сәерлегенә һәм үз халәтенең гайре табигыйлегенә төшенде. Тән камыр кебек йомшак, аны җыеп алып булмый, кул-аяклар оеган кебек тыңлаусыз иде.

Айзирәк көч-хәл белән торды да, эшенә җыенды. Ә инде фатир ишеген тышкы яктан яптыңмы, кала ыгы-зыгысы сине шундый бөтереп ала ки, анда төшең түгел, иртән нәрсә ашаганың да онытыла. Ул да онытты, төннәрнең берендә янә шул төшне күргәнче, Нурислам турында уйламады да.

— Мина психологка барырга кирәк!

Чираттагы тапкыр Нурислам белән саташкач, Айзирәк үзенә ярдәм кирәклегенә төшенде. Бу юлы ул төшендә картайган һәм Нурисламга китәр көннәрем дә күп калмады, сине көтеп кыз әби булып картайдым, дип сөйләде. Ул инде күкләргә ашмый, бәлки йолдызларга карап, сагышын тарата иде.

— Ә үлеп китсәм? — Айзирәк шушы уеннан корт чаккандай сикереп торды да тиз-тиз киенеп чыгып китте.

Менә шундый чакта күкрәгенә капланып еларга Булаты да юк бит, ичмасам. Тәмле-татлы сүзләр язып, күнелен биләп алды да суга төшкәндәй юк булды. Ә бит ул бергә укыган китаплар турында сөйләшүләрен, автор белән риза булмыйча, Тотыш белән Аппакны кавыштырырга тырышуларын сагына, бик сагына. Хәер, сөйләшү дигәне дә күпертү инде аның. Алар бит күрешеп сөйләшмәделәр дә, нибары интернет аша хат алыштылар. Аралашулары да кешечә түгел, төнге уникедән соң башлана иде. Интернет аша телефон номерларын алыштылар, бер тапкыр сөйләштеләр дә. Егетнең тавышы матур, ышанычлы кебек иде.

– Бәлки аңа минем тавышым ошамагандыр?

Айзирәк бу сорауны баш миендә көнгә ничә тапкыр әйләндерә һәм, алдан карышса да, хәзер инде чыннан да ошамагандыр, дигән нәтиҗәгә килгән иде.

Депрессия. Психолог ана шундый диагноз куйды. Заманның иң киң таралган чире инде бу. Аны билгеләр өчен, анализ биреп торасы да юк. Акча түләп, психолог катына гына үтәсе. Ә бит беренче сеанстан соң да җиңелрәк булырга тиеш иде. Ул исә өенә кайтырга һәм йокларга курка башлады. Һәр көнне үзенне картайган, бөкрәйгән килеш күр дә, мин үләм, Нурислам, кил инде, дип ялвар инде! Исеме Булат та түгел бит, ичмасам.

Айзирәк күнеле белән төшендә үз язмышын күрмәвен сизә, әмма бу төшнең ни өчен башта сирәк, аннан һәр көнне керүен аңламый иде. Бәлки ул кемгәдер ярдәм итәргә тиештер? Ә бит чыннан да! Бу уй аны уятып җибәргәндәй булды. Житте, башка психолог катына бармаска! Юкса табиб дигәне кырын карый һәм, үскәнем, минем бик әйбәт психиатр коллегам бар, дип юхалана башлады. Мин һәр көнне үземне кыз әби килеш төштә күрәм, мин тиздән үләм, дип сөйләнеп йөрсәң, сары йортка бикләп куярга да күп сорамаслар!

Витя аны аңлады булса кирәк. Язучы дусты, суицид белән көрәштәше хиромантия һәм тагын шуның ише нәрсәләр белән дә кызыксына бит әле. Дөресрәге, шушы нәрсәләр ярдәмендә акча эшләргә тырыша иде. Кыз коллегасының мавыгуыннан көлә, ана ышанучы беркатлыларга гаҗәпләнә иде. Әмма беркайчан да үзенең Витя, нишлим, дип ярдәм сораячагын башына да китермәде. Ә бит астралның сүзендә хаклык бар. Кемдер аннан ярдәм сорарга мөмкин. Ләкин кем? Ичмасам, ул бит әбинең исемен дә белми. Шул гомер нишләп аны үзе дип кабул иткәндер инде.

***

Чираттагы суицид өчен беткән авылны сайлаганнар. Айзирәкләр муеннарына таш бәйләгән ике егет белән бер кыз янына бик вакытлы килеп житте. Алар мондый очракта нинди сүзләр әйтергә кирәклеген белә, тәҗрибәләре бар. Бу юлы да коткарырлар. Тик шулай да мәгънә эзләгән бу яшьләр, аны табалмыйча, янадан жан кыю юлын эзләмәсләр дип кем әйтә ала? Менә алар, бөҗра ясап, дәшми генә басып торалар. Теге өчәү салкын күз карашын җирдә тәгәрәп яткан ташларга төбәгән. Кыз телгә килде: «Сез бит минем матурлык бозылмый, дигегез, ә алар йөзен чалшая, сиңа кызганып түгел, җирәнеп караячак, ди. Миңа андый эффект кирәкми...»

Аның сүзләрен азан тавышы өзде. Кирәк бит, кыйшайган-чалшайган иясез йортлар арасында яши торганнары булса, нибары бишәү булыр. Ә контор бинасына охшаган мәчеттә азан әйтәләр!

– Әйдәгез, мәчеткә!

Айзирәкне башта аңламадылар булса кирәк. Аннан барыбер каядыр барырга кирәк бит инде дигәндәй, аңа ияреләр. Мәчеттә аларны ап-ак сакаллы карт каршы алды.

— Классно!

Әле генә жанын кыярга маташкан кыз бала, мулланың күкрәгенә житкән ап-ак сакалын күздән кичереп сокланганда, күзләре баягыдай калайлы түгел, анда гамь бар иде. Джинс чалбарлы биш кешенең мулла артыннан аңлар-аңламас дога сүзләрен кабатларга тырышулары, тигезле-тигезсез сәждәгә китүләре читтән караучыларга, бәлкем, көлке тоелыр. Әмма болар әллә нишләде. Алар үзләре дә аңлатып бирә алмастай хис кичерделәр.

— Рәхмәт, бабай!

— Иманыгыз нык булсын, балакайлар!

— Бабай, исемегез ничек соң сезнең?

— Нурислам.

Айзирәк тораташтай катып калды. Төшләрендә нәкъ шушы күзләрне күреп саташты түгелме соң ул?! Шушы бөрлегәндәй кара, сынап караучан күзләр инде. Таптым мин аны, таптым!

***

Сонгы төшендә Айзирәк үзен ятакта күрде. Аның инде ялварырга да, бер-ике генә тәлгәш булган якты истәлекләрне барларга да хәле юк иде. Ләкин Хәмдия, күзен ачып, дөньяга сонгы кат багарга һәм, дерелдәгән иреннәрен рәхәт җәеп, бер елмаерга өлгерергә тиеш иде.

— Хәм-д-и-и-я!

Гомеренең иң сонгы мәлендә ул Нурисламы авазын ишетте.

***

— Бабай, Хәмдия кем ул?

Карт сискәнеп китте. Ул чандыр гәүдәле бу кыздан андый сорауны һич тә көтмәгән иде. Әллә Хәмдиянең оныгымы икән? Чая кызда Хәмдия чалымнары да бар кебек. Шундый ук дулкынланып торган куе коңгырт чәч, бәләкәй, җыйнак кына буй-сын, уйчан конгырт күзләр. Шул күзләр гомере буе эзәрлекләде аны. Кая барса, кая керсә дә, сынаулы караш күзәтә сыман иде. Гаепле ул аның каршында, нык гаепле.

Бабай, ымлап, артыннан ияәрергә кушты. Капкадан кергәч тә, йорт ягына түгел, бәлки бакча эченә атладылар. Түрдә, алмагачларның киң ябалдашлары кочагына кечкенә генә каралты сыенган иде. Эчкә үттеләр. Айзирәкнең борынын яна аертылган бал исе кытыклады. Ул шунда гына үзенең көн буена да бер валчык тәгам җыймаганын искә төшерде. Бабай калын итеп күмәч кисте, алдына чүмеч белән бал куйды, термостан чәй агызды. Айзирәк капкалаган арада бабай эш кораллары торган шүрлектән бер тартма алды. Сырлап эшләнгән агач тартма йозакка бикләнгән булып чыкты. Бабайның һәр хәрәкәтен күзәтеп утырган Айзирәккә әйтеп биргесез кызык, ул үзен хәтта әкияткә эләккәндәй хис итте. Бабай, авыз эченнән нидер пышылдап, тартманы ачты. Анда газеталардан кисеп алынган материаллар, нәрсәләрдер язылган дәфтәр битләре ята иде. Бабай барысын да тартмадан алды. Шулчак өстәлгә читләре ашалып беткән, каралып торган бер катыргы килеп төште. Бу фото булып чыкты.

— Кызым, бакчы, нәкъ син инде Хәмдия...

Айзирәк гаҗәпләнүдән чәйни башлаган ризыгын йота алмады. Чыннан да, ана үзе сынап карап тора иде. Тик башында кызыл косынка, өстендә ак төрткеләр сибелгән нечкә билле зәңгәр күлмәк, аягында резин итек.

— Бабай, мин бит бу!

Карт кеткелдәп куйды.

— Оныкларның әбиләренә охшавы гаҗәп түгел инде, кызым.

— Бабай, мин бит Хәмдия әбинен оныгы түгел. Мин аның хәтта кайда яшәвен дә белмим.

Айзирәккә үзен борчыган төшләре турында сөйләп бирергә туры килде.

Нурислам карт башын чайкады да, Раббыбызның бер хикмәте инде бу дип, хикәятен сөйләп китте. Ул кыска һәм җаннарны тетрәндерерлек гади иде.

— Хәмдия алдынгы комсомолка иде, мин — агитбригада җитәкчесе. Беренче тапкыр кырда, күкчәчәкләр арасында очраштык. Чәчен җил иркенә куйган, кызыл косынкасын муенына бәйләгән. Минем: «Синең кебек корыч атны иярләгән кызлар чалбардан, хром итектән була, күлмәк белән унайсыз түгелме соң?» — дип сораганым истә. Ни дип җавап биргәндер инде, хәтерләмим, һәрхәлдә җавабы чая булырга тиеш. Мина ул үткен кыз булып тоелды. Кич белән клубта аны һәм колхозның башка алдынгыларын мактадык, мин күкрәгенә значок тактым, күлмәклек ситсы тапшырдым. Кулын кыскандагы җылылык әле дә учымны кызыштыра, кызым... — Карт хикәятен учларына текәлеп дәвам итте.

— Юк эшне бар итеп, ул яшәгән якларга командировкага еш килә һәм кичке уеннан соң аны озатып куя башладым. Ул, гөнаһсыз күзләрен мина текәп: «Мин сина ышанам, Нурислам, син мина кагылмаячаксын...» — ди, ә мин: «Үз-үземә ышанмыйм, Хәмдия. Бәйдән ычкынудан куркам», — дип җавап бирә идем. Хәйран инде менә, кулга-кул тотынышкан да юк, ә без бер-беребезне гомер буе беләбез кебек.

...Хәмдияне очратканда, мин өйләнгән, ике балабыз бар иде. Гыйшкым коточкыч газапларга сала, Хәмдия янына барсам, күз алдында — хатын, өйгә кайтсам, Хәмдия тора. Хәмдияне онытырга да тырышам, әмма сагынуга түзә алмыйча тагын ул яшәгән районга барам. Нидер сизенеп, партком секретаре ачыктан-ачык сорау бирде. Мин икейөзле хәшәрәт булуымны таныдым. Шул сөйләшүдән соң Хәмдия янына башка бармадым. Әмма уңышлары турында ишетеп, аның хакында газетада уч төбе кадәр генә булса да мәгълүмат тапсам, кош тоткандай сөенә идем һәм андый язмаларны кисеп алып җыя килдем. — Карт тартмадан алган кәгазь өеменә ымлады.

— Ул бригадир да, колхоз рәисе дә булды, әмма кияүгә чыкмады. Аның ялгыз калуында үземне бик гаеплим, Хәмдия белән соңгы тапкыр очрашып, оныт мине, үз тормышыңны җайла, дип әйтергә ничә кат талпынсам да, батырлыгым җитмәде. Икебез ике якта: ул Татарстанның иң көнбатыш, мин иң көнчыгыш районында картайдык. Ике җан бер-берсен тапкан икән, алар, нинди вакытка, сәбәпкә һәм җирлеккә туры килүләренә карамастан, ахыр чиктә барыбер кавыша, дигән бер гыйлем иясе. Чөнки аларны пәрәвездән дә нечкә, күзгә күренмәс җепләр бәйли. Син, балам, безнең арада шул күзгә күренмәс җеп булдың һәм мина Хәмдиянең соңгы сулышын алып килдең. Гөнаһсыз җан, урыны оҗмахта булсын. — Ул кулларын догага күтәрде.

Картның күзеннән бер бөртек яшь сытылып чыгып, ап-ак сакал буйлап йөгерде. Айзирәкнең күңеленә нәкъ төштәгечә җанны өшетерлек сагыш үрмәләгән иде...

***

— Янгырдан соң саз ерып, җәһәннәмгә бармасаң ярамыймы сина, кызкатын?

Витёк нык ачуы килсә генә, керәшенчә «катын» сүзен кыстыра иде. Чыннан да, машиналары аз гына бара да ләмгә батып кала. Машина этеп, үзләре дә пычранып беттеләр, ә авылга һаман да барып житеп булмый. Айзирәк капылт

кына машинадан төште дә, җәйге аяк киемен кулына алып, яланаяк килеш авылга китте. Витяның кая барасың, дигән соравына юл читендәге тирәккә оялаган каргалар көче җавап бирде.

— Каар-р-р!

Абау, бигрәк шомлы як! Кая карама тал-тирәк, һәрберсендә каргалар шәһәре. Болар дәррәү кубып өстеңә ташланса... Айзирәк үз уеннан үзе куркып куырылып килде. Күп калмады инде, әнә зират та шәйләнә. Аңа яңа гына казылган каберне табарга кирәк. Төше рас булса, Хәмдия күптән түгел генә гүр иясе булырга тиеш. Менә ул туфрагы иңеп өлгермәгән калкулык, янәшәсендә бер егет мәш килә.

— Әссәламегаләйкем!

— Сәлам...

— Хәмдия әби кабереме?

— Аныкы, ә сез аны каян беләсез? Аның туган-тумачасы да юк иде кебек.

Илнур күрше егете икән. Чардуган корырга килгән. Хәмдиягә әби дип әйтүче булмады диярлек авылда, ул апа иде, дип сөйләде. Яшьлегендә бер кешене бик яраткан, ә ул аны алмаган дип сөйләгәннәрен, Хәмдиянең басукырларда үз-үзе белән сөйләшеп йөргәнен дә кыстырды. Әмма гаеп итеп түгел, яратып әйтә иде ул аны. Их, хәзер кызлар шундый тугры булса, дип Айзирәккә сынап карап та торды. Хәмдия кебекләр булсын, әмма аның сөйгәне кебекләр булмасын, диде Айзирәк, никтер Булатны искә төшереп. Кыз әманәтне үтәргә ашыкты. Нурислам бабай исән чакта күрешә алмасаң, кабере өстенә менә бу орлыклары чәчәрсең, дигән иде бит. Күкчәчәк орлыклары иде алар, беренче очрашкан көннәре төсе...

***

Поезд Алтайга чаба. Айзирәкне тизрәк илтеп җиткерәсе килә аның. Кыз исә кешеләр җавап бирә алмастай сорауларына җавапны шушы борынгы җирләрдә табасына ышана. Ике җанның тибрәлешен тойган нечкә күңеле борынгы бабаларының авазын да ишетми калмас әле.

Телефон чыңы уйларыннан айнытып җибәрде. Булат иде бу. Имән бармак яшел ноктага басам дигәндә генә, телефон кабат дерелдәп куйды. «Смс» хат килгән икән. Ул нибары бер сүз һәм бер смайликтан гыйбарәт иде. Айзирәккә рәхәт, бик рәхәт иде бу мизгелдә. Иреннәр аңлатып булмаслык бер ләззәт белән үзен Хәмдия язмышыннан аралаучы кешенең экранда чагылган исемен пышылдады:

— Сәлам, Илнур!



Сирень
Якупова

# ХИКӘЯЛӘР

## Туй алдыннан

Кызыл чәчәкле шәмәхә яулыгын артка чөеп бәйләгән, иллә дә калын пыялалы күзлеген киеп алган, сары төстәге, инде саннары танылмый да башлаган үлчәм тасмасын муенына аскан әнисе күлмәк кисәргә җыена. Зур имән өстәлгә җәеп салынган аллы-гөлле тукымадан күз алмалы түгел. Сажидә әбигә булачак бу. Сөмбелә бакча башларында гына яшәүче әбинең шул күлмәкне киеп, ак яулыгын туздырып ябып, җил-җил атлап йөрүләренә хәтле күз алдына китерде дә үзалдына рәхәт елмаеп куйды.

— Бизәге бик матур, әйеме, кызым, — диде әнисе, аның елмаюына елмаю белән җавап биреп. — Бисмиллаһ-иррахман-иррахим, ялгышмыйча кисеп-тегеп чыгарга язсын. Тыныч кына, дәшми генә утыр утырсаң, игътибарымны читкә алма.

Сөмбелә ярар диеп башын какты. Әнисенең эшләгәнен күзәтү бик ошый ана. Бу көннәрдә аеруча. Сабантуй атнасы бит. Аның мәктәпне бетергән җәе...

Әнисе яшел тышлы дәфтәрен алды. Шакмаклы битләргә күлмәк, алъяпкыч тектерүчеләрнең исемнәре, үлчәмнәре теркәлгән. Тегүче әнисе генә аңлый торган сүзләр, саннар, сызыклар, уклар шунда. Әлеге дәфтәрдә кызны һәрчак көләргә мәҗбүр иткәне — кушаматлар булды. Сөйләшкәндә әйтәсең инде аны, алар авылында кушаматсыз кеше бөтенләй юк. Ә менә Кәҗә Галиясе, Шыгыр Мәрьяме, Шүрәле Халидәсе, Чикерткә Рәхимәсе яисә Сильсәвит Мәдинә, Прит Әлфинур дип язу Сөмбеләгә бик мәзәк тоела иде.

Дәфтәрнең кирәкле бите ачылгач, «Зингер» машинасы тартмасыннан акбур чыкты. Акбурны күргәч, кызның кызыксынуы бермә-бер артты. Чөнки, галәттә, әнисе үлчи дә, сызгалап-бозгалап вакланмый гына, елтыр кайчысының кисми торган кыры белән эз төшерә һәм кырт-кырт кисеп тә ала. Акбур, өлге кебек нәрсәләр, йә кисәсе тукыма бик кыйммәтле, йә киясе кеше бик таләпчән, фырт булса гына кулланыла иде. Аптырады Сөмбелә, бүген тукымасы да ефәк яки кримплен түгел, ә гади штапель генә, Сажидә әби үзе дә, кем әйтмешли, күлмәк түгел, солы капчыгын да килештереп, риза булып киюче мөлаем карчык. Әнисе кызының гаҗәпләнүдән зур итеп ачылган күзләренә карауга:

Сирень ЯКУПОВА — *шагыйрә; «Йолдызлы уйлар», «Яшәү сере», «Остагелордон до остә» һ.б. китаплар авторы. Чаллыда яши.*

— Яхшы кеше Сажидә астай. Бүген төшемә дә бик матур, гел аклыдан керде. Кинәндерим әле үзен «мудный» яка уеп. Тукымасы күп, алъяпкыч та тегәрмен. Анысы өчен акча алмам, хәер булыр, — диде.

— Карт бит инде ул модалы күлмәк кияргә!

— Алай димә, кызым. Матурлык яшьлеккә дә, картлыкка да килешә. Күңел картаймый ул. Менә күрерсең, мин теккән күлмәкне кигәч, танымаслар әбекәенне.

Әнисе үлчәү тасмасын кулына алды. Сөмбеләгә, бәхәсләшергә бик теләсәң дә, телен тешләргә туры киләчәк, дигән сүз иде бу. Кыз шым булып, бер матурлыктан икенче матурлык туу халәтен күзәтергә әзерләнде.

— Өйдәләрме?! Исәннәрдәгенәмесез!

Хуҗабикә олы үткен кайчысын шап итеп өстәлгә куйды да кече якка ашыкты. Аның:

— Әйдүк, Сажидә астай! И-и-и, кунак кызлары да бар икән! Үтегез-үт, түргә узыгыз, — дигән сүзләре ишетелде.

Шундук ишеккә эленгән ал плюш ачылып китте һәм Сөмбелә каршысында берәм-берәм алты-җиде яшьләрдәге өч кызчык пәйда булды. Аннан, бисмилла әйтеп, бусаганы әбиләре атлап керде.

— Сөмбелә дә өйдә икән. Саумы, кызым!

Әби белән кул биреп күрешкәч, кызчыкларның буйга калкурагы аңа кулын сузды. Аның артыннан бәләкәчләр иярде. Сөмбелә кызларны чуар япмалы эскәмиягә тезеп утыртты, ә Сажидә әбигә йомшак диваннан урын бирде.

— Дога кылыйк, балалар...

Шул арада чәйнекне газга утыртып, олы якка чыгып өлгергән әнисе белән Сажидә әби бик озаклап дога укыдылар. Сөмбелә дә эчтән генә: «Амин... Амин!» — дип утырды.

— Кызым белән икәүләп сиңа күлмәк кисәргә җыенып тора идек әле. Гомерең озын булыр, үзең килеп кердең, — диде әнисе, әбигә җылы елмаеп.

— Рәхмәт инде, Зөләйха. Кулларың алтын синең!

Шулчак әнисе, һай, онытып торам икән, дип, халат кесәсеннән сары борчак кәнфитләр чыгарып, балаларга өләшергә тотынды. Сөмбелә дә кулын сузды. Аның учына да берничә борчак тамды. «Бәбәй», — диде әнисе, аңа яратып карап. Аннан янә кызчыкларга борылды.

— Күр әле бу сандугач балаларын! Ничек матур тезелешеп утыралар! Төпчек малаенныкылар бит, әйеме, Сажидә астай?

— Менә бу игезәкләре — Алия белән Гөлия — Гариф улымның оныклары, бер яшькә зуррагы, Ләйсән исемлесе — Сания кызымныкы.

— И-и, бер-берсенә охшашлыкларын күр әле син. Өч тамчы су инде менә.

Сажидә әби кеткелдәп куйды.

— Күргән берсе шулай ди. Әле монда килешли Бүре Рәшитләренә кердек. Разбурка булды.

— Нәрсә булды?

Сөмбелә прых-х-х итеп көлеп җибәрде.

— Разборка, әни! Нидер аныклау, ачыклау, димәк.

— Әйе, әйе, разбурка! Менә шушы Рәшит кече малае Әмиргә шәһәрдән олы лисәпид апкайтып биргән. Сигез яше тулган көненә, ди. Теге ристаны, буе җитмәгән көенчә, рам астына кереп булса да, бер-ике көндә йөрергә дә өйрәнгән.

— Бик тере, булдыклы егет шул Әмир, — дип елмайды әнисе.

— Кичә генәк менә булдыклы егет булдырган да инде — тыкрыкта лисәпиде

белән минем кызларымны таптаткан. Дүртесе дүрт якка тәгәрәгәннәр, «тимер тай» — бишенче якка ауган. Теге башкисәргә берни юк, лисәен торгызган да чапкан. Минекеләр елашып кайтып керделәр. Кайсының тезе, кайсының терсәге кан.

Шул сүзләрдән соң әбинең оныклары, команда булгандай берьюлы, яшел дару сөрткән яраларын күрсәтештеләр.

— Күрдегезме? — диде Сажидә әби, өф-өф итеп кызчыкларның аяк-кулларына өрә-өрә. — Рәшит хатыны Равия дә аһ итте. И зләкте соң Әмиргә анасыннан! Җәлләп тә куйдым үзен. Алай да, имгәтсән, Аллам сакласын, үтерсәң кызларымны, ни була иде дип, кушылып орышасы иттем. Куркытам янәсе, сабак булсын, дим.

— Елагандыр балакай?

— Тамчы да яше чыкмады. Житмәсә, мина усал карап: «Берсе үлсә, икесе кала. Да чурта бит алар сездә!» — дип ярып салды.

Сажидә әби тагын кеткелдәп куйды. Ана әнисе дә кушылды.

— Һай, бу малайны! Өйрәтеп куйганнар диярсең... Ә кызыкайларның ярасы туйга кадәр төзәлер, Аллаһы боерса.

— Сабан туена кадәрме? — диде Сөмбелә.

— Әйе, әйе, туйга кадәр... Әйдәгез әле, чәйләп алыйк, кунак кызларының баллыдан телләре ябышты ахрысы, ләм-мим бер сүз дәшми утыралар, — дип сүзне икенче тармактан җибәрде әнисе.

— Юк, юк, — диде әбекәй. — Чәйләр эчеп тормыйбыз, йомышны йомышлыйбыз да кайтабыз. Хәлем киткән кебек бераз. Сонга калмыйк дип, кызурак атланылды. Ни бит әле, Зөләйха... Мин үземә күлмәк тектермәскә булдым.

Сөмбелә дә, әнисе дә мондый борылышны, әлбәттә, көтмәгән иде. Тик гомере буе кеше көен көйләп өйрәнгән тегүче үзен бик тиз кулга алды, сер бирмәде. Бер дә аптырамагандай:

— Ярар соң, Сажидә астай. Хәзер төреп бирәм тукыманны. Жепле кәтүген дә... — дип имән өстәлдән шау чәчәкле штапельне жыя башлады. — Өлгерден, кисә башламаган идем.

— Туктале, Зөләйха, ашыкма. Элгәре тыңлап бетер. Минем ул тукымадан... менә бу кызларыма күлмәк тектерәсем килә. Биш митр житәдер бит өчесенә? Сабантуйга өлгертәсе иде! Акчасын күпме сорасаң да бирәм. Кичә генәк пинсә китерделәр.

Сажидә әби акча, ачкыч ише әйберләр өчен күлмәгендәге махсус салынган тирән кесәсен капшап куйды. Кызчыклар да, Сөмбелә дә жанланып киттеләр. «Әйе шул, пардан күлмәк искиткеч булачак бу кычыткан чыпчыкларына! Карт кешегә нигә инде ал да гөл? Өстендәгесе дә бер дигән әнә», дип уйлап куйды Сөмбелә бер әбигә, бер әнисенә карап. Тик әнисе ризалашырга ашыкмады.

Башта ул Сөмбеләгә ымлап кече якка күрсәтте. Чәйнек плитәдә, онытма, диюе. Аннан әби янына диванга килеп утырды.

— Чу әле, Сажидә астай. Әлмәттән яраткан киленем апкайтты дигән идең ич күлмәклекне. Үпкәләсә-нитсә?

— Анысы булыр инде бераз. Икенче кайтуыма әбәзательнә тектереп ки, инәй, диепләр китте.

— Шулай булгач! Юк, үзенә тегәбез! Кызларынамы?.. Кызларына... Аръяк универмагына зәңгәрсу жирлеккә ак бизәк төшкән тукыма кайткан. Нәкъ жәйге күк йөзе инде менә! Алам дисәң, хәзер үлчәп әйтәм, күпме кирәк буласын. Тә-ә-әк...

Әнисе, каршылык күрсәтүче булмаячагына чын-чынлап инанып, муенына

эленгән «сантимитрын» җәлт кенә кулына шудыртып төшерде дә лупа-күзлеген киеп, торып ук басты... Тик ул ашыккан булып чыкты.

— И Зөләйха, юкка мәшәкатьләнәсең... Минем үз сүземнән кайтмый торган «кире карчык» икәнлегемне беләсең бит инде. Гомер бакый бергә яшәдек...

— Аллага шөкер, дус, тату яшәдек, Сажидә астай. Бөтен карчыклар да синең кебек булсыннар иде әле ул, — диде тәвәккәллегенең эзе дә калмаган әнисе. — Ходаем шаһит, бигрәкләр дә шушы тукымадан күлмәк тегеп кидертәсем килгән иде сина! Әле бүген үзенне тан алдыннан гына төштә дә күреп уяндым.

— Ничегрәк кердем соң? Убырлы карчыкка охшапмы?

Сажидә әби тагын кеткелдәде. Кызчыклар да авызларын тотып пырхылдаштылар. Ә Сөмбелә әбинең елмаю аша да сизелгән, нидер көтеп, сагаеп калган йөзен күргәч, әллә нишләп китте...

— Йә, сөйлә инде, бер башлагач, кайларда йөри идем, хушлашып китеп бардыммы?

— Каян беләсең, Сажидә астай? Җүләр кеше әйтмешли, әллә соң ул төш түгел, өн идеме? Чыннан да, син аклы күлмәктән, ак яулыктан кулыңны болгый-болгый шомыртлыкка кереп югалдың...

— Шомыртлыкка?! Шомыртлары кара идеме, Зөләйха?!

— Яз иде бит. Ап-ак чәчәк дингезендә эредең, Сажидә астай...

— Алай булса бер хәл...

Әби уйчан күзләрен сыпырып куйды.

— Төшләребез бертөслерәк булган икән шул. Димәк, рас киләчәк. Күнелне алдап булмый, бик сизгер ул, Зөләйха. Мин дә бүген иртән төш күреп уяндым. Торгач, бик тикберләп яшел сандыгымны актардым. Хәерлекләремне, ак бүз күлмәклегемне барладым... Вакыт җитә, күрәмсең... Син тынла инде мине, күрше. Истәлегем, төсем итеп тегеп бир кызларыма күз явын алырлык матур күлмәк. Сөендер сабыйларны, соңгы әманәтемне үтә...

Сөмбелә, әллә әбинең серле, монсу сүзләреннән, әллә әнисенең яшьле күзләреннән качарга теләп, сикереп торды да, кискен хәрәкәт ясап, үзе йоклый торган почмакны каплап тарттырылган чаршауны ачып җибәрде. Көмешсыман елтыраган карават башында итәге, түше ак атластан булып, фонарь сыман җиңнәре, якасы ак челтәрдән үрелгән күлмәк эленеп тора иде.

Кызчыклар аһ иттеләр.

— Туй күлмәге мәллә?!

— Әйе, — диде әбекәй, тирән сулап. — Гомер ул туйлардан тора. Апагыз әнә яшьлек туена — чыгарылыш кичәсенә әзерләнә... Сезнең өчен Сабантуй җитә. Ә минем исә... үз туем туй...

## Аты юкның...

Мин ир-атсыз йортта үстем. Әйе, ирсез дә, атсыз да. Әниемнең ире, әтием, бик иртә дөнья куйган, ә атыбыз... Ирсез йортта каян булсын ди ул?! Хатын-кыз ат асрыймыни?! Гомумән, аларны янәшә кую да сәер. Кайбер авылдашларым шундук каршы төшәр. «Ә быргадир Вәсимә апа?!» Чынлап та, ул «Васька апа»ны мин гел тарантаста яки арбада утырган килеш кенә хәтерлим. Шунысы бар: гомеренең күп өлешен яхшы айгырларда гына җилдергән әлеге апабыз энесе гаиләсендә яшәде. Димәк, барыбер ирле йортта булып чыга. Атын җигүче, тугаручы, сугаручы, дагалаучы, тышаулаучы ир булган йортта...

Ә мин ир-атсыз йортта үстем, дидем... Әтиләргә читтән генә кызыгып, атлылардан читтән генә көнләшеп. Төшемдә еш кына үземнең ат өстендә йөргәнемне күрә идем. Юк, кая йөрү ди, чаба идем, оча идем мин ат ялына

ябышып! Ул хыялый ат ап-ак була торган иде, яллары озын, йомшак... Әллә соң ул болыт кына идеме икән? Кем белсен... Өнемдә исә атны абыемнан калган иске «лисәй» алыштырды. Оялчан гына, сабыр гына кыз баланы шул «велик» танымаслык итеп үзгәртә дә куя иде, билләһи. Ул чакта иксез-чиксез булып тоелган сикәлтәле болын юлы, иркенлек, каршы искән җәйге җил — шуннан да рәхәт мизгелләрнең булуы мөмкин түгелдер кебек иде миңа!

Үзем хәтерләгән беренче китабым да ат турында булды. Юк, «Алмачуар» түгел, соңрак аны да укыдым, билгеле. Ә менә иң тәүгесе «Канатлы ат» иде. Сукыр лампа яктысында сандык өстенә аягын бөкләп утырып, әле җидесе дә тулмаган кызчыкның әнисенә шигъри әкият укыганын күз алдына китерәсезме? Уку гынамы, тылсым эчендә яшәү инде ул! Шулай булмаса, каһарман егет, падишаһ әмерен үтәп, кайнап торган сөтле казанга чумарга тиешле урынга җиткәч, күз яшьләренә буылып:

— Алга таба укымыйм! Укымыйм! Ул хәзер пешеп үләчәк бит! — дип елап җибәрмәс идем бит инде.

Әнием еларга да, көләргә дә белми:

— Тынычлан, кызым... Үлми ул егет, канатлы аты аны коткара, — дип бик озак үгетләгәч кенә, янә китапны ачып, укуымны дәвам итә алдым. Коткарды бит тәки хуҗасын канатлы ат!

Әкияттә генә түгел, чын тормышта да ат кебек тугры, чыдам җан иясе бармы икән соң ул?!

Дөресен әйтергә кирәк: атлардан бераз шүрли дә идем мин. Кечкенә чагымда ындыр артында булсынмы, су буендамы, яннарына бик якын килми, читтән генә күзәтүне, соклануны артыграк күрә идем. Тыкрыкта-фәлән атлы очраса, коймага елышып, тын да алмый үтеп киткәнен көтә идем. Үсә төшкәч тә әле, атлылар аркасында, елның бер көне минем өчен урамга бөтенләй борын тыкмаслык көнгә әйләнә иде. Ул да булса — Сабантуйга бүләк-сөлгеләр җыйган көн. Безнең авылда бу борынгы матур йола язгы чәчүгә чыкканчы, җир кипкәнче башкарыла иде. Көнен билгеләгәч, өстән яңгыр явып торамы, аяк асты баткак буламы — барыбер, авылда күпме шәп ат бар, һәммәсен егет-малайлар иярли. Авылыбыз зур, илле-алтмыш җайдак җыела. Атлары биеп тора, койрыклары төйнәлгән, егетләрнең кулларында чыбыркы, урам тулып гөрләп киләләр. Искиткеч тамаша! Тиздән, әле түбән урамда, әле өстәгесендә, теге очта, бу очта җыр аралаш: «Рәхмәт! Рәхмәт!» —дигән шатлыклы авазлар яңгырый башлый. Көн уртасына инде сөлге-яулыклар бәйләгән колганы күтәрерлек түгел. Шул арада җайдаклар төркемендәге егетләрнең берәм-берәм беразга югалып торуы да шәйләнә. Алар, бер-берсенә сиздермәскә тырышып, дус булып, күз атып йөргән кызларның капка төпләреннән әйләнеп килә. Билгеле инде, төркемгә кабат кушылганда, ат йөгәнендә әллә ничә чиккән кульяулык җилферди. Кульяулык саны буенча егетнең кызлар алдында тоткан абруе билгеләнгәнгә, ул көнне ялгыз атлыны очратмый күршегә дә керүе читенләшә иде. Капканы ачуың була, җир астыннан үсеп чыккандай, өсте-башы ат тоякларыннан чәчрәгән сазга чумган сабакташың яисә күршең пәйда була. Ат өстендә хан малае кыяфәтендә утыручы, авызы колагына җиткән егетнең сүзе бер генә:

— Кульяулык чиктеңме? Сөендер мине дә, атымны да!

Шулчак син йә кесәңнән чыгарып яулык сузасың, йә тизрәк өенә кереп шыласың инде. Соңгысы ешрак була иде. Һәммәсенә каян чигеп бетерәсен дә каян бүләк җиткерәсең. Җайдакның гына түгел, атның да сөмсере коелгандай тоелса да, сер биреп торыш юк, ике урамны бер итеп, ары китеп баралар. Синнән булмады, башкалар табылыр, янәсе...

***

— Айдар энем, быел Сабантуйга сөлге җыйдылармы соң?

— Әйе! Мин дә катнаштым.

— Син?! Ат мендеңме әллә?

— Ат нишләдем?

— Атка атланып йөрдеңме, дим?

— Нинди атка? Атлар юк бит инде авылда.

— Ничек инде юк? Үзең сөлге җыйдык, дисең...

— Җәяүләп урам әйләндек. Зур егетләр колга тотты, без — чиләкләр.

— Күңелле булдымы?

— Арытты...

— Гармуныгыз бар идеме?

— Баянмы? Юк...

— Җырсыз, көйсез ни ямь?

— Музыка булды бит. Равил абый машинасы белән озатып йөрде. Безнең арттан капка турысына килеп туктый да, ишеген ачып, бар көченә магнитоласын кабыза. Колонкалары шәп! Колаклар тонарлык.

— Хет татарчамы соң?

— Татарча инде, канишно. Мөнир Рахмаев, Индива, Фирдүс...

— Вәйт булдыргансыз! Ишкәнсез ишәк чумарын...

— Ишәген беләм, чумары ни соң аның?

— Чумарын мин дә оныттым бугай, энем. Ә менә ишәкләре Чаллы урамында кичә генә йөри иде.

— Чаллы урамында? Ишәкләр?

— Үземнең дә күзгә күренә дип торам. Эреле-ваклы алты-җиде ишәк чаттагы зур чәчәк түтәлендә рәхәтләнәләр...

— Чынмы?

— Чын шул, чын. Машина тавышына да исләре китми. Ташкент инде бездә хәзер. Кырык градус эссе, ишәкләр... Әле былтыр шәһәр Сабан туенда ишәкләр чабышы да оештырганнар иде. Адәм мәсхәрәсе, татар Сабан туенда — ишәкләр!

— Кызык бит, апа!

— Кызык түгел бу, энем, кызганыч, аяныч...

— Атуса, анда да атлар беткәндер...

— Ирләр беткәч, атлар бетә инде ул... Ир-ат — парлы сүз...

***

Кемгә ничектер, миңа Сабантуйның иң тантаналы, күңелне ниндидер аңлатып булмаслык кыргый горур хис белән мөлдерәмә тутырган мәле — ул ат чабышлары иде...

Менә бәйрәмне алып баручы бәйгегә әзерләнгән җайдакларны мәйданга чакыра: ат хуҗасының, ияртдә утыручы егетләрнең исемнәрен атый. Әлбәттә, атларның да исемнәре яңгырый. Ялык-йолык килеп торган, сөлектәй унбишләп чаптар (авылыбыз зур дип әйттем бит), киткәнче күреп калыгыз безне, дөнья хәлен белеп булмый, теләк теләп, дога укып торыгыз дигәндәй, башларын селки-селки мәйдан әйләнә. Кайберләре, кинәт арт аякларына басып, халыкны бер мәлгә гөж килергә мәҗбүр итсәләр дә, тиз тынычланалар. Аңлыйлар малкайлар: көчне-дәртне әрәм-шәрәм итәсе түгел. Алда — ел буе әзерләнеп көтеп алган сынау...

— Атлар килә! Атлар!

— Мәйданны бушатыгыз!

— Бала-чаганы юлдан алыгыз!

Жыр-биюләр, ярышлар карап дөньясын оныта язган халыкка бу игъланнар аяз көнне яшен суккандай тәэсир итә. Мин дә сискәнеп куя торган идем. Йөрәк ничектер бераз борчулы да, рәхәт тә тибә башлый. Башта берьюлы әллә ничә сорау бөтерелә. Исән-сау килеп життеләрме икән? Атлары абынып, егетләре егылмаганмы? Кем аты беренче икән? Әгәр дә инде туган-тумачаң, күршеләрең чабышта катнашса, исемнәрен үк тезә башлыйсың. Рәис ничәнче килде икән, Фәрит, Рәгать?!.

Ниһаять, барлык сорауларга да тере жавап булып, алган урыннарынча тезелеп, мәйданга атлар килеп керә. Үзләреннән шыбырдап тир ага, кайберләренең сыртында камчы эзләре ярылып ята. Иярдәге егетләрнең дә сулышлары тигез түгел, башларын тасма яки яулык белән кысып бәйләмәгәннәрнең чәчләре үрә торган. Көлке дә, соклангыч та. Бүләкләүләр башлана. Беренче өлеша — Сабантуйны оештыручылар, калганнарын — мәйдан халкы, күбесенчә әби-апалар зурлый. Иң «авыры» соңгы килгән ат муенына төшә — йөгәненә бәйләнгән яулык-сөлгеләрнең чуты булмый. Мин бу йола-гадәткә бик тә аптырый идем. Нигә инде соңгы килгән атка шулкадәр игътибар күрсәтергә? Моңа бит жинүче лаек! Бер Сабантуйда азактан килгән атка дип яулык әзерләп торган күрше әбине шул сорау белән шаккатырдым да әле. «И балакай, элгәредән килә инде бу. Мин дә нәзер әйткән идем... Аннан соң, беләсеңме, бар көченә йөгереп тә иң азакка калган ат гарьлегеннән күз яшьләре белән елый, дия иде минем әни...» Шулчак мин, чыннан да, әбекәй муеныннан сыйпап, яулык бәйләгән чакта, атның бөтен дөнья сыйган төпсез күзләреннән бәллүр тамчылар тәгәрәгәнен күргән кебек булдым. Бүләк-яулыклар аның яшьләрен корыта, кабат ярышларга әзерләнергә көч бирә икән...

***

— Апа, ничек соң Сабантуй? Күңелле булдымы? Соңгы елларда кайта алмаган идегез...

— Күңеллесен күңелле дә... Әниең әйтмешли, машина туе быел. Житмәсә, минем дә аяклар... гомеремдә беренче мәртәбә машинала төштем... Сиңа ничек?

— И-и, ел саен шул бит... Барыбер күтелә инде. Рамил абыем молодец, әйеме! Герләрне уйнатты гына. Көч үзендә! Бүләге дә шәп — микроволновка!

— Әйе, булдырды энекәш! Хөббәт бабабыз тирә-якка бер батыр булган, диләр. Әтиең дә — яшь чагында бил алышкан егет. Син дә, бераз үскәч, көченне сынап карарсың әле, шулаймы?

— Белмим...

— Дөрес әйтәсең, Айдар, алга килми белеп булмый. Менә бүген дә... Кем уйлаган... кем уйлаган безнең мишәр ирләрен бөтен мир алдында көянтә-чиләк белән йөгертер заман житәр дип.

— Кызык бит!

— Сезгә шул кызык кына булсын! Ә чынлыкта — оят... Жир тишегенә кереп китәрлек оят... Сулы чиләкләрен мөлдерәмә тутырып, яшел хәтфә үләнне ерып, кызлар, яшь киленнәр ярышырга тиеш... Ирләрнең урыны — көрәш мәйданы, егетләрнең...

— Теге ялгыз ат вәт жалко булды, әйеме, апа?

— Ат түгел, үзебез жәл, энем. Шундый зур авылдан нибары бер ат дин, ә?

— Ат хужасы бүләкне болай гына алырга тәки риза булмады...

— Шулай... Кайчандыр үзе дә чабышларда беренчелекне бирмәгән Закир

абыйның ияргә утырган егеткә әйткән сүзләрен үз колакларым белән ишеттем. «Бүстрәй чишмәсенә кадәр барып жит, кире кайтканда, атны бар көченә ку! Алдадылар дип рәнжемәсен. Сабантуйны көтеп алды Жирәнкәй...» Кычкырып елыйсылар килде.

— Мескен ат, чабып килгәч, мәйданга да кермәде бит...

— Бүләкләрне, яулыкларны хуҗаның үзенә генә тоттырдылар. Бер әбекәй соңгы килгән атка дип ярты капчык солыга кадәр алып чыккан...

— Зато, берүзе булгач, бөтен приз Жирәнгә эләкте! Шатлыктанмы икән, жиргә ятып, озак кына аунады да әле ул!

— Жиргә ятып елавы булгандыр аның, энем... Хуҗасы артыннан башын иеп атлаган атның, рәт-рәт тезелгән «иномаркалар» арасыннан көчкә үтеп, кайту юлына борылганын күреп, күпләрнең йөрәге әрнегәндер. Бәлки... күрүче дә булмагандыр. Казан артистлары жырлый иде...

***

Мин ир-атсыз йортта үстем. Ир-атсыз илдә үскәннәр кызганыч...

## Әти моңы

— Тагын телевизор каршында утырасыңмы, әни?

Пакет-сумкаларын чыштырдатып, өермә булып кайтып кергән кызы сәлам урынына әнә шундый сүзләр ташлады да, җавап та көтеп тормыйча, «лодочка» түфлиләрен мизгел эчендә аякларыннан шудыртып, үз бүлмәсенә атылды.

— Утырам шул... Утырам! — диде Нәфисә, кызының корылыгына бераз хәтере калып. — И бала, юньләп исәнләшә, хәл-әхвәл дә сораша белмисең. Өтерге тел булып үстең, хәерлегә булсын...

— Ә «телик» хәленне сораша инде алайса? — дип зал ишегеннән башын тыгып елмайды шул арада кыска алсу халатын элгән кыз. — Беләсең бит инде, әни, ясалма ягымлылыкны яратмыйм мин! Шундый булып тугач, нишлим?! Житмәсә, без күрешмәгәнгә, хәзер әйтәм, биш, алты... нибары сигез сәгать вакыт үткән. Ә син, менә ич, матур гына, күзлекләренне киеп, кәнәфигә чумып, телевизор каршында культурно ял итеп утырасың. Димәк, хәлләрең начар түгел, шулаймы?

— Шулаен шулай, Аллага шөкер, кызым. Тик барыбер дә кеше балалары кебек тәмле телле...

— И әни, ярар инде! Анын каравы, мин икейөзләнә, алдаша белмим.

— Хәзерге заманда бу сыйфат та югары бәяләнми, бала. Хәер... гомер-гомергә туры әйткән туганына ярамаган.

Соңгы сүзләрне кыз әллә ишетте, әллә юк, чөнки күзләре, зур ачылып, телевизор экранына төбәлгән иде.

— Үләм! Кыланып та куя инде бу халык! Сиксән яшьлек әби беренче мәхәббәтен эзли! Туксан яшьлек «егетне»! Бу «Жди меня»ны кем генә уйлап тапты икән? Ничек инде вакытыңны жәлләми шуларны карап утырырга була, ә?

— Элегрәк үзең дә ярата идең ич! — диде хатын кырт кына.

— «Ищу тебя» дип аталган чагындамы? — дип көлеп җибәрде кыз. — Әйе, вообще-то, чыннан да, интригалы тапшыру бу.

— Нинди интрига булсын, ди! Чын тормыш, кеше язмышлары, кайгы-хәсрәт, югалту-табышлар монда, бала...

— Әй! — дип кул селтәде кызый. — Телевидение — алдауга, баш катыруга корылган монстр инде ул. Капкынына эләксән... Тукта, тукта, әни, кара әле

мина, әллә елагансың инде, күзләрең кызыл! Тагын кан басымың күтәрелә бит, төне буе дару эчеп чыгачаксың. Сүндерәм хәзер үк!

— Юк, юк, сүндермә... Телевизор каршында елап утыра торганнардан түгел лә анаң...

— Шуңа аптырыйм да, «железная леди»га ни булган, дип.

— Булды шул, булды менә... Син кайтып керер алдыннан гына булды... Әтиемнең — синең бабаңның карточкасын күрсәттеләр... эзлиләр.

— Валлаһи, дин! «Жди меня»данмы?!

— Әйе. Житомир шәһәреннән... кызы.

— Синең әтиеннең кызы? Клёво! Кайда соң ул Житомир? Чит илдә-фәлән түгелме? Кунакка барыр идек!

— Географияне бөтенләй укымагансың, отличница. Украинада ул шәһәр.

— Соң! Украина хәзер заграница бит инде! Әни, аңлатыбрак сөйлә әле. Точно таныдыңмы? Фамилиясен, исемен әйттеләрме?

— Әйе, таныдым. Нәкъ шундый ук фото бездә дә бар. Авылдан алып килдем. Әбиенне жирләгәч...

— Моңарчы белмәгән идеңме туганың барлыгын? Кызык! Тиз үк жавап язарга кирәк. Хәзер сайтларына керәм. Интрига бар дип әйттем бит!

— Йә, житте, тукта! Күрсәтермен мин сиңа заграница, интрига, сайтыңны! «Корвалол» тамызыр идең ичмасам!

Хатын, хәле китеп, диван аркасына сөялде. Бая кызы дөбер-шатыр ишекне ачканда эчкә йоткан күз яшьләре, юлын ачкан чишмәдәй, янә агарып калган йөзе буйлап тәгәрәде...

Кыз аш-су бүлмәсенә ашыкты, тиз арада әнисенә дару әзерләп китерде. Чиксез дулкынлануын, борчуларын шул ике йотым суга кушылган утыз тамчы дару белән юып алып булырына ышангандай, Нәфисә бәллүр чынаякка үрелде...

Әнисе өчен бочылган кыз мыштым гына анын янына чүмәште. Ул телевизорны сүндерергә бик теләсә дә, тетрәнгән ананың кабат кызып китүеннән шүрләп, пультка басып, «монстр»ның тавышын гына әкренәйтте. Озак та үтми, экрандагы кешеләр, тамашачыны өметләнергә, эзләргә, көтәргә чакырып, моңсу елмаештылар да хушлашу ягын карадылар.

Нәфисә, йокысыннан яңа айнып киткәндәй, кызына дәште:

— Кич буе мине саклап утырырга жыенмыйсыңдыр бит? Телефоның ун шалтырады, жавап бир, көттермә дусларыңны.

— Ә син? — диде житдиләнеп, аптырап калган бала.

— Нәрсә мин? Мин нормально... Тиздән әтиең кайтыр. Бар, бар. Шкаф тартмасыннан иске альбомны гына алып бир дә.

— Көрән тышлысынмы?

— Нәкъ шунысын...

Нәфисә альбомны ачарга ашыкмады, үз уйларына чумып, дерелдәгән бармаклары белән анын күн тышлыгын гына сыйпады... Әнисенең үзе генә каласы килгәнен аңлап алган кыз, әле һаман кайдадыр жырлап, хужасын чакырган телефонын эзләп китте. Анын кемгәдер:

— Хәзер... чыгам! — дип эндәшкәне ишетелде.

Бераздан сылу гәүдәсенә сыланып торган, күзләре төсендәге зәңгәрсу кофта, ак чалбар кигән, муенына шнур-чыбыклар аскан кызыкай кабат зал ишегендә пәйда булды.

— Әни, мин урамга алайса, яме.

— Матур гына йөр, кызым. Ашамадың да...

«Макдоналдс — вот что я люблю!!!» Бу сүзләрне әллә Нәфисәнең кызы, әллә сүнеп барган телевизордан реклама гүзәле кабатлады...

***

...Нәфисә әтисен бөтенләй хәтерләми. Ә хәтерлисе шундый килә! Үзен белә башлаганнан бирле килә... Җанын телгәне, йөрәген әрнеткәне дә әнә шул — үзен соңрак, әтисе үлгәч кенә белә башлавы да инде аның. Газизе аяусыз чир белән көрәшә-көрәшә, шәмдәй эреп-сызып сүнгән кара күздә аңа өч яшь тулган булган югыйсә. Сорашканы, сөйләшкәне бар: бирәүләр бу яшьтә әллә ниләр хәтерли. Ә ул — юк. Ничә еллар аңын-җанын тилмертте, газаплады кыз, томан эчендә, иске кинодагы кебек аклы-каралы төсләрдә генә булса да, зинһар өчен, исемә төшеримче әтиемне, дип. Тик юкка гына. Дәшмәде Нәфисәнең балачак хәтере. Әле дә дәшми...

«Сөбханалла, нәкъ әтисе инде. Атасына охшаган кыз бала бәхетле була, диләр». Әтисенә охшап туган, әмма бер тапкыр да әти дип эндәшкәнен хәтерләмәгән Нәфисәгә күрше әбекәй әйткән бу сүзләр коточкыч ялгышлык булып тоела иде. Ничек инде ятим бала бәхетле булсын, дип өзгәләнде ул. Ә нәрсә соң ул бәхет? Бу сорауны ул үз-үзенә соңрак, кинәт кенә бирде. Һәм җавапны да бик тиз тапты. Бәхет ул — өч нарасыен җил-янгыр тидерми ялгыз канат астында үстергән әниләре! Әйе, чыннан да, бик бәхетле иде Нәфисә. Барысы өчен дә әнисенә чиксез рәхмәтле иде. Шул исәптән әтисе турындагы тансык хатирәләр өчен дә...

***

— Син тугач та сөенгәнен күрсәң атаңның! Нишләргә белмәде кырык яшьлек сакаллы сабый.

— Исемемне кем куйды соң?

— Әтиең инде. Мин Гөлнур дип кушмакчы идем. Безнең нәселдә гел «нур»лар бит.

— Нурлар?!

— Әйе, әбием Шәмсенур исемле иде, әнием — синең әбиең Фәрхинур, апамнар, беләсең, Маһинур, Мәдинур, Миңнур.

— Миңа Нәфисә исеме күбрәк ошый...

— Алып кайтканда ук кулдан куймаслык, яратып туймаслык, тупырдап торган таза, матур бала идең. Соң... биш кила булып дөньяга килгәч!

— Юктыр инде, әни, биш үк түгелдер. Абыем өч кило иде, дисең...

— Чирмешән бүлнисендә төн уртасында тудың. Исән-имин котылуыма, дүрт саны төгәл бала табуыма шөкерана кылып, акушер марҗаны тыңлап ятам. Баш врачның өенә шылтырата бу, отчёт бирә, димәк. Бар да әйбәт, кыз бала ди, биш килограмм, ди. Врач ышанмады бугай. Шуннан аның: «Ей бох, пять килограмм!» — дип кычкырып җибәргәнен бөтен ятаж ишеткәндер...

— Әти мине яраттымы соң?

— Яратмаган кая! Кулыннан да төшермәде. Иртә тәпи киттең, быты-быты сөйләшә дә башладың. Түлке, әтиеңә «бабай» дип телең ачылды. Бабай түгел, кызым, әти дип әйт, минәйтәм. Ә атаң көлә: «Бала алдаша белми, бәлки мин чынлап та анарга әти түгел, бабай гынадыр», — ди. Үзе сине һавага чөя-чөя уйната... «Күз тияр, яшәмәс инде... Бигрәкләр дә сөйкемле бала», — дип тә еш кабатлый иде.

— Чынмы?!

— Чын булмый. Курчак кебек киендерә идем үзеңне, күлмәкләренә пар итеп эшләпәләргә тикле тектем. Атаннын сине, тере чәчәгем, дип, авыл буйлап күтәреп йөрүе бүгенгедәй күз алдымда...

***

Нәфисә, ирексездән, күзләрен йомды... Әтисенең көчле кулларында тирбәлеп, болыттай йөзеп, дөньяны өстән күзләп йөрүе нинди рәхәт булгандыр! Очраган бер кеше сиңа елмая, нәни бармакларыннан тота, кытыклап үбеп тә ала. Ә син, ятсынып, әтиеңнең муенына сарыласың...

— Тук, тук! Әллә каршы алучы да юк инде?

Тавыштан дерт итеп киткән хатын әле һаман ачылмаган альбомны диван читенә алып куйды. Аннан, әкрен генә торып чыгып, ире кулындагы әбәт йөртә торган сумкага үрелде:

— Ишек ачканыңны да ишетмәдем.

— Күзләрең йомык иде шул, колакларың да...

— Ярый, ярый. Теләнә салынма, юын да кухняга!

Нәфисә, уенын-чынын бергә кушып, этә-төртә ирен юыну бүлмәсенә озатты. Үзе инде суынырга өлгергән кичке ашны җылытырга куйды...

Аш та ашалды, чәй дә эчелде. Гадәттә һәр кашык ашка, һәр йотым чәйгә кушылып әйтелә торган үтә дә ихлас, җылы сүзләр бүген тел очында калды... Хатынына нидер булганын аңлады ир. «Үзе сөйләр соңрак», дип уйлады ул, йокы бүлмәсенә кереп, кечкенә телевизорны кабызганда. Аннан инде тулысы белән футбол дөньясына чумды...

Кемгәдер сәер тоелыр: Нәфисә гаиләсен тәмле аш белән сыйлагач, кухняда ялгызы гына калып, иркенләп, ире әйтмешли, дөньясын онытып, табак-савыт юарга ярата. Көмеш сыман балкып торган краннан аккан су бигрәкләр дә туган авылындагы Аръяк кизләвен хәтерләтә дисә, беркем дә ышанмас, билгеле, көләр генә. Тик шунысы хак: челтерәп аккан су тавышына ияреп, һәр кичне уй-хыялга чума хатын. Чәй содасы белән ышкып ялтыраткан чынаяк-тәлинкәләрне ап-ак шадра сөлге белән корытканда, эченнән генә көйләп тә ала. Бүген дә, әнә, өзек-өзек, сулык-сулык җыр сызылды, әтисенең җыры:

Сандугачның үзен... күрдем,
Сары бар... түешендә...
Тагын... ниләр... күрермен икән,
Суда йөздем... төшемдә...

***

— Һай, әтиеңнең тавышы! Моңлы иде дә соң!

— Синекеннән дәме, әни? Бигрәк матур җырлыйсың ич.

— Кая инде миңа аңа җитү! Атаң исән чакта, ул өйдә юкта гына җырлаштыра идем. Ишетә күрмәсен, көләр дип.

— Ник миңа күчмәде икән аның тавышы? Бөтенләй җырлый белмим...

— Тавышың бар синең, бала, чынлап тора, ә менә моның, дөрестән дә, чамалы. Әллә нинди, йөрәкләрнең түренә үтеп керә торган, җаннарны өтеп, күңелләрне айкап ала торган үзгә моң иде шул әтиеңдә.

— Ничек инде үзгә?..

— Шулай бер кичне өйгә кайтмый да кайтмый бу. Кайларда гына йөри икән, исән-сау гына була күрсен берүк, дип ут йотам. Эзләп барыр идем, ялгызыңны калдырырга куркам, йокыңнан уянырсың да куркып еларсың кебек. Абыең әниләрдә кунакта чак. Барыбер түзмәдем, капка төбенә чыктым. Шундый җылы җәйге кич! Күк йөзендә эреле-ваклы йолдызлар җемелдәшә, айдан көянтәсен аскан Зөһрә кыз моная. Миңа да ямансу,

күзләргә мөлдерәп яшь тула. Кинәт, төнге тынлыкны ярып, авыл өстеннән жыр агыла башламасынмы! Ерактан, Түбән очтан ук ишетелә. Меңнәр арасыннан да таныла торган әтиең тавышы! Аның үзәк өзгеч, кабатланмас моңы!

— Шуннан?

— Шуннан шул — Аллага шөкер, исән-сау икән, дидем дә кереп яттым инде. Кайткач әйттем: тоткарлансаң, жырлап хәбәр бир ичмасам!

— Жырлый идеме соң?

— Озак жырлый алмады шул... Энекәшең туып кына калды...

***

Нәфисә зал диварындагы сәгатькә күз төшерде. Кызы кайтырга иртәрәк әле. Күн тышлы альбомны күкрәгенә кысып, ул кабат кәнәфигә сеңде. «Әтиемнең моңы ник миңа күчмәде икән?!» Үсмер кыз чагында әнисенә биргән шул сорауны Нәфисә соңыннан үз-үзенә ничә тапкыр биргәндер, Ходай үзе генә белә. Байтак еллар әле ул ниндидер могжизага өметләнеп яшәде. Көннәрдән бер көнне иртән уяныр да былбыллар таң калырлык итеп жырлап жибәрер төсле тоела иде аңа. Сихри моңына бар дөнья сокланыр, авылдашлары: «Нәкъ әтисе инде...» — дип, күз яшьләре аша аһәңле авазларны тыңлап туялмаслар кебек иде...

Аннан соң ул әлеге серле моңны: «Әйдә, кызым, бу жырны жырлап карыйк, тегесен көйлик», — дия-дия, үз сабыеннан эзләде. Тик баласында да, ни кызганыч, сәләт тә, теләк тә сизелмәде. Ә инде бар нәрсәгә фәлсәфә белән караучы кызы: «Әни, газапланма, мине дә азаплама, табигать балаларда ял итә!» — дип жибәргәч, бөтенләй өметен өзде...

Нәфисә, альбомны итәгенә куеп, сак кына битләрен актара башлады... Менә әнисенең сурәте. Акыллылык билгесе — киң мәрмәр маңгай, толымлап үрелгән кара чәч, йөрәккә үтә торган гамьле, моңсу караш... Шунда ук әтисенең саргаеп, таушалып беткән фотосы. Теге «Жди меня»дагының игезе! Яшь матур йөз, баһадирдай жилкә, төз буй-сын. Өстендә хәрби кием, ләкин бер айдан сугыш башланасын, утка керәсен белми әле, йөзендә бәхетле елмаю. Бу аның солдат чагындагы бердәнбер сурәте. Дөресрәге, сакланып калганнардан бердәнбере...

***

— Әни, нишләп әтинең рәсеме берәү генә? Гөлсинәнең әтисенеке әнә әллә ничә. Медальләрен елтыратып, Берлинда басып торганы — иң шәбе!

— Синең әтиеңнеке дә байтак иде лә...

— Кайда соң алар?

— Сөйлим микән, юк микән? Әллә... Ярар, син зур инде, белеп торуың хәерле. Апаң дип әйтергә телем әйләнми, әтиеңнең тагын бер кызы бар бит, кызым...

— Әтиемнең... кызы?! Ничек инде, кайда соң ул?

— Сугыш алдыннан атаң ике ел Украинда әрмия хезмәтендә булган. Шул вакыттадыр, хахлушкадан кызы туган. Бу хакта берни белми чыктым кияүгә. Жиңги тырышты инде аннары. Минем дә күзләрне ачты, атаңның да данын бөтен авылга таратты. Сары чәчле маржасы, кызы белән төшкән рәсемнәрен зур рамга туган-тумачалар арасына тезеп куеп, стенага ук элде бу. Кергән бер кешегә, менә кайнешемнең хатыны, менә баласы дип, чырагачны указка итепләр төртеп-төртеп күрсәтә. Бераз түздем, ни дисәң дә, яшь килен бит... Тик

барыбер егетләргә бирмәс кыюлыгым үзенекен итте — бер иртәне урындыкка басып менеп, карточкалы рамны стенадан алдым тәки, тузанын сөртәм янәсе. Дөрләп мич янып тора иде, йөрәгемне әрнеткән, мине кимсеткән сурәтләрне җыйдым да учакка аттым. Минут эчендә янып көл булдылар, Алланың рәхмәте. Җиңги аңышып та өлгермәде.

— Ачулангандыр...

— Тавышына адәм чыдашлы булмады. Иренә әйтеп үтертәм мин сине, эштән генә кайтсын, дип, күз яшьләре белән елады, мескен. Маржалар шул хәтле җәл булган, күрәмсең, үзенә. Берочтан әтиеннең ялгыз гына төшкән фотолары да очты инде утка...

— Әти ни әйтте соң?!

— Күптән шулай эшлисең калган, диде дә бетерде...

***

Нәфисәнең әнисе дә ул чакта «диде дә бетерде». Һәм башка бу турыда беркайчан да сүз кузгатмады. Нәфисә генә юк-юкта, ерак Украинада яшәп яткан сары чәчле, зур күзле кыз турында уйлый иде. Ул да Нәфисә кебек әтисен хәтерләмидер, ләкин аңардан бәхетлерәктер, чөнки кайдадыр әтием бар, ул исән, мине эзләп табар, дип ышанып, өметләнеп яшидер. Көтәдер, сагынадыр, яратадыр. Әйе, әйе, яратадыр. Чөнки аның әтисен яратмау мөмкин түгел! Ә бәлки... Ә бәлки аның хохлушка әнисе татар егете турында бөтенләй сөйләмәгәндер дә? Башкага кияүгә чыккандыр да оныткандыр... Әлбәттә шулай! Соңгы уйларыннан Нәфисәгә бигрәкләр дә җиңел, рәхәт булып китә иде. Ни дисәң дә, әтисен башка кыз белән бүлешәсе килмәү теләге бик тә, бик тә көчле иде шул аңарда...

Хатирәләр чоңгылында бөтерелгән хатын, әтисенең солдат сурәтен алып калып, ядкарь альбомны ябып куйды... Нишләргә соң, ни кылырга мина, дип уйлады ул, рәсемгә текәлеп. Әтисен бүлешәсе килмәү теләге бүген дә, ничә еллар үткәч тә үз көчендә калган, аз гына да кимемәгән икән ләбаса! Әнә, баягынак та телевизордан әтиемне эзлим, дип фото тотып торган чал чәчле ханымны күргәч, Нәфисәнең аяк астыннан җир убылгандай булды. Соңгы елларда болай да аксап-туксап кына тибә башлаган йөрәге бөтенләй туктап калды кебек. Һава җитмәүдән күзләрен зур итеп ачкан, еш-еш сулаучы хатынны ярый ла экранның теге ягында күрми иделәр... Аңына килеп, бераз уйлау сәләте кайткач кына, азрак тынычланды, үзен-үзе кулга алды Нәфисә... Йә, нигә бөтенләй җебеп төштең, югалып калдың соң әле син, дип пышылдады ул үз-үзенә. Белә иден бит «апан»ның дөньяда барлыгын. Күргәч, икенчерәк икән шул... Йөзгә әтисенә дә, Нәфисәгә дә бөтенләй охшамаган... Урысчага украин сүзләре кушып сөйләшә, бик чая да бугай. Монарчы нигә эзләмәгән диген? Нигә ярты гасыр көткән?

Хатын тирән итеп сулыш алды. Җан тартмаса, кан тарта, диләр. Тик Нәфисәнең тамырларында шаулап аккан татар каны «әтисенең кызы»на бөтенләй тартылмый иде шул. Күрешүне таләп итеп, күңел кыллары да тибрәлми, очрашу мизгелләрен көтеп, йөрәге дә талпынмый... Чит иде, ят иде ул ханым. Һәм... Нәфисә беркайчан да аны туганым дип кочагына ала алмаячак! Шулай булгач, хәбәр биреп торуның нигә кирәге бар? Бәлки, җан тартмаса, кан да тартмыйдыр?

Аһ!.. Нәфисәнең тәне кинәт эсселе-суыклы булып китте. Яшен угыдай өтеп алган уй-сорау шулай тәэсир итте аңа. Матур җырлый микән ул апа? Әгәр дә мәгәр әтисенең моңы... аңа күчкән булса?! Юк, юк! Бу мөмкин түгел! Ул ирексездән: «Ты ж меня пидманула, ты ж меня пидвила...» — дип

такмаклады. Юк, тагын бер кат юк! Беренчедән, әтисенекедәй моң Ходай тарафыннан «Кара урман», «Әллүки», «Гөлҗамал»ларны сузар өчен бирелә. Икенчедән...

***

— Кызым, теге чакта мин ялгышкан булганмын бит...

— Кайчан, нинди ялгышу турында сөйлисең, әни?

— Тавышың бар, моның чамалы, дигән идем...

— Туры сүзгә җавап юк. Дөресе шул булгач.

— Ялгышымны төзәтәсем килә. Синдә бит ул, алтын тавым, әтиең моңы! Абыеңда да, энеңдә дә түгел, нәкъ менә синдә!

— И әни, көлдермә, тугай каргаларын качыра торган «моң»мы? Ни гармунда юньләп өйрәнә алмадым. «Мунчага барып уйна әле, кызым, еракта матуррак ишетелә», — бу синең сүзләр...

— Ике гармун алдырдың...

— Күлмәк тегеп, күз нурларың түгеп җыйган акчага, диң. Их мин, җүләр!

— Сезнең өчен эшләдем, яшәдем лә, бала... Тыңлап бетер әле, бүлдермә. Кабатлап әйтәм, синең хисле күңелеңдә саклана ул диңгез кебек тирән, галәм кебек чиксез әтиең моңы...

— Каян беләсең?

— Беләм генә түгел, күзләреңнән күрәм, сүзләреңнән ишетәм, елмаюыңнан тоям мин аны. Килер бер көн, бәгырь ташларыңны эретеп, тау елгасыдай тышка ыргылачак әле бу тылсым! Үзеңнең дә, тирә-яктагыларның да җан сусавын басар дәва, яшәү көче өстәүче өмет булачак ул әтиең моңы, әби-бабаңнар аһәңе... Ышанасыңмы миңа?

— Ышанам, әни...

***

Ишектәге йозакта черт-черт ачкыч әйләнә башлауга, үзе дә сизмәстән, Нәфисә сикереп үк торды: «Аллага шөкер, бәгырь җимешем кайтты, бердәнберем!»

— Әни, бие!!! Журнал килгән! Биш битендә синең шигырьләр! «Гомернең моңлы агышы»! — дип кош тоткандай бәхетле елмайды кызы керәкерешкә.

Хатын леп итеп яңадан кәнәфигә утырды. Бию түгел, җеп өзәрлек тә хәле калмаган иде аның. Бу юлы әнисенең хәл китүе чиксез шатлыктан булып, даруы шул ук «Корвалол» икәнен белгән кыз тагын кухняга йөгерде...



Клара
Булатова

# ГОМЕР АТЫ ШУНДЫЙ ТИЗ ЧАПТЫ

## Төш

*Шундый биек тау каршында торам,*
*Биеклеген күрер күз җитми.*
*Үзе текә, биеклеге ерак,*
*Текәлеге мине куркытмый.*

*Артта — диңгез. Анысы да бүген*
*Төшкә кергән серле җир инде.*
*Тирәнлеген белмим, ә киңлеге*
*Караш иңли алмас киң иде.*

*Кинәт шунда нечкә таш телеме,*
*Капыл гына ташлап кыяны,*
*Үзәгенә төшеп киң Иделнең,*
*Мәңгелеккә чумып югалды.*

*Исәбенә мәңге чыгалмадым,*
*Юкка чыккан нинди көнемдер?*
*Ничә көннәр шулай югалгандыр —*
*Үлчи калсаң,тулы бер гомер.*

***

*Ал күзлек төшеп ватылды,*
*Алданмый хәзер күзләр.*
*Җанымны ярып талады*
*Үкереп килгән көзләр.*

*Сүнә һәм сүрелә икән*
*Бу күңел,сүрелсә дә.*
*Ал булып ярым күренми,*
*Аллардан киенсә дә...*

Клара БУЛАТОВА – *шагыйрә; «Язлар алда», «Һәрвакыт янымда», «Каурый-канат – җил атым» һ.б. китаплар авторы. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. «Татнефть» ААҖ һәм Татарстан Язучылар берлегенең С.Сөләйманова исемендәге әдәби премиясе лауреаты. Әлмәттә яши.*

*Ничәнче тапкыр югалтам*
*Табылган ярларымны.*
*...Төзәтеп булмастыр инде*
*Беркатлы җаннарымны.*

***

*Зәй сулары шундый кызу акты,*
*Гомер аты шундый тиз чапты.*
*Су өстенә калын бозлар ятты,*
*Су агымын гүя туктатты.*

*Өсләрендә калын боз ятса да,*
*Дәвам итәр сулар агымда.*
*Гомер атларыбыз салган эзләр*
*Сакланырмы Зәйләр ярында?*

***

*— Күзне байлык томалаган,*
*— Күз томаларлык байлык*
*Бөтен илне кумә алмас,*
*Кемдә бар ул, кемдә юк.*

*— Күзне байлык томалаган.*
*— Томалагандыр инде.*
*Ачык күзләр фәкыйрьләрдә*
*Генә калгандыр инде.*

*— Ә кем белә... Гасыр башы.*
*Тарих тагын ни кылмас?*
*Тик күкнең капусы гына*
*Фәкыйрь өчен ачылмас.*

*Ач кешенең ачуы яман.*
*Юксыллыктан ачынгач.*
*Шәрә килеш ирек алган*
*Ярлы халык ни кылмас...*

***

*Майның да инде соңгы көннәре*
*Үтә дә үтә ае, еллары.*
*Үтә дә үтә, үтә дә китә,*
*Чигенә җитә гомер юллары.*

*Гомер юллары, кемгә күпмедер,*
*Ничек бирелгән ничә кешегә.*
*Очсыз—кырыйсыз булса берсенә —*
*Кыска бер мизгел икенчесенә.*

*Илаһым—Аллам тумыштан салган*
*Тәкъдиргә язган гомер куләмен.*
*Сузам дип һаман, узам дип аннан*
*Күпме тартыштым, чара эзләдем.*

*Безгә язылган гомер арасы —*
*Кысасын ватар юк бит чарасы.*
*Илаһи Кодрәт күпме билгеләп,*
*Үзеңә тигән шулай каласы.*

*Фани дөньяда яшәү өчен дә*
*Төрледер язмыш төрле кешедә.*
*Җәзага дучар булу берсендә —*
*Хөкемдар хакы икенчесендә.*

*Кемнең михнәттән сыгыла иңнәре,*
*Хакимлек итә илдә кемнәре?!*
*Ә гомер үтә, үтә дә китә...*
*Майның да инде соңгы көннәре.*

***

*Алдашып яшим. Алданып.*
*Гомерем буе шулай,*
*Һәм инде калган гомер дә*
*Гел шулай үтәр бугай.*

*Кем белә: бәлки, күчергеч*
*Үземнән алган болар?*
*Кемнәрдер фани дөньяда*
*Миннән дә алдандылар.*

*Акылың шуны аңласын,*
*Тетелми түзсен күңел!*
*Бу җирдә адәм баласы*
*Хатадан хали түгел.*

***

*Һәр Мәҗнүннең үз Ләйләсе була,*
*Һәр Ләйләнең дә үз Мәҗнүне.*
*Ләйләләрдән гүзәл түгелнең дә*
*Җаннарында ия үз «җене».*

*Үткәннәре калган. Киләчәктә*
*Кем килерен көткән күңелгә*
*Белеп буламыни? Шуңа күрә*
*Якындагың сакла бүгенгә.*

***

*Сонет өчен*

*Ни яулыкка, ни бүреккә гел сыймаган,*
*Ни башлыкка, ни түрәгә буйсынмаган,*
*Ни көч—кодрәт, ни дан—шөһрәт бер җыймаган,*
*Ни чабылып муеныннан ычкынмаган.*

*Күпме эшләп, кирәкле бер эш кылмаган,*
*Хакимгә дә, хәдимгә дә иш булмаган,*
*Бу башыңны ни дип бүген бәялисең?*
*Аны бүген кем бизмәне бәяли соң?*

*Түргә менгән шәкертләрең биек, ерак,*
*Алар аннан төшеп тормас хәлең сорап,*
*Үз хәле хәл яңашаңда йөргәннең дә,*
*Син дип хәзер исе китми берәүнең дә.*

*Шулай булгач, акылга кил: бу дөньяда*
*Үз турыңда үзең кайгырт, и, Дивана.*



Нәҗибә
Сафина

# ТЫН КАЛ ДА, ТЫҢЛА ӘЛЕ...

## Өмет тирәге

*Булсам өмет тирәге,*
*Бетмәс минем кирәгем.*

*Кайгы—сагышларның юктыр чиге,*
*Җаннан җанга аккан агымдыр ул.*
*Тирәкләрдән төшкән яфракларның*
*Кышын сарысы да сагындырыр.*

*Һәр ел саен сагыш сибеп йөргән*
*Көз җилләрен кемнәр юллый икән?*
*Җаннарына сагыш сарганнарның*
*Хәлкәйләрен алар уйлый микән?*

*Сагыну—сагыш, сары яфрак,дим дә*
*Сискәндерә тирәкләрнең хәле:*
*Яфрак—яфрак өзеп бәгырьләрен*
*Җирне җылытырга сипкәннәре.*

*Салкын кышта мең—мең биләүләргә*
*Биләп саклый алар бөреләрен.*
*Минем, өметемә биләү тапмый,*
*Көз җилеҙәй тузып йөрүләрем.*

*Өметемнең айдай тулган чагын*
*Сагынулардан минем сагышларым.*
*Өмет бөреләрем — биләүләрдә,*
*Исән чыкса иде бу кышларын...*

*Елның гына түгел, тарихның да*
*Була икән үзгә фасыллары.*
*Язы килми калмас тарихның да,*
*Өмет бөреләрем ачылыр әле.*

*Җилгә сибеп кайгы—сагышларны,*
*Яфрак ярыр өмет тирәге,дим,*
*Булсам иде газиз милләтемә*
*Якты өмет нуры, терәге мин!*

Нәжибә САФИНА — *шагыйрә, публицист; «Әгәр дә уйлаганда», «Без — шигырь, тормыш — проза», «Кан хәтере» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

## Нәфес

*Беркатлы без, малны саклаганда,*
*Җаныбызның нурын урлыйлар...*

А.Мансуров

*Кычкырыплар елыйм микән әллә,—*
*Кем дә ишетмәсә, күкләр бар бит.*
*Нишләп икән шулкадәр киң дөнья,*
*Иксез—чиксез дөнья, дөнья тар бит.*

*Киңәйтергә диеп биләмәне*
*Сугышларның туктаганы да юк.*
*Кемнәр шаша миллиардларны кочып,*
*Кемнең туя ашаганы да юк.*

*Дөньякүләм хаким булам, диеп*
*Тезләндермәкчеләр башкаларны.*
*Инде кайда билгеләргә белми,*
*Аптырыйлар бугай башкаланы.*

*Берсе сәнгать өчен, сәнәгать өчен,*
*Диңгез өчен— берәү, тагы, тагы?*
*Дөньясында бер тел булдырам дип,*
*Насарыйның үзен җуйган чагы.*

*Әйе, малга сак бар, җан нурына*
*Коралланган сакны куеп булмый.*
*Калҗа өчен тарткалашкан чакта,*
*Кемнәр җаныбызның нурын урлый?*

*Кычкырыплар елыйм микән әллә? —*
*Күкләр ишетер дә, ишелмәсме?*
*Мәңгелеккә диеп җибәрелгән*
*Галәм катламнары тишелмәсме?*

*Җанның шулкадәрле әрнүенә*
*Түзәлмичә тетридер җире.*
*Кешелекне һәлак итә ала*
*Корал, атом түгел, нәфес чире.*

## Хәтере кайтканнарга

*Иелгән башны кылыч кисми*

Мәкерле мәкаль

*Әй—й—й—й!*
*Тын калыгыз да тыңлагыз!—*
*Ни сөйли Кабан күле:*
*Дәшми торучылар — тере,*
*Сөйләүчеләре — үле?*

*Тын калыгыз да тыңлагыз! —*
*Ни сөйли кыйбла җиле:*
*Көннең батышына карап*
*Баручылары — тиле?*

*Әй, тын кал да тыңла әле,*
*Кыелган татар җаны!*
*Кабан күлендә су түгел,*
*Тулышкан татар каны...*

*Идел ярында таш түгел,*
*Киселгән татар башы...*
*Идел безгә бертуктаусыз*
*Шул хакта хәбәр ташый:*

*Үз заманына тереләр*
*Хуҗа була алмаса,*
*Тудырган анасын, телен*
*Яклар ирләр калмаса,*
*Гафу итмәячәк Кабан,*
*Басачак илне ләме.*
*Сибелгән илдән җил сорый:*
*— Ник сез дәүләтсез әле?!*

*Һәр яфракка, һәр сабакка,*
*Һәр чеметем туфракка*
*Кагыла да уфтана җил:*
*— Илем, җирем, суым, димә, —*
*Булмый ул дәүләтсез ил!*

*Хәтереңә кайтсаң, халкым,*
*Башыңны имә тагы!*
*Башлар киселсә дә, исән*
*Баш имәгәннәр җаны!*

***«Күзгә хисләр» циклыннан***

## Син — күз!

*Сагындырдың,*
*Ах, саргайттың, —*
*Син — күз икән, чыннан да.*
*Яфрак булып өзеләм җилдә,*
*Алларыңа чыгам да...*

*Ах, саргайттың,*
*Җир йөзендә*
*Икең дә исән чакта,*
*Күрешергә чара юкмы,*
*Уйлыйсыңмы шул хакта?*

*Күз икәнсең,*
*Ышандырдың...*
*Сирәк–мирәк төшә кар.*
*Чәчләремдә эремәгән*
*Ак кар бөртекләре бар...*

*Өшетеп*
*Тәмләндерергә*
*Мин кыргый алмамыни?*
*Ваз кичә алмаска синнән*
*Әллә син Алламыни?*

*Кышларда*
*Бөре—биләүгә*
*Төйнәлгән хисләремне*
*Җилләргә сипсәм, белмисең,*
*Белмисең нишләреңне...*

*Син — күз,*
*Мин — яз, арадагы*
*Язмыш кышын эретсәң...*
*Язмыш кышларын эретер*
*Син бердәнбер ир икән.*

## Юк шул...

*Көзге яз иде ул кичә*
*Һәм ләйсән иде.*
*«Җаныма ләйсән булып там!» —*
*Дип әйтсәң иде...*

*Шул җылы сүз җитмәгәнгә*
*Өшегән дөнья...*
*Яшел яфраклар өстенә*
*Ап—ак кар коя.*

*Яшел булса да, яфраклар*
*Өзелгән инде.*
*Шашарлык мизгелләрдә дә*
*Түзелгән иде...*

*Көзге яз иде ул кичә,*
*Ә бүген исә,*
*Күз яшьләрен өзә—өзә,*
*Ап—ак җил исә...*

## Көзге уй

*Йолдызлар күренми бүген,*
*Ай да болыт артында.*
*Тирәкләргә тотынган да*
*Җил исәргә тартына.*

*Җил исми, яфрак төшми, дип*
*Әйткәннәр дә әйтүен.*
*Өзеләсе өзелә шул,*
*Барыбер, дип әйтүем.*

*Сагыш сәгате келт тә келт,*
*Яфрак өзелгән саен.*
*Сентябрь бу — җан гынамны*
*Сагышка манган аем.*

*Сары йөрәк кебек яфрак...*
*Сары көймә шикелле...*
*Сары канатлы кошлардай*
*Тибрәләләр бит инде...*

*Ә чынлыкта, сулган яфрак —*
*Күңел генә алдана.*
*Ә син миңа дөресен әйт,*
*Яфрак кебек алдама!*

*Мин тирәк түгел, миндә шул*
*Яфрак—йөрәк бер генә.*
*Йөрәгемне ала алсаң*
*Үзеңнекен бир миңа!*

## Шундый халәт

*Кеше хәлен кеше белми,*
*Үз башына төшмәсә.*

Халык җыры

*Ни булды?*
*Әйт,ниләр булды? —*
*Сүндемени сагышың?*
*Минем өчен көне дә төн,*
*Ишетмәсәм тавышың.*

*Ни булды?*
*Әйт, ник дәшмисең:*
*«Хәерле иртә!» — диеп.*
*Җылы җитмәгәч, әнә бит,*
*Яфраклар тора көеп.*

*Ни булды?*
*Әйт, ник килмисең*
*Шатлык йомгагы булып.*
*Куанмагач, күңел, әнә,*
*Тора болыттай тулып.*

*Ни булды?*
*Безнең сөюгә*
*Язгы кырау төштеме?*
*Нигә юрарга да белмим*
*Бүген күргән төшемне:*

*Кара күздә*
*Җиләк җыйдым.*
*Җиләкләр кара көйгән.*
*Шундый халәттә каладыр,*
*Ахрысы, соңлап сөйгән...*



Зөлфәт
Хәким

# ҖЕНЛЕ КҮЛ

ТЕАТРАЛЬ РОМАН

**Катнашалар:**

Сәфәржан — 1920 елда Женле Күл буенда туган кеше.
Гайнетдин — Сәфәржанны асрамага алучы.
Нуржамал — Гайнетдиннең хатыны.
Шәйдулла — Гайнетдиннең күршесе.
Хәмдия — Шәйдулланың хатыны.
Зөфәр — Гайнетдиннең улы, 1920 елда туган.
Нәзирә — Шәйдулланың кече кызы, 1927 елда туган.
Әкълимә — Гайнетдиннең кызы, 1927 елда туган.
Кәрәм — Сәфәржаннын улы, 1947 елда туган.
Булат — Гайнетдиннең оныгы, Зөфәрнең улы, 1960 елда туган.
Фатыйх — сугыштан соң билгеләнгән колхоз рәисе.
Тәслимә — Сәфәржанның анасы.
Ак офицер.

*Булат сөйли.*

Безнең авылдан ерак түгел Женле Күл дип аталган шомлы, серле, тирәякның котын алып торган бер урын бар.

1977 елның җәендә үк миндә — 17 яшьлек үсмер егеттә — Женле Күл янындагы очрашудан соң, кайчан да булса кулыма каләм алырмын да язмышы безнең нәсел язмышына бәйле булган Сәфәржан турында китап язачакмын дигән өмет-хыял туды.

Женле Күл... Элек-электән тирә-якка бу урынның котны алырлык даны таралган — анда гел ниндидер шәүләләр йөри, өрәкләр күренә, аларның имәнгеч тавышлары ишетелә иде. Аның күле кин дә, тирән дә түгел, тирә-ягындагы таллар, камышлар, яшел түмгәкләр — болар барысы да, читтән караганда, табигатьнең бер ямьле күренеше булып күзгә ташлана иде. Әмма бу урынга бәйле риваятьләр берсеннән-берсе тетрәндергечрәк булганлыктан, авыл халкы өчен Женле Күл иң куркыныч урын дип санала иде.

Мина унжиде яшь иде. Ул елны дөньяда әллә нинди зур, бөек, әһәмиятле

Зөлфәт ХӘКИМ (Хәкимханов Зөлфәт Зөфәр улы, 1950), *драматург, прозаик, 12 китап һәм 4 җырлар альбомы авторы. Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Казанда яши.*

вакыйгалар кайнагандыр — кайберләрен ишетергә, күрергә дә насыйп булгандыр, ә кайсыларын бөтенләй белми дә калганмындыр.

Минем өчен 1977 ел октябрь революциясенең юбилей елы буларак түгел, ә бәлки башка вакыйгалар белән хәтеремдә уелып калды.

Беренчедән, мин ул елны мәктәпне тәмамладым. Икенчедән, миңа әти мотоцикл алып бирде. Халык телендә «Кәҗә» дип аталган бу матай һәрбер малай-шалайның хыялы иде.

Мин унҗидедә идем. Мотоциклыма атланып, ерактагы офык сызыгына таба очтым. Бара торгач, үзем дә сизмәстән, урманга илтә торган юлга килеп чыкканмын.

Урманда мотоцикл сүнде. Кабыза алмый интеккәннән соң, мотоциклымны этеп киттем.

Бик тирән кергән булганмын икән урманга. Караңгы төште, ә мин һаман әле ачык кырга чыкмаган идем.

Урманның караңгы кочагыннан котылгач, каршымдагы тарафларга күз йөгертеп таң калдым. Ай түп-түгәрәк, зур, аның яктысы болынны яктырткан иде! Күз күреме яхшы, бераз хәл алгач, әкренләп кайтып җитәрмен шөт дип уйладым. Женле Күл яныннан үтәсе бар — шунсы гына куркыта. Стартерга берничә тапкыр тибеп карагач, кабынасына өметемне тәмам җуйдым һәм мотоциклны «җитәкләп» кузгалдым.

Мин Женле Күл тарафына карамаска тырыштым.

## 1

*1977 ел, 1 июль. Ай тулган төн. Булат, мотоциклын этеп, Женле Күл яныннан үтеп бара. Куркып, як-ягына карана. Туктап, мотоциклны кабызырга маташа. Кабынмый. Женле Күл ягына карап сискәнеп китә. Шул яктан аңа таба бер шәүлә якынлаша.*

Булат *(катып кала).* Кем бу? Нәрсә бу? Кешеме соң бу, женме?

*Плащынын капюшоны белән йөзен яртылаш каплаган өрәк якыная да якыная. Булат мотоциклын җиргә яткырып куя. Өрәк, ниһаять, килеп җитә. Булат тын да алырга куркып тора.*

Өрәк. Сүндеме?

Булат *(үзалдына).* Нәрсә турында сорый бу? Көннең сүнүе турындамы? Өйгә кайтып җитү өметем сүндеме? Куркуымның шулхәтле көчлелегеннән яшәү уты сүндеме әллә миндә?

Өрәк. Ник дәшмисең?

Булат *(өрәкнең чыраена карарга базып).* Нәрсә сүндеме?

Өрәк. Мотоциклың.

Булат *(һушына килеп).* Ә-ә-ә, мотоциклым. Әйе, сүнде.

Өрәк. Кабынмыймы?

Булат *(тагын зиһене чуала башлый).* Нәрсә кабынырга тиеш соң? Ә-ә-ә, мотоцикл... Кабына, нишләп кабынмасын.

Өрәк *(кырын яткан мотоциклның арткы тәгәрмәчен күнитек очы белән чак кына әйләндереп).* Нишләп алайса этеп кайтасың?

Булат. Кабынмый шул.

Өрәк. Свечасын чистартасы бардыр.

Булат *(калтыранып).* Бәлки.

Өрәк. Курыкма шул кадәре. Йөрәк тибешенне хәтта мин дә ишетәм. Хәер, Женле Күлдән төн уртасында каршыңа чыксалар, кем курыкмас икән?

Булат. Сез кем буласыз соң?

Өрәк. Кеше. Син жен дип уйлагансыңдыр мине, шулаймы?

Булат. Мин ни уйларга да белмим. Дөресрәге, инде әллә ниләр уйлап

бетердем. Тирә-юньдә иң куркыныч урын бит бу.

**Өрәк.** Әйе, Женле Күл кешеләрнең котын алып тора. Мин җен түгел, мин — адәми зат.

**Булат.** Монда нишлисез соң сез?

**Өрәк.** Мин сине очратасымны белеп килдем монда.

**Булат.** Мине беләсезмени?

**Өрәк.** Беләм. Син Гайнетдинов Булат Зөфәр улы. 1960 елны тугансың.

**Булат.** Дөрес. Каян беләсез мине?

**Өрәк.** Гаҗәпләнерлекмени! Дөнья җырлардагы кебек үк кин түгел бит ул.

**Булат.** Минем урманга барасымны, төнлә шушы юлдан кайтасымны да белдегезмени?

**Өрәк.** Белдем.

**Булат.** Ничек? Каян? Мотоциклым белән урманнарда йөреп, бу тарафларга килеп чыгасымны беркемгә әйтмәгән идем.

**Өрәк.** Чөнки бүген 1 июль. Бүген Ай тулды. Иртән сәгать сигезенче егерме дүрт минутта.

**Булат.** Шуннан? Минем ни катнашым бар монда?

**Өрәк.** Бу дөньяда бернәрсә дә, беркем дә очраклы түгел. Ә кайбер очрашулар котылгысыз рәвештә тормышка аша. Өстәвенә әле мин синең белән очрашачагымны төшемдә күрдем.

**Булат.** Ник кирәк мин сезгә? Сез чынлап та кешеме соң?

**Өрәк.** Кызык сорау: «Кешеме?» Адәм баласы гомер буена да кеше була алмаска мөмкин.

**Булат.** Әллә җенме?..

**Өрәк.** Женле Күл буенда туган Сәфәрҗанның улы мин.

**Булат.** Сәфәрҗаннын улы?!

**Өрәк.** Әйе, синең бабаң белән әбиең коткарган җан иясенең улы мин. 1920 елның 1 июлендә шушы Женле Күлдә туган минем атам. Ул елны көндез 12 сәгать 40 минутта ай тулган.

*Булат өнсез кала.*

## 2

*1920 ел, 1 июль. 12 сәгать 40 минутта ай тулган көн. Гайнетдиннәр йорты. Бишектә бала йоклый. Нурҗамал бишекне чак кына тирбәтеп утыра. Гайнетдин керә, кыяфәте борчулы.*

**Гайнетдин.** Акларның бер отряды безнең авылга якынлаша.

**Нурҗамал.** Бездә ни калган аларга?

**Гайнетдин.** Кызыллар көчлерәк булып чыкты, аклар кайсы кая качалар.

**Нурҗамал** *(пошаманга калып).* И Ходаем, онны яшерергә кирәк.

**Гайнетдин.** Онны яшербез дә, ни... Монда атыш-суеш була күрмәсен. Аларны кызыллар эзәрлекләп килә икән. Авыл тирәсендә сугыша күрмәсеннәр берүк.

*Шәйдулла керә. Аның артыннан хәрби кием кигән олы гәүдәле, 30-35 яшьләрдәге ир кеше белән аксыл битле, шул ук яшьләрдәге йөкле хатын керәләр.*

**Шәйдулла.** Гайнетдин, менә әфисәрнең сиңа үтенече бар.

**Офицер.** Без Мәләкәс янында үзебезнекеләр белән очрашырга тиеш. Анда сугыш булырга мөмкин. Бу авырлы хатын сездә калып торсын.

**Гайнетдин** *(каушый).* Ни... карале, Шәйдулла. Минем әнкәй урын өстендә чирләп ята, яңа туган балабыз бар...

**Шәйдулла.** Мин ни әйтим инде... Синең йорт авылның читендә, шуңа синдә калдырырга тели ул.

**Офицер.** Вакытлыча гына.

**Тәслимә** *(ике куллап корсагын тота).* Калдырма мине!

Офицер *(арыган кыяфәттә)*. Тәслимә, син монда калып торасың.

Тәслимә *(еламсырап)*. Юк! *(Хәлсезләнеп сәкегә утыра).*

Офицер. Урман артында каты сугыш булачак. Без большевикларны барыбер җиңәчәкбез. Берничә көннән мин, килеп, сине алып китәрмен.

Тәслимә *(ялварып)*. Калмыйм мин монда! Калдырма мине!

Офицер. Мин сине килеп алырмын.

Тәслимә. Ә сине үтерсәләр?

Офицер. Син исән калачаксың. Балабыз исән калачак. Бүген ничәсе?

Шәйдулла. Беренче июль.

*Тышта ат тояклары тавышы ишетелә, аннары чапкынның тавышы яңгырый: «Кызыллар инде сигез чакрым ераклыкта гына! Тулы бер полк килә!»*

Офицер. Кузгалабыз! *(Тәслимәне кочаклый)*. Курыкма! Көт мине! *(Чыгып китә).*

Гайнетдин. Китеп җитешә алсалар ярый да.

Шәйдулла. Житешерләр. Башка чаралары юк. *(Чыгып китә).*

Нуржамал *(тәрәзәдән карап)*. Женле Күл буеннан барачаклар, ахрысы.

Гайнетдин. Урманга иң якын юл шуннан. *(Уйга калып)*. Бу әфисәр кире килерме-юкмы, белмим.

Тәслимә *(калтыранып)*. Килә! *(Кычкыра)*. Килә, килә!

Нуржамал *(Тәслимәнең янына килеп утыра)*. Чү, чү, сиңа кычкырырга ярамый. Килә, нишләп килмәсен. Киләм, диде бит. Ятып тор.

*Тәслимә елый. Аны, тынычландырып, сәкегә яткыралар.*

Нуржамал *(иренә пышылдап)*. Кеме икән соң ул аның?

Гайнетдин. Шайтан белсенме. Обозда барган хатын кемнең кеме була торгандыр.

Тәслимә *(ишетеп ала)*. Мин аның хатыны. Никахлашырга гына өлгермәдек.

Нуржамал. Балага узарга өлгергәнне, ничек инде никахка вакыт тапмадыгыз?

Тәслимә. Безнең авылга банда керде. Аларны аклар бәреп чыгарды. Аклар коткармаса, мине бөтен банда көчләячәк иде. Мине ул коткарды, үзем иярдем мин аңа.

Гайнетдин. Кем армиясеннән соң алар?

Тәслимә. Атаман Дутов гаскәрен кызыллар тар-мар китергәч, безнең якка килеп чыктылар алар.

Нуржамал. Атаң-анаң, туганнарың бармы?

Тәслимә. Беркемем дә юк. Ятимә мин.

*Төн житә. Нуржамал бишекне тирбәтә, моңлы җыр көйли. Гайнетдин йокларга ята. Тәслимә йокыга китә. Нуржамал ире янына барып ята. Урман артыннан тонык кына булып сугыш авазлары ишетелә — мылтык аткан, пулемёт такылдаган, шартлаган тавышлар яңгырый.*

Гайнетдин. Ярый әле авылыбызның ирләрен үзләре белән алып китмәделәр, хәзер без дә шул мәхшәргә эләккән булыр идек.

Нуржамал. Кайсылары җиңәр икән?

Гайнетдин. Бәлшәвикләре көчле. Аклар бөтен фронтларда җиңелеп качалар, ди.

Нуржамал. Кызыллар килсә, бу хатын турында ни диярбез соң?

Гайнетдин. Әнә староста Шәйдулла белер ни дип әйтергә. Шул алып керде бит аларны безгә.

*Тәслимә торып утыра.*

Тәслимә *(авыр тавыш белән)*. Мин кысталдым. Тышка чыгып керәм.

Нуржамал. Комган ишек катында. Суы да җылы килештер әле.

*Тәслимә чыгып китә.*

Нуржамал. Шушы гына житмәгәние безгә!

Гайнетдин. Ярар, мәңгегә бездә калмаячак бит ул, ник аптырыйсың.

Нуржамал. Моның белән бергә йортыбызга берәр бәла кермәде микән?

Гайнетдин. Гел бәла көтеп ятма инде син. Аның монда калмый бүтән чарасы юк иде. Ишетәсең бит, ничек атышалар тегендә.

*Жил-капканың шыгырдаганы ишетелә, этләр өрә башлый.*

Нуржамал. Нишләп һаман керми инде?

Гайнетдин. Чыгып китмәде микән? Этләр өрә.

Нуржамал. Төн уртасында кая барсын ул?!

Гайнетдин *(торып, киенә).* Хәлен күрден бит. Чыгып китүе дә ихтимал. Аннары, әфисәр кире килгәч, жавап тотарга туры киләчәк.

*Тиз генә чыгып китә. Күп тә үтми, урам яктан тәрәзә янына килеп кычкыра: «Нуржамал! Ул Женле Күл буендагы юлдан киткән. Елаган тавышы ишетелә. Куып тотарга кирәк. Әйдә, син дә чык!»*

*Нуржамал күлмәген киеп, ире артыннан чыгып йөгерә.*

## 3

*Женле Күл буе. Тулган ай тирә-якны яп-якты иткән. Таллар, куаклар, түмгәкләр.*

Нуржамал *(дер-дер калтырап).* Гомеремдә Женле Күлгә якын килгәнем юк иде. Куркам. Урманга таба киткәндер ул.

Гайнетдин. Юк, мин аның тавышын Женле Күл ягыннан ишеттем — хәле бетеп, шунда кереп яткандыр ул.

Нуржамал *(тирә-якка карап).* Бигрәк якты.

Гайнетдин. Бүген ай тулды бит.

Нуржамал. Куркам мин. Әйдә, кайтабыз.

*Шул вакытны Женле Күл буендагы таллар арасыннан яна туган бала елаганы ишетелә.*

Гайнетдин. Ишеттенме?

Нуржамал. Йә Ходам!

*Нуржамал, ана инстинкты белән, бала тавышы килгән якка омтыла, Гайнетдин ана иярә.*

## 4

*Шул ук күренеш. Таң аткан. Гайнетдин Тәслимәнең жәсәде янында түмгәктә утыра. Шәйдулла берничә иярчене белән килеп житә.*

Шәйдулла *(әле мәеткә, әле Гайнетдингә карап).* Зиратта күмдермим!

Гайнетдин. Кеше бит ул, ничек инде зиратта күммәскә?

Шәйдулла. Женле Күлгә килеп бала тапкан хатын — кеше микән, ай-һай, белмим. Кызыллар килә, ә без монда ак әфисәр хатынын Женле Күлдә күмеп ятыйкмы?

Гайнетдин. Кая куярга соң аны хәзер?

Шәйдулла. Урманга илтеп күмәргә кирәк.

Гайнетдин. Юк, шушында жан тәслим кылган икән, шушында күмәбез.

Шәйдулла. Шушындый куркыныч урында тагын кабер ясап куябызмы? Болай да бу урыннан халыкның коты алынып тора. Кызыллар төпчегә башласа, үзен гаепле буласың.

Гайнетдин. Ә син аклар кире килүдән курыкмыйсынмы? Тегe

әфисәр килеп, үлгән хатыны турында төпченә башласа?

Шәйдулла. Килмәсләр дә, төпченмәсләр дә. Ул отрядтан бер кеше дә исән калмаган, ди. Бәлшәвикләр влачы булачак хәзер бездә. Баланы нишләтергә уйлыйсыз?

Гайнетдин. Ничек инде нишләтергә?! Хатынымның сөте белән туйдырырбыз. Аннары күз күрер.

*Гайнетдин, баш киемен салып, битен сыпырганда, барысы да шаккатып карап торалар — төн эчендә аның чәче ап-ак булган.*

Шәйдулла *(күзләрен акайтып).* Гайнетдин! Синең чәчең агарган бит! Башың ап-ак синең!

Гайнетдин *(калтыранган кулы белән башын капшап).* Төне буе Женле Күлдә мәет саклап утырып кара әле син.

Шәйдулла *(калтырана).* Урманга илтеп күмәргә кирәк, урманга! *(Ашыга-ашыга китеп бара).*

Гайнетдин *(аптырашта калган авылдашларына карап).* Җегетләр, көрәкләр алып килеп, шушында кабер казыйбыз да, җирләп куябыз!

## 5

*Гайнетдин йорты. Хәзер инде бер бишек урынына ике бишек эленеп тора. Нурҗамал бишекнең берсен тирбәтеп утыра. Гайнетдин, ишек катында бөкәнгә утырып, чабата үрә. Шәйдулла белән Хәмдия керәләр.*

Шәйдулла *(киеренкелек белән).* Саулармы?

Гайнетдин. Ходай рәхмәте белән әлегә саулар. *(Эшен читкә куя. Кулларын чалбарына ышкып ала).*

Хәмдия. Теге балага күз салырга дип кергәниек, ачуланмасагыз.

Нурҗамал. Карагыз. *(Бишекне каплаган чүпрәкне ала).*

Хәмдия *(шат тавыш белән).* И-и-и, бигрәк тәти икән үзе.

Шәйдулла *(кырыс).* Бала бала инде ул. Авыл халкы әнә әллә ниләр сөйли. Гайнетдин белән Нурҗамал Женле Күлдән җен малаен алып кайтканнар, дип.

Гайнетдин. Обоздан калган хатын баласы икәнне белмиләрмени?

Шәйдулла. Ә нишләп ул хатын имынны Женле Күлгә барып тапкан аны? Димәк, ул хатын да иблис токымыннан булган!

Хәмдия. И, ярар инде, монда да коткы кертмә.

Шәйдулла. Син, хатын, тик кенә тор! Халык сүзенә ышанычаклар. Синең белән минекенә түгел. Дөресен әйткәндә, мин үзем дә нык шикләнәм.

Хәмдия. Аңа бирәр исем кушарга кирәктер.

Гайнетдин. Без инде исем уйлап таптык. Мулланы чакырып, исемне кушасы гына бар.

Шәйдулла. Нинди исем куярга уйлыйсыз?

Гайнетдин. Сәфәрҗан дип.

Шәйдулла. Син, күрше, баланы нишләтергә икәнне уйла.

Гайнетдин. Нишләтәсең инде аны? Алга таба тәкъдиргә ни язылган — шул булыр.

Шәйдулла. Алга таба ниләр насыйп буласын чамалыйм. Актүбәдә дә, Чәбиядә дә инде кызыллар влачы. Актүбәдән Тавык Мисхәте кайтты. Комган сатарга барган. *(Чыраен сытып).* Тапкан вакыт комган сатарга! Кызыллар комганнарын конфисковать иткәннәр, акчасын талап алганнар, үзен типкәләп кайтарып җибәргәннәр.

Гайнетдин. Бу бала аларга комачауламый бит.

Шәйдулла. Кем баласын асрап ятканыңны белсәләр?

Хәмдия. Кемнең кем баласын асрауда аларның ни эше бар?

Шәйдлула *(жикереп)*. Син тик кенә тор! Тыгылма!

Гайнетдин. Син үзен өчен куркасын. Ак әфисәр белән анын хатынын безнен өйгә син алып керден. Шуна жанын тыныч түгел.

Шәйдулла. Мин апкермәдем. Ияреп кенә кердем мин ул әфисәргә. Ул үзе, менә бу йортта калдырыйк хатынымны дип, синен йортны күрсәтте.

Хәмдия. Кеше баласын асраганга яна влач каршы булмас әле.

Шәйдулла *(усал тавыш белән)*. Сугыш бара илдә, тавык баш! Кан коелганда, юк кына жирдән гаеп каезлап табалар. *(Хәмдиягә)*. Әйдә, чыгабыз.

*Шәйдулла белән Хәмдия чыгып китәләр.*

Нуржамал. Куркам мин. Нишлибез, Гайнетдин?

Гайнетдин. Ничек яшәгәнбез, шулай яшәячәкбез. Бу баланы да әлегә без карарга тиеш.

## 6

*1932 ел. Гайнетдиннен йорт-жире. Каршы якта Шәйдулланың йорты, каралты-курасы күренә. Читтәрәк кое сиртмәсе күккә төбәлеп тора. Гайнетдин кагылган казыклар янына читән үрер өчен, чыбыклар ташый. Шәйдулла килә.*

Шәйдулла. Колхозга кермисен инде, алайса?

Гайнетдин. Кермәүче бер мин генә түгел бит.

Шәйдулла. Пропаганда житеп бетми. Партиянен төп планнарын крестьяннарга әле озак анлатырга кирәк булачак. Арабызда халыкны котыртучылар да бар шул. Икелемикеле уйлар шулар аркасында туа. Каладан вәкил килеп китте. Колхозга каршыларнын списогын төзергә кирәк, аларга башка төрле ысуллар белән тәэсир итәрбез, диде.

Гайнетдин *(битараф)*. Колхозыгызга ин беренче булып жыен әтрәкәләм, булдыксыз, алама кешеләр керде. Мин аларны мыскыллап әйтмим, әмма алар белән бер сафта буласым килми. Мин үземчә, үз тормышым белән көн күрергә телим. Мина кагылмасыннар, мина тимәсеннәр, минем дә башкаларда эшем булмас. Кирәк түгел мина кем беләндер тигезләшү.

Шәйдулла *(бераз гасабилана)*. Теге колхозлаштыру вәкиле синен белән кызыксынды. Ничә баласы бар, дип сорады.

Гайнетдин. Әйттенме сон?

Шәйдулла. Әйттем. Олы улы Заһидка 15 яшь тула, икенче малае Зөфәргә 12 яшь, кызы Әкълимә исемле, ана 5 яшь кенә әле, дидем. Сәфәржаныгызны да әйттем. Ана да унике дигәч, вәкил сорады: унике яшьлек игезәкләре бармыни, диде. Дөресен әйтергә туры килде. Аклар семьясыннан калган баланы тәрбиялимени, дип каткат сорады. *(Паузадан сон)*. Колхозга кермисен инде, алайса?

Гайнетдин. Тирәнлеген, агымын белмәгән килеш, болганчык суга ашыга-ашыга кемнен керәсе килсен!

Шәйдулла. Син әле анлап бетермисен бүгенге влачнын кодрәтен.

Гайнетдин. Ин беренче булып син анлыйсын килгән влачларнын куәтен. Нинди генә влач булса да, син — йә староста, йә менә хәзер авыл советы рәисе. Әле колхозыгыз төзелгәч, колхоз башлыгы булырга да тырышырсын.

Шәйдулла *(кырыс)*. Колхоз рәисе итеп теләсә кемне куймаслар. Син минем белән аркылы-торкылы сөйләшмә. Аерым хужалык була торып, колхоз ягына төкеренмә! Бу вәкилгә дә, монда килеп йөрүче чекистка да синен турыда ин куркыныч нәрсәләрне сөйләмәдем әле мин.

Гайнетдин. Минем хакта нинди куркыныч нәрсәләр сөйләр иден?

Шәйдулла. Мин бит Сәфәрҗанынның төннәрен Женле Күлгә йөрүен аларга әйтмим. Ә бит авыл халкы сизенә, берәрсе миннән башка да әләкли ала. Нишләп йөри синең Сәфәрҗанын Женле Күлдә? Ә?!.

Гайнетдин. Аның анасының кабере шунда. Йөрсә ни булган?!

Шәйдулла. Ай тулган көндә ул анда тәүлек әйләнә йөри. Ник тыймыйсың? Нишләп ул анда төнлә йөри? Ул куркыныч урын! Авыл халкы анда аяк басарга да курка. Кеше түгел ул! Жен ул!

Гайнетдин. Женле Күлгә йөрүдән минем аны тыясым килми.

Шәйдулла *(ни әйтергә белмичә, нәфрәтләнеп тора)*. Нишләп малайларың читән үрергә булышмыйлар?

Гайнетдин. Алар өчесе дә урманга чыбыкка китте.

Шәйдулла *(читкә карап)*. Сәфәрҗанынны авылдан озатырга кирәк.

Гайнетдин. Кая озатасың аны? Кайда кеме бар анын? Ул хәзер минем улым! Нуржамалны имеп үскән бала ул!

Шәйдулла. Ул бит сезнең үз балаларыгыз белән дә тынышмый бугай?

Гайнетдин. Төрле чаклар була. Балалар бит алар. Ул безнең улыбыз! *(Читән үрергә тотына)*.

Шәйдулла. Ахыры начар тәмамланмагае!

*Шәйдулла китеп бара. Гайнетдин, кәефсезләнеп, өенә кереп китә.*

*Нуржамал, көянтә-чиләкләр күтәреп, кое янына килә. Хәмдия, үз өеннән чыгып, ашыга-ашыга, көянтә-чиләкләр белән кое янына килеп җитә.*

Хәмдия. Нишләп уйга баттың әле, Нуржамал?

Нуржамал. Кызым Әкълимәнең эче авыртып тора.

Хәмдия. Безнең кызыбызның да шулай. Икенче көн инде.

Нуржамал. Берәр чир йөри микән әллә?

Хәмдия. Чир йөридерме, юкмы — белмим. Сәфәрҗаныгыз җыеп алып кайткан бөрлегәнне ашадылар бит алар — сезнең Әкълимәгез дә, безнең Нәзирәбез дә.

Нуржамал. Юып ашаттым мин аларга.

Хәмдия. Сәфәрҗан ул бөрлегәнне Женле Күлдән җыеп алып кайткандыр.

Нуржамал. Юк, әрәмәдән җыеп апкайткан ул аны.

Хәмдия *(пышылдауга күчеп)*. Аны гел Женле Күл тирәсендә күрәләр. Ай тулган төндә кунып та кала икән.

Нуржамал. Халык әллә ниләр сөйли инде.

Хәмдия. Ничә яшендә укырга өйрәнде әле ул?

Нуржамал. Дүрт яшендә. Биш яшендә язарга өйрәнде.

Хәмдия *(шомлы тавыш белән)*. Сәер түгелме?

Нуржамал. Нәрсәсе сәер?

Хәмдия. Төнлә күрә дип тә сөйлиләр. Кешенең ни уйлаганын белә торган сәләте дә бар икән.

Нуржамал. Халыкка аңа гайбәт кирәк инде.

Хәмдия *(ачу белән)*. Ул безнең уртанчы кызыбыз белән бер класста укый. Аңардан бөтен класс курка, ди. Үзегезнең малайларыгызга сүз әйтерлек түгел, ә менә Сәфәрҗаныгыз безнең кызлар тирәсендә уйнамасын.

*Хәмдия су алып кереп киткәч, Нуржамал кое янында торып кала. Янына Гайнетдин чыга.*

Нуржамал *(боегып)*. Сәфәрҗанны детдомга тапшырып булмас микән?

Гайнетдин. Беркая да озатмыйм, үз улым кебек якын ул миңа.

Нуржамал. Миңа да ул үз балам кебек. Бөтен авылга, бөтен халыкка каршы килеп булмый шул. Күрәсең бит, аны гел үртиләр. Жен малае дип тә, төн убыры дип тә, сихерче дип тә, шайтан дип тә.

Гайнетдин. Ул — бик сәләтле бала. Башкалар күрмәгәнне күрә торган, башкалар аңламаганны аңлый торган булып үсә. Аны Женле Күлдә туганга түгел, әнә шул уйгыр, башлы булганы өчен куралмыйлар.

Нуржамал. Алга таба аны үстерү хәлебездән килмәс дип куркам. Ай тулыр алдыннан, аннары берничә көн буена әллә нишли бит ул, кыяфәте үзгәрә, халәтен аңлатырлык түгел. Куркам мин, куркам. Детдомда врачлары да бардыр, дәваларлар, күзәтерләр. Колхозга да кирәргә теләмисең. Алга таба аны да, үзебезне дә ныграк кагачаклар.

Гайнетдин. Ничек үз кулларым белән детдомга илтеп тапшырыйм мин аны?! Күрәсең бит: авылны, безне, Вахит абыйсын, Зөфәрне, сеңлесе Әкълимәне ничек ярата ул!

Нуржамал. Ә аны яраталармы соң алар? Әкълимә генә, әле кечкенә булганга, аны-моны аңламыйча, Сәфәр абый, Сәфәр абый, дип тора. Вахит белән Зөфәр алай бигүк якын итмиләр бит.

Гайнетдин. Авыл халкы тәэсиреннән ул. *(Уйга кала).* Төкерер идем мин барысына! Синең бу аһ-зарларыңа да колак салмас идем. Барыбер тынгы бирмәячәкләр шул. Шәйдулла кайчаннан бирле: «Жен малаегызны берәр тарафка озат!» — дип теңкәгә тия.

7

*1940 ел. Женле Күл. Булат сөйли.*

— Сәфәржанны детдомга илткәннән соң, егерме ел вакыт үтте. Татар авылына герман сугышы белән гражданнар сугышыннан соң егерме беренче елгы ачлыктан интегү, яңа влачның хәллерәк крестьяннарны изгәнен күрү һәм колхозлаштыруны тату язган булган икән. Авыл үзенең тырышлыгы, сабырлыгы белән исән калды. Авыл үзенең урман-кырлары, болыннары, инеш-елгалары, чишмәләре белән үз урынында яши бирде. Женле Күл дә үзенең күп гасырлар буена саклап килгән шомлылыгы, мәңге ачылмаслык сере белән, аңга сыймаслык көче белән үзенә тартып, үзенең бөек серенә карата халык күңелендә битарафлыкка урын калдырмыйча, шул ук вакытта куркытып, өркетеп, билгесезлеге белән янап яшәвен дәвам итте. Женле Күл тарафында элеккечә шәүләләр күренгәләп, сәер тавышлар ишетелгәләп торды. Шунда бала тапкан хатынның кабере барлыкка килү Женле Күлдәге шомны тагы да ныграк куертты. Ай тулган төннәрдә ул якка хәтта карарга да ярамый, дип сөйли башладылар.

1940 елның жәендә Женле Күлдә инде берничә көн рәттән кемдер качмыйпосмый гына, кешеләр күрүгә аптырамыйча йөри, дип сөйләделәр.

«Шунда күмелгән хатынның жаны үзенә урын таба алмый микән? — дип уйлады авыл халкы. — Женазасыз күмелгән кеше бит ул. Кеше иде микән ул хатын, әллә... Теге әфисәр түгелме икән? Ул бит егерменче елны исән калган, имеш. ЧК аны эзли икән, хатынының кабере янына килүе ихтимал, ди...»

Тагын әллә нинди имеш-мимешләр йөрде чаттан чатка, йорттан йортка.

*1940 ел. 20 июнь. Ай тулган төн. Гайнетдин Женле Күлгә килә. Шомлы тынлык. Ул әкрен генә як-ягына карана. Караңгылык эченнән бер шәүлә пәйда була. Алар бер-берсенә якынаерга кыймый торалар.*

Гайнетдин. Сәфәржан, синме?

Сәфәржан. Әти, исәнме!

Гайнетдин. Исәнме, улым! *(Кочаклашалар. Ай яктысында бер-берсен күзәтәләр).* Син бит житкән егет булгансың!

Сәфәржан. Миңа егерме яшь бит инде.

Гайнетдин *(калтыравык тавыш белән).* Соңгы вакытта хатлар язмадың.

Сәфәрҗан. Менә кайтам, менә кайтам дип язылмады, шулай итеп шактый вакыт үтте шул.

Гайнетдин. Син монда күптәнме?

Сәфәрҗан. Өч тәүлек.

Гайнетдин. Ник башта өебезгә кайтмадың?

Сәфәрҗан. Күнел туп-туры монда тартты. Өебезгә бүген иртәнге якта кермәкче идем. Ни хәлләрегез бар?

Гайнетдин. Бер көе дисәм, алай да түгел шикелле. Без аерым хуҗалык бит инде... Калхуз төзеделәр...

Сәфәрҗан. Колхоз рәисе кем соң?

Гайнетдин. Шәйдулла. Баштан ук аны куйдылар да бүгенгәчә шул.

Сәфәрҗан. Мин белә белгәннән бирле шул җитәкче инде монда.

Гайнетдин. Яраклаша белә торган кеше ул. Шәйдулланың ике кызы да инде кияүдә. Олысы Жирекле кешесенә чыкты, уртанчысын Иштерәк авылыннан килеп алдылар. Нәзирәләре генә калды.

Сәфәрҗан. Нәзирә үскәндер инде.

Гайнетдин. Безнең Әкълимә шикелле — егерме жиденче елгы ул.

Сәфәрҗан. Әкълимәгә дә унөч яшь инде, ай-яй! Заһид абый ничек? Зөфәр дә минем шикелле булгандыр инде, без аның белән бер елгы бит.

Гайнетдин. Кайткач, өйдә барысын да үзең күрерсең, сорарсың, рәхәтләнеп сөйләшербез. Әйдә, кайтабыз.

Сәфәрҗан. Бераз утырыйк. Һавасы сихәтле монда. Белсәң иде ничек сагындым — авылны, авыл тирәсендәге һәрбер калкулыкны, агачларны, болыннарны. Сине, әнкәйне бик сагындым, әти! *(Гайнетдинне кочаклап ала).*

Гайнетдин. Без дә сине сагындык. Хатың килми торса, гел куркуга калабыз. *(Күз яшен җиңе белән сөртеп).* Сине детдомда калдырганда, җанымның ничек җылаганын бер үзем генә беләм.

Сәфәрҗан. Ә мин, хәтерлисеңме, ничек еладым? Детдомга барып житкәч: «Әти, калдырма мине детдомда. Авылыбызда, сезнең белән яшисем килә. Мин бөтен эшләрне үзем эшләрмен, иң авыр эшләрне миңа кушарсың!» — дип еладым.

Гайнетдин. Шәйдулла тынгылык бирмәде бит. «Ул җен малаен авылдан озатырга кирәк», — дип жөлегемә үтте.

Сәфәрҗан. Башыңны салындырма әле, әти! Укыттылар, эшкә урнаштырдылар. Депода эшлим. Ике ай эшләгәннән соң ук ,бригадир итеп куйдылар. Җылы баракта урыным бар. Менә отпуск бирделәр.

Гайнетдин *(җанланып).* Маладис, улым. Башлы шул син, акыллы! Гайре табигый сәләтләрең турында беләләрме?

Сәфәрҗан. Мин белгертмәскә тырышам. Караңгыда күрүемне кайберәүләр сизенә.

Гайнетдин. Мин хәтерлим: син бала чагында ук кешенең нишләргә җыенганын кыяфәтеннән «укый» торганиең. Ансын белгертә күрмә. Гаеп итәрләр дә, хилафлык килер үзенә.

Сәфәрҗан. Бу сәләтләрем Җенле Күлдә ай тулган төндә туганнан икәнне белерләр дип куркасың син.

Гайнетдин. Әйе, куркам. Синең турыда дөресен белерләр дип куркам. Мин бит сине табылдык бала дип яздырганием, детдомга биргәндә. Дүрт яшьлек баланы урманда ташлап киткәннәр, дип алдаган идем.

Сәфәрҗан. Дөресен яздырырга идең, әти.

*Булат сөйли.*

— Сәфәрҗан авылга кайтып киткәннән соң, бер ел узгач, 1941 елның җәендә сугыш башланды. Яңа сугыш, кешелек тарихында әле булмаганча коточкыч сугыш.

## 8

*1943 ел. Гайнетдин йорты. Өйдә кайгы.*

*Нуржамал, Әкълимә, Нәзирә утыралар. Өстәлдә похоронка кәгазе. Хәмдия керә.*

Хәмдия. Нуржамал, похоронкага ышанмаучылар да бар. Бөтенләй үк бетерешмәгез әле.

Нуржамал *(сыктанып)*. Ышанасы килми дә...

Гайнетдин. Заһид артык кыюланып ташлый торгание шул. Анда да саксызлыгын онытып харап булгандыр.

Хәмдия. Кияүләребезнең икесен дә озаттык сугышка. Шәйдулланың уң кулында ике бармагы булмаганга гына калды, ул да киткән булыр иде.

Гайнетдин. Мине дә илледә булганга гына алмый калдылар. Ул балаларны утка керткәнче, безне, картракларны алсыннар иде. *(Газаплы тавыш белән)*. Их, Заһид улым, улым, улы-ы-ы-ым!

Хәмдия. Туктале, Гайнетдин, өметне җуймаска кирәк.

Гайнетдин. Өмет кәгазе килмәде бит, әнә нинди килде — өстәлдә ята.

Нуржамал. Мин дә ялгыш җибәрмәделәр микән дип уйлап куям. Ул хәтле күп солдат арасында буталулар да була торгандыр.

Хәмдия. Зөфәрегездән хат бармы соң?

Нуржамал. Ай башында килгәние. И, Ходаем, Зөфәр дә харап булса, ничек чыдармын! *(Елый)*.

Гайнетдин *(кырыс)*. Тукта, тукта, уламый тор. Үзең ялгыш язып җибәргәннәрдер, диден бит әле. Житешерсең еларга. Заһид пехотада иде. Пехотаны аны гел алга куалар. Зөфәр дальнебойная артиллериядә — алар нимескә ерактан аталар.

*Шәйдулла керә. Бер сүз дәшми, сәкегә утыра. Аннары өстәлдәге похоронканы ала.*

Шәйдулла *(укыгач, кәгазьне өстәлгә куя)*. Геройларча һәлак булган дип язылган. Шәп егет иде Заһид.

Хәмдия. Бәлки, исәндер әле.

Шәйдулла. Берүк исән булсын инде. Бер авылга инде утыз дүрт похоронка — бигрәк күп бит.

Гайнетдин. Сәфәрҗанны детдомга озатканыма үкенәм. Синең сүзенә төкереп, малайны авылда калдырырга иде.

Шәйдулла *(карангыланып)*. Авыл ят итте аны.

Гайнетдин. Авыл житәкчесе ят иткәч, халыкка житә кала.

Шәйдулла. Яшьтәшләре дә куркалар иде анардан.

Гайнетдин. Үсә төшкәч, аңларлар иде, курыкмаслар иде.

Шәйдулла. Аннан хәбәр юкмы соң?

Гайнетдин. Сугыш башлангач, бер хаты килде дә шуннан ары юк. Иртәгә эшелон белән фронтка китәбез, дип язган иде. Аның озатучысы да булмаган бит инде анда.

Шәйдулла. Ул бик акыллы, елгыр егет, ким-хур булмас, югалып калмас.

Гайнетдин. Үз йортыбыздан киткән булса, ана җинелрәк булыр иде.

Шәйдулла. Аны барыбер монда калдырырга ярамас иде. Аның төнлә Женле Күлгә йөрүен ишеткәч, чекистлар яшертен генә шул тирәне нык күзәттеләр. Минем шигем бар: аның атасы, теге әфисәр, егерменче елны исән калган бугай. Шуның эзенә төшәр өчен күзәткәннәрдер, ахрысы. Сезгә үз балагыз кебек булса да, андый контраның малае монда яшәргә тиеш түгелие, Гайнетдин. Мина боларны сөйләргә ярамыйдырие, кәнишне... Серне ачтым ачуын, әмма берегез дә беркемгә бу хакта сүз катмагыз.

Нуржамал. Кемгә нәрсә сөйлик без? Бездә әнә нинди кайгы! *(Елый)*.

**9**

*1946 ел. Әкълимә идән юа. Нәзирә керә.*

Нәзирә *(шат күңелле)*. Әкълимә! Без бүген җиләккә бармыйбызмыни?

Әкълимә *(сискәнеп китә)*. Уф, Нәзирә, котымны алдың. Нинди җиләк! Менә-менә Зөфәр абый кайтырга тиеш. Миңа өйне җыештырырга, кырырга-юарга куштылар.

Нәзирә. Кайчан кайтырга тиеш соң ул?

Әкълимә *(күтәренке кәеф белән)*. Демобилизация булды, берәр айдан кайтып та җитәрмен, дип язган иде. Әткәй белән әнкәй калага киттеләр — абый кайтуга тәмлерәк нәрсәләр алып булмасмы дип.

Нәзирә. Алай икән. Үзем генә бармыйм инде. Ул Җенле Күл тирәсеннән үзем генә үтәргә куркам.

Әкълимә. Көндез нәрсәсеннән куркасың инде аның?

Нәзирә. Ю-у-ук, барыбер куркыныч.

Әкълимә. Зөфәр абый кайтсын инде. Аны да алып барырбыз җиләккә. Сугыштан кайткан кеше белән урманнар да, җенле күлләр дә куркыныч булмас.

Нәзирә. Әкълимә, карале, ә теге... Сәфәрҗан абыеңнан хәбәр юкмы?

Әкълимә *(боегып)*. Кырык дүртенче елның августында соңгы хаты килде.

Нәзирә. Исән түгел микәнни?

Әкълимә. Белмибез. Аны балалар йортына алып киткәндә, мин шундый нык елаган идем. Мине бәләкәй чакта гел ул күтәреп йөри иде бит. Әллә нинди сыбызгылар ясап бирә торганые. Хәтерлисеңме, иске арбага синең белән икебезне утыртып йөри торганые? Берсендә инеш буенда арба авып, синең иңбашың сыдырылды, минем тезем кара янып чыкты.

Нәзирә *(елмаеп)*. Хәтерлим. Әй эләкте шуннан соң Сәфәрҗанга олылардан! *(Житди)*. Кырыгынчы елны кайткач, мин аны күреп шаккаттым. Бөтенләй шәһәр кешесенә әйләнгән. Җен малаена һич кенә дә охшамаган.

Әкълимә. Нишләп җен малае булсын ул?! Теләсә кемне штабка алмыйлар. Хәрби училищеда да теләсә кемне укытмыйлар. Фоторәсемен күрсәткәнием бит. Капитан званиесен дә, орденнарны да тиктомалга бирмиләр. Исән генә булсын инде берүк.

Нәзирә *(Сәфәрҗан турында сөйләшүдән тәм табып)*. Теге кырыгынчы елны кайткач, ул миңа: «Син, Нәзирәкәй, унөч яшеңдә шушылай таң калырлык чибәр булгансың, берничә елдан егетләрнең күз явын алачаксың бит!» — дигәние. Шунда минем оялуымны белсәң! Битем уттай янып, йөрәгем сикереп чыгар кебек булганые.

Әкълимә. Хатлары да аның шундый оста, матур тел белән, акыллы итеп язылган. Хәзер менә үзе дә юк, хаты да юк. Заһид абый да юк. *(Елый)*. Бар инде, Нәзирә, эшем күп. Аннары иркенләп сөйләшербез.

*Нәзирә чыгып китә. Әкълимә шактый вакыт сәкедә моңсуланып утыра. Шау-гөр килеп Зөфәр, Гайнетдин, Нурҗамал керәләр. Зөфәр хәрби киемнән. Алар белән өйгә шатлык тула.*

Гайнетдин *(кычкырып)*. Әкълимә! Без ишәеп кайттык!

Нурҗамал. Балакаем, Зөфәр абыеңны очраттык бит калада!

Әкълимә. Зөфәр абый! *(Йөгереп килә)*.

Зөфәр *(шаккатып)*. Әкълимә, син бит инде җиткән кыз икәнсең! *(Саклык белән генә сеңлесен кочаклый)*.

Әкълимә *(оялып)*. Зөфәр абый, синме бу?

Гайнетдин. Самавырны тизрәк куегыз! *(Капчыгыннан ризык төргәкләрен алып ян сәкегә куя)*.

*Йортта куанычлы ыгы-зыгы куба. Ана белән кыз чәй әзерләгән вакытта ата белән улы сәкегә утыралар.*

Гайнетдин. Менә, улым, кайтып та җиттең. Чын ир-егет булып кайткансың, маладис! Заһид абыең гына... (*Икесе дә башларын иеп уйга калалар).*

*Нурҗамал, елап, аралыкка кереп китә. Әкълимә нишләргә белми аптырап тора.*

Гайнетдин (*кырысланып).* Ярар, ярар, җитешерсез еларга!

Зөфәр. Заһид абый менә дигән егет иде.

Гайнетдин. Кабере бармы икән, шуны да белмибез бит.

Зөфәр (*паузадан соң).* Авылдан ничә кеше кайтмады?

Гайнетдин (*авыр сулап).* Йөз уналты.

Зөфәр. Колхоз рәисе һаман Шәйдулла абыймы?

Гайнетдин. Юк, Ясәү малае Фатыйхны куйдылар. Кырык өченче елны ранен булып кайтканые. Бик хәрәкәтчән булгач, шуңа күзләре төште. Районда туганы да бар... Тора-бара Шәйдулланың влачка кирәге бетте. Фатыйх анын кече кызына күз атып йөри, диләр.

Зөфәр (*сеңлесенә карап елмая).* Ә безнең Әкълимәбезгә нинди асыл егетләр күз ата икән?

Әкълимә (*уңайсызланып).* Абый, ярар инде. (*Аралыкка кереп поса).*

Зөфәр. Качма-качма, бу сораудан качып котылганнары юк әле.

Нурҗамал. Кызым, самавыр кайнады.

Әкълимә (*самавырны өстәлгә китереп куя).* Абый! Без сине иртәгә Нәзирә белән җиләккә алып барабыз.

Зөфәр. Урманны бер әйләнсәң ярый. Ләкин мин җиләк җыя торган кеше түгел инде, сеңлем.

Әкълимә. Сиңа җыярга кушучы юк бит. Без җыярбыз, син ашап кына йөрерсең. Безгә сугыш хәлләрен сөйләрсең.

Зөфәр (*кинәт кәефсезләнеп).* Сугыш хәлләрен... Әй, сеңлем! Аны сөйләп кенә бетерерлекмени соң?!

## 10

*14 июль. Ай тулган көн. Кичке эңгер-меңгер вакыты. Женле Күл яныннан сузылган юлдан, көлешә-көлешә сөйләшеп, Зөфәр, Нәзирә, Әкълимә кайтып киләләр. Кызлар җиләк белән тулы кәрҗиннәр тоткан, Зөфәрнең кулында каен себеркесе.*

Нәзирә. Ярый әле Женле Күлне караңгы төшкәнче узабыз.

Әкълимә. Мин дә нәкъ шуны әйтмәкче идем.

Зөфәр. И, кызлар, сугышны күргән ил өчен нәрсә ул женле күлләр, шайтанлы болыннар?!

*Женле Күлгә җиткәч, Әкълимә сискәнеп китә.*

Әкълимә (*күл буена ымлап).* Абый, анда кемдер бар.

Нәзирә (*куркып, як-ягына карана).* Кайда?

*Өчесе дә туктыйлар. Әкълимә ишарәләгән яктагы куаклар арасыннан капюшонлы плащ кигән берәү чыга һәм боларга таба якынлаша. Нәзирә Зөфәрнең артына кача, Әкълимә ана сыена.*

Зөфәр (*чак кына ишетелерлек итеп).* Курыкмагыз, кызлар. Бу дөньяда иң куркыныч нәрсә җен түгел, бу дөньяда иң куркыныч зат — кеше.

*Якынлашып килүче Сәфәрҗан булып чыга. Ул плащын салып чирәмгә ташлый.*

Сәфәрҗан *(тирә-якны янгыратып).* Зөфәр! Берүзең ике кыз белән ничек курыкмыйча урманга бардың? *(Көлә).*

Зөфәр *(кычкырып).* Сәфәр! Сәфәрҗан! Синме бу?

Әкълимә *(таң калып).* Сәфәр абый, синме?

Сәфәрҗан. Әкълимә сеңлем, монда миннән башка тагын кем йөрсен?!

*Сәфәрҗан белән Зөфәр ирләрчә каты иттереп кочаклашалар.*

Зөфәр. Сәфәр туган, исәнме!

Сәфәрҗан. Исән, Зөфәр туган, исән! *(Әкълимәне күтәреп бөтерелеп ала).* Бәләкәй чакта мин сине күтәреп йөрергә ярата идем.

Әкълимә *(читенсенеп).* Төшер, төшер. Мин бит авыр хәзер. Җиләгем коела!

Зөфәр. Монсы күрше кызы Нәзирә.

Сәфәрҗан. Ә мин таныйм. Нәзирәне танымаска. *(Нәзирә белән кул биреп күрешә).*

Нәзирә *(оялып).* Исәнме, Сәфәр абый.

Сәфәрҗан *(сокланып карый).* Исәнме, Нәзирә.

Зөфәр. Авылга кайттыңмы соң әле син?

Сәфәрҗан. Юк, әле авылда булмадым.

Зөфәр *(Сәфәрҗанны җилтерәтеп).* Киттек, әйдә, тизрәк кайтабыз!

Сәфәрҗан *(иркен сулап).* Бераз утырыйк әле монда, Зөфәр.

Зөфәр. Кызлар, йөгерегез, әти белән әнкәйдән сөенче алыгыз! Без хәзер кайтып җитәрбез.

*Кызлар, кәрҗиннәрен күтәреп, авылга таба йөгерәләр.*

Зөфәр. Ай-яй кыяфәт шәп синең, иптәш капитан! Синең белән күрешмәгәнгә уналты ел бит. Исән икәнсең, маладис! *(Кочаклашып алалар).* Авылга соңгы хатың кырык дүртенче елда килгән булган икән.

Сәфәрҗан. Яраланып, госпитальгә салдылар да... Госпитальдән никтер язасы килмәде. Терелеп аякка баскач, үзем кайтып җитәрмен, дидем. *(Плащын алып калкурак урынга җәя. Утыралар).*

Зөфәр. Яраң каты булдымы?

Сәфәрҗан. Хәйран. Әмма мин бирешерлек үк авыр түгел. Сөйләрмен әле барысын да.

Зөфәр. Башта туп-туры өйгә кайтырга идең.

Сәфәрҗан. Җан монда тартты. Бүген — 14 июль. Мин төнне бирегә кундым. Сагындырган туган як табигате! *(Тирән сулыш ала).* Күрше кызыбыз бик чибәр булып җитлеккән икән.

Зөфәр. Әйе, Нәзирә җиләк кебек. Аңа яңа персидәтел кызыгып йөри. Ясәви Фатыйхын хәтерлисеңме?

Сәфәрҗан. Хәтерләмәскә. Бала чакта минем кан дошманым иде бит ул.

Зөфәр. Колхоз җитәкчесе ул хәзер.

Сәфәрҗан *(көлемсерәп).* Авылны җитәкләргә мине яратмый торган кешеләрне юри куялармы әллә?

Зөфәр *(көлә).* Мөгаен, шулайдыр. *(Җитдиләнеп).* Үзгәрешләр шактый. Сугыштан кайтмаучылар да күп, яралылар да. Бала-чага үсеп җиткән — таныйрлык түгел. Без дә үзгәрдек. Без дә сугышка кадәрге малайлар түгел.

Сәфәрҗан. Бөтен нәрсә үзгәреп тора, ләкин кешеләр күңелендәге әшәкелек сугышка кадәр ничек булган, хәзер дә шул ук.

Зөфәр. Алай дими тор әле, туган. Авылдашларың белән аралашып кара әле, хәзер алар сиңа бөтенләй башка мөгамәләдә булырлар. Син — Офицер. Түшеңдә орденың, медальләрең ялтырый.

Сәфәрҗан. Мин алдан ук сизеп торам: авыл мине барыбер кабул итмәячәк.

Зөфәр. Сине детдомга алып кит-

кәннән бирле бүгенгәчә, бала чакта авыл малайлары сине какканда яклый алмаганыма уфтанып яшим. Дөресен әйткәндә, мин үзем дә синнән бераз курка идем. Төрлечә уйлый идем мин синең турыда. Ә инде үсә төшкәч, сине сагынып, кызганып, качып кына елый торган идем.

Сәфәрҗан. Әйе, моннан мине тамырымнан йолкып алып киткәннәр иде шул.

## 11

*Гайнетдин, Сәфәрҗан, Нурҗамал чәй эчәләр.*

Сәфәрҗан. Авыл шулай ук ямьле — үзе дә, тирә-ягындагы табигате дә.

Нурҗамал. Безнең монда баш каткан — очны очка ялгап яшәп, туган як ямен күрергә вакыт юк. Аерым хуҗалык булгач, бигрәк тә...

Гайнетдин. Башыңны гел кайгыга батырсаң, дөньясының яме калмас.

Нурҗамал. Кайгыны аны сорап теләп алмыйсың бит. *(Еламсырап).* Заһид балакаем кай җирләрдә ята икән?

Сәфәрҗан *(сагыш белән).* Үскәндә Заһид абый миңа бик кырыс булса да, барыбер гел гаделлек ягында иде.

*Шәйдулла керә. Нурҗамал, күз яшьләрен сөртә-сөртә, мич тарафына китә.*

Шәйдулла *(тартынып кына).* Саулармысез.

Гайнетдин. Исән-саулар әлегә. Әйдә, уз, утыр, чәй эчәбез.

Шәйдулла *(ни әйтергә белми торгач).* Зөфәр өйдә түгелмени?

Гайнетдин. Районда эш белешеп йөри. Әкълимә аңа ияреп китте.

Нурҗамал. Чәй ясыйммы?

Шәйдулла. Юк, яңа гына эчтек чәйне. *(Сәке читенә утыра).* Ну, Сәфәрҗан, авылны әйләнденме?

Сәфәрҗан. Әйе. *(Шәйдулла текәлеп карый).* Сагындырды авыл.

Шәйдулла. Сагындырыр инде ул. Кем уйлаган сине менә шушындый герой булып кайтыр дип.

Гайнетдин. Ник алай дисең әле син?

Шәйдулла. Болай гына...

Сәфәрҗан. Мин аның ник алай дигәнен беләм. Контраның малае ничек кеше була алды, дип шакката ул.

Шәйдулла *(ялагай тавыш белән).* И, алай димә инде, Сәфәрҗан. Мин синең исән-сау кайтуыңа бик шат. Авылдашлар әнә пыш-пыш киләләр: җен малае кеше булган, дошман төшереп калдырган орлыктан шушындый сәвит офицеры чыгарга тиеш микәнни, дип чәйнәнәләр.

Сәфәрҗан. Беләм, ишетәм. Ә шулай да мине авылдан детдомга озатырга кушучы син булдың бит, Шәйдулла агай.

Шәйдулла. Син хәзер инде олы кеше, аңларга тиеш. Җенле Күлдәге кабер турында чекистларның сорашуларын син белмисеңдер бит әле? Ак әфисәрнең малаен авылда асрыйсыз, дип җелегемне суырдылар. Минем сине авылдан детдомга рәзе җибәрәсем килгәние?!

Сәфәрҗан. Юк, син нык тырыштың, Шәйдулла агай. Кырыгынчы елны авылга кайтып киткәннән соң, син бит депога минем өстән язып җибәргәнсең — авылның котын алып торган җен малае дип тә, обоздан төшеп калган эт дип тә, ак офицерның орлыгы дип тә атагансың мине. *(Кызып).* Сез аның кем икәнен, нәрсә икәнен белмисезмени, дип язгансың!

Шәйдулла *(каушый).* Курыктым мин. Авыл халкы бик хөсет. Син матур киенеп, көчтәнәчләр белән авылга кайткач, ачлы-туклы хәерче авылдашлар: «Контра бала-

лары барыбер яхшы яши!» — дип миңа бәйләнеп интектерделәр. Төнлә уполномоченный килеп синең турыда төпченде. Курыктым мин. Сине монда бүтән кайтартасым килмәде. Яздым, әйе, яздым! Хәзер инде бәйләнүче дә булмас, сине моннан куучы да булмас. Син — боевой офицер, орденоносец!

Сәфәрҗан. Син хәзер авыл җитәкчесе түгел, куа алмыйсың.

Шәйдулла. Алай димә инде, Сәфәрҗан.

*Хәмдия керә.*

Хәмдия. Нихәлләрегез бар? Шәйдулла, син монда икән. Ничек соң, Сәфәрҗан, ял иттенме инде бераз? *(Ире янына утыра).*

Сәфәрҗан. Нәрсәдән ял иттеңме дип сорыйсың, Хәмдия апа?

Хәмдия. Нәрсәдән дип...

Сәфәрҗан. Яшәүдән, дөньядан ял итү мөмкинме икән соң ул?

Хәмдия. И-и-и, син бигрәк картларча сөйләшәсең.

Гайнетдин. Ә ул бала чактан ук олы кешеләрчә сөйләште.

Хәмдия. Исән-сау кайтканыңа куанырга кирәк, балакаем. *(Еламсырап).* Әнә, безнең бер киявебез сугыш бетәргә ярты ел кала һәлак булды, икенче кияү аяксыз кайтты.

Шәйдулла. Кайда урнашырга исәбең?

Сәфәрҗан. Белмим әле.

Хәмдия. Әллә кая китмәс инде, үз районыбыз тирәсендә калыр.

Сәфәрҗан. Дөрес, Хәмдия апа, әллә кая китмәм инде мин. Табигатьне аны берничек тә алдап булмый. Аның үз законнары бар.

*Фатыйх керә.*

Фатыйх *(елмаеп).* Здравия желаю! *(Барысы белән дә күрешеп чыга).*

Шәйдулла *(шундук кузгала).* Ярый, без чыгыйк инде.

*Шәйдулла белән Хәмдия тиз генә чыгып китәләр.*

Гайнетдин. Карчык, әйдә, су ташып, мунча ягып җибәрик әле.

Нурҗамал *(каушабрак).* Чәй эчертим инде кунакка.

Фатыйх. Нинди кунак инде мин, Нурҗамал апа. Сәфәрҗан белән үзебез ясап та эчә алабыз.

*Гайнетдин белән Нурҗамал ике ир-егетнең әңгәмәсенә комачауламас өчен чыгып китәләр.*

Фатыйх *(көлә).* Гайнетдин абый, колхозга кирәргә өндәр дип, миннән гел шулай кача инде ул.

Сәфәрҗан. Кирәргә теләмәгәч, ник өндисең соң син аны?

Фатыйх. Гайнетдин абый кебек оста куллы кешегә зимагур сыман кайлардадыр, ялланып, акча эшләп йөрү килешми. Үзебез дә аның кебек балта осталарына мохтаҗ. Аны ничек булса да колхозга кертергә кирәк. Сөйләш әле үзе белән. *(Сәфәрҗанны җентекләп күзәтә).* Син хәзер әнә нинди...

Сәфәрҗан. Аның күңеле үзенчә яшәргә тели, шуны ник аңларга теләмисез? Күмәклекне беркайчан яратмады.

Фатыйх. Ярар, без бу турыда сөйләшмик әле. Күрешмәгәнгә уналты ел бит. Үзеңнең планнарың нindирәк?

Сәфәрҗан. Каладан буяу алып кайтып, анам каберендәге рәшәткәне буйыйсым бар.

Фатыйх *(чыраен сытып).* Ул кабер авылыбызда зур тап-тимгел булып, Женле Күлнең шомлылыгын арттырып тора.

Сәфәрҗан *(усал).* Кабер турында алай димә!

Фатыйх. Алай ямьсез карама миңа, Сәфәрҗан!

Сәфәрҗан. Бала чакта мине иң нык җәберләгән кеше син иден. Җен малае дип үзәгемә иң нык үтүче син булдың. Хәзер инде без бала-чага

түгел. Икебез дә сугышны үттек. Олы жанлы булырга вакыт. Кагылмагыз мина да, анам каберенә дә.

Фатыйх. Ярар. Сине мондый кыяфәттә күрүемә мин шат. *(Кузгала).*

Сәфәржан. Мин дә синен авыл житәкчесе булуына шат.

Фатыйх. Син бигүк еракка китмәссен шикелле.

Сәфәржан. Нишләп алай дип уйлыйсын? *(Торып баса.)*

Фатыйх *(ишек катына житкәч).* Ай саен ай тула бит.

Сәфәржан. Әйе, ай саен ай тулып тора. Табигатьтән беркая китеп котыла алмыйсын. Табигатьнен үз законнары.

Фатыйх. Ә моннан еракта чакта ничек түздең?

Сәфәржан. Минем туган жирем бар, анам кабере бар, минем тамырым сузылган төбәк бар, авылым бар, шул авылда мине якын итүче берничә кеше бар — гомумән, минем Ватаным бар дигән уй-тойгыны үземә тукыдым мин, шул бер бөек хискә үземне инандырдым.

*Фатыйх чыгып китә.*

## 12

*Нәзирә, көянтә-чиләк күтәреп, коега суга бара. Кое янына Сәфәржан килә.*

Сәфәржан. Исәнме, Нәзирә!

Нәзирә. Исәнме, Сәфәр абый!

Сәфәржан *(ягымлы итеп).* Кайчан мине жиләккә алып барасын?

Нәзирә *(югалыбрак).* Нишләп мин сине жиләккә алып барырга тиеш?

Сәфәржан. Зөфәрне алып барырга ярый, ә мине юкмы?

Нәзирә. Без бит аны Әкълимә белән алып бардык.

Сәфәржан *(серле тавыш белән).* Мин шактый дөнья күрдем, ә синен кебек гүзәл затны беркайда очратканым булмады.

Нәзирә *(ояла).* Сәфәр абый, минем әле суны күп ташыйсым бар.

Сәфәржан. Безнен сөйләшеп торуыбызны күрерләр дип куркасынмы?

Нәзирә. Безне бергә күреп куркырлар дип борчылам.

Сәфәржан. Атаң гына курыкса инде.

Нәзирә. Минем әтине дошман итмә, Сәфәр абый.

Сәфәржан. Ничек инде мин мондый сылунын әтисен дошман итим?!

Нәзирә. Синен бала чакта да беркемгә ачуын килми иде бугай.

Сәфәржан. Күрсәтәсем генә килмәгәндер.

Нәзирә. Әти мина гел: «Ул жен малае янына якын килмә!» — ди торганые. Ә минем ул ачуланган саен синен янына барасым килә иде. *(Елмаеп.)* Әкълимә белән икебезне арбага утыртып йөри иден. Синнән куркырга кушканнарына аптырый идем? Малайшалайнын сине үртәгәненә дә шакката идем, анламый идем.

Сәфәржан. Хәзер анладынмы сон инде?

Нәзирә. Анлыйсым килми.

Сәфәржан. Клубка чыгасынмы бүген?

Нәзирә. Әкълимә белән чыгабыз дип сөйләшкән идек.

*Сәфәржан ишегалларына кереп китә. Чиләк-көянтә күтәреп Әкълимә чыга.*

Әкълимә *(Нәзирә янына килеп).* Нәрсә булды сина? Әллә нишләгәнсен.

Нәзирә *(һушына килә алмый).* Белмим, әллә нишләп киттем шул.

Әкълимә. Нәрсә булды сина?

Нәзирә. Белмим. Йөрәгем дыкдык кага. *(Көянтәгә чиләкләрен элеп китеп бара).*

*Фатыйх күренә, читтән карап тора. Аны күргәч, Әкълимә, тиз генә су алып, өйләренә кереп китә. Нәзирә тагын суга чыга. Кое буенда аның янына Фатыйх килә.*

Фатыйх *(папирос каба).* Сәфәр нәрсәләр сөйли?

Нәзирә. Хәлләрне сораштырды. Бала чакларны искә төшердек.

Фатыйх. Син аның белән сак бул. *(Тәмәкесен кабыза).*

Нәзирә *(гаҗәпләнеп).* Ник мин сагаерга тиеш? Күрше малае бит ул.

Фатыйх. Аның кем малае икәнен белмисеңмени?

Нәзирә. Кем малае булса да, башкалар шикелле ике куллы, ике аяклы кеше.

Фатыйх. Аны барыбер авыл халкы кешегә санамый.

Нәзирә. Чөнки ул кыерсытуларга түзгән, детдомда да югалып калмаган. Акыллы, укымышлы, офицер. Аны күралмаучылар ник күралмауларын үзләре дә аңламыйлардыр, ахрысы.

Фатыйх *(ачулы тавыш белән).* Нишләп әле син аны яклыйсың?

Нәзирә. Фатыйх абый, минем эшем күп, минем әле кер юасым бар.

Фатыйх *(ягымлы булырга тырышып).* Миңа өч минут вакытыңны кызганма инде, Нәзирә. Сиңа ничек гашыйк булып йөрүемне беләсең бит.

Нәзирә. Фатыйх абый, әти тәрәзәдән карап тора.

Фатыйх *(тәмәкесен ташлап таптый).* Торасың да шулай дисең. Шәйдулла абый миңа ачу саклыйдыр, әмма мин чыгармадым бит аны персидәтеллектән.

Нәзирә. Эш анда түгел. Кеше әллә ниләр сөйләр.

Фатыйх. Мин колхоз җитәкчесе, авылымның һәр кешесе белән сөйләшеп тора алам.

*Нәзирә, су алып, өенә таба китә.*

Фатыйх. Клубка чыгасыңмы бүген?

Нәзирә. Белмим. *(Ишегалларына кереп китә).*

*Сәфәрҗан чыга. Фатыйх аңа таба атлый.*

Фатыйх *(коры гына).* Тагын озак буласыңмы әле авылда?

Сәфәрҗан. Ник алай сорыйсың?

Фатыйх. Чөнки авыл халкы: «Озакка кайтканмы? Авылда кала микән әллә? Алга таба нишләргә җыена икән?» — дип кызыксына.

Сәфәрҗан *(читкә карап).* Җаным ничек тели, шулай итәрмен.

Фатыйх. Сәфәрҗан, сиңа моннан китәргә кирәк.

Сәфәрҗан *(Фатыйхның йөзенә текәлеп).* Нишләп китәргә тиеш мин?

Фатыйх. Соң, яратмыйлар сине монда, яратмыйлар!

Сәфәрҗан. Син үзең мине күралмагач, башкалар да яратмаска тиеш дип ышандырырга тырышасың. Син бала чакта ук башкалардан үзеңне өстен куярга тырыша идең. Мине дошман итүең дә Женле Күлдә туганым өчен түгел, ә синең ишеләргә буйсынырга теләмәгәнем өчен булды. Малайларны миңа каршы котыртуың да инеш буенда синең иягеңә кундырганым өчен бит.

Фатыйх *(кырыс).* Бу — минем туган авылым. Мин — хәзер колхоз рәисе. Мин авыл өчен, авыл халкы өчен җаваплы кеше. Монда бала чактагы шаяру-котыруларны искә алып торуның кирәге юк.

Сәфәрҗан. Бу авыл — минем дә туган авылым.

Фатыйх. Син барыбер төшеп калган орлыктан үскән нәрсә монда.

Сәфәрҗан *(усаллана).* Язмыш җилләре кешене, орлык кебек, әллә кайларга илтеп ташласа да, кайда да булса ул тамыр җәяргә тиеш. Монда минем туган җирем! Минем шушында тамырым. Язмыш ничек бормаланса да, барыбер шушы җир миңа

— изге жир. Ничек дип аталса да, хәтта Женле Күл булса да, иң якын туфрак шушында. Анам шушында жирләнгән. Әйт әле миңа: Туган ил, Туган жир, Ватан тагын ничек билгеләнә?!

13

*Шул ук күренеш. Төн житкән. Фатыйх Нәзирәне клубтан озата килә.*

Ф а т ы й х *(кызның кулын тотып).* Нәзирә! Без синең белән пар килгәнбез.

Н ә з и р ә *(салкын гына).* Кем әйтте?

Ф а т ы й х. Үзем сизәм.

Н ә з и р ә. Иртә әле миңа кияүгә чыгарга, Фатыйх абый.

Ф а т ы й х. Моны кем әйтте сиңа?

Н ә з и р ә. Үзем беләм.

Ф а т ы й х *(житди кыяфәт белән).* Мин — колхоз рәисе, атаң эшләгән урынга куелган кеше... Без бергә булырга тиеш. Атаннның миңа бераз ачуы киләдер... Аны чыгарып, мине сайлаганнарына мин гаепле түгел. Без синең белән өйләнешкәч, үпкәсе бетәр, хәлле тормыш корып жибәрербез.

Н ә з и р ә. Туңдым мин. Керим инде.

Ф а т ы й х. Минекеләр сезгә сөйләшергә килсеннәрме? Яучы жибәримме?

Н ә з и р ә *(кискен).* Юк, юк, куркам!

Ф а т ы й х. Курыкма. Вакыты житкән бит инде.

Н ә з и р ә. Юк, юк! Ашыгырга кирәкми. Туңдым мин. *(Өйгә таба атлый).*

Ф а т ы й х. Ярый, тыныч йокы. Иртәгә күрешербез.

*Нәзирә кереп китә. Фатыйх тәмәке кабыза. Беравык уйланып алганнан соң, Гайнетдиннәр ягына карап тора. Аннары әкрен генә, тәмәкесен тартатарта китеп бара.*

*Ул киткәч, саклык белән генә Нәзирә чыга. Гайнетдиннәр өеннән, якягына каранып, Әкълимә пәйда була.*

Н ә з и р ә *(пышылдап диярлек).* Әкълимә! Кил монда!

Ә к ъ л и м ә *(йөгереп килә).* Нәрсә ди?

Н ә з и р ә. Кияүгә чык миңа, ди.

Ә к ъ л и м ә. Ә син?..

Н ә з и р ә. Никтер жаным тартмый минем ул кешегә.

Ә к ъ л и м ә. Ник болай нык калтыранасың? Әле сине алып китүче юк бит.

*Сәфәржан чыга. Кызлар янына килә.*

С ә ф ә р ж а н. Кызлар, нишләп йокламыйсыз инде? Тиздән таң ата.

Н ә з и р ә. Ә үзең ник йокламыйсың?

С ә ф ә р ж а н. Әллә нигә бер кайтып йоклап ятыйммыни? Йокым качты минем, кызлар. Әкълимә, туңасың, өстенә берәр нәрсә киярге иден. Бар инде, кер.

Ә к ъ л и м ә *(әле Нәзирәгә, әле Сәфәржанга карап ала).* Ярар алайса, сау бул, Нәзирә. *(Кереп китә).*

С ә ф ә р ж а н. Сине күрәсем килде. *(Кителен салып Нәзирәнең иңенә элә).*

Н ә з и р ә *(киеренкелек белән).* Таң атканда күрәсең килдеме?

С ә ф ә р ж а н. Минем сине тәүлек әйләнә күрәсем килә.

Н ә з и р ә. Клубка ник чыкмадың?

С ә ф ә р ж а н. Мине авыл халкы яратмый.

Н ә з и р ә. Яратмыйлар дип... Куркалар, шүрлиләр, диген. Яратмау түгел бит инде ул.

С ә ф ә р ж а н. Курыккан нәрсәне яратканнарын кайчан күргәнең бар?

Н ә з и р ә. Ә мин сине клубта көттем. Барысына ачу итеп, сине анда күрәсем килгән иде.

Сәфәрҗан. Ә клубка чыгып, янына килгән булсам? Кеше сүзеннән курыкмас идеңме?

Нәзирә *(елмаеп)*. Без бит күршеләр.

Сәфәрҗан. Ә миннән курыкмыйсыңмы?

Нәзирә *(сагаеп)*. Куркам. *(Җылы тавыш белән)*. Ләкин башкалар курыкканча түгел. Башка төрле курку белән куркам мин синнән. Никтер мин шул куркуымның булуына шат. Шул куркуымның дәвам итүен телим.

Сәфәрҗан. Мин китәм, Нәзирә. *(Күкрәк тутырып сулыш ала)*. Шушы һаваны озак елларга җитәрлек итеп тирәнтен сулап алырга иде!

Нәзирә *(боек тавыш белән)*. Тагын кайчан кайтасың?

Сәфәрҗан. Белмим. Бәлки, бөтән кайтмам да.

Нәзирә. Түзалмассың, кайтырсың. Син туган якны нык сагынасың.

Сәфәрҗан. Каян беләсең?

Нәзирә. Күренеп тора.

Сәфәрҗан. Бу дөньяда кадерле әйберләрдән, кадерле кешеләрдән, яраткан нәрсәләреңнән язмыш гел аерып тора инде ул. Рәхимсез рәвештә. Ә икенче яктан карасаң, дөнья син теләгәнчә генә барса да кызык булмас иде. Үзеңнең теләкләреңне, күңелең тарткан нәрсәләрне онытырга, юк итәргә дә үзеңдә көч табарга кирәк. Югыйсә акылдан язарга мөмкин.

*Сәфәрҗан Нәзирәнең кулын, кош тоткан кебек, ике куллап тота, өреп җылыта. Нәзирә тагын калтырана башлый.*

Нәзирә *(еламсырап)*. Сәфәрҗан абый! Сәфәр! Сәфәрҗан!

Сәфәрҗан. Асыл кош син, Нәзирә! Бар, кер инде, йокларыңа вакыт аз калды. *(Кызның иңеннән кителен алып кия)*.

*Сәфәрҗан үз йортларына таба китеп бара. Нәзирә беравык басып тора да өйләренә йөгереп кереп китә. Сәфәрҗан өйгә керәм дигәндә генә, караңгылык эченнән Фатыйх килеп чыга.*

Фатыйх *(усал тавыш белән)*. Сәфәрҗан! *(Килә)*.

Сәфәрҗан *(тыныч кына)*. Нәрсә булды, Фатыйх?

Фатыйх. Син кайчан китәсең?

Сәфәрҗан. Кайдан кая?

Фатыйх. Ни дигән сүз инде бу?

Сәфәрҗан. Үзең бит тузга язмаган сорау бирдең. Бу дөньяда кайдан кая китеп котылу мөмкин?

Фатыйх. Син авылдан тизрәк китәргә тиеш.

Сәфәрҗан. Бу — минем туган җирем.

Фатыйх. Син очраклы рәвештә монда туган кеше.

Сәфәрҗан. Бу дөньяда бернәрсә дә очраклы түгел.

Фатыйх. Ә син үзең нәрсә әйтмәкче буласың?

Сәфәрҗан. Син нинди ысул белән кайда тугансың, мин дә шулай ук дөньяга килгәнмен.

Фатыйх. Мин сиңа сер итеп кенә әйтәм... Синең белән район милициясеннән кызыксындылар. Сугыш беткәч үк, әле син авылга кайтканчы.

Сәфәрҗан. Ничек дип кызыксындылар?

Фатыйх. Син авылга кайтмадыңмы дип кызыксындылар.

Сәфәрҗан *(җикереп)*. Юкны сөйләмә! Минем тизрәк китүемне телисең син, шуңа әллә ниләр уйлап чыгарасың. Минем белән кем кызыксынса да, мин — разведрота командиры. Мин сугышны башыннан азагына кадәр үттем.

Фатыйх *(ярсып)*. Сәвит влачы аркасында туып-үсеп, белем алып, тылда ятар идеңме әллә?

Сәфәрҗан. Мин синең халәтеңне аңлыйм, эчеңдә ниләр кайнаганны, барлык уй-хисләреңне аермачык күрәм.

Фатыйх. Нәрсә аңлыйсың, нәрсә күрәсең?!

Сәфәрҗан. Хәрәкәтләреңнән, күз карашыңнан, сөйләшүеңнән барысы да аңлашыла. Мин сине үтәли күрәм, Фатыйх!

Фатыйх. Шулайдыр, әлбәттә. Женле Күлдә туган затта андый күрү сәләтләре тумыштандыр инде ул. *(Чиксез нәфрәт белән).* Син кеше түгел! Кыяфәтең кешенеке булса да, синдә җен утыра. Мин дә бит бераз күрә беләм!

Сәфәрҗан. Кайсыдыр шагыйрь әйткән бит: «...Күнелендә җеннәр оялаган икән, димәк, анда фәрештәләр яшәгән...» Ансы ярар. Туган җирне мин башкача, үземчә яратам, Фатыйх. Анам кабере юкка чыкмасын өчен, дошманга каршы сугыштым мин. Женле Күл элеккечә Женле Күл булып калсын өчен, кан койдым. Син дә туган җиреҥ өчен сугышкансыңдыр яуда. Әмма туган җиреҥ синеҥ бердәнбер кадерле нәрсәң түгел. Синеҥ табынган төшенчәләр тагын бар әле — Советлар Союзы, Москва, партия, Сталин...

Фатыйх. Ә синеҥ өчен алар юкмыни?!

Сәфәрҗан. Син мине аңлап бетермәдеҥ. Минем бер генә изге төшенчәм бар. Бер нәзек кенә җеп минем өчен изге урынга үзәгемнән сузылган, бер җеп кенә мине бәйләп тота туган җирем белән. Мин шул җепкә ябышам. Ябышам да өзелер дип куркам. Миндә үз-үземне белә-белгәннән бирле кимсенү хисе яши — дөньяда үземне артык, кирәкмәс кеше итеп тою бәгыремне гел ашап тора. Әйе, мин төнлә дә күрәм, кешеләрне үтәли күрү сәләтем дә бар. Шуна күрә бу дөньяның һәр төсе, һәр кыймылдавы, һәр сулышы аермачык минем өчен. Шуна күрә һәр капма-каршылык минем өчен анык күренә. Шуна күрә үземнеҥ бу дөньяда яшәвемнеҥ фаҗигасе никадәр тирән икәнне бер үзем генә беләм.

Фатыйх *(кинәт курка башлый).* Чынлап та шайтан син! Күренмә бүтән авылда! Женле Күлгә дә аяк басма! Халыкның болай да гел коты алынып тора! *(Кыҗрап).* Йөрмә монда! Югал! Кит! Күренмә!

Сәфәрҗан. Син чынлап та куркасың миннән. Чөнки син мине бала чакта җиңә алмадың. Хәзер дә җиңә алмыйсың. Буйсындыру хәлеңнән килми. Син андыйлардан нык куркасың. Тагын бер сәбәп бар әле — Нәзирә.

Фатыйх. Мин сине төрмәгә утыртам! Җаен табармын. Статьясы да табылыр.

Сәфәрҗан *(тыныч кына).* Кыбырсыма бу кадәре. Мин китәм.

Фатыйх *(таләпчән тавыш белән).* Кайчан?

Сәфәрҗан. Сәгать ничә?

Фатыйх *(кулындагы сәгатькә карап).* Иртәнге дүрт.

Сәфәрҗан. Бүген кичкә мин инде авылда булмыйм.

Фатыйх. Ярар. *(Кызу-кызу китеп бара).*

## 14

*Берничә көн үткән. 13 август. Ай тулган төн. Женле Күл. Төн. Сәфәрҗан, тирә-якка карап, иркен сулыш ала. Аннары түмгәккә утыра. Якында гына куак ботаклары шытырдаган тавыш ишетелә. Сәфәрҗан, сагаеп, урыныннан кузгала һәм шул якны күзәтә. Кинәт агачлар арасыннан Нәзирә килеп чыга.*

Сәфәрҗан *(шаккатып).* Нәзирә! Нишләп йөрисең монда?!

Нәзирә *(көчкә сулыш ала).* Синең яныңа килдем.

Сәфәрҗан. Тилердеңме әллә?

Нәзирә. Әллә тагы... *(Сәфәрҗанга сыена).*

Сәфәрҗан. Бөтен тирә-якны өркетеп торган Женле Күлгә килергә ничек йөрәгең җитте? Җитмәсә, төнлә!

Нәзирә. Ә мин синең монда икәнеңне белдем. Урманнан кайтучылар: «Женле Күлдә тагын кемдер йөри»,

— дип авылда сөйләделәр. Бүген ай тулганны күрдем дә синең монда икәненә шигем калмады.

Сәфәржан. Әйе, бүген ай тулды. Иртәнге өченче егерме җиде минутта. Ә шулай да ничек курыкмадың?! Әгәр мин монда булмасам...

Нәзирә. Сине бик күрәсем килде. Фатыйх белән сөйләшкәнегезне теге көнне тыңлап тордым. Шуннан соң ике көн өйдәгеләрдән качып еладым.

Сәфәржан. Ник еладың?

Нәзирә. Сине кызганып.

Сәфәржан. Тапкансың кызганыр затны. *(Житди кыяфәт белән).* Мин бит чыннан да җен!

Нәзирә *(Сәфәрҗаннын муенына куллары белән сарыла).* Ә миңа барыбер — җенме син, кешеме.

Сәфәржан *(югалып кала).* Ничек инде? Нәрсә булды сиңа?

Нәзирә *(елый).* Белмим.

Сәфәржан. Хәзер ник елыйсың? Һаман да мине кызганыпмы?

Нәзирә. Юк, сөенечтән. Сине күргәнгә куанып елыйм.

*Сәфәржан Нәзирәне кочагына ала.*

## 15

*Берничә ай вакыт узган. Көз ае. Нәзирә, чиләк күтәреп, коега суга бара. Аны күреп, Әкълимә өйләреннән чыга. Ашыгып Нәзирә янына килә.*

Әкълимә. Нәрсә булды сиңа, Нәзирә? Ник әйтмисең? Ничә көн инде кара көеп йөрисең!

Нәзирә *(кайгылы тавыш белән).* Харап булдым мин, Әкълимә.

Әкълимә. Мин синең иң якын иптәшең. Әйт инде! Фатыйхның бәйләнүеннән туйдыңмы әллә?

Нәзирә. Әйе, туйдым. Югыйсә яратмаганымны да белә бит инде. Инде миңа өйләнергә теләвен белгертеп, әти белән дә, әни белән дә сөйләшкән.

Әкълимә. Ярар. Ни дисәң дә, колхоз җитәкчесе бит әле.

Нәзирә *(Әкълимәгә туры карап).* Мин — Сәфәрҗанныкы.

Әкълимә. Бүтән кайтмыйм дип китте бит ул.

Нәзирә *(елый).* Шулай диде шул.

Әкълимә. Елама, монда әле бернинди кайгы юк.

Нәзирә *(ачынып).* Бар шул менә!

Әкълимә. Әйт, әйт, Нәзирә, нәрсә бар? Әйт тизрәк, коега кеше килгәнче.

Нәзирә. Мин авырга уздым, ахрысы.

Әкълимә *(һушсыз калып).* Нәрсә-ә-ә?

Нәзирә. Күзенне акайтма инде, болай да куркам. Баштарак анламый йөрдем. Хәзер инде шигем калмады.

Әкълимә. Кемнән соң ул?

Нәзирә. Кемнән булсын инде?! Сәфәрҗаннан! Башка кеше белән минем кочаклашканым да юк.

Әкълимә *(котсыз калып).* И Ходаем! Нишлисең инде хәзер?

Нәзирә *(ыңгырашып).* Нишләргә дә белмим шул! Әти үтерә мине! Торабара беленәчәк бит инде ул.

Әкълимә *(як-ягына каранып).* Тукта, елама, кеше күрә.

Нәзирә. Үләм мин. Адәм көлкесенә калам бит. Ничек төшерергә икән аны? Ничек әтиләргә белгертмичә эшләп була икән аны?!

Әкълимә. Туктале! Мин бүген үк Сәфәрҗанга хат язам.

Нәзирә. Кайда соң ул?

Әкълимә. Әлегә Казанда.

Нәзирә. Адресын беләсеңме?

Әкълимә. Беләм. Әле берничә ай шушында булам дип язган. Хат бер атнада барып җитә.

Нәзирә. Минем йөкле икәнемне белгәч, кайтмый да кайтмый инде ул монда.

Әкълимә. Сөрт күз яшьләренне! Бир чиләгенне, суны үзем алып бирәм. Елама, әнә, кемдер килә.

*Сәхнә караңгылана.*

## 16

*Шул ук күренеш. Шәйдуллалар йорты ягыннан кычкырган, елаган тавышлар ишетелә. Шәйдулла атылып чыга. Тыярга тырышып, Хәмдия анын артыннан йөгерә.*

Шәйдулла *(акырып)*. Үтерәм!

Хәмдия *(чәрелдәп)*. Кеше көлдермә! Тукта!

Шәйдулла *(хатынына сугып җибәрә)*. Сине дә үтерәм! Нәрсә карадың?! Синең кызыңны кем карарга тиеш?!

*Гайнетдин чыга. Шәйдулла, йөгереп килеп, аны түшеннән эләктерә. Тарткалаша башлыйлар. Нуржамал аларны араларга маташа, Хәмдия, елап, ары-бире йөгереп йөри.*

Шәйдулла *(ярсып)*. Синең җен малаең кызымны харап иткән! Үтерәм барыгызны да!

Гайнетдин *(тарткалашып)*. Тыныч кына сөйләшик әле, Шәйдулла!

Шәйдулла. Тыныч кына? Тәмам гарык булганием мин синнән, синең ул шайтаныңнан, өстәвенә тагын нәселемә бәла китердегез!

Нуржамал *(ялвара)*. Тынычлан, Гайнетдин! Сугышма! Халык күрә бит.

Шәйдулла. Күрсеннәр! *(Хәле бетә, еш-еш сулый. Хәмдиягә эндәшә)*. Бар, кызыңны алып чык монда! *(Хәмдия өйләренә йөгереп кереп китә. Шәйдулла анын артыннан кычкырып кала)*. Үтерәм сине дә, кызыңны да!

Гайнетдин *(ертылган күлмәген капшап)*. Бөтенебезне үтереп бетереп нишләмәкче буласың?

Шәйдулла *(ысылдап)*. Дәшмә, контра! Подсуд китәчәксез барыгыз да!

Нуржамал. Синең кызың балага узганга нишләп без подсуд китик?

Шәйдулла. Син имезеп үстерден ул шайтанны! Женле Күлдән иблис токымын алып кайтканыгызны шул вакытта ук күңелем сизгәние! Бүкәнгә куеп, балта белән урталайга чабасы калган аны!

*Хәмдия Нәзирәне житәкләп алып чыга. Ун адым чамасы ара калгач, Нәзирә кулын йолкып ала һәм бер урында басып кала. Барысы да Нәзирәгә текәлеп карап торалар.*

Шәйдулла *(шашкан кыяфәт белән)*. Оят! Хурлык! Позор!

Хәмдия *(ачыргаланып)*. Ник бөтен дөньяга фаш итәсең? Аза купмыйча гына, үзара бетереп булыр иде бит.

Шәйдулла. Нәрсә? Үтерәм мин сине! Кызыңны да бүген үк бәреп үтерәм! Үзара, тыныч кына?! *(Гайнетдингә күрсәтеп)*. Бу бетләләр белән шыпырт кына шушы позорны бетерергә кушасыңмы мина?! *(Хатынына кизәнә. Гайнетдин аны тота, сугарга ирек бирми. Хәмдия читкә тайпыла)*.

Нуржамал. Хәмдия, кит, кит, якын килмә!

*Фатыйх килә.*

Фатыйх *(ерактан ук кычкыра)*. Руки вверх! *(Барысы да тып-тын калалар)*. Нәрсә, яна сугыш башландымы әллә? *(Ямьсез итеп көлеп куя. Аннары барысына да күз йөгертеп чыга)*.

Шәйдулла. Менә боларның җен малае авылны мәсхәрәләде!

Фатыйх. Беләбез, беләбез. Өегездәге гауга әллә кайларга ишетелә.

Хәмдия. И Ходаем!

Фатыйх. Сәфәрҗаннан мин шушының ише бер пакостьне күптән көткәнием. Шуна күрә анын моннан тизрәк китүен теләдем. Әле бу анын соңгы зыяны түгелдер. Женле Күл тирәсен сукалатырга кирәк булыр. Ул урынны үзгәртергә кирәк. Халык та курыкмый башлар, яна бәлаләр дә килмәс.

Гайнетдин. Ул тарихи урынны сукаларга ярамый. Борын-борыннан халык аны шомлы урынга санаган икән, киресенчә, аңа тияргә ярамый. Анда кабер дә бар.

Шәйдулла. Син контра каберен изгеләштермәкче буласың! Син үзең дә контра, единоличник!

Гайнетдин *(жикереп)*. Минме контра?! Минем улым сугышта ятып калды. Мин — үз хезмәтем белән тамагымны туйдыручы! Минме контра?! *(Шәйдулланы якасыннан эләктереп ала)*. Мин синең шикелле сорыкорт булмадым беркайчан да!

Фатыйх. Ну-ка, ну-ка! *(Аерырга тотына)*. Мин югында сугышырсыз. Сәфәржаның кайда соң синең хәзер?

Гайнетдин *(усал тавыш белән)*. Сиңа барыбер түгелмени?

Фатыйх. Син минем белән алай сөйләшмә! Жавапка сине дә тарта алабыз.

Гайнетдин. Куркытма. Мин куркудан узган инде.

Фатыйх. Ничего, табарлар Сәфәржаныгызны.

*Нәзирә өйләренә йөгереп кереп китә. Фатыйх көлемсерәп карап кала.*

Шәйдулла *(кыжрап, Гайнетдингә ташлана)*. Үтерәм! *(Тагын сугыша башлыйлар. Нуржамал аларны араларга тотына, Фатыйх шаркылдап көлеп карап тора).*

*Көтмәгәндә Сәфәржан пәйда була. Барысы да баскан урыннарында катып калалар.*

Сәфәржан. Саулармысез!

Фатыйх *(чәнчүле тавыш белән)*. Бигүк сау түгел шул. Син монда кайберәүләрнең сәламәтлеген какшатып киткәнсең бит. Әле мондагы яңалыкны белмисеңдәдер.

Сәфәржан. Беләм. Тыңлап тордым.

Фатыйх. Алай икән. Ну, нәрсә әйтерсең? Нишләргә исәбең бар?

Сәфәржан. Мин Нәзирәне алып китәргә дип кайттым.

*Барысы да өнсез калып карап торалар.*

Шәйдулла *(кинәт кычкырырга тотына)*. Алып кит! Күземә күренмәгез! Авылда эзегез дә булмасын! Читкә китеп, теләсә нишләгез! Ник шунда дөмекмисез! Авылда эзегез дә булмасын! *(Абынасөртенә атлап, өенә таба китә).*

Хәмдия *(елый-елый иренә иярә)*. Каргама үз balаңны!

Шәйдулла. Синеке ул, минеке түгел!

*Карангылык.*

## 17

*1947 ел. Гайнетдиннәр йорты. Нуржамал йон эрли. Хәмдия керә.*

Хәмдия. Нихәлләрең бар, Нуржамал?

Нуржамал. Бер көе. Утыр.

Хәмдия *(сәке читенә утыра)*. Нәзирәне уйлап, күз яшьләрем калмады инде. Сезгә хатлары килә, ахрысы...

Нуржамал. Сәфәржан язгалап тора.

Хәмдия. Закамскида яшиләр икән, ансын беләбез. Ниләр дип яза соң?

Нуржамал. Әйбәт кенә яшәп яталар. Малайлары туган. Кәрәм дип исем кушканнар.

Хәмдия *(сыкранып)*. Яннарына барып кайтыр идем, Шәйдулла йодрыгын селкергә тотына. Бала кемгә охшаган икән?

Нуржамал *(елмаеп)*. Тач сезнен Нәзирәгез, ди.

Хәмдия. Харап булды кызым, хараплар булды. Кайлардан китереп

чыгара бит язмыш хәсрәтләрне.

Нуржамал. Бер дә харап булмады кызын. Сәфәржан күмер бушату базасында нәчәлник урынбасары, кызыңның тамагы тук, арты жылыда.

Хәмдия. Ә авылдагы яманатын кая куясың?

Нуржамал *(коры гына)*. Кызын башын югалтканга кем гаепле?

Хәмдия. Ник алай каты бәреләсең син миңа, Нуржамал? Мин болай да ут йотып яшим.

Нуржамал. Безгә гомергә каты бәрелделәр — аерым хужалык булганыбыз өчен дә, Сәфәржан аркасында да. Кайгы-хәсрәтне дә сездән ким күрмәдек.

Хәмдия. Анын каравы балаларыннан уңдың. Заһид геройларча һәлак булган. Зөфәрең акыллы егет булып чыкты, кала кызына өйләнеп, шунда төпләнде. Кыз бала апкайтканнар дип ишеттем. Әкълимәгезгә күрше авыл көрәшчесе өйләнде. Бәхетле кеше син.

Нуржамал. Сәфәржан да безнең улыбыз. Шуна күрә синең кызыңа жил-яңгыр тигезмәс, гаиләләре дә начар булмас.

Хәмдия. Жен малае дигән табы балаларына да йокмас микән?

Нуржамал. Йокса да, йокмаса да, синең кызың Нәзирә тапкан бала инде ул хәзер.

*Хәмдия чыгып китә. Гайнетдин керә.*

Гайнетдин. Хәмдия ник кергән?

Хәмдия. Шыншырга. Аны да аңлап була инде. Кара көеп, тәмам какчаланып беткән. Өстәвенә Шәйдулласы көне-төне желеген суыра — кызы өчен битәрли. Кыйный да бугай.

Гайнетдин. Мин Иштерәк кешесен очраттым, сыер алырга килгән. Миңа эш бар ул авылда. Мунча житкерергә. Берничә көннән шунда барам.

*Шәйдулла керә.*

Шәйдулла *(кыюсыз)*. Исәннәрмесез.

Гайнетдин. Исәнме.

Шәйдулла. Хәмдия сезгә кергән булган икән...

Нуржамал. Кергәние шул. *(Әле иренә, әле күршесенә карап алганнан соң)*. И-и-и, мин бүген тавыкларымны ашатмадым бит! *(Ирләр әңгәмәсенә комачауламас өчен, тиз генә чыгып китә).*

Шәйдулла. Кергәнемә аптырыйсыңдыр?

Гайнетдин. Бу дөньяда мине аптыратырлык нәрсә калмагандыр инде ул.

Шәйдулла. Чөнки син үз туган авылыңда, үз туган жиреңдә башкалар кебек яшәмисең. Тыңгылык тапмавың да шуннан. Аерым хужалык булуың да беркайчан кимсетмәде үзеңне.

Гайнетдин. Яшәү рәвешем кимсетерлек булса, мин алай яшәмәс идем. Кеше үзен үзе генә кимсетә ала. Ә тыңгылык тапмауга килгәндә... Синең кебекләр аркасында шулай ул. Житәкче булып торганда да, беркайчан үз авылың, үз халкың өчен тырышып яшәгән кеше түгел син. Влач нәрсә әйтер дип, влач үзгәргәнгә карап үзгәреп, гомер буе авылдашларның күнеленә коткы иңдереп яшәдең.

Шәйдулла. Чөнки минем үземне гел куркытып тордылар. *(Паузадан соң)*. Мин синең белән талашырга дип кермәдем. Фатыйх районнан рөхсәт алып кайткан имеш, Женле Күлдә берәрсе күренсә, атып үтерәчәкләр икән.

Гайнетдин. Ник миңа әйтәсең моны?

Шәйдулла. Бу турыда Сәфәржанга хәбәр ит. Ай тулган төннәрнең берсендә Женле Күлгә килеп чыгуы ихтимал. Бәладән баш-аяк!

*Шәйдулла чыгып китә.*

## 18

*1959 ел. Закамск шәһәре. Уртача гына җиһазланган фатир. Нәзирә олыгайган. Ул, борчылып, тәрәзәдән тәрәзәгә йөри.*

Нәзирә *(үзалдына).* Кайда икән ул?.. Унбишенче көн бит инде... *(Хәлсезләнеп, урындыкка утыра).*

*Сәфәрҗан кайтып керә. Озын плащтан, аягында күнитек, башында фуражка.*

Нәзирә *(йөгереп килә).* Кая югалдың син? *(Иренә чишенергә булыша).*

Сәфәрҗан. Чак кына теге дөньяга олакмадым. Хәер, күп калмады бугай инде. *(Хәлсезләнеп, караватка ята).*

Нәзирә *(иренең аягындагы күнитекләрне салдырырга тотына).* Нишләп эшкә чыкмый, кайда ул, дип эшеңнән килеп йөдәттеләр.

Сәфәрҗан. Син нәрсә дидең?

Нәзирә *(караватк кырыена утыра).* Нәрсә дим, белмим, дидем. Кайда булдың соң син?

Сәфәрҗан. Беләсең бит инде кайда булганымны. Кәрәм нишли?

Нәзирә. Йоклый. Ул инде сине эзләп авылга кайтырга җыенган иде. Әти Женле Күлдәдер, барып алып кайтам, дип юлга җыена башлады. Көчкә тыйдым. Нишләп анда булсын ул, мәйтәм, йөрмә анда барып, дип начылый күңдердем.

Сәфәрҗан. Ярый тыйгансың әле.

Нәзирә. Ник сөйләдең соң син улыбызга Женле Күл турында?

Сәфәрҗан. Ул үзенең атасы турында барысын да белергә тиеш.

Нәзирә. Соңгы вакытта ул Женле Күлне еш телгә ала. Күңеле шунда тарта. Куркам мин. Синең кебеккә әйләнсә... Ник син аңа ай тулган төннәрдә Женле Күлгә очып барасы килүең турында әйттең? Хәзер анарда да шундый теләк туа башласа?

Сәфәрҗан. Ул сиңа охшаган, минем юлдан бармас. Мин аңа яхшылап аңлатырмын.

Нәзирә. Без синең белән әйбәт кенә яши башлаган идек. Эшеңдә дә бик тиз күтәрделәр үзеңне. Инде җаныңа тынгылык табар вакыт бит. Үзеңне берәр ничек үзгәртә алмыйсыңмыни соң син?

Сәфәрҗан. Табигатьне алдап булмый.

Нәзирә. Авылга кайта алмавыма да, синең холкыңа да — барысына да күндем бит инде мин. Улың хакына гаиләдә тынгылык яса! Газабыңны җиңә алырлык көч бар бит синдә. Женле Күл беркая да китми, үз урынында тора ул. Ананның каберен дә карап торучы бар. Мин дә туган ягымны өзелеп сагынам бит!

Сәфәрҗан. Без синең белән икебез ике төрле тартылабыз туган якка. Син — туган җиреңә кире кайтасы килгәннән. Мин — туган җирем барлыгын исбатларга теләгәннән.

Нәзирә. Ашарга җылытыйммы?

Сәфәрҗан. Соңрак. Ятып торыйм әле. *(Түшәмгә карап ята).*

Нәзирә. Берничә ел түздең бит анда кайтмыйча.

Сәфәрҗан. Табигатьтән дә көчлерәк булу мөмкин түгел. Мин ай тулган төнне шул урында дөньяга килдем, шуңа гына җаным тарта минем анда. Шуннан да гайре табигыйрәк сәбәпләр эзләмә.

Нәзирә. Эшеңнән чыгарсалар?..

Сәфәрҗан. Миңа барыбер хәзер.

Нәзирә. Нишләп бу юлы озак тордың?

Сәфәрҗан. Миңа аттылар. Ау мылтыгыннан. Бикләл авылына көчкә барып җиттем, каным күп акты. Бикләндә бер яхшы танышым яши. Фронтта бергә булдык. Шуларда яттым. Бүлнисләргә барасым килмәде.

Авылның мал врачын чакырып, тәнемдәге ядрәләрне алдырдык. Бавырда берничәсе калды.

Нәзирә. Кайда аттылар?

Сәфәрҗан. Женле Күл буенда. Дөресен әйткәндә, атып үтерергә җыенганнарын белгәч, кичекмәстән кайтырга булдым. Житте. Озаграк торылды бу дөньяда.

Нәзирә. Бүлнискә яткырырга кирәк сине. Операция ясарлар.

Сәфәрҗан. Кирәкми. *(Борылып, Нәзирәгә карап ята).* Син бит минем үлүемне телисең.

Нәзирә *(сискәнеп).* Тилерденме әллә?!

Сәфәрҗан. Мин бит күрәм, Нәзирә, сине үтәли күрәм.

Нәзирә. Синең шундый сәләтең барлыгын беләм.

Сәфәрҗан. Мин үлсәм, сиңа авылга кайтырга җиңелрәк булачак. Мин бу дөньядан китсәм, сине атаң да, авылдашлар да гафу итәчәкләр.

Нәзирә *(нәфрәтләнеп).* Кеше түгел син! Шуңа гашыйк булганмындыр мин сиңа. Син мине сихерләдең — күз карашың, тавышың, хәрәкәтләрең белән. Син кеше булсаң, ул төнне Женле Күлгә сине эзләп барыр идеммени!

Сәфәрҗан *(елмая).* Ә мин шулай килеп чыгасын алдан ук белдем.

Нәзирә. Син бит мине яратып үзеңнеке итмәдең, шулаймы?

Сәфәрҗан. Сәбәпләрнең берсе — атаң Шәйдулладан үч аласым килүдә. Авылдашлардан, Фатыйхтан үч аласым килде.

Нәзирә. Ә минем язмышым турында аз гына да уйлап карамадыңмы?

Сәфәрҗан. Юк, ул турыда уйламадым.

Нәзирә *(үзен кая куярга белми).* Син чыннан да җен!

Сәфәрҗан. Төп сәбәп алардан үч алырга тырышуда түгел. Тамырымны авылга тирәнрәк җәелдерергә теләдем мин. Миндә гел бер курку яшәде — авылдан йолкып алып, читкә олактырырлар да, мин дөньяда урынсыз, туган җирсез калырмын дигән курку. Дөньяга чит-ят булудан курку мине хәйләкәрлеккә өйрәтте.

Нәзирә *(елый).* Мин авылыма да кайта алмыйм. Әнкәйне дә күмәргә кайта алмадым. Мин хәзер үзем туган җиремнән йолкып алынган агач сыман. Нинди язмыш бу?! Кем каргаган икән мине?

Сәфәрҗан. Мине кем каргады икән?

Нәзирә. Син көчле, син — башкалар күрмәгәнне күрүче! Мин, бәлки, шуңа күрә сиңа гашыйк булганмындыр да, шуңа акылымнан язып, синең кочагыңа барып кергәнмендер. Син әкиятләрдә генә була торган сәләтләргә ия, нишләп мине дә, үзеңне дә бәхетсез итәргә омтылып яшисең син? Ярар, миңа төкергән, суратта дә үзең нишләп болай бәхетсез соң син? Нишләп яктылыкка түгел омтылышың, нишләп һәрвакыт фаҗигаләргә каршы атлыйсың?

Сәфәрҗан. Артык күп күргәнгә, артык күпне аңлаганга күрә. Гафу ит мине, Нәзирә. Мин сиңа рәхәт күрсәтә алмадым. Һәм ул мөмкин дә түгел иде. Үзе газап белән яшәүче башкаларны бәхетле итә алмый!

## 19

*1960 ел. Гайнетдин йорты. Өстәлдә самавыр. Сәфәрҗан белән Гайнетдин утыралар.*

Гайнетдин. Мунчага су ташып куелган. Хәзер анаң ягып җибәрә, мунча керерсең.

Сәфәрҗан. Авылда нинди яңалыклар бар?

Гайнетдин. Хәмдияне җирләгәнне хатта яздык инде. Бүтән зур яңалыклар юк шикелле. Зөфәр калада стройкада эшли. Килен, шәһәрнеке булса да, бик инсафлы, акыллы кыз

булып чыкты. Ике кызлары бар иде, менә тагын малай апкайттылар. Булат дип исем куштылар. Әле күптән түгел барып кайттык яннарына. Женле Күлдә облава ясадылар. Кемгәдер, нәрсәгәдер аттылар. Кан аккан. Бүре булды бугай, диделәр.

Сәфәрҗан. Женле Күлгә таба завод төзелеп килә икән.

Гайнетдин. Трассаны шуннан сузарга тиешләр. Женле Күлгә ком ташып, ул тирәләрне корытып тигезләргә маташалар, ди.

Сәфәрҗан. Женле Күлгә тимәсләр. Күңелем сизә.

Гайнетдин. Шәһәр киңәя шул. Завод торбалары инде күренеп үк тора. Кадалып китсен заводлары, калалары, торбалары. Бик ябыккансың, Сәфәрҗан. Дөньяда үзеңә урын табалмыйсың сыман. Монда минем дә гаебем бар шул.

Сәфәрҗан. Гаеп һәр кешедә була. Кемдә күпме гаеп барын ничек итеп нинди бизмәннәрдә үлчәргә мөмкин соң?

Гайнетдин. Син — тирән күрә белүче, сизгер, көчле кеше, нишләп болай хәлсезләндең?

Сәфәрҗан. Күп күрү, артык сизгер булу — кеше өчен җәза. Дөньяның ямен табалмадым. Мин аны артык тирән күрдем, артык нечкә тоемладым. Сизгер булу минем тормышымны фаҗигале итте. Кешеләрне үтәли күрә белүем, төнлә күрүем мине детдомнарда, сугышларда исән калдырды. Әмма яши-яши, дөньяның нечкәлекләрен тою миндә курку уятты. Курка башладым соңгы вакытта. Нидән, кемнән — белмим. Миңа бик авыр. Газабым кичеп чыккысыз минем. Бернишләтә алмыйм.

Гайнетдин. Сиңа ял кирәктер. Онытылып тор, башыңны ял иттер.

Сәфәрҗан. Юк, яшәүдән ял итү мөмкин түгел.

Гайнетдин. Синең йөзеңнән төс качкан, ятып тормыйсыңмы?

Сәфәрҗан. Ятырга житешермен. *(Гайнетдингә туры карап).* Әти, миңа яшәргә күп калмады — санаулы көннәр генә. Мин үләргә кайттым. Мине Женле Күл буенда, анам кабере янында күмәрсең, яме. Беркемгә белгертмичә, тиз генә җирләрсең. Алайса анда күмәргә рөхсәт итмәсләр.

Гайнетдин *(тетрәнеп).* Нинди үлү турында сөйлисең, Сәфәрҗан, улым?! Чирләп алулар була инде ул... Терелерсең, савыгырсың, Аллаһ боерса.

*Шәйдулла керә.*

Шәйдулла *(басынкы тавыш белән).* Исәнме, Сәфәрҗан.

Сәфәрҗан. Исәнме.

Шәйдулла. Кайтканыңны әйттеләр... Нәзирә, Кәрәм ничек анда?

Сәфәрҗан. Шул бер юнәлештә — Кәрәм үсә, Нәзирә картая бара.

Шәйдулла. Хәмдия вафат булды... Сезгә хәбәр биргәниек...

Сәфәрҗан. Мине эштән җибәрмәделәр, Нәзирә кайтырга курыкты.

Шәйдулла. Яныгызга үзем барып кайтырга җыенып йөри идем.

Сәфәрҗан. Барып кайт, барып кайт. Кызыңны каргап, куып җибәргәнеңә ундүрт ел бит инде.

Шәйдулла *(ян сәке читенә утыра).* Озакка кайттыңмы?

Сәфәрҗан. Мәңгегә.

Шәйдулла. Закамскига синең белән бергә барсам дигәнием...

Сәфәрҗан. Минем әле керәсе җирләрем бар. Үзең генә барырсың.

Шәйдулла *(кузгала).* Ярар, намаз вакыты җитә.

Сәфәрҗан (көлемсерәп). Намазлыкка бастыңмыни?

Шәйдулла *(ишек катында туктый).* Әлхәмдүлиллаһ, намазны укыйм.

Сәфәрҗан. Гадәттә, намаз укыганда, догалар кылганда, Ходайдан чынбарлыкны яхшы якка үзгәртү турында сорап ялваралар. Кешеләр никтер үзләрен үзгәртүне сорамыйлар. Намазлар укыганда, Аллаһтан үзеңне Кеше итүен сора, Шәйдулла агай.

Шәйдулла *(шомраеп).* Бәлки башка төрле үтенечең дә бардыр миңа?

Сәфәрҗан. Бар! Минем өчен дога кыла күрмә, яме! Кимсетә күрмә мине!

*Шәйдулла чыгып китә.*

Гайнетдин *(паузадан соң).* Синең кайсы төшең авырта соң, улым?

Сәфәрҗан. Тән авыртуына түзәрлек, җан сызлавына чыдарлык түгел, әти. *(Авыр сулап куя).* Һәр кешенең үз шайтаны, үз фәрештәсе була, диләр. Алар кеше җаны өчен үзара көрәшәләр, имеш. Барыбер табигатьне алдап булмый!

Гайнетдин. Син сугышны кичкән егет, бирешергә ашыкма!

Сәфәрҗан. Шунсы кызык: сугышта минем төнлә күрүем, кешеләрне кыяфәтләреннән «укый» алуым, тирәнтен сиземләвем башка юнәлеш алган иде — күргәнемне, тойганымны җан газабына әверелдерми башладым. Фронтта кан, кайгы, вәхшилек күп булгангадыр инде. Сугышта мин башкаларга хас булмаган сыйфатларым аркасында исән калдым. Кайвакыт бер хыял миндә калка иде — җан газабын, бәгырь сызлавын тәгаен җенсәм, сугыштан соң да эчке сыкравым бимазаламаса, дөньяны үзгәртү сәләтенә ия булыр идем шикелле. Табигатьне алдап булмый шул.

Гайнетдин *(аңышмыйча утырганнан соң).* Врачлар нәрсә ди соң?

Сәфәрҗан. Мин врачка күренмәдем. Барыбер бавырдагы ядрәләрне алып булмас иде.

Гайнетдин *(паузадан соң).* Женле Күлдә күренгәннәрне атачаклар, дип мин сиңа хәтта язган идем бит.

Сәфәрҗан. Ә мин шуны белгәч, атсыннар дип, махсус кайттым. Мин аларның барысын да караңгыда аермачык күрдем. Араларында мылтык тоткан Фатыйхны күргәч кенә: «Юк, бүген түгел! Фатыйх мылтыгыннан түгел!» — дип урманга таба йөгердем.

Гайнетдин. Син үзеңнең сәләтләрең белән бу дөньяда бәхетле булырга тиеш иден бит, югыйсә. Женле Күлгә йөрүдән туктасаң, бәлки, төрле сәерлекләреңә игътибар итмәсләр иде. Үзеңнән тора бит барысы да. Башкалар шикелле булу хәлеңнән килмәс идемени?

Сәфәрҗан. Мин гел үземне иң бәхетсез кеше дип санадым. Туган җирем бар икәнне үземә дә, башкаларга да көн саен исбатлап торасым килгәннән, туган туфрагыма тартылу миндә чамадан тыш көчле хискә, хәтта ки чиргә әверелде. Кешеләрне тирәнрәк аңлаган саен, күбрәк күргән саен, туган якка сусавым көчәйде.

Гайнетдин. Миндә гаеп... Сине саклау хәлемнән килмәде.

Сәфәрҗан. Әйе, синдә гаеп зур. Мине Женле Күлдән алып кайтмаска иде сезгә. Шул ай тулган төнне туып, шул ук ай яктысында үләргә кирәк иде мина.

Гайнетдин *(җан ачысы белән).* Ни сөйлисен син, Сәфәрҗан?!

Сәфәрҗан. Ник туа бу кеше, нигә килә икән дөньяга? Нинди генә көчле булма, гомереңнең теләсә кайсы мизгелендә ярдәмсез, чарасыз, өметсез калуың ихтимал.

Гайнетдин. Шуңа күрә нигә килә кеше дөньяга дигән сорау беркайчан урынлы булалмый, улым. Дөньяга килгән бер җан иясе дә бу сорауга җавап бирәлмый. Ник туганын ана беркем әйтми, аңлатмый, ә үзе ул аны аңларга сәләтле түгел. Ник туганын аңларга тырышып, аның гомере үтеп китә. *(Елый).* Нишли алам мин синең өчен, улым? Әйт!

Сәфәрҗан. Мине Женле Күл буенда, анам кабере янында җирлә.

**20**

*1981 ел. Зөфәр белән Булат капка төбендәге утыргычта утыралар. Булат солдат киеменнән.*

Зөфәр *(моңсу тавыш белән).* Менә шулай, Булат улым. Әти дә, әнкәй дә юк инде, урыннары җәннәттә булсын. Без дәвам итәбез нәселне. Синдә минем өметем, алга таба бу нигезне син сакларга тиеш

буласың. *(Тирә-якка күз йөртеп).* Ниндидер бушлык тоям. Житмәсә, Шәйдулла абыйлар пужумы буш тора. Йорты, каралты-курасы да нык әле, югыйсә.

Булат. Әти, без әби белән бабай каберендә булдык. Женле Күлгә, Сәфәржан абыйның каберенә кайчан барабыз?

Зөфәр. Иртәгә инде, улым, бүген ардырды. Аның каберен дә, анасыныкын да гел карап торам. *(Тирән сулап).* Калага бөтенләй китәсем килми. Шушында гына яшисе килә. Анаң мине гел битәрли. «Ике арада калган кеше син — ни шәһәрнеке, ни авылныкы түгел!» — ди миңа.

Булат. Калага унике чакрым гына. Авылда яшәп, эшкә шәһәргә йөрергә мөмкин. Жиде рейс автобус йөри икән хәзер.

Зөфәр. Әйе, жайлы хәзер, юл да әйбәт.

*Кәрәм килә.*

Кәрәм. Нихәл, Зөфәр абый!

Зөфәр. Сәлам!

Кәрәм. Улың армиядән кайттымы? *(Кул биреп күрешә).*

Зөфәр. Аллага шөкер, улым кайтты.

Кәрәм *(Булатка).* Мине танымыйсыңмы?

Булат. Юк.

Кәрәм *(серле елмаеп).* Хәер, мине хәтта Зөфәр абый да танымый.

Зөфәр. Мин сине ферма төзүче шабашникларның бригадиры дип беләм.

Кәрәм. Нәкъ шулай. Авылга көнаралаш кайтасың, ахрысы?

Зөфәр. Пенсиягә чыккач, бөтенләйгә кайтырга исәп. Менә күрше мәрхүм Шәйдулла агайның йорт-жирен кызганып утырам әле. Әрәм булыр инде.

Кәрәм *(катгый итеп).* Юк, юк, әрәм булмаячак!

Зөфәр. Каян беләсен?

Кәрәм. Беләм, Зөфәр абый, беләм. Булат укырга жыенамы, эшкә керәме?

Булат. Эшкә урнашырга уйлыйм. Институтка читтән торып укырга керәчәкмен.

Кәрәм. Маладис! Планнарың зурдан икән!

Булат *(гаҗәпсенеп).* Минем исемемне каян беләсез?

Кәрәм. Мин әллә ниләр беләм әле. Ярый, мин шушы тирәгә күз салырга дип кенә килгәнием. Исәнлектә очрашырга язсын.

Зөфәр. Сау бул!

*Кәрәм китә.*

Булат. Бу төзүче шабашниклар бригадирымыни?

Зөфәр. Әйе. Бик оста куллы төзүче, диләр моны.

Булат *(уйга калып).* Миңа бик таныш шикелле бу кеше.

Зөфәр. Таныш кебек кешеләр очрый инде ул. Таныш түгелләре дә авылыбызда күп хәзер.

Булат. Женле Күл элеккечәме?

Зөфәр. Кызганычка каршы, бигүк элеккечә курыкмыйлар хәзер Женле Күлдән. Кала ягыннан завод торбалары якыная. Шул тарафтан үтәргә тиеш икән торбалар. Женле Күлне, андагы ике каберне нишләтерләр — белгән юк. Туган якны житәкчеләребез элек тә якламады, хәзер бигрәк тә! Совхозыбызнын директоры — килгән килмешәк, партком секретаре да — читтән китереп куелган кеше. Аларга авыл тарихы, аның табигате, аның риваятьләре кирәкмени?! Женле Күлдә соңгы вакытта тагын кемнедер бик еш күрәләр. Мин үзем әллә нигә бер каберләрне карарга гына барып кайтам. Кемдер, нәрсәдер бар анда.

Булат *(кинәт сорап куя).* Кайчан ай тула?

Зөфәр. Числинниктан карарбыз. Әйдә, керик.

*Өйгә кереп китәләр.*

## 21

*1981 ел. 17 июнь. Иртәнге 4 сәгать 4 минутта ай тулган. Женле Күл. Булат курка-курка гына бара. Туктап, тирә-якка колак салып тора, як-ягына карана. Күпмедер вакыт узгач, каршысына бер шәүлә чыга. Булат котсыз калып карап тора. Өрәк капюшонлы озын плащ кигән.*

Булат *(куркуын жиңеп).* Кәрәм абый, синме?

Кәрәм *(капюшонын сала).* Мин бу, Булат энем. Мин — Сәфәржанның улы Кәрәм!

Булат. Мин сине таныдым, әмма кем икәнеңне эти янында әйтмәдем инде. Моннан дүрт ел элек, 1977 елда очрашканыбызны да беркем белми. Нишләп этидән үзеңнең кем икәнеңне яшерден?

Кәрәм. Кем икәнемне Зөфәр абый тиздән белер. Мин калада төзелеш трестының нәчәлник урынбасары булып эшлим. Отпуск алдым да, ферма төзүчеләрнең бригадиры дигән булып, авылга яшерен рәвештә килдем. Әүвәл бу тирәне, кешеләрне шыпырт кына күзәтергә теләдем. Аннары авылны, Женле Күлне саклап калу эшенә тотыначакмын.

*Карангылык эченнән кемдер килә.*

Булат. Нинди шәүлә анда?

*Зөфәрнең тавышы ишетелә: «Булат!»*

Булат. Әти бит бу! Әти! Кил монда!

*Зөфәр килә.*

Зөфәр *(курка-курка килә).* Уф, көчкә килеп життем.

Булат. Әти, беләсеңме бу кешенең кем икәнен?

Зөфәр *(еш-еш сулап).* Беләм. Сәфәржанның улы Кәрәм. Безнең туганыбыз. Ул атасына да, Нәзирәгә дә ның охшаган. Безнең янга килеп сөйләшкәндә, аның һәр хәрәкәте, сөйләшүе Сәфәржанны хәтерләтте. *(Елмаеп).* Мин танымаган булып кыландым. Үзе әйтер әле, мәйтәм.

Кәрәм *(шатлык белән).* Зөфәр абый!

Зөфәр. Кәрәм! *(Кочаклашалар).*

Булат. Син аның нинди зур нәчәлник икәнен беләсеңме соң?

Зөфәр. Беләм. Анасы Нәзирәдән хат килде, барысын да язган.

Кәрәм *(моңаеп).* Әни дә олы яшьтә инде. *(Паузадан соң, жанланып).* Мин аны авылга алып кайтам, яңа йорт салып бирәм.

Зөфәр. Әйе, Нәзирә авылны ның сагынгандыр, күпме еллар үтте бит инде.

Кәрәм. Атам Женле Күлдә туып, сезнең йортта үскән, анам — күрше нигездән. Димәк, минем туган жирем шушында, Зөфәр абый, шулай бит?

Зөфәр. Әлбәттә! *(Борчулы тавыш белән).* Тик менә моннан торбалар үтәчәк, диләр бит, авыл үзе дә куркыныч астында дип сөйлиләр.

Кәрәм. Юк, юк! Көрәшә торгач, мин проектларны үзгәрттердем. Инде имзалар да куелды — торбалар читтән үтәчәк, трассалар да авылга тимәячәк. Туган жирне, туган якны саклар өчен, бар көчемне куячакмын. Бу — минем бурычым!

Зөфәр. Рәхмәт яусын сиңа, энем! Их, атаң исән булса, ның горурланыр иде синең белән. Инде аңа кырын караучы да булмас иде.

Кәрәм *(Булатны иңеннән кагып).* Булатны үзебезнең трестка эшкә алырмын. Сезгә дә, Зөфәр абый, яңа йорт салырбыз.

## 22

*Булат сөйли.*

— Сәфәрҗан улы Кәрәм бик абруйлы, даны еракларга таралган шәхескә әйләнде. Трест җитәкчесе итеп билгеләнгәннән соң, ул авылыбызны да, аның тирәсендәге мохитне дә төзекләндерү, җыештыру эшен үзенә максат итеп куйды. Җенле Күл дип аталган серле, сихерле урыннан ул чын мәгънәсендә бакча ясады. Каладан сузылган торбалар, трассалар читләтеп уздырылды. Сазлыклы урыннары киптерелде, тирә-ягы чүп-чардан арындырылды. Ике кабер урнашкан җирдә, күп тә үтмәде, җыйнак кына яна зират барлыкка килде.

Хәзер инде мин үзем дә олы яшьтәге кеше. Җенле Күлгә барган саен, андагы тынычлыкка, иминлеккә, һавасының татлылыгына сөенеп туя алмыйм.

Хәзер инде халык элеккечә курыкмый Җенле Күлдән. Кемдер балык үрчетеп маташа. Шашлык пешерергә каладан киләләр. Зираттан да кеше өзелми, туганнарының каберләрен карарга гел килеп-китеп торалар. Янәшә генә үткән юлдан тыз-быз машиналар чаба. Әйтерсең лә бу төбәктә беркайчан бернинди фаҗига булмаган. Яшәү дәвам итә. Шулай тиештер инде, күрәсең...

Шул ук вакытта миндә ниндидер бер сәер тынгысызлык хисе сулкылдый — кешеләрнең соңгы вакытта Җенле Күлдән курыкмаулары куркыта башлады мине. Бу урынның шомы, тәэсире тәмам бетәр дә Сәфәрҗанны онытырлар дигән курку яши миндә.

Туган якның тарихын онытып, Туган җирне югалтудан тора-бара курыкмаслар нишләрбез дигән уй мине торымнан-торымга котсыз калдыра башлады.

*Тәмам.*

**14 сентябрь, 2010 ел —**
**28 июль, 2011 ел.**

---

## Электрон почта да төпсез түгел

**Редакциягә әсәрләр, мәкаләләрнең фәкать машинкада басылган яки компьютердан чыккан кульязмалары гына кабул ителә. Бер биттә 30 юл (компьютер текстында да!), бер юлда (сүз араларын да исәпләп) 60 тамга булырга тиеш. Кәгазьнең бер ягы буш кала. Машинка текстының беренче нөсхәсе генә кабул ителә. Компьютер текстының дискеты да булу кулай.**

**Хатлар исә, җинел танылырлык итеп, кулдан да язылырга мөмкин.**

**Редакциянең электрон адресына фәкать кечкенә күләмдәге язмалар (хатлар, документлар, фикерләр һ.б.) гына кабул ителә.**

**Электрон адреска күләме 5 биттән арткан язмалар җибәрелгән очракта, почта аша аның оригиналын (кәгазьгә басылган вариантын) алгач кына әсәр кабул ителгән санала.**



Ләйсән Фәтхетдинова

# СҮЗ КЫЙММӘТЕ БҮГЕН — ИХЛАС ФИКЕР

## Мәгънә

*Дөньяның малыннан баш тарттым —*
*Яшәүнең кызыгы калмады...*
*Акчага кул сузган чакта да*
*Бер рухи рәхәтлек алмадым.*

*Котылдым нәфестән мизгелгә,*
*Бушады бар дөнья, карашым...*
*Тик нәфес тудыра икән лә*
*Җир—дөньяга гашыйк баласын!*

*Авырту тоймадым тәнемдә —*
*Кадерен оныттым саулыкның.*
*Чирләгән, иң авыр чагымда*
*Иманым белән мин савыктым.*

*Әйләнә—тирәдә кешеләр,*
*Тоймадым аларның кирәген.*
*Үземне кирәксез тойганда*
*Сыкрады «битараф» йөрәгем!*

*... Дөньяның малыннан баш тарттым —*
*Яшәүнең кызыгы калмады...*
*Акчага үрелгән чакта да*
*Илаһи рәхәтлек алмадым.*

*...«Шигырең мәгънәсез», дисәң дә,*
*Ышанам... син мине аңладың!*

***

*Мин иҗатка кайтам...*
*Әмма хәзер*
*кыйммәте дә башка сүзләрнең.*
*Мин, мөгаен, күп әйтергә теләп,*
*Мөмкин кадәр азрак сөйләрмен...*

Ләйсән ФӘТХЕТДИНОВА (СОЛТАНОВА) – *шагыйрә, «Тере тынлык» исемле китап авторы. Казанда яши.*

*Сүз кыйммәте бүген — ихлас фикер.*
*Тик күп булса ул да — кадерсез.*
*Кешеләрнең соңгы йорты — зират,*
*Ә гомерсез сүзләр — кабердсез...*

*Мин иҗатка кайтам...*
*Әмма хәзер*
*кирәге дә аз бит сүзләрнең.*
*Мин, мөгаен, кайчак, дәшми генә,*
*Чиксез фикерләрне сөйләрмен...*

***

*Буын арты буын алышына,*
*Тормыш алышына гүяки...*
*Ничек кенә, кайчан яшәсәк тә,*
*Күп сөйләсәк, хәтта дәшмәсәк тә,*
*Юлыбыз бит безнең бер, ләкин...*
*Нинди дер сер яшеренгән кебек,*
*Нидер бардыр кебек бу эштә —*
*Буын арты буын алышына,*
*Хәерчелек күреп яшәсәк тә,*
*Бай—муллыкта булган килеш тә...*
*Буын арты буын алышына!*
*Ә без һаман дөнья куабыз!*
*Бәби тәпиен дә, мәетне дә*
*Бер Җир биргән суда юабыз...*
*Буын арты буын алышына!*
*Тормыш алышына, ел үтеп.*
*Безнең гомер, никтер, узып бара*
*...Рәхәт көннәр килгәнен көтеп...*

***

*Һавасы да чиста кебек,*
*Кояшы да кадерле...*
*Тик, нәрсәдер, белмим генә,*
*Кысып тора бәгырьне.*

*Дөрес юлда түгел кебек*
*Дөрес дигәннәребез.*
*Ник бертөрле фикер белән*
*Яшибез соң әле без?*

*Бик артта калганбыз кебек,*
*Гүя узган гасырда.*
*Яшәү рәвеше, тормыш та*
*Ялгыш кебек — барсы да...*

*Барсы да эшләнә кебек,*
*Милләт, диючеләр күп...*
*Дөньякүләм караганда —*
*Зур гамәл—эшләр дә — чүп.*

*Дөрес җирдә тумаганмы,*
*Әллә акыл ялгыша?*
*Нәрсәдер дөрес түгел күк...*
*Әйтерсең, галәм юлыннан*
*Баскан җирем калыша.*

*Бары да хата микән соң?*
*Бәлки бездер ул — хата?..*
*Җир тарихы битләрендә*
*Аңлашылмас һәм күренмәс*
*Хәреф—җөмләләр ята...*

## Халык һәм кеше

*Кеше кичермәс кайгыны*
*Халык күтәрә ала.*
*Тарих диңгезе өстеннән*
*Тирәнгә карап барам...*

*Һәр халыкның үз язмышы,*
*Үз җаны бар, үз җыры.*
*Һәрберсенең үз тормышы,*
*Үз вакыты, үз чоры...*

*Канлы күз яшьләре сеңгән*
*Үз моңы бар һәркемдә.*
*Халык күтәргән хәсрәтне*
*Күтәрә алмас беркем дә.*

*...Һәр халыкның үз батыры,*
*Халык иҗатына күчкән*
*Мәхәббәт сагышы бар.*
*Табышлары, югалтуы,*
*Гомерлек ялгышы бар.*

*Йөрәкләрне телгәләгән*
*Милли хис бар һәркемдә.*
*Мәңгелек көч халыкта ул!*
*Кеше көче — бер көнгә...*

***

*Сүз дә җитми, көй дә җитми, көче җитми тавышның...*
*Йөрәктән—йөрәккә күчә ул халыкның язмышы.*

*Көн дә җитми, ай да җитми, ел да җитми сөйләргә.*
*Халкымның кичергәннәре — гасыр язган көйләрдә.*

*Аңлатырга көч тә җитми, җитмәс аңа бар сәләт.*
*Халык язган шигырьләрдә — безнең бүгенге халәт.*

*Һәр халыкның үз язмышы, үз моңы бар, үз теле.*
*Халык күргәнне тоярга җитәр микән бер гомер?*

*Күп сөйлибез, күп йөрибез, күп эшлибез шикелле.*
*Милли хисең үлгән булса, эш файдасы икеле.*

*...Килмешәкне кем яратсын, чит җирләрдә хәл кыен.*
*Милләтең исән чагында, халкың янына сыен.*



Рухия
Ахунҗанова

# ХЫЯЛЛАРДАН ЧЫНБАРЛЫККА КАЙТТЫК

## Шигырь

*Шигырь — канатлы ат.*
*Синеке ул,*
*Тезгененнән әгәр*
*Тота алсаң.*
*Шигырь — зәңгәр киңлек,*
*Очар кош ул,*
*Аның белән тигез*
*Оча алсаң.*

*Шигырь — шатлык, сагыш,*
*Сөю, нәфрәт...*
*Синең күзләреңнән*
*Анда моңы.*
*...Үзең тою кирәк.*
*Сүзләр белән*
*Мөмкин түгел*
*Аңлатуы моны.*

## Тормыш

*Кырык төрле яра ясый тормыш,*
*Һәм төрлечә итеп үзе ямый.*
*Утка ата, суга сала шулай,*
*Һич аямый кайчак, һич аямый.*

*Күңел һаман җәрәхәтле әле,*
*Йөрәктәге яра телем—телем.*
*Икмәк кисәгедәй ул телемнәр*
*Хәтерләтә утлы ялкын телен.*

Рухия АХУНҖАНОВА – *шагыйрә; «Җырлы чишмә», «Олуг шәһәрдә кунакта» исемле китаплар авторы. Шигырьләре һәм әдәби язмалары көндәлек матбугатта даими басылып килә. Сарман районы Җәлил бистәсендә яши.*

*Хыял тулы мажаралар эзләп,*
*Бик күп булды абынылган мәлләр.*
*Шул абыну—егылулар аша*
*Без тормышка килмәгәнме әллә?!*

*Хыяллардан чынбарлыкка кайттык.*
*Июль ае. Серкә очыра арыш.*
*Яшь аралаш көлә—көлә бүген,*
*Өмет баглап,киләчәккә барыш.*

## Туган тел

*Туган тел —*
*Сине ашлы иткән тел,*
*Асылташлы иткән тел,*
*Йөзең ямьле иткән тел,*
*Сүзең тәмле иткән тел.*

*Тирбәлгән бишегең ул,*
*Ачылган ишегең ул,*
*Әхлагыңа әдәп ул,*
*Яшәвеңә сәбәп ул.*

*Бердәнбер ул,*
*Бер бит ул,*
*Күңелдәге гөл бит ул.*
*Батырлык ул,сабырлык —*
*Уйласаң,таң калырлык!*

## Замандашка

*Сорау белән дәшәм бүген*
*замандашка.*
*Үзем карыйм мәңгелек ут —*
*мәрмәр ташка.*

*Таптыкмы әле хәбәрсезләр*
*каберен без?*
*Беләбезме исәннәрнең*
*кадерен без?*

*Гасырлардан калган мирас*
*сакланамы?*
*Безгә булган ил өмете*
*акланамы?*

*Әй,замандаш,синдә нинди*
*гамь ята соң?*
*Сиңа дәшәм. Миндә сорау*
*уятасың...*

## Кире кайта

*Киеп битлек,*
*Эшләмә этлек,*
*Эшлим дип егетлек.*
*Андый чакта*
*Фәрештәләр сакта:*
*Гамәлең кире*
*Нәкъ үзеңә кайта.*

*Сөйләмә сафсата:*
*Сүзең сине сата —*
*Ук үзеңә ата.*
*Этлегең — булган эш...*
*Гомерең узган ич,*
*Шунысы кызганыч.*

## Соңга калма...

*Әйтеп тәүге бисмиллаң,*
*Соңга калма,дисбең ал.*

*Биш вакыт кыйлган дога —*
*Түгел кемгәдер ода.*

*Фанилык — көрәш кыры,*
*Һәммәбез — Аллаһ колы.*

*Тормыш булса да диңгез,*
*Яшәвебез — бер мизгел...*

## Кем өчендер

*Кем өчендер —*
*Көннәр гел кояшлы,*
*Төннәр һәрчак айлы.*
*Тормышы да —*
*Яккан мичтәй җылы,*
*Яшәве дә җайлы.*

*Аңа һаман*
*Язмыш мәрхәмәтле,*
*Шуңа йөзе көләч.*
*Үз урынын*
*Раслау өчен, аңа*
*Кирәк түгел көрәш.*

*Әлегә аңа*
*Табын мулдан булып,*
*Сыгылып торган бер чак.*
*...Хаклык эзләп,*
*Сыза башка берәү,*
*Сүнгәндәй төнге учак...*

## И Габдулла–Апуш!

*(диптих)*

**1**

*И Габдулла–Апуш!*
*Синең хәлне*
*Аңлаучылар саны*
*Ничә генә...*
*Синең хәлдә калгач,*
*Бәлки, берәү*
*Искә төшергәндер*
*Кичә генә.*

*И Габдулла–Апуш!*
*Ата сүзен*
*Ишетмәгән олан*
*Сине аңлар...*
*Ятим күңеленә*
*Эзен салып,*
*Сызылып ата чөнки*
*Алсу таңнар.*

*И Габдулла–Апуш!*
*Ана назын*
*Иртә югалткан кыз*
*Синең хәлдә...*
*Күңел тетрәүләре*
*Синең белән*
*Тоташтырган аны*
*Шушы мәлдә.*

*И Габдулла—Апуш!*
*Сөйгәненнән*
*Баш тартучы егет*
*Синең кебек...*
*Мәхәббәттән өстен*
*Аның чире.*
*Авыру егет шуны*
*Уйлый элек.*

*И Габдулла—Апуш!*
*Фани дөнья,*
*Беләсең, ич, тора*
*Югалтудан...*
*Бер югалткач, нәрсә*
*Кире кайта?*
*Файда бармы кемдер*
*Юатудан?*

**2**

*И Габдулла—Апуш!*
*Барысын бирдең,*
*Нәрсә алдың әрсез*
*Тормыштан син?...*
*Алу кая?! Үзеңне*
*Таладылар,*
*Юмарт булган өчен*
*Тумыштан син.*

*И Габдулла—Апуш!*
*Дөньялыкта*
*Булмаган ич хәтта*
*Яшәр өең...*
*Йорт—җирсез бер дәрвиш —*
*Шагыйрь, имеш.*
*Җиһаннарны иңләп*
*Киткән көең.*

*И Габдулла—Апуш!*
*Синең иҗат,*
*Шөкер, күңелләрдә*
*Урын алган...*
*Халкың шуңа күрә*
*Һәр сүзеңне,*
*Ядкарь итеп, моңлы*
*Көйгә салган.*



*Бу рәсемне фотожурналист Мидхәт Шакирҗанов Бельгия гражданы Андре Тимермансның Казанга – Муса Җәлилнең 60 еллык юбилей тантанасына килгән вакытында төшергән. Уңнан сулга – М.Җәлилнең кызы Чулпан, хатыны – Әминә ханым, А.Тимерманс һәм аның хатыны. Казан, 1966 елның 15 феврале.*



*Шагыйрь Сибгат Хәким, улы Рафаэль (хәзерге вакытта күренекле сәясәтче, дәүләт эшлеклесе, Татарстан Фәннәр академиясе академигы) һәм хатыны Мөршидә ханым. 1956 ел.*



*Татар журналистикасы һәм әдәбиятында күренекле урын яулаган хатын-кызларыбыздан бер төркем. Уңнан сулга: Венера Ихсанова, Рәйсә Ишморатова, Ләбибә Ихсанова, Зәкия Туфайлова. 1972 ел.*



*Шагыйрь Фәнис Яруллин хатыны*
*Нурсөя ханым белән. 1995 ел.*



*Әлмәттә шагыйрә*
*Саҗидә Сөләймановага*
*куелган бюст-һәйкәл.*



*Пушкинга багышланган бәйрәмдә. Уңнан сулга – шагыйрь Илфак Ибраһимов, төрек әдибе, тәрҗемәче Фатих Кутлу, тәрҗемәче Наил Ишмөхәммәтов, шагыйрә Лилия Газизова. 2009 ел, 6 июнь.*

Кояш
Тимбикова

# СӨЛГЕ БУЛСЫН БҮЛӘГЕМ!

Сәгать унберенчегә киткәч, каенлыкта сәер гөжләү, гадәттән тыш сәер хәрәкәтләр башланды. Табын корып, сыйланып-кәефләнеп утыручылар да, җыр-бию карарга ачык сәхнә янына җыелганнары да, бары бер булып, басу ягына ашыктылар. Берберсенә бөтенләй таныш түгел кешеләр, үтеп барышлый сораштыралар:

— Киттеләр микән әле?

— Юк, ди әле, атлар комиссия үтә, имеш.

— И-и, хайваннарга да комиссия дигән нәрсә такканнармы?! Хурлык!

— Ипподромныкылар киткән инде!

— Ә-әй, ипподром аты атмыни ул?! Аларны бит уколлар кадап, витаминнар каптырып үстерәләр. Дармоедлар алар. Менә колхоз аты — әйтсәң дә, урынында!

— Кайсы алдан килер бит әле?..

Ат чабышын карарга килүчеләр арасында әллә кемнәр бар. Берәве — атның ни икәнен дә белмәүче шәһәр баласы. Аның янәшәсендә үк, тумыштан авылда яшәп, соңгы гомерен каладагы баласы янында җыеп бетерергә килгән карчык баскан. Картлар да күренә. Ап-ак чәчле бер бабай күкрәгенә орден-медальләрен тагып чыккан. Аның тирәсендәгеләр, узыш карарга килүләрен онытып, батыр бабайны күзәтәләр.

— Күрденме картынны — түше тулы тәңкә!

— Әйтәсең бармы?! Мондый тәңкәләрең булганда, мактансаң да урынында! Ике «Дан» ордены, малай! Аның бит өчесе — Геройга тарта!

— Алайса бу карт Герой ук түгел икән әле.

— Күнелең киң булса, Геройга да тутырырга була, медальләрне санасаң, артып та кала, «Батырлык өчен» медале үзе генә дә ни тора?!

Карт үзе бу сүзләрне ишетмәмешкә салыша, гел юлны гына күзәткән булып кылана. Аның инде төссезләнә башлаган күзләрен сагыш баскан. Тирәюнен янгыратучы соклану сүзләренә дә ул: «Әй, егетләр, егетләр! Күзегезне юкка кыздырмагыз! Ул орденнарның, барын бергә җыеп, сездәге яшьлеккә алмаштырыр идем. Кире кайтсын иде кырык яшьлек чакларым — бүләкләрнен мондыен гына алыр идемме?!» — дип, күнеленнән гел кире җавап кайтарып тора кебек.

Атлар әле китмәгән икән. Хәзергә алар да — тамаша кылырга әзерләнгән халык арасында. Ир-егетләр аларны якын ук килеп тә, читкәрәк китеп тә карый. Аннары бәхәс кыза.

— Менә шунысы алдан киләчәк! — дип, берәве сүз башлый. Икенчесе аңа каршы төшә.

— Һи-и, кеше көлдермәсәнә! Бу авыр санлы ат йөз метрлар китүгә күбеккә батачак.

Ак бәкәлле кара бия бәхәсләрнен үзегенә әйләнде. Иясе, ябык кына бер агай, мангаена ук төшереп кызыл бизәкле кара яулык бәйләгән. Боларны күрү белән: «Кара, икесе дә бертөсле!» — дип уйлап куясын. «Кечкенәләр, тиктормаслар, сөйкемлеләр». Аты берөзлексез бии, карт гел аны иркәләп тора, мангай чәчләрен рәтли, сыйпый, сөтен савып-савып ала. Бу хәлгә гаҗәпләнгәне:

— И-и бичара, колынлы бия икән әле! — дип, атны кызганып куйды. — Савып дөрес эшли. Чапканда кыенга килә бит ул, — диючесе дә табылды.

Монарчы эндәшми торган, ак челтәр күлмәк кигән ир кулын гына селтәде.

— Хайван азаплап йөри инде шунда, ахмак, — диде. — Ятсын иде бия абзарында, колынын имезеп!

Яна бәхәс кузгалырга шул җитә калды. Йөрәгенең ярсулыгы очкынлы күз карашыннан ук сизелеп торучы, җинел сөякле икенче ир, «челтәр күлмәк»кә каршы төшеп:

— Синнән сорап тормаганнармыни?! — дип әләктереп алды. — Аларның чабышка беренче катнашулары түгел, бик беләсең килсә!

— Чабарга була ул, юл иркен. Килер шунда сөйрәлеп, сөтен агыза-агыза...

— Мал танымасан, йөрмә монда ачу китереп, яме. Сөйрәлердәйнеке башта ук сөйрәлә анын, беләсең килсә! Беренче, димим, әмма ләкин өченче урынны бирәүгә дә бирми бу, бик беләсең килсә!

— У-уу! Күрәселәр бар икән! — «Челтәр күлмәк» бөтенләй кызып китте. — Мин, агайне, мондагы атларның барысын да әнә күзеннән үткәзеп чыктым: шәп ат бер генә. А-а-нау, алмачуар тимер күк! Чабышкы дисән дә чабышкы! Бу бит синең атың атка да охшамаган, кәҗә бит бу!

Ярсу ир бераз сүз таба алмыйча торды, аннары:

— Күрербез! — дип, тирән мәгънәле иттереп әйтә куйды. — Мин синең белән тел талдырып та тормыйм.

— Ярар, ярар. Бүтән эшең булмаса, бар, садакаңны әзерлә! Бу йолкыш иң артка калачак, хәер бирерсең. Авылы да Хәерби бит анын, хәер бир, дип кулын сузып тора...

Атлар тирәсендә ир-егетләр күбрәк йөри. Хатын-кыз җәмәгате шуларның бәхәсеннән ишетелгәненә дә канәгать. Белгәненә шөкер итә, аңлап җиткермәгәнен үзе фараз кылып тутыра. Шунлыктан бер колакка эленгән сүз, икенчеләргә җиткәндә, шактый ук «баеп» та өлгерә.

Гөлҗиһан исә мондагыларның барыннан да аерылып тора. Йөзенә карап, илле-илле бишләрдән артыкны бирмәсәң дә, анын килеш-килбәте бик өлкәннәрнекенә тартым. Өстендәге кызыллы-яшелле күлмәге дә карчыкларныкыча итеп тегелгән, күкрәкчәле ак алъяпкыч бәйләгән, башында батист яулык. Бер кулы — каш өстендә, икенчесе белән, алъяпкычы итәгенә яшереп, нидер тоткан.

Гөлҗиһан берәүнең сүзенә дә кушылмады, шулай да чабышка китәргә торган атлар янына мөмкин кадәр якынрак килергә тырышты. Башкалар ат хуҗаларына сорау биргәндә, җавапларның иң беренчесен, төгәлен ишетеп калырга теләп, сөйләүченең авызына карап торды. Сабыр гына атласа да, ул һәр ат турында азмы-күпме мәгълүмат алды. Аннары, күзәтү өчен унайлы төшне сайлап, беләгенә кызыл бәйләгән егет янына барып басты.

Дружиначы бу егет ара-тирә: «Солыны таптамагыз!», «Юлның уң ягына чыкмагыз: килгән шәпкә атлар ул якка туры бәреп кереп китә, туяк астында калырсыз»... — кебек кырыс-кырыс кисәтүләр ясап торгаласа да, Гөлҗиһанга актан-карадан сүз әйтмәде.

Гөлжиһан кымшанмады да. Ул, атлар килгәнче, каккан казыктай шунда торачак, көтеп алачак, кемнең кайчан килүен үз күзе белән күреп калачак иде. Егерме чакрым ераклыктагы авылдан шәһәр каенлыгындагы Сабан туена килүенең бөтен максаты да шул анын.

Чабыш алдыннан юлга су сиптергеч машина чыкты. Ирләр моңа да бәя бирергә ашыкты:

— Дөрес итәләр, тузан күзгә керә бит ул!

— Асфальт җәйдерәселәре калган! Андыйны юдырсаң, тузанның бөртеге дә калмый.

— Ахмак икәнсең, ат тоягы җиргә басар өчен яратылган ул! Гөлжиһанның басу юлына су сиптергәннәрен күргәне юк иде. Хәйран калды. Сабырлыгы сынып, дружиначы егеттән:

— Карале, энем, тузанлы юлны чылатып бетергәч, атлар таеп егылмасмы соң? — дип сорамыйча булдыра алмады. — Безнең заманда тузан шул килеш торадырые, зыяны тимидерие...

— Анын, әби җаным, чамасын беләләр, атка чуртым да булмый аңа!

Гөлжиһан куырылып калды. «Әби» дип вакытыннан элек картайтуы — бер хәл. Атларга карата күңелендә тамчы да шәфкать йөртмәгәч, нигә монда эшем кешесе булып тора соң бу адәм? Эндәшмәве хәерлерәк буласы икән. Гөлжиһан тирәнрәк сулап куйды да мөлдерәмә күзләрен дымлы юлга текәп тынды.

Әллә ни озак көтәргә туры килмәде — атлар, салмак атлап, юлга төштеләр, кузгалып китәргә тиешле урынга юнәлделәр. Кара яулыклы карт иң арттан бара. «Атын ардыртмас өчен шулай сабыр атлатадыр, — дип уйлады Гөлжиһан. — Вакытсыз каударланунын нигә кирәге бар?!»

Чабышчылар белән танышып-күрешеп чыкканнан соң, Гөлжиһанның күңелен шушы ак бәкәлле кечкенә чабышкы биләп алды. Анын хакындагы ямьсез бәхәсне дә ишетте ул, әмма теләкләрнең иң изгесен «ак бәкәл»гә багышлады. «Исән-имин әйләнеп кайта күр! Сөрлегеп китеп, аягыңны имгәтмә! Колыныңда бар, ди бит. Чирләсәң, аны кем үстерер? Хуҗаңны егып калдырма тагын! Ул да начар кешегә охшамаган...»

Карт кыяфәтендәге: «Әле минем дә төшеп калырга исәп юк!» — дип кыюлану галәмәте Гөлжиһанны әсир иткән иде.

Старт алырга киткән атлар күренмәс булгач та, Гөлжиһан ике ягына карт каеннар тезелгән киң юлдан күзен алмады. Иреннәре өзлексез калтыранды. Уң кулы һаман алъяпкыч астында торды. Вакыт-вакыт, әле син исәнме дигәндәй, сул кулы алъяпкычның өске ягын сыйпап куя.

Чабыш карарга килүчеләрнең Гөлжиһанда да, анын теләкләрендә дә, кулларынын ни капшавында да кайгысы юк. Өзлексез бәхәсләшәләр, шаян сүзләр яудыралар. Тирә-юнь гөж килә. Азга гына тынып тордылар да сүз тагын куерды. Берәү: «Киләләр!» — дип кычкырып салган иде.

— Белмәсәң, сөйләмиләр аны! Юк бит.

— Бәлки, әле алдан машина үтәр, нәчәлникләрне озата йөргәндәге кебек...

— Ни пычагыма ул машина, туйган ул машиналардан...

— Әле әнә милиционер әйтә: чабышны туктатып торачаклар, ди. Кемдер атына аракы эчергән. Шунын аркасында хәзер бөтенесен өр-яңадан тикшерәчәкләр икән.

— Кит моннан! Ат — синең белән мин түгел ул, нишләп аракы эчсен?!

— Эчмәс! Биреп кара!..

Ярый әле, бәхеткә, атлар киткән яктан тузан күтәрелде. Бөтен җаннарны бер сорау биләп алды: «Алдан кем килә?»

— Кара! Икесе бер булып атлый!

— Өчәве бергә килә бугай! — Дүртәү бер эзгә басалар!

Юлны иңләп дүрт ат килә иде. Тик ул алдан караганда гына тигез күренә икән. Аралар якынайган саен, хәл ачыклана барды. Гөлжиһан әлеге дүрт чабышчы арасыннан үз теләгәнен, Ак бәкәлне танып алды. «Килә! Килә бәгырькәем! Сөрлекмәгән, егылмаган, сонармаган! Сау-сәламәт килеп бара!» Иясе белән аты бербөтенгә әйләнеп, уктай алга атылып килүче кечкенә кара атны сонра башкалар да абайлады.

— Кара, кара, бабаң нишләтә!

— Әйткән идем бит! Әйдә-ә-ә, бабай, бирешмә!

— Менә сиңа мә! Кәжә бәтие генә диген син аны!

Иң алдан алсу күлмәкле малай очып үтте. Анын нечкә сыйраклы биек сынлы чаптары әлеге араны узудан һич йончымаган. Тизлеген киметеп, сабыр атлата башлагач та, арт санын уйнаклатып, көязләнергә тотынды. Теләсән, өр-яңа баштан узышка керт, алдан килүен көт тә тор!

Финиш сызыгын кичкән һәр атны халык сырып ала. Гаҗәеп манзара иде бу: әйтерсең лә иң четерекле имтиханны чабышчылар түгел, тамаша кылучылар тоткан. Яраткан атларын күрү белән, анын янына киләләр дә сораштыра башлыйлар, атны сыйпыйлар, хуҗасын котлыйлар, ана бүләкләр сузалар. Кайбер хатыннар, башларындагы яулыкны сыпырып алып, ат йөгәненә бәйләп куя. Нигә болай итүләрен үзләре дә белештерми: кайсы көлә, башкасы елый...

Гөлжиһан, тирә-юньдәге башка бернәрсәгә дә игътибар итмәстән, туп-туры «ак бәкәл» ягына китте. Әй ашыкты, әй кабаланды. Барып житәренә биш-алты адым гына калгач, шып туктады. Кечкенә батырны халык сырып алган иде. «Менә, ичмасам, булдырдың!», «Иллә мәгәр жилле икәнсең!», «Биян — асыл зат синең!» — диешәләр. Имән баганасыдай ирләр арасына курчак кадәр генә Гөлжиһан ничек барып керсен? Күңеле генә очар коштай талпына. Шул бия янына килеп житә алса, бөтен дөньясы тигезләнер сыман. Аннары сабан туеннан кайтып китсә дә була.

Һич уйламаганда, Гөлжиһанга «күк капусы» ачылды. Ак бәкәлне котларга, карт чабышчының кулын кысарга дип, төркем янына баягы «челтәр күлмәк» тә килгән икән. Авызы колагына житкән, берөзлексез сөйләнә:

— Вәт, малай! Шул кәжә бәтие икенче килер, дип кем уйлаган, ә?! — ди.

Анын шул сүзне ычкындыруы булды, төркем эченнән әүвәлдә үк Ак бәкәлне яклап сөйләгән ярсу ир калыкты. Килеп тә чыкты:

— Син нәрсә! — дип, «челтәр күлмәк»нең каршына барып та басты. — Көч сынашканчы — матурны, жингәннән соң батырны хуплап йөрисеңме?! Кит, күземнән югал!

«Челтәр күлмәк», эшне зурга жибәрмәскә өметләнеп, вәкарь белән:

— Кит әле, синең янга килмәдем! — дип әйтеп салды. — Былтыр кылган гөнаһым күк торма күз каршымда!

Бер-берененең якасына ябышырга житешкән бу икәүне башкалар сырып алды. Һәр икесенең яклаучылары да, хурлаучылары да табылды. Гауга купты.

Шул хәлләрдә Гөлжиһан Ак бәкәл белән чабышчы карт янында берүзе торып калды. Ул иң элек:

— Исән-имин килеп життегезме? — дип сорады.

— Килде-ек, килми, безгә ни булсын?! — Карт шатлыгын яшерергә тырыша иде.

— Алай димә! Алай дип әйтә күрмә! Дөньяда көтелмәгән хәлләр дә күп була... — Гөлжиһан, сөйләгәне унаена, атның дым бәреп чыккан муенын сыйпарга тотынды. — Тирләгәнсең! Әнә ничек тирләгәнсең...

Аннары ул алъяпкычы астындагы кулын чыгарды. Бик пөхтәләп кат-кат бөкләгән борынгы кызыл башлы сөлге тотып торган икән ул. Сөлгене, ике куллап, картка сузды:

— Кабул итеп ал, зинһар! — диде. — Заманында үз сабан туебызга әзерләп торган идем — насыйп булмады...

Карт аны-моны абайламадымы, башка нәрсә турында уйланып, кул сузарга кирәген белмәдеме — бүләкне кабул итеп өлгермәде. Гөлҗиһан, сөлгене бөтен буена сузып җибәрде дә «ак бәкәл»нең муенына бәйләп куйды.

Ул да түгел, атны кабат ирләр урап алды. Гөлҗиһан читкә тайпылды. Күңеле гаҗәеп бер ләззәт кичерә иде. Елыйсы килүе дә — рәхәтлектән. Ул үзалдына: «Менә бит, барыбер бирдем! Барыбер сабан туе батырына туры килде!» — дип сөйләнде. Шушы гамәле белән ул моннан утыз биш еллар элек булган фаҗигане томалап куйгандай итте.

Гөлҗиһанның килен булып төшкән елы иде. Язгы эшләр бетте. Җәй җитте. Алдагы бәйрәм шатлыгы турында хәбәр таратып, авыл урамына яшьләр чыкты — сабан туена бүләк җыю башланды. Гөлҗиһан, батыр егеткә атап, сабый чагында, әбисе белән бергә басып, кул станында чүпләп суккан кызыл башлы озын сөлгене биреп җибәрде. Ире Миңлехәйдәр аңа алдан ук вәгъдә итте:

— Әгәр дә мәгәр, — диде ул, Гөлҗиһанны киң күкрәгенә кысып,— Җирән кашкам белән беренче килеп, бүләккә синең сөлгене алмасам, исемем Миңлехәйдәр булмасын!

Килгән булыр иде Миңлехәйдәр, мөгаен, беренче килгән булыр иде.

Сөлгене дә, һичшиксез, ул алган булыр иде. Тик, кызганычка каршы, Балыклы Күл авылында ул елны сабан туе уздырылмады. Бүләкләрне яшь киленнәргә кире өләшеп чыктылар. Миңлехәйдәр дә, аның кебек үк мәйдан батыры булырдай бик күп башка ирләр дә сугышка китеп барды. Киттеләр, кайтмадылар...

Каенлыктагы тантана әле кызып кына килә иде. Ат чабышы турында хәбәрләрне көрәш мәйданындагы яңалыклар алмаштырды. Тирә-юньне җыр тутырды. Табын яннарында, яше-карты бер булып, җир жимертеп бии башладылар.

Гөлҗиһанны болары әллә ни кызыксындырмый иде инде. Ул әле һаман халык арасында әрле-бирле йөренгәләүче Ак бәкәл ягына күз ташлады да кайтып китәргә ниятләде. Ат атлаган уңайга сөлгенең кызыл чүпләмле башы жилфердәп-жилфердәп китә. Яу кырында ятып калганнарның якты хатирәсенә үрләтелгән мәңгелек ялкыннар, диярсең...

*1969*

# ТАТАР ШИГЪРИЯТЕНЕҢ ҮСЕШ–ҮЗГӘРЕШ ЮЛЛАРЫ

## 2013 ЕЛДА «КАЗАН УТЛАРЫ» ЖУРНАЛЫНДА ДӨНЬЯ КҮРГӘН ШИГЪРИ ӘСӘРЛӘРГӘ КҮЗӘТҮ

XX-XXI гасыр чикләре татар поэзиясендәге үсеш-үзгәреш, бер яктан, 1990 еллардагы рухи һәм милли яңарышның, икенче яктан, 1960-1980 еллардагы шигъри күтәрелешнең матур нәтиҗәсе буларак кабул ителә. Сиксәненче елларның икенче яртысыннан милли мираска мөнәсәбәтнең үзгәрүе нәтиҗәсендә халыкның үз үткәне, мәдәни байлыгы белән кызыксынуы арту, моңа кадәр күләгәдә калып, күренми яткан әдәби катламнарның ачылуы, татар әдәби-эстетик һәм иҗтимагый фикерендәге яңарыш шигърияттә яңа сыйфатларның алга чыгуына юл ача. Туксанынчы еллардагы фикер төрлелеге, азатлык, хөррият җилләре һәм төрлечә карашлар сыешуы шигърияттә күренешләрне яңачарак бәяләргә, сурәтләргә, матурлыкны үзгә эчтәлектә, калыпта яктыртырга мөмкинлек бирә. Болар, сүз сәнгатенең башка төрләре кебек үк, поэзиянең дә бөтен яссылыкларда — эчтәлек һәм форма ягыннан — эзләнүләр юлына керүенә этәргеч була. Яңарыш традицияләрне дәвам итеп үсү-үзгәрү, тема-проблематик яктан төрләләнү, яңа сукмаклар эзләү, иҗади тәҗрибәләр ясап карау, фәлсәфи яктан тирәнәю, иҗтимагый тормыштагы күренешләрне дә кешелек, яшәеш кыйммәтләренә бәйләнештә ачарга омтылу белән билгеләнә. Әлеге дәвер шагыйрьләренең иҗат принципларын, кыйммәтләрне тагын бер кат күздән кичерүе ягыннан да үзенчәлекле.

Нәкъ шушы ике гасыр чигендә XXI гасыр башы татар шигъриятендә урын алачак, сүз сәнгатен үсеш-үзгәрешкә китерәчәк стиль тенденцияләре аермачык билгеләнеп җитә: романтик, лирик-эмоциональ башлангычның дәвам ителүе; милләт тормышына, җәмгыятькә бәя бирүгә йөз тоткан тәнкыйди башлангычның көчәюе; җәмгыятьнең актуаль мәсьәләләрен әдәби материалда чишәргә омтылган интеллектуаль тенденциянең үсүе; модернистик эзләнүләрнең алга чыгуы. Бу сыйфат-хасиятләр хәзерге чор татар поэзиясендә, реаль чынбарлыкны бәяләү белән генә чикләнмичә, кешелекнең яшәеш кануннарын аерып чыгарган, кешене олы кыйммәт итеп күтәргән яисә тормыш закончалыкларын тәнкыйть утына алган яңа әдәби модельнең төзелүенә китерә. Шуның нәтиҗәсендә татар шигърияте чын мәгънәсендә милли рухлы, укыган саен яңа мәгънә, үзгә яклары белән ачыла бара торган лирик-эмоциональ, үзенчәлекле, бер үк вакытта модерн алымнарны да чит итмәгән, алымнар синтезына нигезләнгән шигъри әсәрләрне мәйданга чыгара.

Чор шигъриятендә калыплашып өлгергән әлеге сыйфатлар «Казан утлары» журналының 2013 елгы саннарында дөнья күргән шигъри әсәрләрдә дә әйдәп бара, үстерелә.

Әлеге әсәрләрне күзәтеп чыгу гына да чор шигъриятендә реализмның әйдәп баручы буларак үз позициясен саклап калуын дәлилли. Мондый шигъри әсәрләр, традицияләрне дәвам итеп, иҗтимагый тормышка, җәмгыятьтәге вазгыятькә, милләт тормышына аерым игътибар бирә, заманга, милли сәясәткә хас проблемаларны калкытып куя.

«Казан утлары» журналының 2013 елгы саннарында басылган реалистик юнәлешкә мөнәсәбәтле шигырьләрнең бер бәйләмен татарның киләчәге, милләт

язмышы, үткәне өчен сызлану берләштерә, традицион төстә милли эчтәлек алга чыга. Шуна бәйле төстә күп шигырьләр гражданлык лирикасына карый.

Мондый әсәрләрдә татар халкының ачы язмышы (лирик герой язмышы еш кына милләт язмышына берегеп китә), татар халкы кичергән фаҗигаләр яки җәмгыятьтәге хәл-халәт хисенең төп сәбәбенә әверелә, шәхес-система, лирик герой — җәмгыять каршылыгы, иҗтимагый детерминация саклана, кешенең үз-үзен танып-белү мәсьәләсе төп проблема буларак күтәрелә, әсәрләрнең үзәгенә «без нигә мондый, тормыштагы гаделсезлеккә ничек җавап биреп була?» кебек сораулар куела. Н.Әхмәдиевнең «Хатирәләр үлми, искерми», Г.Әхтәмованың «Изгелектә безнең бар ният», Р.Идиятуллинның «Энҗе сүз әңгердә балкый», Р.Шаһиеваның «Ана теле — гүзәллек», И.Гыйләҗевның «Җаным ирек, хөрлек тели», Ч.Мусинның «Дөнья иркен — җанда кысанлык» кебек шигырь бәйләмнәрендә, М.Кәримовның «Ватан», «Рәшәткәләр», С.Гәрәеваның «Без — татарлар», Ә.Мәхмүдовның «Китәбез...», Ф.Тархānованың «Нигез», «Бетеп бара татар авылы» һ.б. шигырьләрендә җәмгыятьтәге, милләт тормышындагы вакыйга-хәлләр нәтиҗәсендә туган хис-кичереш аша авторларның җәмгыятьтәге тәртипләргә яки милли мәсьәләләргә мөнәсәбәте, ягъни гражданлык позициясе ачыла. Мәсәлән, Н.Әхмәдиевнең «Хатирәләр үлми, искерми» шигырьләр бәйләме Г.Тукайның «Кыйтга» шигыреннән алынган юллар белән башланып китә. Әлеге эпиграф шигырь структурасында метафора вазифасын үтәп, бүгенге вазгыятьне бәяләүгә юнәлтелә, Такташ иҗатыннан үстерелеп килгән традицияне дәвам итеп, җил, давыл символик образлары да шул ук эчтәлектә шигырь тукымасында урын ала. Татарларның буйсынып яшәргә мәҗбүр ителүе, татар халкы кичергән фаҗигаләр лирик герой күңелендә сагыш хисен уята:

*Гасыр узды, әмма туктамады*
*Гарасатлы җиле, давылы.*
*Татарымны саклап калды дине,*
*Саклап калды аны авылы.*

Әлеге шигырь бәйләмендә урын алган «Сагыну» шигыре гомуми фонда лирик геройның татарның язмышына бәйле сызланудан юануы кебек кабул ителә.

М.Кәримовның «Рәшәткәләр» шигырендә «рәшәткәләр» ачкыч сүзе уйнатылып, «рәшәткәле язмыш» варианты алга чыга. Төрле эчтәлектәге рәшәткәләр арасында бәргәләнгән йөрәк образында бәйсез, хөр булып яшәргә хыялланган кеше һәм татар халкы гомумиләштерелә, рәшәткәләр яшәп килгән вазгыятьне символлаштыра. Шундый халәттәге тормыш-яшәеш, үз чиратында, лирик герой күңелендәге сызлануга сәбәп төсен ала:

*Рәшәткәләр аша карый-карый,*
*Без тиңләштек бугай тоткыннарга.*
*Рәшәткәле язмышыбыз безне*
*Сөйри тагын нинди упкыннарга?*

Г.Бәйрәмованың «Ил кадерен белер — илсез калган» шигырендә татар авылларының юкка чыга баруы милли фаҗигане бер сәбәбе төсен ала, шул юлда авыл татар милләтен саклаучы югарылыгына күтәрелә. Шулар аша автор фикере төгәлләштерелә: кешене үткәндәге якты хатирәләре яшәтә, милләтне дә авыл саклап калырга сәләтле.

Х.Мөдәррисованың «Тамчы суга бу җәй дөнья мохтаҗ...» шигыре реалистик яссылыкта кеше фәлсәфәсен тәкъдим итә. Шигырь структурасында тамчы су кеше яшәеше өчен кирәкле рухи азык, иман, күңел байлыгы кебек кабул ителә. Шуна бәйләп, автор кешенең иманга килү аша гына сакланып кала алу мөмкинлеген билгели. Яшь шагыйрә Г.Корбанованың «Офык читләрендә ышык таулар» шигырендә милләтләр бердәмлеге сакланып калу юлы кебек тәкъдим ителә.

Аерым бер шигырьләрдә милли тема танылган шәхесләр образларына

мөнәсәбәтле формалаша. Бу алым татар шигърияте өчен шулай ук традицион. Мәсәлән, Л.Шәехнын «Без сайлаган юллар хата түгел» шигырьләр бәйләмендәге «Спартанларның батырлыгын...» шигырендә Спартанларның батырлыгы / Җәлилләрнең батырлыгы янәшәлеге укучыны «теләсә кайсы халыкны каһарманнары саклап кала» дигән фикерне аңлауга китерә. Шушы ук мотив Л.Шәехнын «Ике Салих», Р.Низаминың «Хөрмәтле Шамил ядкяре» кебек шигырьләрендә дә дәвам итә, үстерелә, иҗат кешеләре халыкның рухи яшәешен тергезүчеләр, телен, әдәбиятын, мәдәниятен саклаучылар югарылыгына күтәрелә, традицион төстә аларга хөрмәт милләтне бәяләүче бизмән кебек тәкъдим ителә. Соңгысында бу фикер сәнгати алым — Г.Тукайның «Хөрмәтле Хөсәен ядкяре» шигыре белән ассоциация — аша тирәнәйтелә. Шундый ук мотивлар М.Мирзаның «Борынгыдан килгән Идел-Йортта...», мәхәббәт лирикасы остасы буларак танылган шагыйрә Ф.Тархановаҗның «Туфан» кебек шигырьләрендә дә урын ала.

С.Әхмәтҗанованың «Арча капкасы» шигырьләр бәйләмендә үзгә күренеш — ерак тарих аша бүгенгене бәяләү сыйфаты — алга чыга. Милләт азатлыгы, татар телен үстерү, гадәт-традицияләрне саклап калу мәсьәләсенә мөнәсәбәттә тарихи-мәдәни хәтерне торгызу мотивы калка, милли хәтер милләт сакчысы кебек тәкъдим ителә. Гомуми планда караганда, бу юнәлештәге шигырьләрдә публицистлык сыйфатының көчле булуы күзгә ташлана, хәтта ул бер стиль тенденциясе буларак билгеләнә ала.

Шуның белән янәшәдә аерым бер шигырьләрдә җәмгыятькә бәя, милли хәл-халәткә мөнәсәбәт метафора-символлар, эзоп теле аша ачыла. Шунысы үзенчәлекле: алар хәзерге татар поэзиясендә кабат эзоп теле алымының актуальләшүен, лирик герой кичерешләрен яки автор позициясен житкерү барышында алга чыгуын күрсәтә. Беребезгә дә сер түгел, совет чоры шигъриятенең «рәсми булмаган» канатында эзоп теле иң еш мөрәҗәгать ителгән алымнардан санала. 1990 еллар шигъриятендә исә, символик образ, метафора, детальләргә мөрәҗәгать ителсә дә, милләт язмышы хакындагы фикерне турыдан-туры белдерү сыйфаты алга чыга, үзгәртеп кору биргән мөмкинлектән файдаланып, фикер әйтеп калу теләге көчәя. Бу күренеш үзеннән-үзе публицистик башлангычның активлашуына һәм эзоп теленең икенче планга күчүенә китерә. Гомумәдәби фонда «яшерен эчтәлек» алымның кабат янаруы шигърияттнең «үз» традицияләренә әйләнеп кайтуы буларак кабул ителә, чөнки милли әдәбият өчен икенчел эчтәлек тудыру алымы традицион.

Р.Сәләховның «Таш өстендә үскән куаклар» шигыре шушы яктан кызыклы. Бер караганда, шигырьдә идеологик укыла торган яки идеологик эчтәлеккә ишарә ясаган образлар юк. Әмма шигырь тукымасында кабатлана килгән «таш өстендә үскән куак» образы кабатлау алымы аша символик югарылыкка күтәрелә. Шуна мөнәсәбәттә куак / кеше, таш / иҗтимагый вазгыять янәшәлекләре пәйда була һәм яшерен эчтәлекне ачарга ярдәм итә: горур калганда, яшәүгә өметне җуймаганда, алга таба яшәргә көч табып була! Шушы ук фикер символик эчтәлек аша милләт язмышына бәйле дә аңлашыла ала. Шундый ук мотив Р.Низаминың «Мин китәм...» шигырендә дә урын ала. Р.Сәләховның «Яшел күзле яз» шигыре дә образның мәгънәләрен уйнату аша мәгънә тирәнлегенә юл тотып язылган. Яз, традицион эчтәлеген дәвам итеп, якты киләчәк мәгънәсендә урын ала. Шушы ук шигырь кысаларында аның идеологик эчтәлеген (җәмгыятьнең, илнең киләчәге), фәлсәфи мәгънәсен (кешелекнең язы), лирик-психологик эчтәлеген (яшьлек) аңлау мөмкинлекләре дә калдырыла. Без Р.Сәләховтан киләчәктә дә сәнгати яктан югары шигъри үрнәкләр көтеп калабыз.

Шушы елда журналда дөнья күргән Ф.Гыйззәтуллинаның «Яңу дәверләрендә» роман-поэмасы бу елның гына түгел, гомумән, татар поэзиясенең уңышы буларак бәяләнүгә лаек. Соңгы елларда мәйданга чыккан татар поэмаларының бер хасияте булып төрле катламнарның синтезына омтылыш тора. Ул синтез еш кына дини-мифологик образлар, гыйбарә-әйтелмәләр аша уздырылган фәлсәфи уйланулар: кеше һәм гомер, яшәү һәм үлем, вакыт агышы, кеше гомеренең бәясе, яшәү мәгънәсе; сәяси-иҗтимагый фикерләр: идеология һәм милләт язмышы, система алып килгән фаҗига, милләтнең үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге кебек мәсьәләләрнең бер әсәр

чикләрендә очрашуына бәйләнә. Катламнарның бергә кушылуына әдәби текстның үз эчендә башка текстлар белән ассоциациясе аша — интертекстуальлек ярдәмендә ирешелә.

Жанр таләпләре ягыннан шигъри повесть буларак кабул ителгән әлеге әсәрдә дә мондый сыйфатлар чагылыш таба, алар милли тема-проблеманы үзенчә бәяләү һәм чишүгә ярдәм итә. Милләт язмышы лирик герой фаҗигасе аша житкерелә һәм метафорик, шартлы-символик образ-детальләр нигезендә тирәнәйтелә, нәтиҗәдә реалистик әсәр интеллектуаль алымнар белән байый. Композицион җәһәттән үзенчәлекле төзелгән поэма төгәл ике — вакыйгалар һәм хис катламына аерыла. Беренчесе — вакыйгалар катламы — лирик геройның ятим тормышы, туган жиреннән аерылуы хакында хәбәр итә. Әлеге вакыйгалар катламы үзе үк метафорик янгырашка ия булып, милләтнең ятимлегенә дә ишарә ясый.

Әсәрнең үзәгендә торган милләт фаҗигасе бик күп күренеш, деталь, элементлар аша көчәйтелә: Агыйдел күренеше, ак пароход, караб образлары, ут, кое һ.б. Лиро-эпик әсәрнең үзәгенә куелган ут образы символик янгырашка ия. Әсәр структурасында аның күп мәгънәләре уйнатыла, шушы алым хәтта бер әсәр чикләрендә ут / хыялларның юкка чыгуы, ут / хәтерне уятучы, ут / милләт фаҗигасе, ут / иҗат кебек төрле янәшәлекләрне яктырта алуга китерә. Шуның белән янәшәдә автор ассоциация уята алырлык образ-детальләргә дә мөрәҗәгать итә. Агыйдел — елга — гомер агышы, ак пароход кеше гомере, тормышы кебек укыла, пароход янәшәсендәге караб образ-детале милли шигърияттәге караб образы белән бәйләнеш урнаштыра, нәтиҗәдә образның мәгънәсе киңәя, ул аерым кеше чикләрендә генә калмыйча, милләт булып гомумиләшә. Шулар аша милләтне саклап калучы көчләр буларак дин, иман күтәрелә:

*Белмим, ничек дәваларга бәгырьне,*
*Кемгә ярып күрсәтергә йөрәкне...*
*Сугыш чорларыннан бирле Ил-көнгә*
*Без йөрәкләр белән булдык терәкле.*
*Ут телендә, су телендә аңлашып,*
*Суд казаларыннан калдык сакланып.*
*Авыл белән ач-ялангач булсак та,*
*Бераүне дә таламадык, сатмадык.*

Л.Янсуарның «Дөньялыктан саркыламы сагыш...» шигырьләр бәйләмендә дә иҗтимагый фикерләрнең фәлсәфи мотивлашуы күзәтелә.

Милли эчтәлекле реалистик шигырь-поэмалар, сүз дә юк, сәнгати яктан камил, бай эчтәлекле. Шулай да, журналның еллык саннарын тулаем карап чыкканнан соң, аваздаш темаларга язылган шигырьләр артып китмәдеме икән, дигән сорау туа. Әлбәттә, бүгенге вазгыять шартларында бу күренеш, бәлки, үзен аклыйдыр да, әмма журнал битләрендә реалистик юнәлештәге әсәрләрнең эчтәлек ягыннан бай, мотивлар җәһәтеннән төрле булуын да күрсәсе килә.

Романтик юнәлешкә мөнәсәбәтле шигъри әсәрләр, кагыйдә буларак, кешелек яшәеш кыйммәтләрен анлау-анализлауга йөз тота, фәлсәфи гомумиләштерүләрне үз итә, дини кануннардан читләшүнең мәгънәсез яшәешкә илтүе, яшәү мәгънәсен югалтуның ачылыгы, шуңа бәйле битарафлыкка, ваемсызлыкка чуму мотивлары урын ала, романтик образ-деталь, алымнарга таяна, аеруча каен, йолдыз, кояш, ай, болыт образларының актив булуы күзгә ташлана. Бу юнәлештәге шигырьләрдә мәхәббәт темасы алга чыга, шуңа бәйле рәвештә күңел лирикасына мөнәсәбәтле әсәрләр күпчелекне тәшкил итә. Мәсәлән, С.Гәрәеваның «Сердәшем каен», «Туган бусагам», «Җәй уртасы», Р.Сөләймановның «Елыйсыңмы?», «Белмимен нишләргә» һ.б. шигырьләрдә, яшь шагыйрә Д.Нәгыймуллинаның «Бәхетемне сина бүләк итәм» шигырьләр бәйләмендә мәхәббәткә бәйле хис-тойгылар урын ала.

Бу урында шунысын да әйтеп китәргә кирәк: журналның шигърият рубрикасында урын алган яшь авторларның иҗатында да, «Ак җилкән» рубрикасында урын алган яшьләрнең иҗат җимешләрендә дә традиционлыкның көчле булуы күзгә ташлана.

Аларның күбесендә яңалык күзәтелми, алар традицион детальләргә мөрәҗәгать итә, сөйгән ярны югалту-сагыш хисенең, кавышу шатлык хисенең сәбәбе төсен ала. Билгеле, әле алар яшьләр, аларның беренче иҗат җимешләре, киләчәктә әдәбият дөньясы алардан күпне көтә.

Бу юнәлештә Р.Рахманның шигырьләре уңышлы. «Ә сагышым — моңлы җыр икән» шигырьләр бәйләменә тупланган шигъри үрнәкләрдә мәхәббәт лирикасының фәлсәфи мотивлар белән баюы күзәтелә. Шагыйрә мәхәббәтне ике кеше арасындагы хис-халәт баскычыннан яшәү мәгънәсе, яшәеш гармониясенең чыганагы югарылыгына күтәрә, шушы юлда җир кояшы, якты көн, баеган кояш кебек шартлы-романтик образ-детальләргә мөрәҗәгать итә. Шундый ук мотивлар яшь шагыйрә Л.Вәлиеваның «Урал ала моң дәрьясы» шигырьләр бәйләмендә дә урын ала һәм хатын-кызлар шигъриятенең тагын бер талантлы шагыйрәгә баюы хакында хәбәр итә.

Р.Сөләймановның «Елыйсыңмы?», «Белмимен нишләргә» кебек шигырьләрендә Х.Туфан шигырьләренә охшатып стильләштерү күренеше урын ала. Шагыйрь шигырь юлларын кабатларга ярата, әлеге кабатлаулар шигырь структурасында фикерне көчәйтүгә юнәлтелә.

Аерым шигырьләр татар поэзиясе өчен традицион туган як темасына мөрәҗәгать итеп языла. Мәсәлән, С.Гәрәеваның «Туган җиргә торам бәйләнеп» шигырендә хис-кичерешләр үткәннәрнең якты хатирәсе буларак сакланачы ялан кыр, тау, су сукмагы образлары аша җиткерелә, алар туган җир белән бәйләнешне саклаучылар булып тәгәлләшә. Х.Мөдәррисованың «Уфа» шигыре дә шушы яссылыкта иҗат ителә, туган як, туган каланы ярату хисе үзәккә куела, ал нур, ак сирень исләре, йолдызлы төн, алтын ай кебек романтик образ-детальләр шушы мәхәббәтне ачуга юнәлтелә. Әмма әлеге шигырьне укыгач, ирексездән Х.Туфанның «Казанның кадерле кичләре» шигыре хәтергә килә, охшаш мотивлар, сурәтләү чаралары, үлчәм шул хакта сөйли:

*Ал нурга коенган урамнар,*
*Һавада ак сирень исләре.*
*Моң булып чакыра, иркәли,*
*Уфаның җыр тулы кичләре.*

Х.Мөдәррисова

*Кил әле, Иделнең җиләс җиле,*
*Юлларга чәчәкләр сип әле.*
*Ак булып, саф булып истә калсын*
*Казанның кадерле кичләре*

Х.Туфан

Аерым шигырьләр романтик материалда кешенең яшәеш кануннарын бәяләргә, яшәеш закончалыкларын аерып куярга омтыла. К.Булатованың узган елда басылган шигъри әсәрләре шушы фикерне раслый. Шагыйрәнең «Яшәргә омтылыш шундый нык» шигырьләр бәйләменә тупланып бирелгән шигырьләрендә ата-ана сүзен хаклап яшәү; иҗтимагый кануннарга баш имичә, кешелегенне саклап калу; матди тормышка түгел, рухи яшәешкә, рухи югарылыкка омтылу; мәхәббәттә тугрылык автор тарафыннан шундый яшәеш кануннары буларак билгеләп куела.

М.Мирзаның «Бербөтенлек хакның таләбендә» шигырьләр бәйләменә тупланып бирелгән шигырьләрендә дә шундый сыйфат белән очрашабыз. Әлеге шигъри үрнәкләр татар поэзиясен экзистенциаль мотивлар белән баета. Кеше гомеренең чикләнгәнлеге («Бер күк астында яшәп тә...»), язмышны үзгәртеп булмау тойгысы («Козгын кунды өйнең түбәсенә...») лирик герой күңелендә сызлану тойгысын тудыра. Бу сызлану аерым кеше тормышыннан башлап милләт яшәешенә кадәр гомумиләшә. Шушы фонда Ә.Фәйсалга ияреп язылган «Табигый сайланыш — каты канун» шигыре сызланудан юану буларак кабул ителә:

*Һәлакәтен чигендәрә алган*
*Бөгелсә дә, сынмас, тураер.*
*Бүленсә дә — кабат якынаер,*
*Туганнарын җыеп зураер...*
*Тарихында килеп киткәннәр күп.*
*Гыйбрәтләнеп тагын ни әйтим?*
*Өммәтеннән көч-кодрәт алыр да*
*Тураеп ук басар милләтем.*

Шушы ук сыйфат белән яшь шагыйрә Г.Корбанова әсәрләрендә дә очрашабыз. «Юшкыннарны юа вакыт» шигырьләр бәйләмендә иманга тугрылык («Юктыр синен...»), мәхәббәттә тугрылык («Хыялдагы бер хатирә булып») төп яшәеш кануннары кебек билгеләнә. «Язларым...» шигырендә яз / җәй / көз / кыш янәшәлеге кеше гомеренең төрле этапларын тергезеп, вакытның кешедән өстенлеген раслап куя. Шушы ук автор иҗатында форма эзләнүләре дә күзгә ташлана. Мәсәлән, «Кара болыт» шигырендә кара болыт / ак болыт янәшәлеге тудырылып, һәр икесенең дә мәгънәви трансформация кичерүе күренә. Шигырь тукымасында ак болыт бушлык, билгесезлек төсмерен ала (мәсәлән, Р.Хариснын «Ак шом» шигырендә дә шушы мәгънә төсмере белән очрашабыз), кара болыт — яңгыр болыты — файда чыганагы итеп куела.

Бу чор шигъриятенә хас сыйфатларның берсе буларак интеллектуаль тенденциянең, шартлы-метафорик юнәлешнең үсеш алуы билгеләнә. Әдәби тәнкыйть шигъриятнең бер үзенчәлеге төсендә уйлануччан башлангычның көчәюе, лирик геройның рухи дөньясы катлаулануы, зиһен һәм фикер эшчәнлеген тулырак ачарга омтылышның, эчке уйлану, нәтиҗә ясау рухының үзенә бер агым буларак үсүен, интеллектуаль башлангычның көчәюен билгеләп үтә. Интеллектуаль поэзия җәмгыятьнең актуаль мәсьәләләрен әдәби материалда чишәргә омтыла, дөньяның, яшәешнең торышына анализ ясый. Еш кына рухи кризис, иҗтимагый торгынлык вакытында алга чыккан интеллектуаль тенденция авторның игътибарын кешенең күңел кичерешләреннән бигрәк, зиһен, акыл мөмкинлекләренә юнәлтә, аларга каршы тору юлларын кешенең үз шәхси мөмкинлекләреннән, интеллектыннан эзли. Биредә автор сөйләүче, аралашучы, әңгәмәдәш кенә түгел, ә бәлки эзләнүче, сорау куючы буларак килеп баса, аның уй-фикерләре әсәрнең хис-кичереш халәтен барлыкка китерәләр. Шуңа бәйләнештә анализ рухы көчәя, шигърияттә аналитик уйлану алга чыга, сәнгатьчә фикерләүдә шартлылыкка, вакыт образына еш мөрәҗәгать ителә. Интеллектуаль тенденция вакыт образын, үтә шартлылык алымнарын үз итә. Быелгы «Казан утлары» журналында дөнья күргән шигырьләр арасында Ж.Сөләйманов, Й.Миннуллина шигырьләренең шушы алымнарга йөз тотуы күренә.

«Өтүкән жирендә ут яна» поэмасы әдәби тәнкыйтьтә еш кына «йолдызлар белән генә эш итә», дип тәнкыйтьләнүче Й.Миннуллина иҗатында да үзгәрешләр барганлыгы хакында хәбәр итә. Әсәр структурасында сюжет сызыгы ике вакыт катламын берләштерә. Тарихи вакыт 552 елда I Төрки каганлыгы төзелгән, 604 елда аның Көнбатыш һәм Көнчыгыш каганлыкларына аерылган вакытына мөнәсәбәтле вакыйгаларны тергезә, шартлы алымнардан вакытлар кушылуы күзәтелә. Поэма тарихи сюжетка нигезләнсә дә, төп фикер интеллектуаль сюжет чылбырында житкерелә. Бүлек башларында тәкъдим ителгән эпиграфлар автор позициясен ачу барышында ачкыч хезмәтен үти һәм төркиләргә бирелгән бәя, аларга бәйле вакыйгалар милләтнең бүгенге халәтенә бәйле фикерләрне үткәрергә ярдәм итә. Коллыкның башы һәр халыкның үз холык-фигыленә, үз асылыннан ераклашуга барып тоташа, ягъни халыкларның жинелүенә, башка бер халыктан бигрәк, ин беренче чиратта, ул үзе, аның төрле гамь белән яшәве гаепле дигән гыйбарә ассызыклана («Жиде яугир яудан кайта — Жидесендә жиде ятның гаме»). Бу фикер автор тарафыннан әйттерелеп, алдагы бүлекләрдә көчәйтелә. Таркаулык — «Күк белән Жир арасында Минем илем, синен илен», үз максатына тугрысызлык, матди байлыкка кызыгып, рухи кыйммәтләрдән читләшү — «Ялангачны киендерсә, Мал-

туарга тиендерсә — Шулай булса, безнен халык, татлы сүзгә хәйран калып, Чаптар атын читкә бора, Дошман белән кинәш кора — Сөйгән яры тол була. Оланнары кол була», динсезлек, Аллаһ каргышы — «Дин үзгәртә. Жилкәсенә баса Тәнре каргышы», тәхеткә омтылыш нәтижәсендә хакимият вәкилләренен тугрысызлыгы — «Иярлә дә бүз атынны, Чиру тупла сак кына, Үз халкына түгел, Тәгин, Бөек илен хакына», ятларга хезмәт итү — «Елтыр күлмәген сәдәпләп, Үз исемен жуйган бәкләр», мескенлек — «Каганнан ятим калып, Йола алыштырган халык» кебек тулаем тискәре сыйфатлар татар халкынын холкын ассызыклый, үз чиратында бу сыйфатлар «Аллаһ каргышы» — жинелүгә — этәрүче көч дип алына. Шушы өлештә әсәр тукымасына автор фикере кушылып, анын үз халкын кисәтүе, әле дә булса дәвам иткән мондый тискәре сыйфатлардан арынырга чакыруы булып янгырый.

Дәүләтчелекне югалту вакыйгалары белән бәйле халык фажигасе хис катламынын эчтәлеген билгели: лирик герой күнелендәге әрнү, сызлануга сәбәп төсен ала. Татарларнын тискәре холкы тудырган борчылу белән алмашыну аша сызлану үзенен югары ноктасына күтәрелә, киләчәкнен билгесезлеге аны тагын да көчәйтә:

*Өтүкән җирендә ут яна,*
*Туфракта сутелә тамырлар.*
*Кайт кына — учыңа яшергән*
*Борынгы учеңнән танырлар.*
*Юрама югалган эзләрдән*
*Вакытның хөкеме хаклымы?..*

Шул рәвешле, төп фикер сюжет үстерелеше ярдәмендә түгел, ә бәлки, интеллектуаль әдәбиятка хас булганча, фикер сөземтәләре ярдәмендә ачыклана. Бу әсәр Й.Миннуллинанын матур табышы булып тора. Гомумән, татар поэмасы 1960-1980 еллардагы күтәрелешен, шигъри мәйданга С.Хәким, И.Юзеев, Р.Әхмәтжанов, М.Әгъләмов һ.б. кебек поэма осталары килүен көтә.

Интеллектуаль алымнар аша яшәешкә (жиһан) һәм жир тормышына, кешегә бәя бирү омтылышы Сөләйманның «Татар бишегендә татар баласы», «Канатларны — каурый каләм иттем» кебек шигырьләрендә дә көчле.

Журналда урын алган поэтик әсәрләргә хас тагын бер тенденция төсендә модерн алымнарнын активлашуы күзгә ташлана. Әлеге үзенчәлек Б.Ибраһимов, Р.Зәйдулла, Р.Акъегет шигырьләрендә урын ала. Мәсәлән, бу яктан Р.Зәйдулла шигырьләре үзенчәлекле, кызыклы. 1990-2000 еллар аралыгында экспрессионистик алымнарга еш мөрәжәгать иткән, гыйсъянчы лирик геройны әдәби мәйданда янарткан Р.Зәйдулла шигырьләрендә башка стиль тенденциясе алга чыга. «Чарасыздан жанны бер өн били» шигырьләр шәлкемендә шагыйрь, проза әсәрләренә хас үзенчәлекне янартып, символларга мөрәжәгать итә, шулар аша ачылган автор позициясе күпкатламлы төсмер ала. Мәсәлән, «Кирмән» шигырендә кирмән, чәнечкеле гөлләр, үксез кош образлары бүгенге вазгыять шартларындагы милләт яшәешен шәрехләргә мөмкинлек бирә. «Төрек кызы» шигырендә лалә, янып торган пиала кебек суфичылык поэзиясе аша танылa торган образлар һәм яну мотивы («Ымсындыра безне гыйшык кичәсе, / Пиаладан янар өчен эчәсе, / — Актарырлар аннан безнен көлләрне, / Һәм ташларлар өскә лалә гөлләрен») дөньяви мәхәббәтне ачуга юнәлтелә. Суфиларда шәраб эчеп исерү сурәте актив кулланыла; Аллаһ белән кушылу мотивынын көчле булуы билгеле. Шигырьдәге әлеге сурәтләр исә дөньяви контекстта хатын-кызга мәхәббәтне тасвирлый. Лирик герой жир кызына мәхәббәт тотучыга әверелә. Шуларга нисбәтән шигырьнен идеясе дә формалаша: мәхәббәт кеше күнеленә рәхәт бирә, бәхет китерә.

«Жәлил» шигырендә дә символик сурәт алга чыга. Дәрдемәнд шигъриятеннән үстерелә килгән ил карабы, дингез образлары милләт тормышын, яшәешен гәүдәләндереп килә. Үзенчәлекле образлар системасы ярдәмендә шагыйрь татар милләтенең торышын күрсәтә, шагыйрь һәм милләт язмышын илаһи бердәмлектә сурәтләргә омтыла. Гомумән, бу чор лирикасында караб бату, йотылу куркынычын аңлата һәм анын котылуы өчен кирәк булган корбан борынгы риваятьләргә ишарә

ясый. Халыктагы ышанулар буенча, бата башлаган корабтан бер жанны дингезгә ташлау котылу китерә, дип уйланыла. Шигырь тукымасында символның әлеге мәгънәсе урын ала һәм бетү, югалу, үлем мотивын алып керә, «дингез сораган ясак» карабны коткару өчен кирәкле корбан булып аңлашыла, «дингез сораган ясак» / Җәлил янәшәлеге тудырыла. Шул рәвешле Җәлил гомеренең милләт язмышыннан аерылгысызлыгы ассызыклана: ул, милләтенең киләчәк бәхете хакына, халкын коткару өчен җанын бирә (шундый ук мотив һәм сурәтләр белән без Тукайга багышланган әсәрләр арасыннан Х.Габидовның «Нигә бу шәмнәр сүнә» шигырендә дә очрашабыз). Иҗат кешесе — милләт сакчысы, иҗат — рух сакчысы мотивы Р.Зәйдулланың «Җиз кыңгырау», «Риваять» шигырьләрендә дә үзәккә куела. Гомумән, Р.Зәйдулла шигырьләре сәнгати яктан югарылыгы, үзгәлеге, күпкатламлы булуы белән игътибарны җәлеп итә.

Р.Акъегетнең «Күнелем — салават күпере» шигырьләр бәйләмендә үзгә күренеш белән очрашабыз. Биредә янәшәлекләрне үзәккә кую төп алым буларак аерылып чыга, нәкъ менә әлеге үзенчәлеккә, үзгә шигырь калыбына мөрәҗәгать итү, бер яктан, Р.Фәйзуллинның кыска шигырьләре белән ассоциатив бәйләнешләр уздырырга мөмкинлек бирә, икенче яктан, традицияләрнең дәвам итүен, алай гына да түгел, 1960 елларда яңалык буларак кабул ителгән бу сыйфат-үзенчәлекләрнең «үз» булып өлгерүен, милли шигърияткә хас күренеш буларак үзләштерелгәнлеген раслый. «Яшьтәшләрдән...», «Агачлар биек булганда...», «Кояш сурәте» шигырьләре шул рәвешле кабул ителә.

Әлбәттә, кечкенә генә мәкалә чикләрендә бер ел дәвамында басылган барлык шигъри әсәрләргә дә бәя бирү мөмкин түгел. Гомумиләштереп әйткәндә, «Казан утлары» журналының 2013 елгы саннарында дөнья күргән шигъри әсәрләр XXI гасыр башында барган күп кенә тенденцияләрне чагылдыра. Образлылык, традицион мотивлар шагыйрьләрнең милли нигезләргә йөз тотуы, татар поэзиясенең элгәреге унышларын дәвам итүе, үстерүе, камилләштерүе, баетуы хакында сөйли. Нәкъ шушы сыйфатлар шигъриятнең гасырлардан-гасырларга күчә килгән шигъри көченең сакланып калуын тәэмин итә.

Бер үк вакытта кайбер җитешсезлекләрне дә әйтми калу мөмкин түгел. Бер яктан, журнал төрле катлам укучыга — яшьләргә дә, өлкән буынга да кызыклы булырга тиеш. Журнал битләрендә сан ягыннан күбрәк авторларның иҗаты белән танышасы килә, шушы фонда бер үк елда бер үк авторның (И.Гыйләҗев) ике тапкыр басылуы үзен аклыймы икән? (Юк, мин һич кенә дә аның шагыйрь буларак талантын кире какмыйм). Хатын-кыз шагыйрәләр иҗатын да күбрәк күрәсе килә. Әлбәттә, яшь һәм өлкән буын хатын-кыз шагыйрәләр иҗатына киң мәйдан бирелә, әмма урта буын шагыйрәләр игътибардан читтәрәк кала шикелле. Икенчедән, интернет белән мавыккан, чит кыйммәтләргә йөз тоткан бүгенге яшь буынны тәрбияләү, милли әсәрләр укуга, әдәбиятка тарту, журналның даими укучылары итү өчен, милли нигезләрдән аерылмаган хәлдә, әдәби концепция ягыннан үзгә, фәлсәфи-интеллектуаль әсәрләр дә тәкъдим итәргә кирәктер, минемчә. Чөнки журналның киләчәге аларга да бәйле бит. Өченчедән, татар шигъриятенең алтын фондын тәшкил иткән шигыйрьләрнең әсәрләрен бастырып бару да зыян итмәс иде кебек. Һәр санда димим, елына дүрт тапкыр гына булса да Дәрдемәнд, С.Сүнчәләй, Һ.Такташ, Х.Туфан, С.Хәким, И.Юзеев, С.Сөләйманова, М.Әгъләмов, Зөлфәт һ.б. шигырьләре дә басылып барса, күркәм булмас идеме?! «Әдәби мирас» һәм «Шигъри хәтер» рубрикалары шуның матур башлангычы кебек кабул ителә һәм ул дәвамлы булсын иде дип телисе килә. Гомумән, «Казан утлары» журналы киләчәктә дә үзенең классик юнәлешен саклап, шигърият мәйданында барган һәр үзгәрешнең үзәгендә «кайнасын», әдәби бизмән булып торсын иде.

**Нурфия ЮСУПОВА,**
*филология фәннәре кандидаты,*
*КФУ доценты*

# МИЛЛИ СӘНГАТЕБЕЗНЕҢ ОЛЫ ХӘЗИНӘСЕ



*Милли театрыбыз иң яшь сәнгать төрләреннән саналса да, ана телебезне, милли үз йөзебезне саклап калуда ул тулы бер гасыр дәвамында зур роль уйнады. Татарстан телевидениесе аша узган гасырда куелган спектакльләрне караганда да, без театрларыбызның лаеклы сәнгати югарылыкта булуын күрәбез. Социализм дигән модернизацияләнгән җәмгыятьнең идеологиясенә буйсынып хезмәт иткәндә дә, милли театрыбызның миллилеге асылын саклавы безне сокландыра... Театрларыбыз репертуарына кергән тәрҗемәдәге рус, чит ил драматургиясе буенча куелган спектакльләрдә дә миллилек өстенлек итә. Миллилек мәгърифәтчелеккә өстенлек бирү белән генә аңлатылмый. Театрларыбыз бик кыю рәвештә социаль-иҗтимагый тормыш, халыкның яшәү көнкүреше, традицияләре темаларына да гел әһәмият бирә. Нәкъ менә халыкка якын торуы, аның рухи ихтыяҗларын тоемлавы театрларыбызның милли йөзен билгелидер дә, чынында.*

*Шөкер, бүген дә театрларыбыз милли сәнгатебезнең әйдаманы, олы хәзинәсе булып хезмәт итә. Укучыларыбызга Республика театр әһелләре берлеге рәисе, Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының баш режиссёры Фәрит Бикчәнтәев белән әңгәмә тәкъдим итәбез.*

**— Фәрит әфәнде! СССР дәүләтенең мәдәният өлкәсендә алып барган сәясәтендә төп шигарь буларак: «Формасы белән милли, эчтәлеге белән социалистик» дигән сүз тезмәсе бик еш кулланыла иде... Хәзер ул лозунгларга елмаеп кына карыйбыз. Әмма шул дәвердә безнең иҗатчыларыбыз формасы белән генә түгел, ә эчтәлеге белән дә чын милли мәдәниятебезне-сәнгатебезне үстерделәр. Сезнен үзегезнең дә шәхес буларак та, иҗатчы буларак та формалашуыгыз шул дәвергә туры килә. Бүген миллилекне авыл тормышы белән генә бәйләп, икенче планга куеп «сөйләшүчеләр» дә бар. Бу хакта Сезнең фикерләрегез укучыларыбыз өчен бик тә әһәмиятле булыр иде.**

— Минемчә, миллилекне аерым бер темага бәйләп яки ниндидер планга куеп булмый. Авыл темасын күтәрсән, милли булыр, авыл турында сөйләмәсән, милли булмаячак, дип. Миллилекне авыл белән генә бәйләүчеләр, минемчә, бик нык ялгышалар. Ә икенче яктан уйлап карасак, танылган шәхесләребезнен күбесе бит авылдан чыккан. Мин, мәсәлән, авылда йорт сатып алдым, авылны, анын тормышын аз-маз күрә башладым, шуңа берникадәр килешәм: авыл темасы, авыл үзе бетсә, халкыбызнын милли чыганаклары, рухи байлыгынын искиткеч зур бер өлеше югалыр дип куркам. Без Бәрәскә авыл советы рәисе Илгиз Хәйруллин белән бик дус, очрашкан саен ул үзенен проблемалары турында сөйли. Авылларнын юкка чыгу проблемасы мине дә бик нык борчый. Бу сүзләрне ихлас күнелдән әйтәм, сүз өчен генә түгел. Илгиз фикеренчә, бер егерме елдан авыл бетәчәк, анын урынында гел дачалар гына калачак. Өлкәннәр әкренләп дөньядан китә, хәзерге яшьләрнен

авылда каласылары килми. Бу бик зур проблема. XIX гасырның ахыры — XX йөз башы — милли үсеш, шуның белән бергә шәһәр культурасы, мәдәнияте, интеллигенция катламының күтәрелүе, белемгә омтылу, аеруча шәһәрнең милли культурасы барлыкка килү чоры. Советлар хакимияте урнашу белән, болар барысы да бетерелә, милләтләр тигезләштерелә. Совет чорында шундый идеология урнашты: әллә кая омтылмагыз, сезнең авылыгыз бар, шул тема белән чикләнегез, янәсе. Минемчә, бу проблеманы ике сүз белән генә анлатып булмый. Монда илебезнең тарихы зур әһәмияткә ия. Мисал итеп, «Зәңгәр шәл» спектаклен китерергә мөмкин. Татар театрының 20 нче елларда өч юлдан китү мөмкинлеге булган. Берсе анын — төрки дөнья, икенчесе — көнбатыш-европа театрына ияру, өченчесе — үз милли юлын табу. Менә шул вакытта — 1926 елда — мәйданга К.Тинчурин белән С.Сәйдәшев иҗат иткән «Зәңгәр шәл» спектакле чыга. Татар кешесенә яңадан чабата кидертеп, үзебезчә, безнең милләтебезгә генә хас сыйфатларны үз эченә алган, менә шушындый формадагы театрга нигез салынган. Ике талантлы кеше очрашкан... Алар, әлбәттә, аңлаганнар: совет заманында милләтне саклап калыр өчен, халыкка якын булу кирәк, бары тик халык белән тыгыз элемтәдә генә татар театры, татар мәдәнияте, милли үзаңыбыз үсешкә ирешәчәк. Без аларга рәхмәтле булырга тиеш, чөнки ул заманда театр төрки культура юлыннан китсә, сәхнә сәнгате башында торучыларны гаепләп юк итәрләр иде, европа театрлары юлыннан атласа, без үзебезнең йөзебезне югалтыр идек. Менә шул вакытта авыл темасы театрда тупланеп калгандыр, мөгаен. Әгәр дә бүген бары тик авыл темасы милләтне саклап калачак дип әйтәләр икән, килешәм дә, килешмим дә. Урталыкны сайларга кирәк дип уйлыйм мин. Без шул юлдан барырга тиеш. Совет заманында, 70 нче еллар, 80 нче еллар башы, аеруча худсовет заманнарында, безгә өстән программа төшерәләр иде. Мәсәлән, сезонга бер рус классикасы куелырга тиеш иде, репертуарда чит ил драматургиясе булырга тиеш, йә азәрбайҗан, йә үзбәк, йә таҗик әсәре булу шарт, моны нык тикшерәләр, күзәтәләр иде. Бер яктан, җинел дә булган, чөнки план бар. Нидер уйлап табарга кирәк түгел. Ә хәзер бит план юк. Без ирекле, икенче яктан... Ирек дигән нәрсә ул бик хәтәр. Кеше ирекка чыдый алмый.



*«Арбалы хатыннар» (З.Зәйнуллин) спектакленнән күренеш. 2010 ел.*

Миллилек кешедә йә бар, йә юк инде ул. Авылда яшиме, шәһәрдәме... Авыл кешеләренең кайберләре милләтнең ни икәнен анламый, шәһәрдә дә шулай ук. Балалары да шул рухта тәрбияләнә. Шәһәр гаиләсендә дә менә дигән милли җанлы бала үстерүчеләр бар.

Кайбер җырчыларның, шагыйрьләрнең бөтен иҗатлары авыл темасына корылган. «Туган авылым», «авыл бетә», «авылга кайтасы килә», «әнием авылда калды...» Кайт! Авылдан китәләр, авылны сагынып җырлар җырлыйлар, шул җырларны авылларына кайтып җырлыйлар һәм үзләре артыннан яшьләрне ияртеп китәләр. Абсурд! Алар бит җырларында шәһәргә чакырмыйлар, җырларында авыл турында җырлыйлар. Сагыналар. Сагынасын икән, кайт та тор авылда. Шагыйрьләрнең шигырьләрендә дә шулай. Бөтенесе турында сүз бармый, әлбәттә. «Йөрәгем әрни, авылым бетә, / Кайткан идем авылга, авылым бетә» ... Бетермә, бар, кайт та эшлә.

Миллилек дип кычкырып йөргәнче, милләтенә хезмәт итәргә кирәк. Минем өчен



*«Зәңгәр шәл» (К.Тинчурин) спектакленнән күренеш. 2011 ел.*

гасыр башындагы җәдитчеләребез үрнәк булып тора. Алар милләтебезне күтәрергә тырышкан, алга барырга өндәгән. Хәзер миллилек артына яшеренәләр, үзләре милләт өчен берни эшләмиләр. Артка гына тарталар. Имеш: «Ничек инде сез чит ил классикасын куясыз, начар булсын, әмма үзебезнеке булсын». Халкыбызны белемле итәргә тырышып, мәдрәсәләребезне үзгәртеп, күпме көрәшкән ул шәхесләр гасыр башында. Шәкертләр күтәрелгән. Тукайлар, Фатих Әмирханнар, Гаяз Исхакыйлар... Ә хәзер янадан кирегә әйләнеп кайтабыз.

**— Театрларыбызның репертуарларына күз салсак, шөкер, аларда күпчелек милли драматургларыбызның әсәрләре сәхнәләштерелүен күрәбез. Г.Камал театрында да үзебезнекеләр өстенлек итә... Соңгы ике-өч елда К.Тинчуринның «Зәңгәр шәл»е, Г.Камалның «Банкрот»ы кабаттан сәхнәләштерелүе, М.Җәлил исемендәге Опера һәм балет театрында Р.Ахиярованың «Шагыйрь мәхәббәте», «Алтын Урда» опера-балетлары сәхнәгә куелуы театрлар өчен генә түгел, ә тулаем милли сәнгатебез өчен олы вакыйга булды. «Зәңгәр шәл» — мелодрама булуга карамастан, драматик коллизиясе бик кискен булган әсәр. Анда сыйнфый каршылыкларны, социаль тигезсезлекне, муллаларның «чын йөзен» ачу беркемне дә битараф калдырмый. Ә инде качкыннарның бунты һәм байларның милкенә «кызыл этәч» җибәрү күренешләрен тамашачылар алкышлап каршылый иде... «Зәңгәр шәл»не ничәмә-ничә тапкыр сәхнәләштергәндә дә, «бунтка» чакыру, «Набат» бар кебек. Сез моны ничек шәрехлисез? Бу куркыныч түгелме?**

— Бу бит бунтка түгел, ә якты киләчәккә чакыру, иреккә чакыру. Хөррият, ирек бик зур җаваплылык таләп итә. Сәхнә әсәре — ул образ. Кешенең эчендә бунт булырга тиеш. Бүгенге тормыш белән килешмәү. Ә «Зәңгәр шәл»гә килгәндә, аны хәзер тарихи әсәр итеп кабул итәргә кирәк. Бу әсәр, спектакль турында мин бик озак сөйли алам. 1926 елда язылуга карамастан, бик кызыклы бер факт бар: нәкъ менә шушы елны совет экраннарына «Булат-батыр» исемле кинофильм чыга. Нәкъ менә качкыннар турында. Кызганычка каршы, фильмны бик аз күрсәтәләр. Аерым татарлар, чукындырудан качып, урманнарда яшәгәннәр һәм анда үзләренчә зур эшләр алып барганнар. Чарасызлыктан. «Зәңгәр шәл»дәге урман пәрдәсе — тарихи факт. Ә менә иске карашлы ишаннарны тәнкыйтьләү Тинчурин белән Сәйдәшев тарафыннан совет заманында төп теманы яшерү өчен генә булдырылган. Тарихны кабатлап булмый. Бунтка түгел, кешенең эчке рухын иреккә чакыру бу. «Зәңгәр шәл»нең төп сәхнәсе урман күренеше булса, әсәрнең төп идеясе — кешенең иреккә омтылуы.

**— Тинчурин — безнең олы язучыбыз һәм драматургыбыз... Ул да, Г.Камал кебек, драматурглыкта танылганчы театрда артист, аннары соң үзе режиссёр, сәнгать җитәкчесе була... Баксаң, безнең күпчелек драматургларыбызны да театр тәрбияләп үстергән икән. Галиәсгар Камал үзе, Риза Ишморат, Таҗи Гыйззәт, Туфан Миңнуллин, Рабит Батулла, Юныс Сафиуллин, Рәдиф Сәгъди, Данил Салихов, Фәнәвил Галиев, Илгиз Зәйниев... Белүемчә, Сез үзегез Нәкый Исәнбәт иҗатына бик мөкиббән. Нәкый аганың үлемсез «Хуҗа Насретдин»е кайчан сәхнәбезгә кайтыр? Хуҗанасретдинлык безнең милләтнең асылында бит инде! Безгә калса, Камал**

**театрында Хуҗаны уйнарлык ике буын — яшь һәм урта буын артистларыбыз бар... «Банкрот»та без аларны күрдек? Әллә хәзергә «Банкрот» җитеп торыр, аның янына «Хуҗа Насретдин» да килеп керсә, бүгенге репертуардагы «салмак комедияләр»гә урын тараер дип шикләнәсезме? Халыкның юморга булган ихтыяҗын «Мунча ташы», Буа театры гына канәгатьләндереп бетерә алырмы?**

— Канәгатьләндерә бит әле. «Мунча ташы»на билетлар юк, Буа театры килсә дә, билетлар юк. Димәк, канәгатьләндерә. «Банкрот» артыннан театр «Хуҗа Насретдин»ны эшли башлаячак. Юмор ул — югары, катлаулы жанр. Ә безнең кайбер театрлар эшләгән жанрны мин берничек тә атый алмыйм. Чын юмористлар бездә бик аз, юк дәрәҗәсендә. Минемчә, бездә әле хәзергә юморның культурасы юк. Француз юморы, инглиз юморы бар. Әгәр дә безнең юмор татарны надан, томана итеп күрсәтә икән, мин бу юмор белән килешә алмыйм. Юморның максаты шунда: көлү аша халыкны күтәрергә тиеш ул. Иманым камил: безнең театрга комедия карарга киләләр икән, шул ук «Банкрот»ка булсынмы, «Мәхәббәт FM»гамы, «Хуҗа Насретдин»га да килерләр дип уйлыйм, инде кызыксыналар, бу спектакль турында сорашалар, димәк, безнен халык чын комедияне аера белә. Комедия шулай ук югары жанр, ә анекдот ул — халык уйлап чыгарган. Ул бар икән, булсын. Ул да булсын. Халык надан түгел, аера белә. Ул аңлый: бүген мин Камал театрына, ә иртәгә «Мунча ташы»на барам, ди. Ул бит бу ике театрны бутамый.



*«Банкрот» (Г.Камал) спектакленнән күренеш. 2013 ел.*

**— Алдагы соравым провокационрак иде... Хәзер чын-чынлап җитди итеп сорыйсым килә. Милли репертуар мәсьәләсе — бик җитди мәсьәлә.**

**Пьеса авторының милләте татар булу гына әле аны милли иҗатчы итми. Мәрхүм Шамил Зиннур улы Закиров белән Сезнең ярдәм булып, «Яңа татар пьесасы» конкурсын оештырып җибәрүегез ул зур этаплы эш иде. Ялгышмасам, беренче конкурс бердәнбер роман — Мәхмүт Галәүнең «Мөһаҗирләр» романы буенча сценарийлар конкурсы булды. Качаклар темасы — татар халкы өчен генә түгел, бөтен инсан өчен мәңгелек тема... Әнә диндәшләребез булган сүриялеләр нинди фаҗигаләр кичерә бүген? Конкурска күренекле язучылар, артистлар тартылуын һәм әйбәт кенә сценарий үрнәкләре булуын үзегез үк әйткән идегез. «Мөһаҗирләр» ник сәхнәгә менмәде?..**

— Менәчәк. Сценарий дигәннән, без конкурс игълан итүен иттек, «Мөһаҗирләр»не бит Минзәлә театры да, Ринат Әюпов та үз театрында куйды. Инсценировкалар куела. Без А.Гыйләҗевнең «Яра»сын, Ф.Хөснинең «Йөзек кашы»н куйдык. Инсценировкалар театрда туарга тиеш дип саныйм. Инсценировканы иҗат итүче автор режиссёр белән бергә эшләгәндә генә сәхнә әсәре туа ала. «Мөһаҗирләр»гә килгәндә, хәзергә аның вакыты җитмәгән, күрәсең.

**— Гомумән, безнең әдәбиятыбызда, роман булсын, поэмалар булсын — сәхнәләштерерлек әсәрләр бик күп. Әнә Аяз Гыйләҗевнең «Яра»сын, Г.Исхакый буенча «Курчак туе»н сәхнәләштердегез. Тинчурин театрында Р.Заһидуллин Н.Фәттахның**


*«Банкрот» (Г.Камал) спектакленнән күренеш. 2013 ел.*

**«Итил суы ака торур»ын, Кол Гали буенча «Йосыф»ны сәхнәгә алып менде. Татар яшьләре театрында Р.Әюпов Г.Тукай, М.Җәлил буенча тамашалар күрсәтте... Болар — чын милли репертуарны тотардай әсәрләр... Сезгә карата тәнкыйть фикерләре әйтүчеләргә мин шул мисалларны китереп, Сезне яклаштырам кайчакта...**

— Рәхмәт, әлбәттә. Хәзер инде мин яклауга мохтаж түгел, чөнки театрны, мине тәнкыйтьлиләр икән, минемчә, бу унай күренеш, шулай булырга тиеш. Димәк, бу кешеләр битараф түгел, менә бөтенләй дәшмәсәләр, бернәрсә язмасалар, анысы инде куркыныч. Шуна күрә бүген тәнкыйтьне бик тыныч кабул итәм.

**— Шамил Закиров белән Сезнең ул башлангычыгызны дәвам итү бик тә кирәк. Безнең һәр милли театрыбызда милли каһарманнарыбызга багышланган бер спектакль булу кирәк, минемчә. Ул бигрәк тә яшь буын өчен кирәк. «Кол Гали», «Канкай углы Бәхтияр», «Идегәй»ләр бик кыска гомерле булды. «Моңлы бер җыр» да М.Җәлил юбилее өчен генә идеме? Г.Тукаебыз сәхнәгә милли каһарман булып кайчан менәр? Быел һәм алдагы елда Сөембикәбезнең тууына 500 ел тула. Бу уңайдан, Фәрит әфәнде, иң күренекле драматургларга дәүләт заказы рәвешендә пьеса яздырырга уйламыйсызмы? Сөембикә-патшабикә турында Гавриил Державинның «Царица Сююмбике» драмасы бар. Үзебезнең язучыларның берничә романы басылып чыкты? Флүс Латыйфиның «Хыянәт», В.Имамовның «Утлы дала», Ф.Бәйрәмованың «Күчем хан»ы сәхнәгә менәргә лаек дип беләбез. Г.Исхакыйның «Олуг Мөхәммәд»е дә сәхнәләштерүне көтә. Кардәш әдәбиятлардан тәрҗемәләр ясап сәхнәләштерү буенча нинди планнар бар?**

**Сорауларым бик күп булды... Әйткәнемчә, болар эпохаль әһәмияткә ия!**

— Мин бик үк анлап бетермим, ни өчен милли каһарманнарыбыз сәхнәгә менәргә тиеш. Әгәр дә әсәр роман булып иҗат ителгән икән, укысыннар. Ни өчен бөек Тукайны сәхнәгә менгезергә — шигырьләрен укысыннар. Мине, әлбәттә, тарих бик кызыксындыра. Тарих — ул фән. Тукайның юбилеен эшләргә тәкъдим ясаганнар иде. Мин күз алдыма китерә алмыйм, ничек инде Тукайны артист уйный. Тукай — бөек, аны мин сәхнәдә гади телдә сөйләштерә алмыйм. Театр күбесенчә бүгенге көн проблемаларына кагылырга тиеш, минемчә, ә тарих безнең өчен томан артында. Аны бары тик фән генә төгәл, дөрес итеп ачып бирә ала. Театрда Сөембикәләрне, Олуг Мөхәммәдне куюо... Мин куркам. Куркуымның сәбәбе нидә дисәгез, ялгышудан куркам. Мин әле бүгенгедәй хәтерлим: Марсель Хәкимовичның «Идегәй» белән ничек газапланганын. Бу спектакльне ул бик авыр чыгарды. Инде премьера чыгар алдыннан икеләнгәнен искә төшерәм. Идегәй бит ул каһарман түгел, аның дастаны бөек. Идегәй бит ул тарих буенча бөтенләй башка персонаж. Геройларны күккә чөю заманын без бит инде уздык. Совет заманында шактый геройларны күтәрдек. Ә хәзер кинәт кенә барысы да үзгәрде, карыйбыз — ул бөтенләй герой булмаган икән. Ә инде тарихны бөтен дөреслеге белән ике сәгатьлек бер спектакль эченә сыйдырып бетерү бик авыр. Театр дөреслеккә корылган булырга тиеш.

**— «Банкрот»ка әйләнеп кайтыйк әле! Миңа, тамашачы буларак, «Банкрот» һәрчак ошый. Үзенең актуальлеге, тормышчанлыгы, халыкчанлыгы белән. Характерларның төрледән-төрле ягы белән. Яңа «Банкрот»ны да рәхәтләнеп карадым. Кабул иттем... «Банкрот»та автор материалы бик бай, әмма һәр очракта да спектакльләр гел режиссура өстенлеге белән тәкъдим ителде. М.Сәлимҗановта да, Сезнең куелышта да... Сиражи ролендәге**

**Радик Бариев — мөстәкыйль аерылып торучы «артистлар тибы» буларак (андыйларны чит образда күрүе кыен — алар үзләре булып күренә, кабул ителә), барыбер Радик Бариев булып калды, әмма барыбер өр-яңа Сиражи булып кабул ителде яки, киресенчә, Радик Бариев Сиражи булып кабул ителде, тик барыбер Радик Бариев булып калды. Ничек кенә әйтсәк тә, шулай килеп чыгуы — «Банкрот»ны бүгенге көнгә кайтарды — Сиражины бүгенге көн Сиражие итте. Бирсен Ходай, И.Әхмәтҗанга — Тукай, Р.Шәрәфигә Әҗәл кушаматы тагылган кебек, Р.Бариевка да Сиражи, дисеннәр. Бу Сиражига нинди-дер «трюк»лар, манералар өстәмәүдә генә түгел, ә төс-кыяфәте белән «сәүдә эшендә» шомарган халыкларга охшаган татарның өр-яңа булачак алдапсатары, мошенник-Мавродие, хәтта олигархларны сурәтләү булып кабул ителде... Бу чыннан да шулаймы?**

— Бүгенге олигархлар белән чагыштырганда, Сиражетдинга аларга каләр бик ерак әле. Әлбәттә, аның акчаларын без бүгенге курска әйләндереп карадык. Бүгенге көн белән санасаң, якынча 52 миллион була. Сиражетдинны Мавродий белән чагыштыру да дөрес булмас. Ул бит гади халыкны алдамаган, Мәскәү банкын алдаган. Бервакыт шундый бәхәс килеп чыккан иде, Г.Камалның «Банкрот»ы сатирик әсәр дип, мин шундук кырт кистем. Юк, ул сатирик әсәр түгел, чип-чиста комедия. Сатирик булса, без анда кемнедер тәнкыйтьләргә тиешбез, кемнәндер көләргә тиешбез. Бәлки язылу чорында, 1911 елларда ул сатирик булып яңгырагандыр, ләкин бүген Сиражины мин тискәре персонаж итеп кенә кабул итә алмыйм. Ул — татар, хәйләкәр татар. Монда, минемчә, татарның менталитеты күренә, бармы бу сыйфатлар татарда — бар. Сиражетдинда артистлык сәләте бар, ул талантлы кеше, кирәк бит, шундый юк-бар нәрсә белән генә 52 миллион отып алырга. Ул — татарның югарыга омтылуы, спектакльнең финалы да шуның белән бетә — Сиражи самолётка утырып очып китә. Акча темасы Сиражетдинны ачу өчен бер ысул гына. Игътибар белән караган булсагыз, ул бит башта дөньяда барган прогресс белән кызыксына. XX гасыр башында бөтен өлкәләр зур үсеш ала, гап-гади татар малае да ничектер бу прогресска кушылырга тиеш бит. Ул — вак сәүдәгәр, аның зур сәүдәгәр буласы килә. Бу шулай ук татарның менталитеты, гасыр башында киң таралган күренеш. Татарның Апанаевлары, Акчуриннары, Рәмиевләре... Алар да бит юктан килеп чыкмаган. Сиражетдин гап-гади алдакчы гына түгел, минемчә, ул — хыялый. Хыялын тормышка ашыра торган бәндә.

**— Ә «Казан ягы» каһарманнарын яшь һәм урта буын артистлары уйнавы, «Мәскәү ягы» каһарманнарын өлкән буын — И.Баһман, Н.Дунай, Х.Җәлил һ.б. башкаруы очраклы роль бүленеше генә түгелдер бит? Монда нинди киная бар? Әллә соң алар — мәскәүлеләр — стажлы «Банкрот»лар, казанлылар әле өйрәнчек «Банкрот»лармы? Табибның ришвәт алуы бүгенге түләүсез медицинага шәп тибеп ала — тамашачы көлде дә соң! Рәхәтләнеп... нәфрәтләнеп...**

— Бу очракта да Сиражиның зирәклеген, талантын күрсәтер өчен, чөнки мәскәүлеләр инде тәҗрибәле кешеләр, шуңа күрә әлеге рольләр олы яшьтәге артистларга бирелде. Аларны алдарга, ай-һай, нинди талант кирәк. «Банкрот» спектаклендә мин ачарга теләгән фикерләрнең берсе шул: безнең милләт талантлы милләт булган, хәтта хәйләдә дә. Монда пассионария турында сүз бара. XX гасыр башында пассионарлык бөтен өлкәдә булган. Үз милләтенне, үз-үзенне тоя, аңлый башлау. «Талантлы милләттән икән бит мин, мин тик утырырга тиеш түгел, ни дә булса эшләргә тиеш», — дигән уйлар Сиражетдинны да шушы хәйләгә этәргән, күрәсең. Бу да милли тема, ничек кенә әле!..

**— Сиражиның хезмәтчесе Гарәфи хуҗасын поезд бәдрәфендә ничек талаганнарын «сөйләп биргән» күренеш — авторның зур уңышы. Сез Гарәфине «телсез» иткәнсез... Әлбәттә, Искәндәр Хәйруллин аны автор вариантында да шәп уйнар иде... Үзгәртү нигә кирәк булды? Аллагы күренештә булачак «суд»тан ачы көлү өченме? Судта, ягъни тикшерү эшендә төп шаһит «телсез». Шул телсез шаһитның «сүзенә» карап хөкем чыгара мәхкәмә... Бу күренеш — бүгенге икътисад өлкәсендә җинаятьчеләрне «фаш итүдән», коррупция белән көрәшүдән ачы көлә торган иң көчле урын! Яңа «Банкрот» — режиссёрның да, тулаем коллективның да зур уңышы. Г.Камал үзе дә: «Афәрин!» — дияр иде!**

— Г.Камал үзе «афәрин», дияр идеме, белмим, ә менә оныгы спектакльдә булды, ул «афәрин», диде. Бу безнең өчен зур бәя. Ә ни өчен Гарәфине телсез ясадык? Шул ук алда әйтелгән сәбәпләр аркасында. Әгәр дә ул гади сүз белән генә Сиражетдинның талануы турында сөйләп бирсә, бәлки ышанмаслар иде, ә менә болай аңлатканда, доверенныйлар бөтенләй югалып кала. Сүз белән аңлатса, алар бәлки каршы да чыгарлар иде, ә бу очракта һич кенә дә каршы чыгып булмый.



*Репетиция вакытында. Уңда — Эмиль Талипов.*

**— Фәрит әфәнде! Театр сәнгатенә милли кадрларыбызны үзебездә әзерләү өчен бар мөмкинлекләр дә бар, әлбәттә. Социализм чорында милли театрлар өчен артистларны Мәскәү, Ленинградта укыту оештырыла иде. Артистлар гына түгел, язучылар, шагыйрьләр, драматургларны да... Хәзер ул уку йортларында аерым яшьләр мөстәкыйль рәвештә белем ала, ә республикадан тулы бер студия группасы булып укулар оештырылмый! Бүген шундый ысулда эшләүнең ихтыяҗы бармы? Ул уку йортларында, гомумән, милли кадрларны әзерләү дигән курслар, программалар бармы? Үзебездә кадрларны, аерым алганда, режиссёрлар әзерләү буенча яңалыкларга тукталсагыз иде?**

— Безнең өчен кадрлар әзерләү инде яңалык түгел, без күптән аларны әзерли башладык. 90 нчы еллар башыннан алып Мәдәният һәм сәнгать университетында югары театраль белем бирү өлкәсендә эшли торган кафедра ачканнар иде. Аны Марсель Хәкимович, Рәис Кыямович Беляевлар оештырды. Мине дә чакырдылар — педагог буларак. Шул 90 нчы еллардан башлап югары белем алып чыккан кадрлар Г.Кариев театрында да, К.Тинчурин, Әтнә һ.б. татар театрларында хезмәт итәләр. Режиссёрларны тәрбияләү, әлбәттә, авыррак. Ә менә Мәскәүгә, Санкт-Петербургка укырга җибәрүләргә килгәндә, укытып та карадык, кайтмыйлар бит кире. Бу проблема бар. Икенче проблема — әлеге уку йортларында укыту бик кыйммәт тора. Элек социализм чорында аерым программа, идеология бар иде. Хәзер ул бетте. Шул ук милли мәсьәләгә кайтсак, аннан яшьләр кем булып кайтыр? Безнең үзебез өчен дә кадрлар әзерләү хәзер яңалык түгел. Без әкрен генә булса да әзерлибез. Монда бит әле укыту белән генә чикләнеп булмый. Без яшьләребезне Мәскәүгә, Петербургка һәрдаим җибәреп торабыз, алар анда барып, спектакльләр карап, театрларны өйрәнеп кайта, үзебезгә чакырып торабыз. Безнең яшь режиссёрлар өчен «Науруз», «Һөнәр» фестивальләребез бар. Яшьләр катнаша. Актёрлар йортында режиссёрлар өчен лаборатория эшли. Бу лабораториядә катнашучы яшьләребезнең берсе хәзерге вакытта ВГИКта укый — Регина Саттарова, Юлия Захарова ТЮЗда спектакль куя, Нәфисә Исмәгыйлева — Әлмәт театрында, Айдар Җаббаров ГИТИСта укый. Аңа ышанычыбыз зур, ул Камал театрына режиссёр булып кайтырга тиеш. Режиссёр — сирәк профессия, аны төркем-төркем итеп чыгарып булмый. Бу һөнәргә индивидуаль укытсаң гына, нәтиҗә булачак.

Артистларны тәрбияләү өчен безнең театр училищебыз да бар. Училищены тәмамлаган кадрлар бөтен татар театрларында сәхнә тота. Камал театрының ярты труппасы Казан театр училищесын тәмамлаган: Алсу Гайнуллина, Илдар Хәйруллин, Наилә Гәрәева, Ирек Баһманов, Раушания Юкачева, Венера Шакирова, Люция Хәмитова, Әсхәт Хисмәтов, Фәридә Сафина — барысы да үзебезнең кадрлар. Искәндәр Хәйруллин, Радик Бариев, Фәнис Җиһаншин, Минвәли, Рамил,


*Хатыны Люция Хамитова һәм улы Йосыф белән.*

Миләүшә, Илтөзәр — барысы да үзебездә укыды (Казан мәдәният һәм сәнгать университеты). Хәзер инде алар — йолдызлар. Минемчә, бүген каядыр җибәреп торуның кирәге дә юк. Монда кайнасыннар. Әле Марсель абый әйтә иде, театрда кайнарга тиешләр, театрда үсәргә тиеш артист, театрда массовкаларда катнашып, монтировщик, мебельщик булып эшләп, театрны эчтән өйрәнергә тиеш. Татар театрын, бигрәк тә театрның традицияләрен ул биредә кабул итәргә, үзенә сеңдерергә тиеш. Шул очракта гына милли татар артисты тәрбияләнәчәк.

**— Безнең халкыбыз — чын-чынлап театр сөюче халык. Бу инде аның геннарыннан ук киләдер... Ерак бабаларыбыз милли бәйрәмнәребезне, төрле уен, алыш, бәйгеләрне тамаша итеп үткәргән бит... Яр Чаллы, Түбән Кама, Яшел Үзән, Алабуга, Нурлат, Азнакай кебек зур шәһәрләребездә заманча балалар һәм яшьләр театрлары кайчан булыр икән?**

— Һәрбер төбәкнең үзеннән тора дип уйлыйм. Монда балалар театры турында сүз алып барырга кирәкмидер. Алар мәктәпләрдә оештырылырга тиеш. Минемчә, иң элек булган театрлар турында уйларга кирәктер. Г.Кариев исемендәге театр бинасыз калды, Чаллыда курчак театры бинасыз, Яр Чаллы татар театрының бинасы начар. Театр өчен төзелгән бина түгел ул. Хәзерге вакытта балалар өчен яңадан театрлар оештырудан мәгънә юк, минемчә. Минзәләдә, Чаллыда, Түбән Камада театрлар бар. Алар бит балалар һәм яшьләр өчен дә спектакльләр куялар. Курчак театрларын арттырсаң, начар булмас иде.

**— Инде шәхсән гаиләгезгә кагылышлы сорау бирим... Сәнгатькәрләр арасында тулы өч буын вәкилләре үзләрен милли сәнгатькә багышлавын беләбез. Камаллар династиясе, Сәлимҗановлар династиясе, Хәйруллиннар династиясе... Бу исемлекне тагы да зурайтып буладыр! Бикчәнтәевләр династиясе. Артист һәм режиссёр Рәфкать Бикчәнтәевне, артист Наилә Гәрәеваны артист һәм режиссёр Фәрит Бикчәнтәев дәвам итә. Артист һәм режиссёр Фәрит Бикчәнтәев белән артист Люция Хәмитованың уллары Йосыф сәхнәдә, киноэкраннарда беренче адымнарын ясады. Йосыфның киләчәктә планнары нинди?**

— Йосыф хәзерге вакытта Казан (Идел буе) федераль университетының Халыкара мөнәсәбәтләр, тарих һәм Көнчыгышны өйрәнү институтында өченче курс студенты. Кинода төште, спектакльләрдә уйнады — «Әлдермештән Әлмәндәр», «Әни килде», «Зәңгәр шәл» — театрда үсте ул. Телләр өйрәнә. Кытайга китәргә җыена, ярты елга. Хәзер бит яшьләргә мөмкинлекләр күп, юллар ачык. Театр юлыннан китсә — китсен. Театрны ул яхшы белә, иҗат белән яши. Музыка, биюләр белән мавыга. Һөнәрләрнең кайсын сайласа да, без каршы килмәячәкбез.

**— Җавапларыгыз өчен рәхмәт. Сезне һәм республикадагы барлык театр сәнгате әһелләрен Халыкара театр көне белән тәбрик итәбез. Барчагызга саулык, иминлек, иҗат уңышлары, бәхет теләп калабыз!**

*Әңгәмәдәш —*
**Илфак ИБРАҺИМОВ**

# ТАҢ ЙОЛДЫЗЫ ЭЗЕННӘН...

## Сәхнә



Тан йолдызы кабыну белән яна тормыш башланадыр төсле. Көннән-көнгә, айдан-айга, елдан-елга кабатлана табигатьнең бу халәте: төнне озатып, көнне каршы алу. Күпме жырга, күпме шигырьгә керткән аны халык. Чулпан йолдызы — сафлык, яшьлек һәм өмет символы. Кешеләр арасында да шундый йолдызлар, шундый символлар була. Бу язма да шуларның берсе — Алсу Гайнуллина турында. Театр сәхнәсендә 40 ел эчендә нинди эзләр уеп калдырган ул? Сәхнәдәге Алсу белән тормыштагы Алсу бер-берсеннән ни белән аерыла? Сораулар күп...

Кызык бит: бер кеше — бер актриса, ә рольләр — дистәләп һәм һәрберсендә аерым бер язмыш, аерым бер характер. К.Тинчуринның «Казан сөлгесе»ндә — Мөршидә, Т.Миннуллинның «Сөяркә»сендә — Әнисә, А.Островскийның «Бирнәсез кыз»ында — Лариса, К.Тинчуринның «Сүнгән йолдыз»ларында — Сәрвәр, Г.Ибраһимовның «Татар хатыны ниләр күрми» спектаклендә — Гөлбану, А.Гыйләҗевнең «Өч аршын җир»ендә — Шәмсегаян, Х.Вахитның «Талак, талак» әсәрендә — Гөләндәм... Гадәттә, әсәрләрнең тәэсир көче шундый була ки, атна-ун көн, ә кайчак айлар буе аның атмосферасында йөрисең. Бу яктан актрисаларга сак булырга туры киләдер.

— Алсу ханым, герой актрисага үтеп кергәч, аның характеры сезгә йогамы?

— Ансыз булмыйдыр инде, берникадәр күләмдә йога, — ди Алсу апа. — Ләкин үзеңне геройдан аерып карый белү кирәк, аны сәхнәдә калдырып төшәсең. Юкса, һәрберсен күңелең аша уздыра башласаң, акылдан язарга мөмкин. Дөрес, бу әле эштән тыш (сәхнә турында әйтүем) вакытта роль турында уйламыйсың дигән сүз түгел. Уйлыйсың, кайсыдыр моментларын эшкәртәсең, үзгәртәсең, ләкин аның тормышын син бары тик сәхнәдә генә яшәргә тиеш.

## Спектакль — нәтиҗә генә

Алсу Гайнуллинаның һәр роле үз характеры, үз нечкәлекләре белән уйнала. Алсу Гайнуллина диюгә, күңелемә иң элек Туфан Миннуллинның «Әниләр һәм бәбиләр» пьесасындагы Валентина образы килә. Аның яна туган улы турында сөйләгәндә, күзләренә яшь тулуы, ире Сашенька765ны ничек яратуы турында сөйләве... Самимилекнең, бәхетнең үзе кебек тоела иде миңа Валентина һәрчак. Бу роль Алсу апага искиткеч килешә, иң яраткан рольләр дип уйлый идем. Ялгышканмын: бик үк яратып бетергән рольләреннән түгел икән:

— Кайбер кешегә сәхнә эше җиңелдер кебек тоела. Чыктың — уйнадың, авыр күтәрергә кирәкми бит! Алай гына булса икән. Чынлыкта, спектакль — нәтиҗә, айларга сузылган бик зур эшнең бары нәтиҗәсе ул! Әзерлек вакытында героиняны яратырга, аңларга өйрәнергә тиеш син! Ул сиңа башта чит тоелса да, ошамаса да. Һәр роль үзенчә якын инде. Ләкин «Әниләр һәм бәбиләр» спектакле миңа кайсы ягы белән ошап бетми иде: барлык вакыйга хастаханәдә, ятакта бара. Сәхнәгә халат белән чык та ятакка менеп ят — нәрсә инде ул? Ә мин исә матур киенергә яратам, хатын-кыз өйдә дә, эштә дә матур йөрергә тиеш. Вакыт үзу, яшь бару



*«Арбалы хатыннар» (З.Зәйнуллин) спектаклендә – Сөяксез Гайшә (сулда). Чатан Рәйхан – М.Шәйхетдинова.*

белән, билгеле, үзенне карау теләге кими, авырлаша бара, аңа да карамастан, тырышырга кирәк, — дип елмая ул. Килешми мөмкин түгел, ә бу матурлык, сәхнә дөньясы, анда тудырган образлар шәхси тормышка комачауламыймы икән, дигән сорау туа.

Сүзебез каршылыклар, образлар мәсьәләсенә кереп киткән икән, Гаяз Исхакый әсәре буенча куелган «Курчак туе» спектаклендәге Наташага тукталмый ярамас.

Беренче карашка, Наташа — әсәр тукымасында антагонист персонаж, ике чик арасында калган Камәрне ялгыш юлдан җибәрүче. Ләкин спектакльне карагач, нигә башкарак хис-тойгылар туа? Героинянын характерында якты төсмерләр дә чагылып ала кебек. Шөгыленә карамастан, бу ханым образында кешелеклелек һәм кызгана белүчәнлек сыйфатлары туплана. Абсолют караңгылык булмаган кебек, абсолют тискәре шәхес тә булмый, дигән фикер уяна.

Наташа образын барлык нечкәлекләре белән барлый башласаң, автор (соңрак әсәрне сәхнәләштергән режиссёр да) әлеге героиняны яхшылык белән начарлык дөньялары чигендә калдыра: беренчедән, ул үзе — Камәр хәленә төшеп, ситуация корбаны булган хатын, бу исә үз чиратында аның төп героиняга карата булган кузаллауларын формалаштырган фактор: кыз аңа тере тауар гына түгел, ә иң элек үз яшьлеге һәм үз трагедиясенен гәүдәләнеше булып тоела. Икенчедән, Наташа Камәрнен эчке дөньясын күреп ала, анын батырлыгы, горурлыгы һәм яшьлегенә хас кайнарлыгы ханымда соклану уята. Әгәр Камәр белән Наташа вакыйгасын Наташа карашыннан бәяләсәк, аны ярдәм итәргә омтылыш буларак кабул итү дөресрәк. Билгеле, мөмкин булса, Наташа коткаруның башка юлларын сайлар иде, ләкин кулда бары шушы карталар гына һәм уен инде күптән башланган...

Нигә нәкъ менә коткару, диярсез? Чынлыкта, сүз фәхешлек турында бара. Шуны онытмыйк: Камәрдән якыннары, сөйгәннәре баш тартты, кыз үлем белән яшәү чигендә. Горурлыгы да бар: үз-үзен Сәлим бай кебекләр кулына марионетка итеп тапшыра алмый. Әсәрнен буеннан-буена сузылган «Мин курчак түгел!» фразасы Камәрнен эчке дөньясы белән реаль чынбарлык арасындагы каршылыкнын ассызыкланышы булып тора. Ерткычлык, вәхшилек белән тулган кешелек дөньясы исә яши бирә: карт байны — яшь җинаятьче, иске ялганны яна хаксызлык алыштыра: Вафанын тәхеткә килүе дә очраклы түгел, ә нәкъ шул циклнын бер этабы. Әлеге яссылыктан караганда, Камәр дә — Наташанын үткәне, диярга тели автор. Режиссёр исә моны тотып ала һәм тамашачыны да моны аңлый алу дәрәҗәсенә чыгарырга тели. Ләкин үзе сәхнәгә чыгып сөйли алмый бит инде? Роль бирелеше аша ситуацияне аңлату кирәк.

Әгәр Наташага караганда, тамашачы бер җылылык тоя икән, димәк, нәтиҗә бар, димәк, характер бирелгән...

## Пәрдәләр төшкәндә

Алсу Гайнуллина, Илдар Хәйруллин... 40 ел бергә. Ике көчле актёр. Ике шәхес. Бер сәхнә һәм бер уртак язмыш.

— Актёр, актриса белән гаилә корып, нигезле, төпле тормыш алып бару авыррак. Монда эш бер-беренне аңлап бетермәүдәдер. Сәхнә шулай бит инде ул: гастрольләре дә була, төнгә калэр дә каласын. Арага көнләшү, сүз үтеп керергә мөмкин. Ыгы-зыгы башлана, гауга куба. Бу язмыштан качарга теләп, театрдан китүчеләр дә

була. Мин шунысын аңладым: театр тормышы — сәбәп кенә, әгәр мәхәббәт, ышаныч юк икән, ул мөнәсәбәтләр көннән-көн какшый гына бара һәм бервакыт җимерелә дә. Театрдан тыш та саклап калып булмаска мөмкин чын булмаган мөнәсәбәтләрне... Андыйларны күп очратырга туры килде.

Безнең театр труппасы башка труппалардан шул ягы белән аерыла: бездә татарлык бар, сәхнәдә уйнауга карамастан, гаилә учагын кайгыртуны онытмыйбыз. Еш кына шулай чит труппа актрисалары белән сөйләшеп утырган бар. Алар өчен иҗат — беренчел. Безнең өчен исә иҗат та, гаилә дә мөһим. Арып кайтасың, кәефең дә булмаска мөмкин, ләкин йортың бусагасын атлаганда, боларның барысын да читтә калдырасың. Өйдә син — ана, хатын-кыз, гүзәл зат. Өйдә син — гаилә учагын тотучы! Бу ир-ат актёрларга да кагыла. Гаилә кадерен белү, гаиләне саклау, гаиләгә җил, ут тидермәү, сүз кертмәү... Менә миллилек каян башлана! Безнекеләрдә ышаныч, бер-береңә сыена белү, аңлаша белү бар!



*«Әлдермештән Әлмәндәр» (Т.Миңнуллин) спектаклендә – Йөзембикә. Әлмәндәр – Ш.Биктимеров.*

Илдар һәр яктан искиткеч кеше, сокланып туя алмыйм, театрдагы рольләрен аласынмы, кешеләргә булган мөнәсәбәтенме, гаиләбезгә килгәндә дә, ул гел терәк, таяныч булды. Без бит икебез дә сәхнә тормышын беләбез, шуңа бер-беребезгә карата да түзем булырга тырыштык. Ә арадагы мәхәббәт авырлыкларны үтәргә, кайбер ялгышларны кичерергә ярдәм итте. Ни генә дисәләр дә, ике кеше арасында ярату булмаса, ихлас мөнәсәбәтләр дә булмый.

Мин училищега килгәндә, Илдар инде танылган актёр иде. Безнең тирәдә еш күренгәләп йөри, укыта, мәхәббәт турында уйлап та караган булмады. Аннары ничектер үзеннән-үзе бәйләнеп тә китте.

## Әниләр хакында

— Мин үзем ишле гаиләдән, төпчек, тугызынчы бала идем. Әти-әнинең безгә булган җылы мөнәсәбәтен, гаделлеген, абый-апаларның үзара мөнәсәбәтләрен, безгә — нәниләргә булган назын тоеп үстем. Әткәй — баш кеше иде. Әле дә исемдә: әти урында ята, инде тәмам хәлсез. Әни исә аны әле дә ярата, әле дә ихтирам итә: бер-бер сорау туса, гел аның белән генә хәл итә, ашны да иң элек ана салып бирә! Мәхәббәт бит ул сүздә түгел, эштә күренергә тиеш. Шуны күреп үскәнгәдер, гаиләмне кадерләп яшим, Аллаһка шөкер!

— Яшьлеккә кайтыр идегезме?

— Юк... Миңа хәзерге халәтем, хәзерге тормышым бик тә ошый. Ирешкән уңышларым, гаиләм, кадерле ирем, оныгым бар! Рольләрем бар, зуррakларын теләмим: шулай үз рәхәтең, күңел өчен генә сәхнәгә чыгу — бәхет! Ә яшьлектә, Аллаһка шөкер, барлык теләгән рольләрне дә уйнадым, ул яктан күңелем тыныч. Дөрес, алар җиңел бирелмәде, никадәр көч, никадәр тырышлык таләп иткәнен үзем генә беләм. Кайсыларыдыр уңды, кайсыларыдыр юк. Мәсәлән, В.Шекспирның «Антоний һәм Клеопатра» пьесасындагы Клеопатра роле. Без анда режиссёр белән бер-беребезне аңлап бетерә алмадык, ахрысы. Килеп чыкмады. Иң отышсыз ролем шулдыр. Ә иң яраткан образга килгәндә, ул — Т.Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр» әсәрендәге Йөзембикә. Сәхнәгә серле бер төш, әрфия кебек кенә килеп чыга... Матур, якты... Зуррак рольләр нык тырышлык сорый. Уңышка да ирештем, премияләр, исемнәр юктан гына бирелми. Әмма алар — үз вакыты белән... Хәзер иң рәхәт чагым...

— Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе иясе, Россиянең Дәүләт бүләге лауреаты, Татарстанның һәм Россиянең халык артисты... Эш нәтиҗәсе күрсәткече бит бу!

— Әйе. Шулар арасыннан иң кадерлесе — Тукай премиясеңер, чөнки минем өчен ул — милләткә биргән көчемне бәяләү, олылау. Яшь узу белән, мондый әйберләргә житдирәк карый башлыйсың икән. Иман мәсьәләсендәге кебек...

— Алсу ханым, сез хаҗга да барып кайттыгыз дип беләм...



*«Әниләр һәм бәбиләр» (Т.Миңнуллин) спектаклендә – Валентина (сулда). Гөлфинә — Д.Нурлы. Алтынчәч — Н.Ибраһимова.*

— Әйе, Әлхәмдүлилләһ! Ул бәхеткә дә ирешергә насыйп булды. Безнең гаиләдә дингә һәрчак зур урын бирелде. Әни узган гасыр башында, 1909 елда туган. Үзегез беләсез — нинди вакыт. Шуна да карамастан, качып булса да, намазларын укыды, безгә сүрәләр өйрәтте. Чын мәгънәсендә дингә урта яшьләрдә генә килдем. Хәзер уйлап куям: әй, әни, дим, безгә нигә ул вакытта ныклап, каты тотып өйрәтмәдең, бәлки кайбер яшьлек ялгышларын эшләмәгән дә булыр идем. Нишлисең бит, һәр әйбернең үз вакыты. Ярый әле иманга килергә, тәүбә кылырга мөмкинлекләр бар. Кайбер кешеләргә анысы да насыйп булмый бит.

Хаҗга килгәндә, анда барып кайткач, дөньяң үзгәрә. Кеше күнеле сынала! Тормышка, үзеннең кылган гамәлләренә башкача карый башлыйсың. Нигә әле мин изге жирдә үземне болай тотам, гади тормышта да шулай ук гамәл кылу фарыз бит диген уйлар килә. Шуны ассызыклар идем: кеше дингә никадәр иртәрәк килсә, шулкадәр яхшырак, тормышы шулкадәр тизрәк жайлана, күнеле тынычлана, хаталар азрак ясала.

— Ә театр дөньясына кереп китмәгән булсагыз?

— Сигезенчедән соң дизайн училищесына керәсе идем. Ләкин рәсем ясый белмәгәнгә, насыйп булмады. Унынчыны тәмамлаганда, юллар үзеннән-үзе Казан театр училищесына илтте. Ана кадәр чын-чынлап театр дип жєнләнгәнем булмады. Хәтта диктор булырга хыяллана идем, без яшь чакта аннан да яхшырак, аннан да шәбрәге юк кебек иде. Ләкин училищеда Марсель абый Сәлимжанов группасына эләктем. Марсель абыйга бик рәхмәтлемен. Анда укыган чорда, барысы да үзгәрде — карашларым, дөньям. Уку йортын тәмамлаганда, үземне бары тик актриса итеп кенә күрә идем. Аннары Марсель абый белән эшләве дә искиткеч рәхәт булды. Ул шундый режиссёр: актёрны әсәргә кертә, күрсәтә, анлата. Ни кирәген белә. Ул киткәч, бик авыр булды. Ләкин шунысы сөендерә: төзеп калдырган империясе жимерелмәде; үзеннән соң көчле варислар калдырды Марсель абый. Укучысы Фәрит Бикчәнтәев хәзер анын эшен дәвам итә. Алай гына да түгел, театрны тагын да үстерергә, баетырга, кинәйтергә тырыша. Шәхес укучылары, дәвамы белән сынала! Мондый дәвамчылар булу үзе бәхет! Менә шул бәхеткә сөенеп яшибез дә!

...Килешми мөмкин түгел. Алсу Гайнуллинаны тагын бер кат юбилее, театрда эшләвенә һәм гаилә төзүләренә 40 ел тулу белән тәбрик итәбез! Күнел тынычлыгы, иман байлыгы, бәхет һәм үзегез теләгән янадан-яна рольләр насыйп булсын Сезгә! Хатын-кызны нилләр белән генә чагыштырмыйлар, әмма безнең күнелдә Сез гел тан йолдызы! Сабыр, якты, якын, нурлы...

**Эльвира ҺАДИЕВА**

# «ҖЫРЛА, ЕГЕТ, КИЕРЕП КИҢ КҮКРӘГЕҢ...»

## Рафаэль Ильясовка 75 яшь

*Үз җыры, үз моңы белән халык күңелен яулап алган күренекле җырчыбыз, Татарстан радиосының музыкаль тапшырулар редакциясендә озак еллар мөдир булып эшләгән Татарстанның халык артисты, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Рафаэль Ильясовның җырлавын татар милләтенең бик күп күренекле шәхесләре яраткан һәм ярата. Р.Ильясовның юбилей кичәләренең берсендә: «Рафаэль җырлаганда, йөрәк татарча тибә башлый», — дип әйткән иде СССРның халык артисты Марсель Сәлимҗанов, аның редакторлык хезмәтенә дә зур бәя биреп. Бакый ага Урманче Р.Ильясовның сурәтен эшли башлаганда, үзен күрмичә, радиода җырлавын тыңлау белән образы туа башлаган, ул бигрәк тә аның башкаруында башкорт халык җыры «Сандугач»ны ләззәтләнеп тыңлаган... Шагыйрьләр шагыйре Х.Туфан да аны хөрмәт иткән, иҗат кичәләренә чакырган. Үзенең сүзләренә М.Макаров язган «Юксындырсаң, нишләрмен?» җырын тыңлаганда: «Күңелләрне тетрәндерә, күзләргә яшь бөркелә», — дигән бөек шагыйребез Сибгат Хәким, Рөстәм Яхин, Сара Садыйкова, Фәридә Кудашева, Гомәр Бәшировларның фикерләре дә әлегеләргә аваздаш.*

*Рафаэль Ильясов белән әңгәмәбез татар җыр сәнгате, халкыбыз яраткан күренекле җырчының тормыш юлы, иҗат эшчәнлеге хакында.*



**— Рафаэль әфәнде, музыка-җыр сөючеләр Сезне моңлы җырчы буларак белә. Ә бит Сезнең төп хезмәтегез Татарстан радиосының музыкаль тапшырулар редакциясендә башланган, 1964 елдан бүгенгә кадәр 50 ел гомерегез шунда үтте, дисәм дөрес булыр. Никадәр тапшыру әзерләнгән, татар музыка хәзинәсен халыкка ишеттерү өчен, күпме эш башкарылган. Музыкаль тапшыруларның цикл, рубрика исемнәрен генә санау өчен дә күп вакыт кирәк булыр иде. Башкортстанның күренекле шагыйре һәм әдәбият белгече Гыйлемдар Рамазанов 1992 елны «Кызыл таң» газетасында басылып чыккан «Туганлык тудырган моңнар» исемле мәкаләсендә болай дип язган иде: «Музыкаль редакция хезмәте һич кенә дә җиңелләрдән түгел. Биредә эшләүчеләр журналист та, тәҗрибәле музыка белгечләре дә, үзләре үк җыр-моң осталары да...»**

— Әлбәттә, радиомузыкаль тапшырулар мөхәррирлеге эшенең оештыру мәсьәләләре бик зур көч, вакыт, белем, түземлелек таләп

итә. Сәнгать советлары үткәрү, татар музыкасының матур профессиональ үрнәкләрен радиога китереп яздырып, текстларын эшләтеп, худсоветка куеп, фондка тапшыру — барысы да мөхәррир эше. Радиодан яңгыраган әсәр, беренчедән, татар халкын менә шушы музыкаль казанышлар белән таныштыру булса, икенчедән, үзешчән сәнгатьтә катнашучылар өчен репертуар мәсьәләсендә турыдан-туры ярдәм итүнең иң гүзәл үрнәге.

**— Сез музыкаль тапшырулар редакциясенә килгәнче, бу эш белән таныш идегезме? Кайчан, ничегрәк бу вазифага алынырга булдыгыз?**

— Илленче еллар ахырында музыкаль тапшырулар редакциясе хезмәткәрләре Зәйнәп Хәйруллина, Мәһинур Җиһаншина, Исмай Шәмсетдинов, Екатерина Соколовалар белән таныш идем. Чөнки анда, гобой өчен композиторлар әсәрләрен, халык көйләрен өйрәнеп, чыгышлар ясаганымны хәтерлим.

Консерваторияне тәмамлап, Пермь опера һәм балет театры оркестрында гобойчы буларак эшләп алгач, Казанга кайттым. Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбленең сәнгать җитәкчесе Җәүдәт Айдаров мине ансамбльгә эшкә алды. Кыска гына вакыт эчендә коллектив белән бөтен союзны әйләнеп чыгарга, гобойда уйнарга, хорга кушылып җырларга да насыйп булды. 1964 елның ноябрендә Мәһинур апа Җиһаншина тәкъдиме белән радиода эшли башладым. Ул вакытта редакция эшенә юнәлеш, радиодагы музыкаль сәясәтне дөрес билгеләүдә сәнгать советы әгъзаларының роле бик зур булды. Чөнки анда бик мөхтәрәм кешеләр: күренекле композиторлар, музыка белгечләре, шагыйрьләр, җырчылар, музыкантлар керә иде. Һәрбер музыкаль әсәрнең язмышы шушы сәнгать советында хәл ителә, тормышка юллама бирелә иде. 1964 елдан 1990 елга кадәрге вакыт — сәнгать советының иң актив эшләгән еллары. Шул вакыт эчендә төрле жанрларда иҗат ителгән бик күп яңа әсәрләр, магнитофон тасмасына язылып, радио фондына алынды, тапшыруларда яңгырады. Әлеге язмалар нигезендә төрле музыкаль программалар әзерләнде. Бөтенсоюз радиосы өчен, шул исәптән «Маяк» радиостанциясе, Башкортстан радиосы, союздаш республикалар радиосы өчен тапшырулар даими рәвештә әзерләнде.

Радио гомер-гомергә иҗат лабораториясе ролен үтәп килде: җырчыларны, шагыйрьләрне, композиторларны, гомумән, бар булган талант ияләрен үз тирәсенә җыйды, туплады. Бу 1990 елларга кадәр, СССР таркалганчы, Бөтенсоюз радиосы юкка чыкканчы, шулай булды. Редакция тыңлаучыларның, мөхәррирләрнең музыка дөньясына булган карашларын киңәйтергә, белем-мәгълүматларын арттырырга да ярдәм итте.

Радиода «Музыкаль Татарстан», әдәбият һәм сәнгать университеты тапшыруы, табышмак-концертлар, концерт-викториналар, симфоник музыка сөючеләргә әңгәмә-концертлар, яңа язмалар һәм башка мөһим тапшырулар бар иде. Бүген дә эфирга чыгып килә торган «Осталык һәм остазлык» программасы — халыкның аеруча яратып тыңлаган тапшыруларының берсе. Тавыш яздыру студиясендә язылаcы әсәрләрнең югары сыйфатлыларын сайлап ала белү — редакция хезмәткәрләренең бурычы. Ә бу исә халкыбыз хәзинәсенең сыйфаты өчен башкарылган мөһим эш булып кала.

Музыкаль тапшырулар редакциясенә олы эшләр йөкләнде һәм аның тиешенчә башкарылуы да таләп ителә иде.

**— Әлеге тапшыруларны әзерләү өчен, музыка белгечләре дә чакырылгандыр?**

— Әлбәттә, алардан башка мөмкин түгел иде. Республиканың танылган музыка белгечләре Зәйнәп Хәйруллина, Мәхмүт Нигъмәтҗанов, Галина Касаткина, Йолдыз Исәнбәт, Яков Гиршман, Мәһинур Җиһаншина һәм башкалар бик зур ярдәм итте.

Соңрак без музыка белгечләре Сирина Латыйпова, Клара Тажиева, Гөлшат Нигъмәтуллина, Нәргис Мөштәри белән эшләдек.

Тормыш катлаулануга карамастан, музыкаль редакция бүген дә җыр-моң сәнгатебез сафлыгын, аның профессиональ югарылыгын төшермәү өлкәсендә максатчан эш алып бара.

**— Рафаэль әфәнде, шулкадәр катлаулы һәм җаваплы эш белән бергә үзегезнең иҗатны да аралаштырып бару җиңел булмагандыр...**

— Күп каршылыклар кичеп җырларга

туры килде. Жырлавымны радио хужалары да бик хуплап бетермиләр иде. Мине музыка училищесының жыр бүлегенә алмадылар, ул вакытта миңа 14 кенә яшь иде. Шулай гобойчы булып башта училище, аннан консерватория тәмамладым. Консерватория профессоры Зөһрә Байрашева, Нәҗип Жиһановка алып кереп, жырлатып карадылар. Ул: «Син консерваторияне гобойчы булып тәмамла, ә филармониядә консерватория тәмамламыйча да жырлый аласың, — дип, дөрес кинәшен бирде. «Син жырчы да булырсың әле», — дигәне бүгенгедәй хәтеремдә. Чынлап та шулай булды бугай, әкрен-әкрен генә жыр дөньясына кереп киттем. Бөтенсоюз, бөтенроссия аттестация комиссияләрендә үтеп чыгып, югары дәрәжәләргә ирешеп, рәсми рәвештә хокук алганмын. Казанның иң күренекле жырчылары, Мәскәүдән килгән вәкилләр утыра иде ул комиссияләрдә. Мәрхүм мәдәният министры Булат Гыйззәтуллин шушы аттестация комиссияләрендә жырлаганнан соң, сәхнә мәсьәләсендә миңа киң офыклар ачты. Зөһрә Байрашева, комиссия әгъзалары гажәеп жылы сүзләр белән аттестация комиссияләренең гала-концертларында чыгыш ясарга тәкъдим итәләр иде.

Казанның иң зур сәхнәләрендә үземнең аерым концертларым белән дә, төрле төркемнәрдә катнашып та жырладым. Урта Азия, Мәскәү, Ленинградта, чит илләрдә атаклы жырчылар белән бергә чыгышлар ясарга насыйп булды. Күрәсең, халык жырларына игътибар итеп ялгышмаганмындыр. Филармония һәм опера театры житәкчеләренең бу өлкәдә мөнәсәбәтләре жырлавыма карап булгандыр, дип уйлыйм. Опера театры артистлары белән Уфа шәһәрләрендә ун көнгә егермешәр концерт куеп кайта идек. Уфа тамашачысы без килгәнче билетларны сатып алып бетерер һәм концертлар зур уңыш белән үтәр иде. Чыгышлар турында Фәридә Кудашева, Бәхти Гайсин, Гыйлемдар Рамазанов, Шәриф Бикколлар зур ихтирам һәм хөрмәт белән мәкаләләр язарлар иде. Төп жырчы булып баргангамы, миңа игътибар зур иде. Опера театрының атаклы жырчылары Фәхри Насретдинов, Зөләйха Хисмәтуллина, Рәйсә Билалова, Венера Шәрипова белән Урал, Себер, Идел буе шәһәрләрендә жырларга насыйп булды. Опера театры дирек-

***Гомәр БӘШИРОВ, халык язучысы, Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты:***

*«Моң бит ул зарлану да, кайгы-хәсрәт чигү дә, иңрәү дә түгел, хәзер безнең Х.Бигичев, З.Сәхәбиева, З.Сөнгатуллина, Рафаэль Ильясов кебек беренче классы, ифрат талантлы, жырның эчтәлеген тулысынча ачып бирә алу кодрәтенә ия жырчыларыбыз бар. Без алар белән горурланабыз».*

***Гөлшат ЗӘЙНАШЕВА, шагыйрә, Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты:***

*«Рафаэль Ильясов халкыбызның иксез-чиксез биниһая сагышын жырлый... Табигый, ягымлы тенор тавышы белән ул — чын мәгънәсендә халык жырчысы, халыкчан башкару остасы».*

***Фәридә КУДАШЕВА, Россиянең атказанган, Татарстанның һәм Башкортстанның халык артисты, С.Юлаев һәм Г.Тукай исемендәге дәүләт премияләре лауреаты:***

*«Рафаэль миңа бик якын туганым шикелле. Мөрәжәгать иткән чакларымда бик игътибарлы, ярдәмчел булды ул. ...Аның кешеләр күңеленә үтеп керә торган үзенчә моңы бар. Киң сулышлы, әйбәт дикцияле, күкрәккә салып жырлый торган халык улы ул».*

***Мәхмүт НИГЪМӘТҖАНОВ, музыка белгече, фольклорчы, профессор, Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты:***

*«Рафаэльнең, татар музыкасының чын бәясен белүе белән, күп жырчылар, композиторлар иҗатын саклап калуда өлеше зур!»*

торы Михаил Боголюбов миңа яхшы мөнәсәбәттә булды, без китергән керем театр өчен бик зур ярдәм иде.

Үзебездә, ничә еллар студия белән житәкчелек итсәм дә, шунда төшеп жыр яздырганымны хәтерләмим. Әгәр дә минем радиода язмаларым бар икән, алар Мәскәүдән бөтенсоюз радиосының тавыш язу бригадасы килгәндә, тавыш язу режиссёр-редакторларының үтенече буенча эшләнгән жырлар. Әйтик, Мәскәү тавыш язу режиссёры Игорь Георгиевич Дуткевич, мин чакырып китергән жырчылар язылып беткәч: «Әйдә, Ильясов, хәзер инде үзең жырлап кара», — ди иде. Редактор буларак жырчыларны китерү, аларга расписание төзү, планнарын раслаттыру өчен дә ел ярым алдан әзерлек алып барылды. Чөнки Мәскәүдә бу мәсьәләдә бик нык төгәллек сорала иде. Алар күп акча тотып, безгә килеп, безнең музыка-жырларыбызны, опера, симфония, балет, хор әсәрләрен яздырып торды. Үзем, редактор буларак, Мәскәүгә барып, сәнгать советында катнаша идем. Мәскәүнең композиторлары, күренекле жырчылары, Зур театр солистлары, СССР Композиторлар берлеге житәкчеләре, безнең татар композиторлары әсәрләренә бәя биргәндә, ихтирам белән хуплап чыгыш ясыйлар иде. Болар бар да шатлыклы, сагындыра торган мизгелләр булып күңелемдә саклана!

**— Сезнең вокал алымыгыз табигый диярлек. Гобойда уйный белү тирән итеп тын алырга, авазларны дөрес әйтергә, сузарга ярдәм итәме?**

— Музыкаль образлар тудыра, гобойда уйнаганда, жырлаганда да үз һөнәрем буенча консерваториядә алган белемем, югары белемле музыкант-педагоглар белән аралашу, бер үк музыка таләпләре ярдәм иткәндер дип уйлыйм. Татар жырларына килгәндә, мәсәлән, «Юксындырсаң, нишләрмен?»не «ай-һайһай»га жырлап булмый. Марс Макаров әлеге текстка шулкадәр төнгәл музыка язган. Анда диапазон да, драматик кичерешләргә дә урын бар, рәхәтләнеп жырларга мөмкинлек бар. Нинди генә халык көен алсаң да, һәрберсенә аерым мөнәсәбәт кирәк.

**— Рафаэль әфәнде, башкорт халык жыры «Сандугач», татар халык жырлары «Уел», «Камәр», «Аппагым-жанашым», «Галиябану», «Олы юлның тузаны» кебек киң сулыш сорый торган көйләр Сезнең гомерлек юлдашыгызга әверелделәр...**

— «Сандугач»ның иң беренче башкаручысы Мәгафүр Хисмәтуллин бу жырны ядкарь итеп миңа тапшырды, аның ризалыгы белән мин аны репертуарыма алдым. Гомумән, халык көйләренә хөрмәтем бик зур, аларга саклык белән мөрәжәгать итәргә кирәк. Халык көйләрен хилафлык китермичә, чама хисен белеп, музыкаль вөжданың кушканча, күңелеңне биреп, сүзләрне «жылытып», профессиональ жырчылар Рәшит Ваһапов, Гөлсем Сөләйманова, Зифа Басыйрова дәрәжәсендә жырламыйча мөмкин түгел. Чөнки халык көйләре — безнең тарихи байлыгыбыз, язмышыбыз. Аларны башкарганда, профессиональлек тә кирәкми кебек, әмма музыкаль нечкәлек, төгәллек, стиль ягын саклау мөһим. Жырчы жырны тыңлаучыга тавыш аппараты аша гына түгел, акылы, күңеле, йөрәге аша житкерә. Ул таләпләргә ни дәрәжәдә жавап бирә алганмындыр — анысы тыңлаучылар хөкемендә.

**— Сезнең өчен жыр сәнгате өлкәсендә кемнәр үрнәк?**

— Италиянең дөньякүләм танылган жырчылары. Аларның башкару культурасы, тавыш белән идарә итү осталыгы, үзләрен сәхнәдә тотышлары... Менә шундый жырчыларны яратам. Татарстан артистларына килгән вакытта, мин озак еллар Зөләйха Хисмәтуллина белән жырладым. Аны һәр көнне концерт вакытында сәхнә артында тыңлап утыра идем. Шуннан соң сәхнәгә чыксам, минем жырлау аппараты жырлау өчен тулысынча әзер була иде (распевка урынына). Соңгы вакытларда Илһам Шакиров белән сәхнәләрдә жырларга туры килде. Ул һәрвакытта да бер үк жырны үзгәрешләр кертмичә, беренче мәртәбә жырлаганча башкарды. Хәйдәр Бигичев шундый казанышларга иреште, Зилә Сөнгатуллинаны бик хөрмәт итәм, югары культуралы жырчы. Гөлсем Сөләйманова, Разия Тимерханова жыр сәнгатен пропагандалауда уңышлар теләп, хуплап шалтырата иделәр... Моннарыннан үзенә һәйкәл салган легендар жырчы Фәридә Кулашева турында аерым әйтергә кирәк. Аның жырлау осталыгы хакында яңалык



*Рафаэль Ильясов һәм Максат Гомәров (баянда). 1993 ел*

әйтә алмам, анысы һәммәбезгә мәгълүм. Фәридә апаны мин рухи остазым, рухи әнием дип саныйм. Чөнки аның белән бала вакытымнан бирле аралаштым. Шундый югары культуралы жырчыларга сыендым мин.

**— Бәлки укыгансыздыр да, «Казан утлары» журналында үткән елның уңынчы, бу елның беренче саннарында Мөнир Абдуллинның «Җырланмаган әле безнең жыр» һәм Рәфикъ Юнысның «Жыр өмәсе үткәрик әле!» мәкаләләре дөнья күрде. Алар бүгенге жыр сәнгатендә жырның сыйфаты, сүзенең, шигыренең тәме китүе, гомумән, татар эстрадасындагы күп кенә житешсез якларны журналист күзлегеннән бәһалиләр. Бу хакта сезнең фикерегезне дә беләсе иде...**

— Әйе, алар бүгенге бик актуаль проблеманы күтәрә. Конкурслар да бик еш уза, жыр сәнгате турында да күп язабыз, күп сөйлибез... Әмма ләкин нәтиҗәсе юк. Конкурсларда, эстрадада яңгыраган жырлар тиешле сайлап алу үтми. Зур исемнәр астында жыр ярышы үткәрәбез икән, биредә жырланасы жырлар да, жырчылар да иләк аша узарга тиеш дип уйлыйм. Сайлап алу комиссиясендә жыр сәнгатендә күпмедер хезмәт күрсәткән кешеләр утыра. Еш кына аларның күп нәрсәгә күз йомулары сизелә. Лауреатлар дип сәхнәгә күтәрелгән яшьләрнең күңелен дә төшерәсе килми. Үзләренчә тырышканнар, дисең. Әмма аларга «шулай ярый», дип кенә лауреат исеме бирү, минемчә, бик үк дөрес гамәл түгел. Хәзерге жюри әгъзалары элеккеге жюри кимәленә якын да килә алмый. Әгәр дә чын мәгънәсендә шундый конкурсларны оештыралар икән, бөтен ягын да уйлап, төгәл фикергә килеп, жюри әгъзаларыннан алып башкаручыларына кадәр бик зур таләпчәнлек куярга кирәк. Бу зур проблема турында зыялы шәхесләр, сәнгать белгечләре катнашында югары дәрәҗәдә утырып сөйләшү зарур...

...Рафаэль Ильясовның моңын сүзләр белән генә аңлатып булмыйдыр. «Жырны — жырчы, жырчыны жыр күтәрә», ди халык. Р.Ильясов башкаруында бер генә «очсызлы» жыр да ишетмәссең. Ул — үз халкының рухи мирасы асылын күңеленә сеңдергән шәхес. Классик башкару культурасын чын-чынлап халыкчан башкару рәвеше белән яраштырып, жырларының аһәнен тагын да баета, халык моңын жаны-тәне белән тоеп, йөрәгенә салып жырлый, хисләренең иң тирән серләрен югары сәнгатьлелек белән гәүдәләндерә белә. Һәр жырында киңлек, иркенлек булып, гүзәллек һәм илаһи яктылыкка омтылу сизелә.

Ничә буын радиотыңлаучыларны тәрбияләгән күренекле композиторларыбыз әсәрләре һәм халкыбыз моңнары да Р.Ильясов эшләгән радио аша гына яңгырый хәзер. «Татарстан» дәүләт телерадиокомпаниясенең радиотапшырулар хезмәте житәкчесе Тәүфыйкъ Сәгыйтов та: «Татар моңының ерак-еракларга барып житүендә, «Яңа гасыр» радиосы һәм телевидениесенең дә уңышлы гына эшләп китүендә Рафаэль Ильясовлар язып туплаган музыкаль байлыклар хезмәт итте» дип дөрес бәһасен бирә. Рафаэль Ильясовның кайсы гына иҗат тармагын алсаң да, милләт пакьлеге сафында торучы олуг хезмәт дип кабул итәбез. Югары зәвыклы шәхес кенә үзенә дә, башкаларга да таләпчән була. Гомер бәйрәмегез белән Сезне ихлас котлыйбыз, кабатланмас моң иясе!

**Филүсә АРСЛАН,**
*Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе*



*Сулдан уңга: Флёра Гыйззәтуллина, Гөлзадә Сафиуллина һәм Гөлшат Зәйнашева. 1989 ел.*



*Язучы Фәүзия Бәйрәмова.*



*Язучы Рашат Низами (сулдан икенче) һәм шагыйрь Ренат Харис (уңнан икенче) Уфа дәүләт университетында «Казан утлары» журналына багышланган очрашудан соң. 1986 ел.*



*Сулдан уңга: биючеләр Фердинанд Гыймадиев, Роза Мостафина, җырчылар Римма Ибраһимова, Зиннур Нурмөхәммәтов һәм Вафирә Гыйззәтуллина. Ленинград, 1986 ел.*



*Контрабаста уйный – Лариса Маслова.*



*Академик Әбрар Кәримуллин белән очрашу кичәсе.*

# КАШ ЯСЫЙМ ДИП...

РАШАТ НИЗАМИГА ИКЕ ХАТ

*Хөрмәтле Рашат дус! «Чын мирас» журналының быелгы гыйнвар санында басылган «Ул — Яруллиннар йолдызлыгыннан» дигән язманны укыдым да сиңа тагын бер хат язарга булдым. Хәтерендәдер, беренче хатны мин «Сәйдәшнең соңгы елы» («Казан утлары» №2, 2010 ел) дигән әсәреңне укыганнан соң, үзенә генә дип, бәлки, файдасы тияр дип язган идем. Ләкин бу хатым сиңа гына түгел, чөнки ул «Кызым, сиңа әйтәм, киленем, син тыңла» рәвешендәрәк булып чыкты. Сиңа, бәлки, файдасы инде тимәс тә, ләкин яшьрәк буын язучыларыбыз бар бит әле. Татар әдәбиятында чын тарихи жанрны, шәт, алар тернәкләндереп җибәрерләр һәм бөек кешеләребез, олы вакыйгаларыбыз турында җитди әсәрләр язарга алынырлар. Дөресен әйткәндә, без бүген «тарихи» дип йөрткән романнарыбызның күбесе асылда «маҗаралы романнар». Әйтемнең беренче өлеше сиңа булса, аның икенче өлеше — яшьләргә һәм башкаларга да... Әүвәле беренче хатны искә төшерик.*

***

Хөрмәтле Рашат дустым! «Сәйдәшнең соңгы елы» дигән кыйссаңны укыгач, сиңа хат язасым килде.

Үз халкыңның бөек шәхесләре турында әсәрләр язу — мактаулы һәм шул ук вакытта үтә җаваплы эш. Алай гына да түгел, бу — үтә хәтәр эш. Бөек шәхесләр, йөрәкләренә үз халкының бөек проблемаларын сыйдыру белән бергә, аларның әхлакый, эстетик биеклекләренә, рухи маякларына да әверелә. Бүгенге дөнья Муса Җәлилгә, Рудольф Нуриевка, Рәшид Сюняевка, Роальд Сәгъдиевка, Нәҗип Җиһановка, Софья Гобәйдуллинага карап, татар халкы турында фикер булдыра. Бүгенге татар кешесенә мескен милләт вәкиле булып түгел, ә бөек халык вәкиле булып яшәргә кирәк! Эпиграфың турында тагы бер мәртәбә уйлан әле — без «мескен халыкның сансыз уллары» мыни?!

Әйе, бөек шәхесләр дә вак-төяк җитешсезлекләрдән, хәтта хаталардан азат түгел. Ләкин шәхескә бәя биргәндә йә аның образын сәнгать чаралары белән сурәтләгәндә, ул җитешсезлекләр хәлиткеч була алмый. (Әйтик, Насыйриның сукыр күзе, М.Гафуриның һәм П.Хузангайның аксаклыгы, С.Михалковның тотлыгуы һ.б.) Шәхесне бөеклеккә күтәрүче төп көч — бөек эш. Фәкать бөек эшләр, безнең очракта — бөек әсәрләр, шәхес язмышында хәлиткеч урын тота. Әйтик, университетларга, консерваторияләргә нигез салу, иҗат берлекләре, яңа газета-журналлар ачу, сәнгатьне яңа төрләр, яңа жанрлар белән баету һәм башкалар...

Син Салих Сәйдәшевкә кагылышлы күп материал җыйгансың һәм укучыга матур итеп сөйләп чыккансың. Әсәрнең формасы да кызыклы — композиторның соңгы чоры кичерешләренә аның гомерен сыйдырырга тырышкансың. Ләкин әсәрдә аның гомеренең кайсы мизгелләре күбрәк урын алган соң? Сәйдәшне олпат композитор иткән олы эшләреме, әллә аны төрле гайбәт объекты иткән вак-төяк җитешсезлекләрме?

Ә.Еникинең «Гөләндәм туташ хатирәсе»ндә Сәйдәш нинди?! Кешелеклелек, зыялылык һәм җаваплылык үрнәге!

Заманында мин дә, Сәйдәшне гайбәт пычрагыннан арындырырга теләп, «Сәйдәш яры» исемле поэма яздым. Син аны беләсеңдер дип уйлыйм. Анда Сәйдәш Буада бер кызчыкны пианинода уйнарга өйрәтә, аны үзенә гашыйк итә, кызчыкның

җанын, гомергә җитәрлек итеп, матурлык белән сугара, үзе сафлык, намуслылык, чын егетлек үрнәгенә әверелә. Бу — минем максатым иде.

Ә синен максатынны, Станиславскийча әйтсәк, «сверхзадачанны» мин аңламадым булса кирәк, Рашат. Акылым картайгандыр, күрәсен. Әллә аңладыммы? Син безне 1950-1960 елларда барлык татар зыялылары — яман, бердәнбер яхшы кеше — Сәйдәш булган, дип ышандырырга телисен, ахры. Ә яманнарнын да яманы, синенчә, Нәҗип Җиһанов. Хәтта Композиторлар союзын да ул Сәйдәшкә начар булсын дип төзегән икән ләбаса! («К.У.» №2, 2010, 56 б.). «...Ин ямьсез-тарпычрак бер урамга Сәйдәшев исеме» бирелү дә (йа, Хода!) Җиһанов эше икән! Шул Н.Җиһанов булмаса, татар мәдәнияте дөньянын ин бөек мәдәниятенә әверелер иде бугай. 1988 елда Җиһанов үлеп китте һәм барлык татар композиторына Свиридов, Шостакович, Хренников, Эшпай булырга юл ачылды. Йә, әйт, кайда алар — татар Эшпайлары, Кара-Караевлары, Таривердиевлары? Ник Казан консерваториясе бүген һичьюгы Р.Еникеевларны, Ф.Әхмәтовларны, М.Яруллиннарны, Р.Биляловларны, Р.Ахияроваларны әзерли алмый? Ник? Син сүккән «власть башында утыручылар» да берничә мәртәбә алмашындылар инде. Ник нота да белмәгән җыр башкаручылар (җырчылар түгел) эстрада «йолдызы» булып йөри? Сәйдәш турында язганда, бу сорауларга да җавап кирәк түгелме? Татарнын рухи дөньясы Җиһанов белән Сәйдәшне сыйдыра алмаслык шундый тармыни? Татар дөньясын шулай сурәтләп, син татар зыялыларын рәнҗетмисенме?

Рашат дустым! Көчле шәхесләргә, чын талант ияләренә иҗат итәргә берни дә комачаулый алмый: төрмә дә (Җәлил, Алябьев), фатирсызлык та (Тукай, Хлебников, Клюев), чир дә (Ф.Достоевский, Н.Островский, Ф.Яруллин), сөрелү дә (Хикмәт, Исхакый, Набоков), сугыш та (Ф.Кәрим)... Ә язылган әсәрне халыкка җиткерүдә комачаулап була. Әмма, минем белүемчә, Салих Сәйдәшевнен үз заманында бер генә әсәре дә файдаланылмыйча, дөньяга чыкмыйча калмаган. Бу яктан ана министр Рәхмәтуллин да, радиокомитет җитәкчесе дә, театр директоры да, Композиторлар берлеге рәисе дә, консерватория ректоры да комачаулык кыла алмаган. Сәйдәш музыкасы янгыраган, әсәрләре нәшер ителгән, юбилейлары зур итеп үткәрелгән. Шулай булмаса, ул данга ирешә дә алмаган булыр иде.

Кыйссанда син Х.Рәхмәтуллин һәм С.Вәлиди җәяүле Сәйдәшевне машинага утырырга чакырмаганнар, дип язасын. Сәйдәш шуна үпкәләгән. Син, Рашат, шушы вак-төякне хәлиткеч вакыйга санап, Сәйдәшевне түбәнсетмисенме? М.Садри радиокомитетка Сәйдәш өчен (композитор никтер урамда кала) гонорар сорап керә дә акчасыз чыга — берничә көн элек Н.Җиһанов гонорар алган булган икән. Менә бит Җиһанов Сәйдәшевне ничек җәберләгән(!), димәкче буласын син. Ә Җиһановнын нинди гаебе бар?! Әгәр дә Сәйдәшев алданрак кергән булса, гонорарны ана бирерләр иде, Җиһанов көтәргә мәҗбүр булыр иде. Син «Идел»дә баш редактор чагында бухгалтерын мине гонорар алырга чакырды. Мин берничә көннән сон гына кердем. Фәлән авторга биреп җибәрдек, иртәгә банктан алып кайткач керерсез дип, мине борып чыгардылар. Мин кемгә үпкәләргә тиеш: теге фәлән кешегәме, бухгалтергамы, әллә үземәме? Авторнын Җиһановка карата тенденциозлыгы түгелме бу?

Син Заһидулла Яруллин авызыннан Җиһанов турында «ләгыйнь» дип әйттерәсен. Моны раслаучы документ бармы сон? Имеш, Ф.Яруллиннын башына Җиһанов җиткән. Нигә? Ничек? Фронттан азат итә алмаганмы? 1941 елда Ф.Яруллин әлегә танылмаган, формалашып килүче яшь композитор була. Ул елларда инде ат казанырга өлгергән күпме язучыны, рәссамны, артистны сугышка алып киттәләр! Фәрит Яруллинга дан 1945 елда, ягъни һәлак булып, ике ел үткәч кенә килә. В.Власов, В.Фере, Л.Якобсоннар ярдәмендә язылып бетмәгән балетны кондициягә китерүдә дә Н.Җиһановнын роле кечкенә түгел. 1958 елда шул ук Җиһанов ярдәмендә ана Тукай премиясе бирелә. Монысын да беләсен. Заһидулла абзыйдан теге сүзне әйттерү — Яруллиннар нәселен пычратмыймы, намуссыз итеп күрсәтмиме икән? Ә Сәйдәшнен ноталарын Казансу буенда яндырулар, М.Нигъмәтҗановнын уйдырма мәгълүматлары? «Мәгълүм сәбәпләр аркасында» («К.У.» №2, 65 б.) Сәйдәш опера язуын ташлый. Нинди «мәгълүм» сәбәпләр алар? Властьнын кысуымы,

Жиһановның юл куймавымы, әллә Сәйдәшнең шәхси сыйфатларымы? Сәйдәшне исертергә тырышучы «подставной» бирәр агент-мазар...» турында авыз суы корыту үзенә көлке түгелме?

Кыйссаннан күренгәнчә, Сәйдәш сәгатен югалткалый. Таныш булмаган яшь шагыйрьгә ияреп, аның беренче гонорарына композитор сыра эчеп йөри. Ул караклар белән коньяк эчә. Сәйдәшнең хатыны артист И.Гафуровны данлыклы иреннән ни өчендер өстенрәк күрә... Кыйсса авторы моны берничек тә аңлатмый. Болар һәм шуның ише нәрсәләр, булган хәл булсалар да, Сәйдәшне кайсы яктан ача? Әллә болар авторның уйланмыйча язган опусларымы?

Мондый сорауларны, Рәшат дустым, мин дистәләп дәвам итә алам, ләкин туктала, чөнки син инде минем үземә: «Ник әсәремнең житешсез якларын гына күрәсең?» — дип, хаклы рәвештә әйтә аласың. Ләкин әсәреңдә болардан житдирәк житешсезлекләр дә бар. Син тагы бер мәртәбә Сәйдәшнең диалогларына игътибар ит әле. Ул ни турында сөйләшә? Вак-төяк тормыш мәшәкатьләре генә бит. Күбрәк — зарлану. Мин синең кыйссаңда композиторның бер генә тирән фикерен дә очратмадым. Сөйләгән хатирәләре — сакаллы анекдотлар, зарлану, шыншу, тыйнак булып күренергә тырышу, министрларны хурлау. Ул ни сәнгать турында, ни музыка турында, ни яшәеш турында, җәелеп китеп, фәлсәфә кормый, уйланмый, оппонентлары белән бәхәсләшми. Иң мөһиме — әсәр барышында композитор бернинди конкрет иҗат эше белән дә шөгыльләнми, бернинди киртә дә ватмый, беркемне дә коткармый, беркемне җинми, кыерсытыла да кыерсытыла гына. Шуның өчен дә Сәйдәш ихтыяр көче булмаган, тормыш агымына чалкан ятып, агым кая тартса — шунда, дулкын кая какса — шул якка агып барган бер мәхлукны хәтерләтә. Чынлап та, Сәйдәш — синең сурәтләвеңдә, мескен илнең сансыз баласы. Мескен белән беркем дә горурланмый, мескенне кызганалар гына!

Әсәрдә С.Сәйдәшевнең психологик портреты тәгәл түгел. Аның хисләр гаммасы зарланудан, үпкәләүдән һәм елаудан гына гыйбарәт. Композиторны иҗат ләззәте кичергән сәгатьләрдә сурәтләргә кирәктер, минемчә. Ә синең әдәби осталыгың мона бик житә. Сәйдәшевнең татар музыкасына керткән яңалыгы «Совет Армиясе маршы»нда да, йә булмаса, албан халык җырын «Әдрән дингез» итүдә дә түгел. С.Сәйдәшев — татар музыкаль театрын тудыра язган олпат шәхес! К.Тинчурин белән, әлбәттә. Килешәсеңме? Килешсәң, ник аны шундый итеп сурәтләмәдең? Әллә бөек оештыручы, бөек иҗатчы, бөек җәмәгать эшлеклесе Н.Жиһановка пычрак чәчрәтүне мәртәбәлерәк дип уйладыңмы?

Ләкин татар музыкаль театры тернәкләнеп китә алмады — аны татар мәдәни дөньясында мәгърур дулкын булып күтәрелгән, тагы да дәрәҗәлерәк саналган опера һәм балет сәнгате арткы планга рак этәреп куйды. Музыкаль театр тарафдары — Сәйдәш, опера, балет театры тарафдары — Жиһанов. Менә сиңа бу ике бөек шәхес арасындагы аерма һәм иҗади конфликтның нигезе. Бу идея-фикерне мин сиңа, Рәшат, бүләк итәм. Бу — фәнни-гамәли конференцияләр, яңа диссертацияләр темасы һәм проблемасы. Бу конфликтта көнләшү, дан бүлешү кебек нәрсәләргә урын юк. Жиһановка Сәйдәштән, Ф.Яруллиннан йә башка татар композиторларыннан көнләшергә бернинди дә нигез юк, чөнки ул — илкүләм билгеле кеше, ул властьта, аның әсәрләре, СССР чикләрен узып, Европада яңгырый, ул илкүләм комитетларда, ул — депутат, лауреат... Һәм барысы да хаклы рәвештә! Чөнки Н.Жиһанов — дәүләти аңлы, югары культуралы һәм белемле, киң карашлы, тырышлыкта тиңдәше булмаган иҗатчы. Мәрхүм композитор Фасил Әхмәтов, сокланып, «Мин Жиһановның барлык әсәрләрен язу түгел, күчереп чыгып та бетерә алмас идем!» — дип әйтә иде.

Татар еш кына үзеннән алдынгырак, булдыклырак, көчлерәк, талантлырак, баерак кешедән, бигрәк тә милләттәшеннән, үлеп көнләшә. Бу — безнең милли хурлыгыбыз, хәтта — фаҗигабез. Син шул хурлыклы сыйфатны ике тарихи шәхес арасындагы хәлиткеч мөнәсәбәткә әвереллермәкче буласың. Ай-һай!

Тагын бер сорау: син кыйссаны кем укысын диеп яздың? Әгәр дә бүгенге күпмилләтле Россия, Европа Сәйдәшне белсен, танысын, аның бөек образы татар халкын тагын бер баскычка күтәрсен, дип язган булсаң, китап итеп бастырганда, минем шушы хатыма да игътибар ит әле, Рәшат дус. Әлбәттә, беренче кат укыганда, хат синең

ачуыңны чыгарыр, әмма икенче тапкыр укырга көч тапсаң, ул сина күзелдерегеннән арынырга һәм алтын кысалы, «мурано» пыяласы куелган европа күзлеге киярга ярдәм итәр. Син мона лаек, чөнки син — билгеле язучы, тырыш кеше.

*Уңышлар һәм саулык теләп,* **Ренат ХАРИС**
*27 февраль, 2010 ел.*

***

Ә хәзер «Ул — Яруллиннар йолдызлыгыннан» дигән язма турында берничә фикер. Дөресен генә әйткәндә, Рашат, беренче хаттагы фикерләр бу әсәреңә дә тулаем туры килә. Син үзгәрмәгәнсең. Монда да ваклангансың, кемнәргәдер нахак гаеп таккансың, пычрак ташлагансың, түбәнсеткәнсең. Ә Фәрит Яруллин, Салих Сәйдәшев кебек үк, дәлилсез, бармак имеп ясалган «яклауларга» мохтаж түгел.

Син Олжас Сөләймановның: «Я возвышаю степь, не принижая гор!» — дигән сүзләрен беләсеңдер. Фәрит Яруллинны «зурдин-зур, актин-ак» итеп күрсәтер өчен, син бу әсәреңдә дә иске һәм примитив алым кулланганссың — Композиторлар берлеген, ВКП(б) өлкә комитетын, аларның Бөек Ватан сугышы чорындагы җитәкчелеген пычратырга, бүгенге опера һәм балет театрын түбәнсетергә маташкансың. Дөрес, бер яңалык бар: бу әсәреңнең төп герое — «бронь», ягъни илнең тулы канлы тыл тормышын тәэмин итү өчен, иң кирәкле белгечләрне, эшчеләрне, фән, сәнгать, мәгариф хезмәткәрләрен фронтка китүдән вакытлыча азат итә торган документ. Үз теләкләре белән сугышка китәргә теләгән кайбер кешеләргә «бронь»ны хәтта мәҗбүри биргәннәр, мәсәлән, җырчы Рәшит Ваһаповка. Синең бөтен игътибарың Фәрит Яруллинга түгел, ә нәкъ шул документка юнәлгән, зиһенеңне шул каплаган. Бу «фәнни-популяр» язмаң да миндә бик күп тискәре сораулар тудырды.

Бөек Ватан сугышы башлану белән, Ф.Яруллинга гына түгел, СССРның бик күп күренекле сәнгать әһелләренә шинель кидерәләр һәм «күрәләтә сугышка җибәрәләр». Алар арасында инде шактый танылырга өлгергән композиторлар Заһид Хәбибуллин һәм Хөснулла Вәлиуллин да бар. Алар исән калган, ә Фәрит Яруллин, кызганыч ки, һәлак булган. «Кемне — кешеләрнеме, әллә системаны, сугышның үзен гаепләргәме?» («Чын мирас» №1, 2014, 112 б.) дигән риторик сорау куясың. Болай итеп, син З.Хәбибуллин һәм Х.Вәлиуллинның исән калулары өчен кемгә рәхмәт әйтергә — кешеләргәме, системагамы, сугышның үзенәме? дигән абсурд сорауга урын калдырасың түгелме? Ә, синеңчә, кем гаепле һәм ни өчен? Язмаңда, Рашат, бу сорауга төпле җавап юк, ә тел төбеңдә — Композиторлар союзы җитәкчелеге, ягъни Нәҗип Җиһанов. Син «бронь» хакында: «Истәлекчеләр телдән сөйләвенчә, Фәритне яки «онытканнар», яки исемлектән төшереп калдырганнар, яки ана дигән броньны кулына вакытында биреп өлгермәгәннәр», — дисең. Беренчедән, исемсез истәлекчеләр телдән сөйләгән нәрсә, Рашат, гайбәт дип атала. Ә гайбәт документ һәм дәлил була алмый. Бигрәк тә — кеше үтерүдә! («...яшь талантны саклауда битарафлык күрсәтүчеләр татар Моцартын үтерде».—118 б.). Икенчедән, хәзер бөтен архивлар ачык, ә «бронь» исемлекләре ябык документ түгел. Син, әсәреңә җитди караган булсаң, гөманыңның өчесен дә ачыклый ала идең: онытканнармы, исемлектән сызганнармы, биреп өлгермәгәннәрме?! Бу сорауларга җаваптан бигрәк, син аларны кемнеңдер гаепләү, кемгәдер шик ташлау, аларга карата нәфрәт тудыру коралына әверелдергәнсең шикелле. Ә кемнәргә? Син Фәрит Яруллин сугышка үз теләге белән китте дигән фараз бар, дисең, һәм «...яшь-яшь гаиләсен, ай-һай, ансат кына ташлап китәр идеме икән ул? Бу буталчыклыкта татарны сөймәс рус түрәләренең дә роль уйнавы бик ихтимал» (114 б.), дигән шик ташлыйсың? Моны ничек аңларга? Ф.Яруллинда патриотлык хисе булмаган, дипме? Үзен генә кайгыртуны бар нәрсәдән өстен күргән шкурник, дипме? Ә «татарны сөймәс рус түрәләренең» бу эштә ни катнашлары бар? Ф.Яруллин сугышка үзе теләп китте, дигән хәбәр таратканнармы? Әгәр дә шулай икән, димәк, алар Ф.Яруллинны сөйгән, аның гражданлык позициясен олылаган, композиторыбыз һәйкәленең нигезен ныгыткан. Рәхмәт аларга. Ә син, Рашат, Фәрит Яруллинны һәйкәл итеп күтәрергә теләп аны бу очракта салып таптыйсың түгелме?

Бераз гына рус һәм Мәскәү темасына да тукталып алыйк әле: «...эчүчелек белән дус рус гаиләсе» (116 б.), «Мәскәү каланчасыннан бу эшчән-батыр халыкка *(татарга. — Р.Х.)* астыртын мөнәсәбәт...» (115 б.), «Мәскәү сәясәтчеләрендә безне — татарны аңлаучы күренми...» (117 б.), армиясе белән дошман ягына күчкән генерал Власовны «чиста рус» дип ассызыклау (115 б.) кебек «ачышларын», Рашат, синең үзенә батырлык, каһарманлык булып тоела булса кирәк. Ә чынында болар — урынсызга әйтелгән, Ф.Яруллинга һәм аңа багышланган язмага һич кагылышы булмаган «паразит» сүзләр генә. Син, форсаттан файдаланып, татарны күтәрергә теләп, гомумән русларны, гомумән Мәскәүне түбәнсетергә маташасың, укучылырыңда аларга карата, СССРга, тарихка карата нәфрәт хисе уятырга телисең кебек. Моннан кемгә һәм нинди файда?! Ул нәфрәт хисе белән мин нишләргә тиеш? «Без әле һаман да солдатлар түгел, коллар хәлендәрәк», дип, Тукайның «Тотса мәскәүләр якан...» (117 б.) шигырен дә үз контекстына яраклаштырып, безне кая чакырасың? Ә менә татар халкына һәм Татарстанга берәр афәт чакырып китерүең мөмкин. Ходай сакласын... Минемчә, безгә башка милләтләрне түгел, ә үз татарыбызны аяусыз тәнкыйть утына тотарга кирәк. Ләкин иленне, халкыңны, тарихыңны белеп һәм яратып — Гоголь, Тукай, Салтыков-Щедрин, Шакир Мөхәммәдов кебек! Ләкин пычрак ыргытмыйча, тәкрек чәчрәтмичә!..

Аннары, Ф.Яруллинны да бит композитор итеп Мәскәү консерваториясе тәрбияли, балетның язылып бетмәгән музыкасын рус музыкантлары спектакльдә файдаланырлык хәлгә китерә. «Шүрәле» балеты да Ленинград театрында 1950 елда куелгач кына дан ала, һәм исән чагында Казанда да бик тар даирәдә генә билгеле яшь музыкант тиз арада Фәрит Яруллин дигән билгеле композиторга әверелә. Бүген дә шул ук хәл — фәкать данлыклы театрларның уңышлы спектакльләре генә дөньякүләм яңгыраш ала. Димәк, безгә үз театрларыбызны халыкара югарылыкка күтәрергә кирәк. Бүген «...инде «урыслашып» бетә язган», дип син буярга маташкан (112 б.) Муса Җәлил исемендәге Казан опера һәм балет театры — Россиянең Европада иң билгеле өч театрының берсе. Ә син аны, дөнья музыка сәнгатен яхшы белмәгән журналистларга ияреп, «татарлаштырырга» хыялланасың булса кирәк. Дөньяда бербөтен опера сәнгате инде күптән «итальянлашкан», «немецлашкан», «французлашкан», «урыслашкан», чөнки барлык театрлар репертуары — нигезендә итальяннар Верди, Леонкавалло, Пуччини, Россини, немецлар Моцарт, Вагнер, Глюк, Штраус, французлар Гуно, Бизе, Дебюсси, руслар Чайковский, Глинка, Бородин, Мусоргский, Римский-Корсаков, Рахманинов әсәрләре. Театр җитәкчелегенең дә, татар композиторларының да, минем дә опера, балет сәнгатен бик «татарлаштырасыбыз» килә, әмма моның өчен дөньякүләм яңгыраш алган һәм барлык халыкларга да кызыклы булган, иң югары эстетик һәм әхлакый таләпләргә җавап бирә алырлык әсәрләр тудырырга кирәк. М.Җәлил исемендәге театрны эчтән белгән кеше буларак, әйтәм: театр шул юнәлештә җитди эш алып бара. Аның кайбер уңышларын инде Россия генә түгел, Европа да таный.

Мине, Рашат, синең Бөек Ватан сугышына булган мөнәсәбәтең аптыраштта калдырды. «Улларының ачы язмышыннан чыгып, «Бөек» дип аталган Ватан сугышына яңача караш ташларга да вакыт җитте...» дигәнсең. Мин ул яңача карашны язмаңнан эзләп карадым, ләкин таба алмадым. Әллә «... ике ил арасындагы сугыш... халкыбызның талантлы һәм эшчән улларын үтерү мәйданы да булды» (117 б.), дигән фикереңне «яңа» карашмы? Әллә дөньяны каплап алган сугышны ике ил арасында гына булган дип әйтү, әллә «бөек» сүзен куштырнакларга алып, ул сугышның әһәмиятенә шик белдерү яңалыкмы? «200дән артык Геройларыбыз бар, дип мактанырга, горурланырга ярата идек... бу очракта да ялган интернационализм барлыгын күрү кыен түгел», дигәнсең. Шушымы сугышка яңача караш? «Нәрсә, сугыш җәһәннәменә китеп барган татар кавемнәре бу сугышларда татар халкы мәнфәгатьләрен яклап көрәштеме әллә?» дигән җөмләң (117 б.) мәсьәләгә шактый ачыклык кертә кертүен. Татар егетләре, синеңчә, ил өстенә килгән фашистик афәткә каршы көрәшүдән баш тартырга тиеш идеме? «...Абыем хәрби очучы иде, вертолёт сынаганда, Россия күгендә янып үлде. Милләт файдасына булса, мин аны бу каләр үк кызганмас та идем» (117 б.), дип язгансың. Синең «сверхзадачаң» бөек татарпәрвәр булып танылырга теләү булса кирәк, ләкин бу югарылыкка ирешү юлын

син Россияне, русны, Мәскәүне, Бөек Ватан сугышын түбәнсетүдә генә күрәсең. Бик хәтәр юл бит бу, Рашат Мияссарович...

Язмана эпиграф итеп «Туплар сөйләшкәндә, музалар тик тора» дигән мәкаль куйгансың. Шәп мәкаль, ләкин бу очракта урынсыз. Шушы язмаңда ук син үзеңә үзең каршы килгәнсең — Ф.Яруллин «блиндаж өчен киселгән агач төпләрендә (анда — җыр пластинкасындагы эзләрне хәтерләткән боҗралар) бармакларын биетеп, «көй» чыгара» (113 б.), дип, иронияле елмаю гына уята торган эпизод китергәнсең. Ләкин композиторның сугыш вакытында иҗат иткән әсәрләрен атамагансың. Кайда соң алар? Аларны күрсәтеп, ник безне куандырмыйсың? Ә М.Җәлилнең, Ф.Кәримнең, М.Кәримнең, А.Твардовскийның, Я.Ухсайның, Х.Мөҗәйнең һәм башка бик күп фронтовик язучыларның музалары йокламаган — туп тавышларын бастырып, «Моабит дәфтәрләре» туган, Ф.Кәрим, автомат прикладына блокнот куеп, 150 шигырь, 8 поэма, 2 повесть, 1 пьеса иҗат иткән, Твардовский «Василий Тёркин»ны язган... Ә син, Ф.Яруллинны унайсыз хәлгә куеп, пластинка сырларын хәтерләткән төпләрдә бармакларын биетеп, анардан «көй» чыгартасың...

Ә хәзер синең ике әсәрең буена сузылган Нәҗип Җиһанов темасына тукталыйк. Дөрес, син бу язмаңда Нәҗип Җиһановны бер мәртәбә дә исемләп атамагансың, минем беренче хатымны, мөгаен, укыгансыңдыр. Ләкин аны яманларга курыккансың, чөнки синең гаепләвең Н.Җиһановка берничек тә йокмый, ә миңа имярекка (исемсезгә) ябыша ала. Аның Ф.Яруллинга күрсәткән ярдәме турында — ләм-мим. Бу турыда мин сиңа беренче хатымда язган идем инде. Өстәп шуны әйтә алам: «Шүрәле» балетына музыка язуны матди яктан тәэмин итәр өчен, Татарстан Композиторлар союзы (рәисе — Н.Җиһанов) СССР музыка фондыннан Ф.Яруллинга 1500 сум акча алып бирә һәм композитор эшен дәвам итә. Балет музыкасы клавирына күпмедер үзгәрешләр кертеп, әсәрнең партитурасын язган, аны спектакль либреттосына яраклаштырган — Фере белән Власов, тора-бара, татар композиторының автордашлары булырга исәплиләр, балетның исемен «Али-батыр» дип үзгәртәләр. Берничә ел көрәш бара: бер якта — Фере белән Власов, ә каршы якта — театр, Татарстан Композиторлар союзы (Н.Җиһанов), Казан консерваториясе (ректоры — Н.Җиһанов). Ахыр чиктә Яруллин ягы җиңә һәм «Шүрәле» үз исемен һәм авторын саклап кала. Син боларны беләсең бит. Ә нигә язмыйсың? Нигә син укучыңда, шул исәптән миндә дә, татар халкының горурлыгы булган Нәҗип Җиһановка карата нәфрәт уятырга тырышасың? Зыялы, горур, чын милләтпәрвәр кеше, ә язучы бигрәк тә, һәр сәләтле милләттәшен талант дәрәҗәсенә, олы талантны бөеклеккә таба, иң бөекләрне пьедесталга күтәрергә тырышырга тиеш ләбаса! Кызганыч ки, син ике очракта да каш ясыйм дип, күз чыгаргансың кебек...

Ике әсәреңә дә хас тагын бер сыйфат — документальлек юк дәрәҗәсендә аз, барлык материалларың матбугат аша бик күпләргә инде таныш. Бөек шәхесләр турында язганда, архив документларына таяну — иң беренчел таләп, ә син бик еш үлем, иҗат процессы кебек үтә җитди нәрсәләрне дә «якынча күзаллыйсың» (118 б.) һәм персонажыңны, үзең дә сизмәстән, уңайсыз хәлгә калдырасың. Бүгенге татар язучысы, гомумән, архивларга керергә яратмый. Архивта вакыт әрәм иткәнче, ул, бармактан суырып йә беркем дә аңламаган-белмәгән эзотерикага чумып, албастылар, җен-пәриләр, сихерчеләр турында бер грамм да иҗтимагый җаваплылык таләп итми торган берәр нәрсә әтмәлләп ташлый. Сиңа гына түгел, безнең барыбызга да, шул исәптән әдәби тәнкыйтькә дә, җитдиләнергә, профессиональләшергә вакыт.

Әлегә менә шулар, Рашат Мияссарович! Сиңа сәламәтлек, иҗатыңда уңышлар теләп калам.

**Ренат ХАРИС**

*29 гыйнвар, 2014 ел.*

**Редакциядән:**

*Бу язма бер иҗатчыны да битараф калдырмас дип уйлыйбыз. Фикерләрегезне электрон почтага язып җибәрә аласыз.*

# ТАТАРСТАНЫМ — ИДЕЛ-ЙОРТЫМ!

## Газаплы уяну



XVI гасыр уртасында бәйсезлеген югалтканнан соңгы еллар татар халкы өчен газаплы хыяллар, әрнүле өметләр дәвере булды. Гасырлар дәвамында дәүләтчелеген торгызу теләгенең иң татлы хыялы итеп саклап килде. Әлбәттә, моның нигезендә телен, динен, гореф-гадәтләрен, димәк, халык буларак үзен саклау рухы ята иде. Үз дәүләтчелеген торгызу, башка халыклар белән тигез хокукка ирешү теләге халкыбыз күңелендә һәрвакыт ышаныч бөреләре булып яшәп килде һәм үзгәртеп коруның беренче шифалы җилләре исү белән үк ышанычлы шытымнарын бирде. Шунысын да әйтеп китү бик урынлы булыр: халык хәрәкәте беренчеләрдән булып өч Балтыйк буе илләрендә башланган булса, шул ук вакытта Татарстанда татар халкы арасында Татар иҗтимагый хәрәкәте барлыкка килде. Татар иҗтимагый үзәгенең региональ оешмасы беренчеләрдән булып Түбән Камада оешты һәм рәсми рәвештә расланды.

Күпләребезнең хәтерендәдер: 1988 елның сентябрендә Техника йортының кече залына бер төркем тынгысыз җаннар җыелды. Аларның ачынып-ачынып сөйләгән сүзләрендә — динебез бетә, телебез бетә, милләтебез бетү алдында тора, болай яшәп булмый, нәрсәдер эшли башларга кирәк бит, дигән фикер ярылып ята иде. Әмма нишләргә кирәк икәнен, нәрсәдән башларга икәнен ачыклау авыр иде. Шушы нишләргә кирәк дигән сорау көннән-көн күпләрнең күңелен били башлады, җыелып фикер алышулар даими хәрәкәтнең башлангычы булып китте. Барыбызның да теләкләре изге булса да, фикерләр чуарлыгы үзен нык сиздерде. Хәтта кайбер иптәшләрнең хәрәкәттән читләшүенә һәм үз төркемнәрен оештыруына китерде. Әмма ысуллар төрле булса да, теләкләр бер булгач, барыбызның да тырышлыгы уртак максатыбызга юнәлде һәм ахырда хәрәкәтебезнең бердәмлеге саклана алды.

Үткәрелгән оештыру җыелышында Татар иҗтимагый үзәгенең төп юнәлешләре булып түбәндәгеләр билгеләнде: 1. Республикабызның статусын күтәрү. 2. Кама Аланында татар атом электр станциясен төзетмәү һәм республикада экология проблемалары. 3. Бетүгә дучар ителгән динебезне, телебезне, рухи дөньябызны шушы аяныч халәтеннән коткару һәм татар халкын милләт буларак саклап калу.

Әлбәттә, сәяси күзлектән караганда, иң мөһим проблема булып халкыбыз өчен республикабызның статусын күтәрү тора иде. Чөнки бу юл — татар халкының күптәнге хыялы, Октябрь чорыннан соң әрнүле алдануы һәм бик күп сәяси корбаннар биргән юлы. Мулланур Вахитов, Мирсәет Солтангалиев һәм аларның күпменләгән тарафдарлары — шушы изге юлның корбаннары.

## Республикабызның статусын күтәрү

Табигый ки, үзгәртеп кору еллары башлангач та, беренче бурычыбыз булып республикабызның статусын күтәрү тора иде. Шушы максаттан чыгып, имзалар җыю башланды. Бу гаиләләргә һәм хезмәт коллективларына үтеп кердe, шәһәрдә күпменләгән халык җыйган митинглар оештырылды. Шәһәребезнең Техника йорты алды мәйданында имзалар буенча Татар иҗтимагый үзәге һәм Азатлык

яшьләр оешмасы әгъзаларыннан оештырылган даими штаб эшләде. Сәяси көрәш шулкадәр кискенләште ки, халкыбызның кайбер фидакарь уллары һәм кызлары ачлык игълан иттеләр. Монарчы безнең тормышта күрелмәгән шушы адымга барган Раиф Сабиржан, Энже Хажиева, Якуб Төхфәтулла һәм Рәшит Фәйзрахман кебек милләттәшләребезгә без соклану хисләребезне һәм рәхмәтебезне белдерәбез. Алар үзләренең тәвәккәл адымнары белән битараф күнелләрне дә сәясәткә җәлеп итеп, күпләрнең фикерен статусыбызны күтәрүгә юнәлтә алды. Татар иҗтимагый үзәге әгъзалары башлап җибәргән изге эш милли хисләре сакланган ватандашларыбыз арасына үтеп керде һәм теләктәшлек тапты, үзенә дәвамчылар өстәде һәм нәтиҗәдә шәһәребездә генә дә 50 меңләп имза җыелды.

Шунысын да әйтеп китү артык булмас. Татар иҗтимагый үзәге әгъзалары таләбе белән статусны күтәрү мәсьәләсе Түбән Кама шәһәр Советы сессиясендә һәм партия пленумында да каралды һәм әлеге мәсьәләдә уңай карар кабул ителде. Бу Татарстан коммунистлары оешмаларының статусны күтәрү буенча кабул иткән бердәнбер карар иде. Куанычлы ки, безнең бу омтылыш демократик рухтагы башка милләт вәкилләре: рус, чуваш, башкорт, мари, удмурт, украин һ.б. арасында да зур теләктәшлек тапты.

Сәяси көрәш көннән-көн кыза барды. Ул Түбән Кама, Чаллы, Алабуга, Әлмәт мәйданнарын үтеп, башкалабыз Казанның Азатлык мәйданына барып җитте. Республикабызның дәүләт статусы турында Декларация кабул итү көннәре сәяси көрәшнең кульминациясенә әверелде. Бу көннәрдә Азатлык мәйданында СССРның кайсы гына төбәкләреннән татар вәкилләрен очратмадык. Аларның таләбе бер иде: Татарстанга дәүләт мөстәкыйльлеге статусы! Азатлык мәйданындагы көрәшчеләр сафына Чаллы, Түбән Кама төбәкләреннән фидакарь көрәшчеләрнең дәррәү килеп керүләре, аларның тәвәккәллеге Казан халкында соклану тудырды, көрәш рухы һәм җиңәчәгебезгә нык ышаныч уятты. Азатлык мәйданы гөрләде. Ул чын азатлык өчен көрәш кырына әверелде. Анда даими митинг барды, дин әһелләре, язучылар, галимнәр, артистлар, берсен-берсе алыштырып, ялкынлы нотыклар тотты, көрәшкә чакырды, хокук таләпләре куйды.

Бу онытылмас көннәрнең бер мизгелен күз алдыннан үткәрик. Бер төркем «Бүленмәс империя» тарафдарлары, Казан ял паркы каршында митинг үткәреп, Татарстанның Казан губернасы гына булып калуын таләп итеп, Азатлык мәйданына килеп керде. Милли хисләребезне болай мыскыл итү мәйданга җыелган милләттәшләребезнең күнелендә нәфрәт уятты. Бер төркем лачындай егетләребез аларга капма-каршы басты. Шуның белән карагруһчыларның тузынуларына чик куелды. Бу тәвәккәл адымны ясаучы егетләр алдында шәһәрдәшебез, көрәштәшебез, якын дустыбыз, Мамадыш районы Еники чишмәсе авылы егете Әнәс Габделхәй улы Шәмсетдинов булганлыгын без горурланып искә алабыз.

Ниһаять, 1990 елның 30 августында Татарстан Югары Советы үзенең сессиясендә Татарстанның дәүләт мөстәкыйльлеге турында Декларация кабул итте. Татар иҗтимагый хәрәкәтенең шуннан соңгы этаплары республикабызның мөстәкыйльлеген яклауга һәм ныгытуга юнәлдерелде. Татарстанның үз Президентын сайлау, Россия Президентын сайлаудан баш тарту, дәүләт статусыбызны билгеләү буенча бөтенхалык референдумын үткәрү һәм статусыбызны беркеткән яңа Конституциябезне булдыру этаплары һәм дә шушы юнәлешләрдә уңай нәтиҗәләргә ирешү — халкыбыздан бердәмлек, максатларыбызга бирелгәнлек, көрәшчеләребездән тәвәккәллек таләп итте. Әгәр шушы зур эшләрдә халкыбыз уңай нәтиҗәләргә ирешкән икән, безнең таләпләребез гадел, көрәш юлыбыз дөрес, киләчәккә ышанычыбыз нигезле.

Һичберебез генә дә шикләнмәскә тиеш: татар халкының үз мөстәкыйль дәүләте торгызылыр, дөньяның башка цивилизацияле дәүләтләре, халыклары арасында Татарстан дәүләте, татар халкы үзенең лаеклы урынын алыр. Моның өчен бездән бер генә нәрсә таләп ителә: милли хәрәкәтебезнең уянуы һәм аның милли горурлыкка әверелүе. Горур халык бервакытта да кол булмый һәм ул, тарихның бөтен каһәрле сынауларын уңышлы үтеп, мең еллардан соң да үз дәүләтен торгызуга ирешә. Бу — хакыйкать, моның безнең өчен иң ышанычлы дәлиле булып яһүдләрнең 2 мең елдан соң да үзләренең дәүләтләрен торгызулары тора.

## Республикада экология проблемалары

Мәскәү империячел даирәләре башка регионнарның мәнфәгате белән беркайчан да исәпләшмәде. Республикабызның нәкъ уртасында, зур промышленность предприятиеләре урнашкан районда проектсыз-нисез, ышанычсыз җир катламына дәһшәтле атом электр станциясен урнаштыру — шул диктат сәясәтенең ачык дәлиле. Бу башбаштаклык Татарстанда яшәүче күпләрнең күңеленә шөбһә салды һәм зур каршылык хәрәкәте оешуга сәбәпче булды. Әлеге мөһим эшне Татар иҗтимагый үзәге әгъзалары башлап җибәрде һәм җитәкләде. Иң беренче адымнардан буларак, АЭС җитәкчеләре белән әңгәмә оештырылды. Күпме генә яшерергә теләсәләр дә, АЭСның рөхсәтсез төзелүен, куркыныч булуын һәм ышанычсыз җир катламына утыртылуын инкарь итә алмадылар. АЭС директоры Антоновның: «Куркынычсызлыкны мин гарантиялим!» — дигән сүзләре үзе бер җавапсызлык үрнәге иде. Шушы туып килә торган афәт күпләрнең, нинди милләттән булуына карамастан, АЭСка каршы туплануына китерде.

Шәһәребез тарихында яңалык булган зур-зур митинглар үткәреп, кискен резолюцияләр кабул ителде. ТИҮ әгъзалары, башка регионнар белән берләшеп, АЭС төзүне туктатуны таләп итеп, имзалар җыюны оештырды. Алдан килешенеп, Казан, Уфа, Түбән Кама, Чаллы шәһәрләреннән АЭСка каршы марш оештырылды. Маршта катнашучылар Түбән Камада һәм Кама Аланында халык күңеленә үтеп керердәй митинглар үткәрде һәм пикетлар оештырды.

Бу эштә бигрәк тә зур хезмәт куючылардан шәһәребез кешеләре Роберт Гыйззәтуллин, Наил Махиянов, Юрий Аносов, Вахит Биктаһиров, Рифкать Гәрәев, Казан физигы Альберт Гарипов булды. Әйтергә кирәк, АЭС төзелешенең Татарстан халкына карата хыянәтчел икәнен фаш итүдә Казан университетының кайбер галимнәре дә фидакарь эш эшләде. Алар фәнни дәлилләр белән халыкта төзелешкә кискен каршылык тудыруга ифрат зур өлеш кертте.

АЭСка каршы көчләрнең берләшүе, аның киң халык массаларында теләктәшлек табуы империячел даирәләрне дә халык мәнфәгате белән исәпләшергә мәҗбүр итте һәм, ниһаять, АЭС төзелеше туктатылды. Бу зур җиңү булды. Шушы хәрәкәтнең тәэсире нәтиҗәсендә, гомумән, шәһәрдә һәм промышленность предприятиеләрендә экология мәсьәләләренә игътибар сизелерлек артты. Әмма әле бу эшнең башы гына. Һич тә онытырга ярамый: безнең эчкән суыбыз, сулаган һавабыз, ашаган ризыкларыбыз тиешле таләпләргә җавап бирми. Аларга игътибарны арттыру — безнең уртак бурычыбыз.

## Татар халкын милләт буларак саклап калу

460 ел дәвамында коллык каһәрләренең бөтен ачысын татып, шөкер Ходайга, күп югалтулар белән булса да динебезне дә, телебезне дә, гореф-гадәтләребезне дә, милләт буларак халкыбызны да саклап кала алдык. Бу изге юлда фидакарь изге затларыбыз Кол Шәриф, Габденнасыйр Курсави, Мөхәммәдьяр, Шиһабетдин Мәрҗани, Хөсәен Фәезханов, Габдерәхим Утыз Имәни, Габделҗаббар Кандалый, Каюм Насыйри, Галимҗан Баруди, Риза Фәхретдин, Габдулла һәм Гобәйдулла Буби, Зыя Камали, Хәсәнгата Габәши, Муса Бигиев, Садри Максуди, Гаяз Исхакый һәм башка мулла-зыялыларыбызның халкыбызга күрсәткән хезмәте искиткеч зур булды. Чөнки татарның мәгариф системасы дин белән аерылгысыз бәйләнгән иде.

Совет чорына кадәр татарга мәктәп ачарга һич рөхсәт булмаса да, мәчет-мәдрәсәләрнең эшчәнлеге нәтиҗәсендә татар халкы Русия халыклары арасында иң укый-яза белгән халык булып саналды. Әмма совет чорында дин тыелды, шуның белән мәдәни системабыз да бетерелде. Моның аяныч нәтиҗәләрен без бүген бик нык татыйбыз. Миссионер Ильминский тәгълиматларына корылган, ягъни баланы сабый чактан ук гаилә мохитеннән, туган теленнән, гореф-гадәтләреннән, диненнән аерып тәрбияләү һәм укыту системасы иң аяныч хәлгә — милләтебезне юк итү халәтенә китерде.

Шушы халәтне аңлау милли мәгариф системасын булдыруның ничек мөһим икәнен ачык күрсәтте. Шуның өчен милли балалар бакчалары ачу, ягъни баланы үз милли мохитендә тәрбияләү, милли мәктәпләрдә баланы туган телендә укытып, үз рухи дөньясында тәрбияләү өчен шартлар булдыру Татар иҗтимагый хәрәкәтенең

төп бурычларыннан берсе булып тора. Бу искиткеч мөһим һәм авыр юнәлештә Татар иҗтимагый хәрәкәте зур эш башлап җибәрде. Милли мәнфәгатьләрнен зарурлыгын ата-аналарга, тәрбиячеләргә, укытучыларга, җитәкчеләргә таныту максатыннан, шәһәрнен барлык бакчаларында, кайбер мәктәпләрендә сораштырулар үткәрдек. Нәтиҗәдә, ата-аналарнын милли тәрбия, милли укыту системасына битараф булмауларын күрсәтә алдык. Ачыграк әйткәндә, шәһәрдә 67% ата-ананын милли тәрбия-укыту системасын яклавын билгеләдек. Бу безгә ата-аналарнын таләбен алгы планга куярга мөмкинлек бирде. Шушы таләпләргә нигезләп һәм кабул ителгән дәүләт мөстәкыйльлеге Декларациясенә таянып, депутатларыбыз шәһәр Советы сессиясендә милли бакчалар ачу, милли мәктәпләр булдыруны мәгариф системасынын планына кертә алдылар.

Бу эш бик авыр бара. Әмма куанычлы нәтиҗәләр дә бар: шәһәребездә 2 татар балалар бакчасы ачылды. 84 балалар бакчасында 132 татар төркеме оештырылды. 2 нче татар гимназиясе, 19 мәктәптә 32 татар классы эшли башлады; мәктәпләрнен күпчелек сыйныфларында татар телен укыту юлга салынды, бер татар музыка мәктәбе хасил булды; милли кадрлар мәсьәләсе хәл ителә башлады; 2 нче татар гимназиясенә, татар музыка мәктәбенә һәм кайбер гомуми белем бирү мәктәпләренә җитәкче урыннарга татар милләте вәкилләре куелды; 18 мәктәптә милли мәгариф буенча директор урынбасарлары булдырылды. «Нефтехим» берләшмәсе социаль үсеш идарәсендә җитәкче кадрлар алыштырылды һәм бу эш уңай нәтиҗәләрен дә күрсәтә башлады. Шушы юнәлештә ТИҮнен шәһәр Советы депутатлары Алмаз Якупов, Илдар Сәйфуллин, Рифгать Гатин, Фәрит Низамов, Равил Сәлахов, Рәшит Фәйзрахиев, Раиф Галиев, Гаян Ягъфәров, Рөстәм Мифтахов, Рәсим Нәфыйков, Сөяр Мусин, Рәшит Шәйхәлиев, Рафаэль Азизов, Ильяс Әхиятдинов башкарган зур эшләрне без зур канәгатьләнү һәм рәхмәт хисләре белән билгеләп үтәбез. Аларнын кыю эшчәнлеге дәүләт мөнәсәбәтен милли мәнфәгатебезгә карата уңай якка үзгәртә алды. Бу үзгәрешләр куандыра. Ләкин без милли тәрбия, милли укыту системасы булдырудан ерак әле. Милләттәшләребез арасында аңлату эшен көчәйтергә һәм җитәкче даирәләр алдында таләпләребезне кыюрак куярга кирәк.

Әлбәттә, балалар бакчаларында аерым татар төркемнәре, мәктәпләрдә аерым татар сыйныфлары ачу безне әле һич кенә дә канәгатьләндерми. Моны эшнен башы гына дип карыйбыз. Төп бурыч булып үз тәрбия һәм мәгариф системабызны булдыру тора һәм балаларыбыз шул юлны үтеп үсәргә тиеш. Чөнки башка юл — милләтне бетерү юлы. Ә татарны бетерү сәясәте яна күренеш түгел. Мәсәлән, Русия империясенен халык мәгарифе министры Д.В.Толстой 1870 елда болай язган: «...Безнен ватаныбыз кинлекләрендә яшәүче инородецларны укытунын төп һәм хәлиткеч бурычы булып аларны урыслаштыру һәм урыс халкы белән кушу тора» *(Сөембикә, 1993, № 2, 7 б.)*.

Кызганыч ки, бу бурыч 1970 елларда, ягъни 100 елдан сон коммунистик идеологиянен тырышлыгы белән үтәлеп бетә язды. Әмма аны ахырынача үтәргә ирек бирмәү, үзебезнен тәрбия-укыту системасын булдыру һәм саклау бүгенге көндә милләтебез алдында торган бурычларнын ин мөһиме һәм изгесе булып кала.

Дин ул — кыйбла. Динебезне югалта барып, кызганыч, кыйблабызны да югалта яздык. Шунын аркасында урыслаштыру буенча совет империясе 50 ел эчендә Русия империясе 400 елда да ирешә алмаган уңышларга ирешә. Бу мисал динебезнен милләтне саклауда нинди зур роль уйнавын күрсәтә. Шунын өчен үзгәртеп кору җилләре исә башлау белән үк дингә игътибар арту, мәчетләр сала башлау табигый күренеш иде.

Татар иҗтимагый үзәге бу юнәлешнен мөһимлеген аңлады һәм дин әһелләренә ярдәм итүгә алынды. Шул эшләрнен шатлыклы нәтиҗәсе булып шәһәребезнен үзәгендә, ин матур һәм уңайлы урында, уртак куанычыбыз — җәмигъ мәчетебез ачылды. Тарихи гаделлек өчен бу эшнен каршылыклар белән башлануын да әйтеп үтәргә кирәк. Кызганыч ки, ул вакытта шәһәр җитәкчеләребезнен кайберләре үзгәртеп коруны бу юнәлештә дә алып баруның мөһимлеген аңлап җиткермәде. Бигрәк тә башкарма комитет президиумы әгъзалары Н.Ф.Буханова, А.П.Жуков, Р.Глянц һәм кайбер башкалар бернинди дәлилсез мәчеткә урын бирүгә һәм төзелеш башлауга кискен каршы чыктылар. Күнелләрендәге безнен халыкка булган тискәре карашны яшермичә, ахырынача каршы бардылар.

Шәһәребездә чын күнелдән ярдәм күрсәтүчеләр дә җитәрлек булды. Шушы изге эштә тәвәккәл адым ясаучылар арасында чын күнелләреннән бирелеп йөргән

М.Сибгатов, мәрхүм У.Ваһапов, И.Ихсанов, Г.Исмәгыйлев, Р.Галиев, Т.Нәбиуллин, Ф.Ханов һәм башкаларны әйтеп үтмәү мөмкин түгел. Мәчет урынын билгеләүдә һәм матди яктан тәэмин итеп, аны төзи башлауда мәшһүр җитәкчеләребез В.Пучкин, Г.Сәхапов, Н.Зеленов, В.Хәйруллиннар зур ярдәм күрсәтте. Диндарларыбыздан Фатыйх абзый Рәхмәтуллин һәм Кирам ага Кәшафетдинов һ.б. кайберәүләрнең бу эштә бик тырышып йөрүләре дә зур ихтирамга лаек.

Әйе, дин ул — кыйбла. Кыйблабызның дөрес булуы өчен, динебезнең дә саф, гадел, туры булуы сорала. Үз чиратында, бу диндарларыбыздан фикердә турылык, сүздә дөреслек, гамәлдә сафлык таләп итә. Алар вак-төяк низаглардан арынып, шушы юлга бирелеп хезмәт итсеннәр иде! Иншалла, мәчетләребезгә дә яшь буын килер, аларда укымышлы хәлфәләр булыр, мәгариф белән дин янәшә барып, кыйблабыз да ачыкланыр.

Дин ул — шәфкатьлелек тә. Гомер-гомергә шәфкатьлелек кешеләрнең үзара мөнәсәбәтләрендә, аларның бер-берсенә ярдәмләшеп тормыш итүләрендә зур роль уйнаган. Мөселман диненең төп кануннарыннан берсе — зәгыйфьләргә, ярлыларга ярдәм итү, сабыйларга, картларга булышу. Бүгенге катлаулы заманда шушы кануннарга кайту ифрат дәрәҗәдә кирәк.

Татар иҗтимагый үзәге дә, җәмгыяте-хәйрия, качаклар комитеты, солдат аналары комитеты оештырып, шулар аша бу мөһим эшне җаелдерә башлады. Әмма аларны башкару зур чыгымнар сорый. Барыбыздан да шәфкатьлелек, миһербанлык таләп итела. Элек бу мәсьәләләрне татар байлары хәл иткән. Бөтен дин, укыту-агарту учреждениеләрен, газета-журналларны, нәшриятларны алар үз акчаларына тоткан. Әлегә байларыбыз юк, әмма икътисади мөмкинлекләре булган җитәкчеләребез игелекле эшләр башкара. Мәсәлән, Түбән Кама «Нефтехим» берләшмәсенең «Туган як», «Ватаным Татарстан», «Шәһри Казан» газеталарына, «Сөембикә», «Мирас» журналларына, җыр һәм бию ансамбльләренә, «Татаркино» студиясенә матди ярдәм итүләре өчен рәхмәтебезне белдерү урынлы булыр. Башка җитәкчеләребез дә бу эшкә ныграк алынсыннар иде, чөнки рухи дөньябыз миһербанлы булуга, ярдәмгә бик мохтаҗ.

Зур проблема булып качаклар мәсьәләсе килеп баса. Язмыш безне какты-сукты, куды-таратты. Иксез-чиксез сөргеннәре, вербовкалары татарны Магаданга, Якутиягә, Сахалинга, Байкал-Амурга, Кузбасс-Донбаска, Магниткаларга, Днепрогэсларга, Төмәннәргә китереп тутырды. Җәһәннәм читендәге Камчаткада гына да 10 мең татар яши! Мескен татар һаман тормышы рәтләнүенә өмет тотты. Күпмегә баегандыр, анысы билгесез, әмма туган илен югалтты, ахыр чиктә үзен-үзе дә югалта язды.

Таралганбыз, әмма җыелырга вакыт җитте! Ә җыелышу таралуга караганда күп тапкыр авыр. Шөкер, безнең җыелырга туган җиребез, Татарстаныбыз, Идел-Уралыбыз бар!

## Милли уяну

Без үз мәнфәгатебезгә шулкадәр битараф булып беткән идек ки, һәйкәл түгел, урам исемнәрен дә үзебезчә атарга курка идек. Шәһәребезне генә алып карыйк: аның бернинди милли йөзе юк иде, әйтерсең лә ул Новгород өлкәсендә төзелгән шәһәр! Ә бит гомер-гомергә татар кешеләре шәһәр җитәкчеләре булды, кем соң аларга татар атамаларын кулланырга рөхсәт бирмәде? Гаепне читтән эзләмик, үзебезнең битарафлык, мескенлегебез чиктән ашкан. Милли горурлыгыбыз булса, тыкрыкка Тукай исеме биреп, проспект кебек киң урамнарны Гагарин, Мурадьян, Бызов исемнәре белән атар идекмени?! Шәһәребездә ничәмә-ничә дискоклублар булып, аның берсе дә татар яшьләренә хезмәт итмәде. Әйтерсең лә аларның рухи ихтыяҗлары юк иде! Милли хисебез булса, безнең шәһәребезнең бөтен җәмәгать урыннары «Кама», «Космос», «Восход» һәм башка шундый безгә ят исемнәр белән тулыр идемени?! Без хәтта шәһәребездә бер ресторанны да «Татар халык ашлары» дип атаудан курыктык. Бу мәсьәләләр бик күпләребезнең милли тойгыларын түбәнсеткән кебек, иҗтимагый үзәк игътибарыннан да читтә калмады.

Ниһаять, катгый таләпләрдән соң, меңләгән имзалар җыеп, матбугат битләрендә күпләгән мәкаләләр басылгач, Бакый Урманче исемендәге матур гына урам барлыкка

килде, Тукаебыз исемен йөрткән урам да урынын үзгәртте һәм күнелләргә шатлык өстәп, шул урамдагы бакчада һәйкәл куелды. (Һәйкәлне бөек рәссамыбыз Бакый Урманче иҗат итте.) Шушы эшне башкаруда тырышлыкларын куйган Ф.Котдусовка, Р.Миннуллинга, М.Сибгатовка, Ф.Хановка рәхмәтебезне белдерәбез.

Күп эшләрнең башкарылуы тынгысыз йөрәкләрнең булуыннан, аларның тәвәккәл, конкрет эшләргә алынуыннан тора. «Газель» кече предприятиесе житәкчесе Алмаз Якуповның инициативасы һәм матди ярдәмендә, шулай ук тынгысыз жан Кадрия Ярмиева тырышлыгы аркасында, ниһаять, шәһәребездә беренче татар музыка мәктәбе булдырылды. Нинди зәвык белән бизәлүен барып карагыз, үзегез күреп куанырсыз, анда күпме күнел жылысы салынган! Шушы кече предприятиенең укытучылар хезмәт хакына өстәп түләве — үзе нинди матур күренеш!

Татар яшьләренә ял итәргә урын юк дип зарланып йөрүчеләр дә күп булды. Ә дустыбыз Нәкыйп Ганиев аны шәһәр мәйданнарыннан тапты һәм ничә ел инде яшьләребез мәйданда жырлый, бии, күнел ача, ял итә. Алай гына да түгел, «Чулман» кече предприятиесе житәкчеләре Раиф Галиев һәм Ильяс Хәбибуллин «Нефтехим» берләшмәсе ярдәмендә «Аулак өй» татар яшьләре мәдәният үзәге булдырды. Килегез, рәхәтләнеп ял итегез! Бөтен шартлар тудырылган монда. Күренә: боз кузгалды. Ә күпме урамнар, мәйданнар, ижтимагый биналар милли жан өрүне көтә. Онытмыйк: бу бит үзебездән, бигрәк тә житәкчеләрдән тора.

Әлбәттә, теләк булганда, үзгәрешләр ясап була, әмма аның өчен фидаи жаннар кирәк. Әйтик, хәтер көннәрен үткәрү. Милли әләмнәрне күтәреп, урамга чыгып, үз таләпләренне белдерү яки изге нигезебез булган Болгарга сәяхәт оештыру. Йорттан-йортка, гаиләдән-гаиләгә йөреп, жыелышлар жыеп, кешеләргә сайлауның мөһимлеген, балаларыбызны үзебезнең мохиттә тәрбияләп, үз ана телебездә укытуның кирәклеген ата-аналарга аңлатырга тырышу зур үжәтлек, милли хәрәкәткә бирелгәнлек таләп итә бит. Шунысы куанычлы: бу башкарылган эшләр барысы да бер изге максатка — халкыбызның милли аңын үстерүгә хезмәт итә.

Гаилә ул — дәүләтчелекнең мөстәкыйль күзәнәге. Гаилә нинди — жәмгыяте дә, дәүләте дә шундый. Нинди соң ул безнең гаилә? Элек ана, йорт жылылыгын саклап, бала тәрбияләү белән шөгыльләнгән булса, хәзер ул инде баласын ят тәрбиягә тапшырып, үзе хезмәткә жигелде. Ир-ат элек гаиләнең матди ткасы һәм хужасы булса, хәзер ул да бу вазифаларын күпкә югалтты. Нәтижәдә, гаилә үзенең тәрбияви асылын жуйды. Бу югалтуның безнең өчен иң куркыныч ягы булып баланың ят телдә, ят мохиттә тәрбияләнүе тора. Бала, ана назыннан, туган теленнән, гореф-гадәтләреннән, милли моңнардан аерылып, үз халкыннан читләшүгә дучар ителә. Әле әти-әнисе бер милләттән булып, тирә-юньдә милли мохит булса, балада милли хис бөтенләй үк югалмый. Ә инде гаилә катнаш булган очракта нәтижәләр күпкә аянычлы. Кагыйдә буларак, аларда татар балалары үсми, кызганыч ки, үз милләтенә каршы рухта тәрбияләнгәннәре дә житәрлек була. Кызларыбызның — 44, егетләребезнең 42 проценты катнаш гаилә корганын исәпкә алсак, бу күренешнең никадәр куркыныч икәнен аңларбыз. Уйланыйк, дуслар, уйланыйк, сөекле кызларыбыз, хөрмәтле егетләребез, гаилә корганда уйланыгыз! Безне катнаш гаиләләр куркытмый, безне катнаш гаиләләрнең милләтебезне бетерүгә китерүе куркыта.

Бүгенге тәрбия системасы асылда урыслаштыруга корылган. Шушы афәттән котылу өчен, безгә аналарыбызны башта мөмкин кадәр эштән азат итеп, йорт учагын саклау, бала тәрбияләүгә юнәлтергә кирәк. Балалар бакчалары булган сурәттә дә, баланың теле ана телендә ачылырга тиеш, ул башлангыч белемне ана телендә генә алырга, үз халкының гореф-гадәтләрен, үз мәдәниятен үзләштереп, үз рухи дөньясында үсәргә тиеш. Шуңа ирешкәч, ана башка телләрне, башка культураны үзләштерү жинелрәк һәм аның карашы да киңрәк, рухи дөньясы да баерак булыр. Моның өчен аталарның жаваплылыгы артуы зарур. Аңларга вакыт: безнең халыкка килгән иң зур фажигаләрнең берсе — аракы! Шушы яман чирдән котылу — милләтебез алдында торган иң житди бурычларның берсе, ул котылу, һичшиксез, гаилә ныгуга, балаларның дөрес тәрбияләнүенә, аларның рухи яктан бай булып, физик яктан чыныгып, таза булып үсүенә һәм, ахыр чиктә, милләтебезнең рухи янаруына китерәчәк.

Безнең милләт уңган, акыллы, эшчән һәм булдыклы. Кайсы гына өлкәдә аның мәшһүр шәхесләре юк?! Без шуның белән горурланып, унай сыйфатларыбызны саклап, үзебезнең алга тагы да зуррак таләпләр куярга тиешбез. Башка халыклар алдында үзебезнең тырышлыгыбыз, уңганлыгыбыз, тәвәккәллегебез белән аерылып торырга тиешбез. Без әйбәтрәк эшлик, балаларыбыз әйбәтрәк укысын, гаиләләребез татурак булсын, без матуррак ял итә белик — милли танылуга, хөрмәткә юл шушы гына.

## Үткәннәрдән гыйбрәт һәм киләчәккә бурычлар

1. Дәүләтебезне югалтуның төп сәбәбе — бердәмлек булмау. Бу — сабакларның иң ачысы.

2. Чита морзалардан, Шаһгалиләрдән башланган чит патшаларга сыену, аларга ярарга тырышып, илен дә, динен дә, телен дә алмаштыру күренеше зур фаҗигаләргә китерде. Кичәге житәкчеләребезнең дәүләтебезне торгызуга каршы чыгуы, аны Татарстан дип тә әйтәселәре килмәве шул ук сатылу күренешләренең дәвам итүен күрсәтә. Милли горурлыгыбызны югалтып барабыз — бу сабакларның иң куркынычы.

3. Рәсәйнең тышкы һәм эчке сәясәтен артык хуплап, диваналарча шуны тормышка ашырырга алыну күп күңелсезлекләргә, югалтуларга, аянычлы нәтиҗәләргә китерде. Монда татар улларының Урта Азиядә урыс революциясе ясап йөреп, андагы төрки кардәшләребезнең нәфрәтен алуны да, Әфганстанда артык «тырышып», андагы мөселман кардәшләребезнең каргышын татуны да һич онытырга ярамый. Ә инде Мәскәү сәясәтен хуплап, үзебез үк мәчет-мәдрәсәләребезне җимереп, мулла-мөгаллимнәребезне җәберләп, изге китапларыбызны юк итеп, күпме гөнаһ алдык. Ялгыштык. Без бөтен крестьяннарны каһәрләп колхозларга кертүендә дә, уңганнарны кулак дип сөргеннәргә сөргәндә дә бик тырыштык. Кабат ялгыштык. Оялабыз да, әмма соң инде. Ә каһәрләү органнарының күзе, колагы, җинаятьчел кулы булып НКВД юлларында күпме шымчылык кылдык, күпме язмышларны сындыруда турыдан-туры катнаштык. Гөнаһларын ничек юарбыз?

Шушы гыйбрәтләрне үзләштергән хәлдә, милләт буларак халкыбызны саклап калу, дәүләтебезне торгызу буенча бурычларыбыз:

1. Безгә үз акылыбыз белән, үз кануннарыбыз буенча яшәп, мөстәкыйль сәясәт алып барырга кирәк. Рәсәйнең шикле сәясәтенә аек акыл белән карарга өйрәник!

2. Теләсә нинди авантюристларга ышанудан туктап, сыналган үз кешеләребезгә ышаныйк. Аларга таләпләребезне дә куйыйк, булышыйк та.

3. Сакланасыбыз килсә, без таркалмыйк, үзебезнең Идел-Уралыбызга җыелыйк.

4. Хөрмәт яулыйсыбыз килсә, безгә сатылу, алдану, эчү, ялкаулык, җинаятьчелек кебек сыйфатлардан арынып, сафлыкка, хезмәткә, белемгә бирелеп, сүздә тору кебек асыл сыйфатны үзләштерергә кирәк.

5. Коллык, мескенлек психологиясеннән арынып, рухыбыз бөеклеген саклап, гадел, зур максатлар белән яшик!

6. Милләт буларак халкыбызны саклап калу өчен иң кирәкле сыйфат — милли горурлык. Телебезгә, динебезгә, гореф-гадәтләребезгә кайтып, милли хисләребезне яңартыйк, милли горурлыгыбызны саклыйк! Горур халык бервакытта да кол булмас.

7. Дәүләт торгызуның иң мөһим таләбе — ул бердәмлек. Бердәм булыйк! Фикердә, сүздә, гамәлдә бер булыйк, дуслар!

**Азат ЗЫЯТДИНОВ**
*1993-2013*

**Редакциядән:**

*Күптән түгел күренекле галимебез үзенең 75 яшьлек гомер бәйрәмен билгеләп үтте. Аны бу бәйрәме белән ихлас котлыйбыз, исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез!*

# БЕРЕНЧЕ БӨТЕНДӨНЬЯ СУГЫШЫНДА АЛМАНИЯДӘ МӨСЕЛМАН ӘСИРЛӘРЕ

## 2. Алманиядә лагерь тормышы

1914 елнын 11 ноябрендә төрек солтаны Антанта илләренә җиһад игълан итә — димәк, барлык мөселманнар өчен шактый катлаулы һәм четерекле проблема килеп чыга: бу өндәүгә иярергәме, юкмы? Әгәр дә солтан — хәлифә, ягъни барлык дөнья мөселманнарынын рухи башлыгы икән, ияру мәҗбүри дә шикелле. Ләкин ватандашлык, үз туган иленне яклау мәсьәләсе дә бар... Бераз алга китсәк тә, шунсын әйтик — җиһад игълан итү бөтен мөселман дөньясын кузгатып, мөселманнарны Антанта илләренә каршы көрәшкә күтәрә алмаган.

«Җиһад» игълан ителүе үзенә күрә бер спектакльгә әверелгән. Аны мөселманнар тарафыннан «рәсмиләштерү» өчен, Алмания әсирлегендә булган 14 кешене (кара тәнле Тунис, Марокко, Алжир мөселманнарыннан) Госманлы империясе башкаласына китерталәр. Алман дипломатлары җитәкчелегендә алар мажаралы рәвештә Истанбулга килеп җитә һәм 14 ноябрь көнне оештырылган тантанада катнаша.

Башта Фатиха мәчетендә шәйхелислам (Госманлы дәүләтенен ин югары рухание) җыелган халыкка биш өлештән торган фәтва укыган. Бу фәтвада солтан игълан иткән «җиһад» куәтләнә һәм хуплана, мөселманнарнын төп дошманнары итеп Англия, Франция, Русия, Сербия һәм Черногория, ә дуслары итеп Алмания һәм Австро-Венгрия атала, ләкин җиһад барлык христианнарга каршы алып барылырга тиеш булмаган, бу дәүләтләрнен хөкүмәтләре мөселманнар башына килгән авырлыклар өчен җаваплы дип әйтелгән. Укылган фәтва тексты пропаганда максатларыннан чыгып сонра башка телләргә дә, шул исәптән рус һәм татар телләренә дә тәрҗемә ителеп басылган һәм таратылган.

Фәтва укылганнан сон, җыелган халыкка анын максатларын анлатып, солтан Мәхмәт Рәшат һәм Госманлы дәүләтенен хәрби министры Әнвәр паша чыгыш ясаган. Тантана шәһәр урамнарына күчкән — башта чарада катнашучылар Хәрби министрлык бинасына таба, ә аннан сон Алман илчелегенә юл тоткан. Илчелек балконыннан аларны җылы итеп алман илчесе фон Вангенһайм һәм экзотик кыяфәтле кара тәнле мөселман хәрби әсирләре сәламләгән. Әсирләрнен берсенә хәтта сүз дә бирелгән һәм алар хор белән берничә тапкыр: «Яшәсен солтан-халиф!» — дип кычкырган.

Сонра алман илчесе дулкынланып һәм тәэсирләнеп бу хакта үз җитәкчеләренә хәбәр иткән: «Гаҗәеп энтузиазм! Алмания һәм кайзер хөрмәтенә туктамас исәнлек теләкләре! Бер униформада булган француз әсире чыгыш ясаганнан сон, халык гаҗәеп дәрәҗәдә шатланды». Шулай итеп, спектакль унышлы узды дип санарга була. Сәяси «уен» башланып киткән.

Димәк, «җиһад» алып бару өчен идеологик нигез булдырылган, без исә татар хәрби әсирләренен язмышына җентеклебрәк күз салыйк.

Русия гаскәрендә хезмәт иткән мөселман солдатлары саны турында төгәл

*Дәвамы. Башы 2 нче санда.*

мәгълүматлар юк. Шулай да, кайбер тарихчылар исәпләвенчә, аларның саны 1 миллионга житкән булган. Татарлар, гомумән, Россия гаскәрендә иң зур христиан булмаган төркемне тәшкил иткән, асылда хезмәткә алынган мөселманнарның күпчелеге безнең милләттәш булган, чөнки Кавказ һәм Урта Азия халыклары армиягә алынмаган.

Алман әсирлегенә төшкән татарларның санын атау тагын да авыррак, төгәл статистик саннар сакланмаган. Ләкин татарларның Алмания территориясендә кимендә 100 әсирләр лагеренда искә алынуы бу сан аз булмаган дип фаразларга мөмкинлек бирә. Әйткәнебезчә, шуларның бары тик икесе генә «махсус» яки «пропагандистик» лагерь дигән статус алган, алар үзенә күрә үрнәк булып торырга һәм Алманиянең ислам дөньясына карата дустанә мөнәсәбәттә икәнлеген расларга тиеш булган.



*Виноград тавы лагере. 1915 ел, май.*

Шунысы игътибарга лаек: сугышка кадәр, хәтта сугышның беренче айларында да алман житәкчелегендә мөселман әсирләрен аерым урында туплау планы әле формалашмаган. Бары тик кайбер дипломатлар тарафыннан мөселман әсирләренә карата жылырак мөгамәләдә торырга яисә аларны, рәсми рәвештә әсирлектән азат итеп, туган илләренә кайтарып жибәрергә дигән тәкъдимнәр яңгыраган. Шулай ук мөселманнарны, фронтка жибәреп, ватандашлары арасында уздырылырга тиешле пропаганда чараларында куллану мөмкинлеге турында хыялланучылар да килеп чыккан. Димәк, без бер мөһим үзенчәлекне искә ала алабыз — сугыш алдыннан Алмания үзен мөселман дөньясының дусты итеп күрсәтергә бик теләсә дә, сугыш башлангач, әсирләр белән конкрет эш алып бару планы тиз генә оешмый.

Ниһаять, инде искә алынган Макс фон Оппенһайм 1914 елның 14 сентябрь язмасында Тышкы эшләр министрлыгына мөрәжәгать язып жибәрә — бу документта сүз беренче тапкыр мөселман хәрби әсирләрен аерым урыннарга туплау турында бара. Дипломат әсирләрнең гомум санын барларга, сонра Берлинга якын берәр урында аларны жыярга, әзерлекле белгечләр аркылы алар арасында пропаганда эшен оештырырга һәм, ахыр чиктә, пропаганда максатында әсирлектән азат итәргә яки бер өлешен инглизләргә каршы көрәштә кулланырга тәкъдим итә. Тора-бара фон Оппенһаймның фикерләре тагын да конкретлаша (аларны беренче мәкаләмдә искә алган идем инде) — 1914 ел ахырына алман хәрби һәм сәяси житәкчелеге дә бу чараларны зарур дип таба башлый һәм «махсус» лагерьлар барлыкка килә. Зур дәүләтнең башка бер диндәге әсирләрне аерып, үз файдасына тәрбияләп, хәрби дошманнарга каршы көрәштә катнаштырырга омтылышы — сугышлар тарихында беренче тапкыр шундый эксперимент уздырыла. Ни гажәп, үзе мөселман динендә булмаган дәүләт ислам динен сугыш алып бару өчен идеологик һәм сәяси корал итеп сайлый. Шулай да «махсус» лагерьлар оештыру Алманиянең сугышка кадәр барлыкка килгән ислам стратегиясенең мантыйкый дәвамы булып бәяләнә ала.

1914 елның декабрь башында мөселман әсирләре өчен конкрет урын да сайлана — Генераль штабның сәяси бүлеге житәкчесе Рудольф Надольны алар өчен яңа лагерь төзү ихтыяжы юк, әсирләрне инде элгәрәк оешкан Цоссен лагерена тупларга кирәк, дип исәпли. Димәк, 1914 ел ахырыннан башлап алман житәкчелеге максатчан рәвештә мөселман хәрби әсирләре турында статистик мәгълүматлар туплый һәм

шуларның күбесен Цоссен лагерена күчерә башлый. Дөрес, эш шактый озакка сузыла, чөнки алманнарның мона кадәр андый тәҗрибәсе булмаган әле. Гади башкаручылар да мондый күчерүләрнең мәгънәсен тулысынча аңлап бетермәгән ахрысы. Әсирләрне күпләп күчерүне тоткарлаган тагын бер фактор — 1915 ел башында холера эпидемиясе, зур-зур әсир төркемнәрен Алмания территориясе буйлап күчерү, һичшиксез, чирнең таралу куркынычын тудырган. Шулай да, мәсәлән, 1915 елның февраль мәгълүматларына караганда, якынча 9 мең татар, 3 мең 200 француз (Төньяк Африкадан) әсире тиз арада Цоссенга җибәрелергә тиеш булган.


*Лагерьдагы татар хәрби әсирләре, 1915 ел.*

1915 елның мартыннан документларда инде ике «махсус» лагерь искә алына башлый: Цоссенның мәйданы тар булганга күрәдер инде, аның янәшәсендә тагын бер лагерь төзелә. Яңа төзелгән лагерь Вюнсдорф шәһәренә якынрак була, аны — Ярым Ай лагере (Halbmondlager), ә Цоссенга якынрак лагерьны Виноград Тавы лагере (Weinberglager) дип атый башлыйлар. Беренче лагерьда шушы вакыттан башлап француз һәм инглиз гаскәрләреннән әсирләр — гарәпләр, һиндлар, Африка халыклары вәкилләре, икенчесендә рус гаскәрендә хезмәт иткән татарлар һәм өлешчә башкортлар җыела. 1916 ел башында бу ике лагерьда тупланган әсирләрнең саны үзенең максимумына җитә — Ярым Ай лагеренда 4 мең әсир булса, Виноград тавы лагеренда татарларның саны 12 меңнән арта. Инде әйткәнемчә, күпсанлы татар әсирләре Алмания территориясендә башка лагерьларда да урнаштырылган. Бу «махсус» пропагандистик лагерьлар турында мәгълүматлар күбрәк сакланганга күрә, аларны өйрәнү чагыштырмача җиңелрәк, ләкин башка урыннарда әсирлек авырлыкларын кичерергә мәҗбүр булган милләттәшләребез язмышын да онытырга ярамый. 12 мең татар — ул барлык татар әсирләренең кечкенә бер өлеше генә. Сүз чыккач, бер мөһим мисал китерәм. Алманиянең көньягында, Баварияда, Пухһайм шәһәрендә оештырылган лагерьда Беренче Бөтендөнья сугышы ахырында 24 меңнән артык әсир булганлыгы билгеле, шуларның 14 мене — рус гаскәреннән (күпмесе татар икәнлеге әлегә билгесез). Бүгенге көнгә кадәр алманнар бу шәһәрдә хәрби әсирләр зиратын саклап килә — зиратта рәсми саннар буенча 321 Русия солдаты җирләнгән, шуларның берничә дистәсе — татарлар (күпчелеге — 1918 елда «испанка» (грипп) эпидемиясе корбаннары). Зиратта һаман да 1919 елның ноябрендә татар әсирләре исталегенә куелган кабер ташы тора... Бик тә гыйбрәтле хәл бу, тарихка шулай ихтирам белән дә карап була икән: күпме үзгәрешләр, сугышлар булып узды алман җирендә, ә һәйкәл һаман да тора...

Инде безнең «махсус» лагерьларга әйләнеп кайтыйк. Алар «махсус» дип аталсалар да, бирелә булачак «җиһад»та потенциаль катнашучылар «тәрбияләнергә» тиеш булса да, әсирләр, әлбәттә, санаторийда яшәмәгән — әсир статусыннан азат ителмәгән. Аларның лагерь тормышы һәм халәте башка әсирләрнекеннән принципиаль аерылып тормаган, алар катгый контроль астында тоткын булып калган, туган илләрен, туган якларын өзелеп сагынган һәм әсирлектән котылуны иң зур бәхет дип күргән.

Әсирләр бу лагерьларда җылытылган агач баракларда тотылган, үз униформалары булган. Лагерь эчендә барлык әсирләр аерым батальоннарга бүленгән, батальон башында алман офицерлары торган. Алар, әлбәттә, татар телен белмәгән, шуңа

күрә лагерьда күпсанлы тәрҗемәчеләр хезмәт иткән (руслар, яһүдләр яки алман-колонистлары). Рәсми рәвештә һәрбер батальонга 2 мең әсир керергә тиеш булган, ләкин чынбарлыкта батальоннарның зурлыгы 1 мең кешедән артмаган. Виноград тавы лагеренда һәрберсе дүрт ротага бүленгән 10 батальон булган.

Әсирләрне азык-төлек белән тәэмин итү башка лагерьлар белән чагыштырганда яхшырак булган, мәсәлән, көненә һәрбер әсиргә 300 грамм икмәк бүлеп бирелгән. Ашау ягы артык мул яки бик төрле булмаса да, кайвакыт әсирләр азык-төлек кытлыгына зарлансалар да, сугыш вакытында ачка тилмермәгәннәр.



*Цоссен шәһәрендә татар әсирләре эшләгән урам күрсәткечe.*

Әлбәттә, сугыш барышында шартлар үзгәргән, хәрби-сәяси вазгыять авыраюга азык-төлек белән тәэмин итүдә кыенлыклар күзәтелә башлаган: әсирләрнең көнлек икмәк нормасы инде 230 грамм белән чикләнгән. Гадәти нормадан тыш, сирәк булса да, татар әсирләре арасында Англия һәм Франция хөкүмәтләре үз әсирләре өчен җибәргән азык-төлек тә таратылган, бу — консервылар, шикәр, сохари, чәй. Әсирләр хокуклары турында кабул ителгән халыкара конвенцияләр нигезендә, алар туганнарыннан да хат яки посылка ала алган, шикәр, чәй, сохари, сабын кебек бу гади посылкалар әсирләрнең хәлләрен жинеләйткән. Зур дини бәйрәм көннәрендә (Корбан һәм Ураза бәйрәмнәрендә) Алмания Хәрби министрлыгы тарафыннан мөселман әсирләре арасында өстәмә азык-төлек бүленгән: чәй, шикәр, тәмәке һәм, әлбәттә, корбан чалу өчен сарык тәкәләре.

Кайбер төгәл саннар нигезендә, әсирләрнең азык-төлек белән ничек тәэмин ителүен күз алдына китереп була. 1918 елның 30 сентябрендә лагерь коменданты татар әсирләре арасында түбәндәге азык-төлек таратылуы турында хәбәр иткән: 2812 банка ит консервысы, 296 банка яшелчә консервысы, 1070 фунт сохари (1 фунт — якынча 450 грамм), 2120 фунт шикәр, 240 пакет чәй, 50 фунт чәй һәм 1748 кисәк сабын.

Санитария эше ике «махсус» лагерьда чагыштырмача яхшы оештырылган булган — һәрберсендә лазаретлар, юыну һәм дезинфекция бараклары ачылган. Әсирләргә медицина хезмәтен рус фельдшерлары һәм санитарлары күрсәткән, чөнки мөселманнар арасында әзерлекле кадрлар житмәгән.

Әсирләргә карата мөгамәләдә алманнар үзләрен, һичшиксез, бик гамәли халык икәннәрен тагын бер кат исбатлый: алар мөселманнарны «җиһад» өчен әзерләргә дә омтылган, һәм шул ук мөселманнар төрле эшләрдә дә катнашкан — алар бит барыбер әсир булып калган, димәк, аларны төрлечә файдаланырга мөмкин булган. Шулай итеп, «махсус» лагерьларда тупланган татарлар башка яктан да алман халкы тормышы белән таныша башлаган — аларны лагерьдан төркем-төркем алып китеп, күбрәк авыл хуҗалыгында эшләткәннәр. Гадәттә, әсирләрне аерым алман фермерлары хуҗалыкларына беркеткәннәр — фермер файдасына эшләгәннәрне хуҗа кеше үз исәбенә ашата торган булган. Бу эшләрдә катнашу инде лагерь оешудан ук башланып киткән — көн саен 3 мең кеше шундый хезмәткә җибәрелгән. Әлбәттә, житәкчелек мондый хәлнең пропаганда эшенә комачаулаганын аңлаган, ләкин, күрәсең, Алманиядәге тормыш белән танышу да үзенә күрә пропаганда чарасы икәнлеген исәпкә алган.

Ләкин кайбер әсирләр мондый эштән азат ителгән. Әгәр дә әсир турыдан-туры «җиһад»та катнашырга әзерлеген белгертсә, лагерьда оештырылган нинди дә булса курсларда катнашса, андый кешене алманнар үз эшләре өчен файдалы дип

тапкан һәм башка эштән азат иткән. Лагерьдагы вазгыятьне төгәлрәк күз алдына бастыра торган саннарны да китереп була — аларны 1916 елның мартында лагерь мәчетендә имам булган күренекле татар рухание Габдерәшит Ибраһим хәбәр иткән. Аның исәпләвенчә, мәсәлән, «җиһад»та катнашырга бер меннән артык мөселман теләк белдергән, 180 әсир курсларга йөргән, ә 6 меңгә якын кеше «пропаганданы кабул итәргә әзер» дип аталган. Авыруларны һәм яраланганнарны исәпкә алсак, калганнары — якынча 3 мең кеше — лагерьдан эшкә җибәрелергә, ә 2 мең кеше лагерь территориясендәге эшләрдә катнашырга мөмкин, дип язган Габдерәшит хәзрәт.

Бу саннар сугыш ахырына тагын да арткан — инде 1917 ел языннан башлап ун мең татар әсире көн саен лагерьдан читтә эшләгән.


*Виноград тавы лагеренда агач эшкәрту остаханәсе.*

Ләкин кулыннан эш килгән әсирләр өчен лагерьның үзендә дә шактый үзенчәлекле шартлар тудырылган, төрле остаханәләрдә әсирләр хәтта тормыш алып бару өчен бераз акча да эшли алган. Бигрәк тә лагерьның агач эшкәртә торган остаханәсендә алар гаҗәеп зәвык белән агачтан төрле нәрсәләр житештергән. Бу — уенчыклар, кечкенә тартмачыклар, сувенирлар һәм бигрәк тә заказ буенча ясалган урам күрсәткечләре. Әлеге урам күрсәткечләре шундый кабатланмас стильдә башкарылган ки, хәтта саф алман дәүләт символикасына да безнең күнелгә якын татар үсемлек орнаменты кушылган.

Сугыш елларында тирә-як шәһәрләрдә, хәтта Берлин урамнарында да ул күрсәткечләрне күреп булган. Ошбу остаханәдә матур фотолар төшергән алман офицеры Отто Штиль татар осталары турында болай дип язган: «Бу рус кабиләләре вәкилләре хәтердән генә агачтан йорт хайваннарын, бигрәк тә кошларны, шундый таң калдырырлык төгәллек белән башкаралар ки, алар теп-тере кебек булып чыгалар». О.Штиль тәкъдиме белән боларның иң матур үрнәкләре махсус күргәзмәдә күрсәтелгән, күбрәк өлеше исә сатылган.

Сакланып калган документлардан без әсирләрнең башка эшләре турында да беләалабыз, мәсәлән, 1916 елның мартында лагерьның агач остаханәсендә 26 кеше эшләгән, аяк киеме тегү белән 64 әсир шөгыльләнгән, иң күп кеше, әлбәттә, ашханәдә мәшгуль булган — (200 кеше), әсирләр арасында юл төзәтүчеләр (10), бакчачылар (30), калайчылар (7), пыялачылар (2), хәтта күсе тотучылар (2) искә алына. 33 кеше янгын сүндерүче командада исәпләнгән, 40 әсир ашханәдә бәрәнге әрчүдә ярдәм күрсәткән.

Әсирләр җомга, якшәмбе һәм дини бәйрәм (Ураза, Корбан бәйрәмнәре, Гашура һәм Мәүлид) көннәрендә дә эшләрдән азат ителгән. Ләкин мондый «ирекле» график 1916 ел уртасында үзгәртелгән — җомга көннәрен дә әсирләр эшли башлаган, ләкин аларга көн уртасында намаз кылу өчен сәгать ярым вакыт бирелгән.

Лагерьның үзендә һәм аннан читтә башкарылган эш өчен әсирләр хәтта эш хакы да алып торган. Ул, әлбәттә, зур булмаган, әмма үзенчә тормыш алып бару өчен, кирәк-ярак алгаларга ярап торган. Дөрес, рәсми акча куллану әсирләргә рөхсәт ителмәгән — ул лагерьның үзендә бастырылган «махсус акча» булган — 1, 2, 3, 5, 10, 20 маркалык купюралар. Бу акчага әсирләр, мәсәлән, лагерь буфетында колбаса,

төрле эчемлекләр яки тәмәке ала алган. Эчемлекләр арасында иң популяры баллы, алкогольсез «Энгелһардт» сырасы булган.

Төрле эшләрдә катнашып, татар әсирләре, күрәсең, алманнарда бик уңай тәэсир калдырган — лагерь офицерлары да, фермерлар да аларның тырышлыкларын югары бәяләп торган. Бәлки шул нигездә, инде 1917 ел башында кайбер рәсми вәкилләрдә хәтта шундый бер фантастик план да барлыкка килгән: 200-300 әсирне азат итеп, алман җирендә «татар колониясе» оештырып җибәрергә. Бу колония үзенә күрә «алман мәдәнияттен тарату чыганагы» булып күренгән аларга. План бөтенләй нигезсез булмаган, рәсми оешмаларда ул җентекләп өйрәнелгән — җитәкчеләрнең берсе аны «Алманиянең ислам диненә карата җылы мөнәсәбәтен раслау» өчен файдалы дип, икенчесе, татарларны тагын да ныграк Алмания белән бәйләү өчен аларга Русиядән хатыннарын чакыртырга рөхсәт итәргә кирәк дип тапкан. Габдерәшит Ибраһимнан соң имам вазифасын үтәгән Галимҗан Идрисине исә бу план тәмам рухландырган: 1917 ел башында ул Хәрби министрлыкка шул хакта хат язган һәм «колония» булдыруның төп шартларын санап чыккан: 1. «Татар колониясен» сазлыксыз, корырак урында төзергә. 2. Колонист гаиләләрен Русиядән чакыртырга, 3. Рейхстаг ислам динен Алманиядә рәсми танылган дин дип игълан итәргә тиеш, 4. Колониягә имам билгеләргә, 5. Колониядә 4-6 класслык башлангыч мәктәп ачарга һәм мәктәпкә татар укытучыларын чакыртырга.



*Пухһайм шәһәре зиратында татар әсирләре истәлегенә куелган кабер ташы (бүгенге күренеше).*

Татар колониясенең киләчәге хакында 1917 елның апреленә кадәр җанлы гына сөйләшүләр алып барылуы, ләкин моның тәгаен нәтиҗәгә китермәгәнлеге билгеле. Шулай да бу — Беренче Бөтендөнья сугышы вакытында алманнарның татарларга нинди мөнәсәбәттә булганлыгын күрсәтә торган бик үзенчәлекле факт.

*Дәвамы киләсе саннарда.*

**Искәндәр ГЫЙЛӘҖЕВ,**
*тарих фәннәре докторы, профессор.*

# ВАХИТ ИМАМОВ ИҖАТЫНДА ТАТАР ТАРИХЫ

**Вахит Имамовка 60 яшь**



Элегрәк чыккан бер мәкаләмдә: «Тарихи романнарны бик яратып һәм кызыксынып укыйм», — дип язганмын икән. Алай ук түгел. Әйе, барысын да диярлек укып барам, әмма... юк, яратып укыйм дип әйтү дөрес үк булмас. Моның сәбәпләре төрле. Теге яки бу язучы тарихи вакыйгаларны, шәхесләрне фәнни яктан ни дәрәҗәдә дөрес итеп тасвирлаган һәм, иң мөһиме, әсәр сәнгатьчә эшләнеше ягыннан ни дәрәҗәдә камил вә мөкәммәл — тарихчы-галим һәм гади укучы буларак, иң әүвәл мин шул нәрсәләргә игътибар итәм. Менә шул «нәрсәләр» төрле язучыда төрлечә һәм ул, табигый ки, шулай булырга тиеш тә. Тарихны мин үземчә күзаллыйм, ә язучылар исә әнә шул без күнеккән стереотип карашларны җиңел генә җимерәләр дә куялар. Кайвакыт күңелдә ризасызлык туа. Югары сәнгатьчәнлек күзлегеннән караганда, миңа калса, «тарихи» дип аталмаган жанрларда иҗат итүче язучыларның әсәрләре күпкә отышлырак. Ә мин андый әсәрләрне дә барыбер тарихчы-галим күзлегеннән карап укыйм һәм ихлас ләззәтләнү хисләре кичерәм. Тарих дәреслекләрен укып кына, әби-бабаларыбыз сөйләгәннәрдән чыгып кына халкыбыз тарихын бөтен тулылыгы, нечкәлекләре белән аңлап булмый. Халкыбыз тарихы ул — Галимҗан Ибраһимов, Мәхмүт Галәү, Шәриф Камал, Кави Нәҗми, Гомәр Бәширов, Әмирхан Еники, Аяз Гыйләҗев, Мөхәммәт Мәһдиев, Туфан Миңнуллин, Айдар Хәлим һәм башка бик күп әдипләребез иҗатында! Талантлы шагыйрьләребезнең шигырь-поэмаларында гына түгел, хәтта лирикада да тарих чагыла! Мөхәммәт Мирзаның: «Безнең буын кешеләре өчен әдәбият хак тарихыбызның бердәнбер дөрес чыганагы буларак кабул ителә», — дигән сүзләрендә *(«Мәйдан», 2011, №1, 40 б.)* тирән мәгънә ята.

Тарихи романнар, әйе, языла тора. Нурихан Фәттах, Мөсәгыйт Хәбибуллин, Җәмит Рәхимов, Флүс Латыйфи, Рабит Батулла, Солтан Шәмси, Фәүзия Бәйрәмова, Факил Сафин, Ркаил Зәйдулла, Равил Вәлиевнең төрле елларда дөнья күргән әсәрләрен укучылар яратып укый. Мин моңа бик шатланам, чөнки без, язучылар һәм тарихчы-галимнәр, бер үк эш — изге эш! — эшлибез. Аның асылы — хәзерге заман татар укучысында, беренче чиратта, яшь буында, халкыбызның шанлы үткәне һәм бүгенге уңышлары мисалында горурлык хисләре тәрбияләү. Татар угылы татармын! Менә шул горурлык хисе булмаса, бөтен галәмгә һәм гавәмгә глобальләшеп бетү

куркынычы янаган бер заманда, татарның милләт булып сакланып калу мөмкинлеге югалачак. Яшь буынга милли тәрбия бирү өлкәсендә безгә, бигрәк тә әдәбият һәм сәнгать әһелләренә, бик күп тырышырга, максатчан һәм җиң сызганып эшләргә кирәк. Кызганыч, бу эштән, милли мәгарифне үстерү турында күп сөйләсәләр дә, мәктәпне һәм югары уку йортларын аңлы рәвештә һаман читләштерә баралар.

Шактый озын керештән соң, 1980 еллар башында кыю рәвештә әдәбият дөньясына килеп кергән талантлы язучыбыз Вахит Имамов иҗатына күчик әле. Кызганыч, мин аның үзе, гаиләсе турында бик аз беләм. Чыгышы белән Актаныш районының Иске Байсар авылыннан ул. 1954 елның 18 мартында туган. Урта мәктәпне тәмамлаганнан соң, ике ел чамасы Казан моторлар төзү заводында эшләп ала һәм 1973 елда университетның журналистика бүлегенә укырга керә. Тагын ике елдан укуын читтән торып, бер үк вакытта Балык Бистәсе районы газетасында эшләп дәвам итәргә карар кыла. Армиядә хезмәт итеп кайта. 1982 елдан Вахит Имамов Чаллы шәһәрендә. Башта ул урта мәктәптә тарих фәне укыта, аннан соң КамАЗның пресс-рам заводында мастер, участок башлыгы, өлкән диспетчер булып эшли. 1990 елда «КамАЗ» типографиясе нигезендә газета-китап нәшрияты оештырып, шунда баш мөхәррир вазифасын башкара. 1997 елдан бирле Вахит Имамов Татарстан Язучылар берлегенең Чаллы бүлеген җитәкли, 2005 елдан «Мәйдан» журналының баш мөхәррире. Менә шушы кыска гына рәсми белешмә язучы иҗатын характерлый торган «киң колачлы» дигән билгеләмәнең серен ача да сала, минемчә. Тормыш юлы урта мәктәп тәмамлап, университетта белем алу һәм газета-журнал редакцияләрендә эшләү чорларын гына «кочып алган» язучыдан бүгенге заман тормышын чагылдырган күләмле эпик әсәрләр таләп итү урынсыз. Вахит Имамов исә тормышны тирәнтен белә, яшәү дәверендә, гади эшче һәм мәктәп укытучысы рәвешендә дә, журналист һәм язучы буларак та, төрле социаль катлау кешеләре арасында кайнаган, татар дөньясын бөтен катлаулылыгы, каршылыклары белән аңлый һәм боларның барысын да, сәнгатьчә эшкәртеп, үзенең иҗатында чагылдырырга тырыша.

Алып карагыз аның Татарстан китап нәшрияты чыгарган «Ир канаты» (1988), «Нәзер» (1991) исемле китапларында туплап бирелгән повесть-хикәяләрен, «Аргамак» журналының беренче номерын ачып җибәргән «Кәнәфи» повестен. Таныш вакыйгалар, таныш геройлар — барысы да тормышның үзеннән алынган, берсе дә язучы фантазиясе түгел. Шунадыр күрәсең, укучы аларны яратып кабул итте, кулдан кулга йөртеп укыды. Язучының әхлак проблемаларын күтәргән «Нәзер» повесте һәм «Өмет» хикәясе исә Татарстан телестудиясе төшергән һәм күп тапкырлар телевизор экраннарыннан күрсәтелгән кыска метражлы нәфис фильмнарның сценарийлары өчен нигез булып хезмәт итте.

2001 елда Чаллыда дөнья күргән «Могикан» исемле китап язучының популярлыгын тагын да ныгытты, ул моңа кадәр беркем дә кул тидерергә җөрьәт итмәгән кискен мәсьәләләрне күтәрергә сәләтле кыю автор буларак танылды. Китапка исем биргән «Могикан» повесте күңелдә бигрәк тә нык уелып калган. Күрәсең, әлеге үземнең туган якларга бәйле (безнең авыл Чаллыдан 20 чакрымда гына), бер генә кешене дә тыныч калдыра алмый торган вакыйгалар турында булгангадыр. Әсәрнең үзәгенә, узган гасырның җитмешенче елларында гигант «КамАЗ» корпусларын торгызганда, түрәләрнең гафу ителмәслек саксызлыгы, гади халыкны санга сукмаулары аркасында искиткеч гүзәл табигатьнең, дистәләгән татар авылларының юкка чыга баруы, шул вәхшилеккә каршы тигезсез көрәш проблемасы куелган иде. Кызганыч, бу проблема безнең көннәрдә дә актуальлеген югалтмый.

Вахит Имамовның әлеге китабына урнаштырылган тагын бер әсәр укучының игътибарын җәлеп итә. Ул — «Исемең ничек, татар авылы?» дип аталган тарихи-топонимик очерк. Автор үзенең «Татар энциклопедик сүзлеген» укыгач туган фикерләре белән уртаклаша. Исемнәре бозылып, урыслашып беткән татар авыллары, елга-күл атамалары турында күңелсез статистика китерә. Әйе,

утырып уйлар уйларлык, ди автор, урыска ничек яраргa белмәгән татар түрәләре үз авылларының тарихи исемнәрен кайсы якка гына боргалап бетермәгән дә ничек кенә итеп үзгәртмәгән. Исемнәр дә татарлыгын югалта, урыслаша бара икән бит.

Вахит Имамовның заман таләпләренә сизгер, халык язмышына битараф булмаган, үткәннәрдән сабак алырга өндәүче тынгысыз автор булуын аның 1991 елда рус һәм татар телләрендә басылып чыккан «Әфган «кызалаклары» («Афганские «тюльпаны») дигән очерклар җыентыгы да ачык раслый. Биредә сүз, Чаллы төбәгеннән китеп, Әфганстан җирендә ятып калган фаҗигале сугыш корбаннары турында бара. Интернациональ бурычыбызны үтибез дип башланган «гадел» сугышның киләчәктә сабак алырлык аяныч нәтиҗәләре турында. Заманы өчен бик тә кирәк, укыла торган китап булып чыкты ул. Язучы туплап чыгарган материаллар республикабызның күп кенә мәктәпләрендә, мәдәният йортларында, китапханәләрдә, төбәк музейларында Әфган корбаннарына һәм сугышчыларына багышланган экспозицияләр ачарга этәргеч бирде. Шундый экспозицияләрнең берсен мин С.Рәфыйков исемендәге Зәй үзәк китапханәсе фойесында күрдем. Китапханә хезмәткәрләре сөйләвенчә, аның идеясе Вахит Имамов җыентыгын укыганнан соң туган.

Татар авылын күмәкләштерү тарихы белән бәйле вакыйгаларны рәсми фәндә кабул ителгәнчә түгел, бөтенләй янача, халкыбыз язмышында олы фаҗига буларак шәрехләгән «Тозлы яра» (Казан, 2004), егерменче йөз башларында туган якларын калдырып, чарасызлыктан Япониягә килеп төпләнгән татарлар тормышын реаль картиналарда ышанырлык итеп күрсәткән «Япун татары» (Чаллы, 2004) романнары да язучының уңышлы әсәрләреннән саналырга хаклы.

Табигый ки, югарыда санап үтелгән әсәрләр тәнкыйтьчеләр игътибарыннан читтә калмады. Алар бит, гадәттә, әдәбият дөньясында инде күптән үз юлын тапкан танылган язучыларның яисә яшь авторларның талантлы әсәрләре турында язарга ярата. Әдәбият бусагасына янарак кына аяк баскан Вахит Имамов иҗаты турында беренчеләрдән булып Гариф Ахуновның сүз башлавы үзе үк күп нәрсәләр турында сөйли. «Әдәбиятыбызга саллы прозаик килә!» — дип язды ул куанып үзенең бер мәкаләсендә *(«Мәйдан», 2002, №6, 168 б.)*. Аннан соң матбугатта бер-бер артлы Мөдәррис Вәлиев, Барлас Камалов, Марсель Галиев, Мөсәгыйт Хәбибуллин кебек олпат язучыларыбызның, әдәбият белгечләренең бәяләмәләре басылып чыкты. Вахит Имамовның күпкырлы, үзенчәлекле талант икәнлегенә басым ясап, аның тарихи әсәрләр язарга да сәләтле автор икәнлеген искәртеп үттеләр. Һәм ялгышмадылар.

Халкыбызның борынгы һәм урта гасырлар тарихы белән шөгыльләнүче галим буларак, аңлашыла ки, мине беренче нәүбәттә Вахит Имамовның тарихи романнары, тарихи-документаль әсәрләре, публицистикасы кызыксындыра. Аның бигрәк тә үзе җитәкләгән «Мәйдан» журналында — һәр санында диярлек! — басылып килә торган тарихи-публицистик язмалары ошый. Чөнки Вахит әфәнденең теге яки бу төбәк тарихына, шул төбәкнең тарихи шәхесләренә багышланган язмалары әр-яна, кайвакыт әле фәндә билгеле дә булмаган кызыклы мәгълүматлар белән тулган була. Ул чын тарихчы һәм күбрәк нәкъ менә тарихи әсәрләре белән әдәбиятта үз урынын яулады да инде.

Язучының иҗатын мин даими рәвештә 1993 елдан бирле күзәтеп барам. Шул елны аның атаклы тарихчыбыз Равил Әмирхан белән бергә язылган «Татарларның Ватан сугышы: XVI-XVIII гасырларда милли-азатлык яулары турында тарихи очерклар» китабы басылып чыкты. Йөз җитмеш меңлек тираж белән! 80 битлек китапчык, билләһи дип әйтәм, чын сенсация булды безнең өчен. Беренчедән, күпләрне аның «сәер» исеме шаккатырды, монарчы әле бер генә тарихчы да татарларның урыс хакимиятенә каршы алып барган милли көрәшен, восстаниеләрен «Ватан сугышы» дип атарга, ягъни дөресен язарга батырчылык итмәгән иде; икенчедән, халкыбыз тарих битләреннән төшеп кала язган каһарман бабаларыбызның кылган гамәлләре,

язмышлары белән танышырга мөмкинлек алды. Баксаң, алар гасырлар буена үзләренең борынгы дәүләтчелеген торгызу өчен армый-талмый көрәшкәннәр, кан түккәннәр икән. Тиешле органнар тарафыннан ничәмә-ничә еллар буена махсус яшерелеп яткан әлеге фактлар, ниһаять, халыкка барып ирешә. Китап, кулдан-кулга йөреп, тиз арада таралып та бетте. Республикабыз суверенитетын яклап күтәрелгән милли-азатлык хәрәкәтенең тагын да җанланып китүендә, мина калса, әлеге китапның роле зур булды.

Бер елдан соң Вахит Имамовның «Яшерелгән тарих» исемле тагын бер документаль әсәре дөнья күрде. Рус телендә һәм җәмгысе 400 мең тираж белән! Дөрес тарихка сусаган халык, бигрәк тә татар милли хәрәкәтендә катнашучы яшьләр, язучыга бик рәхмәтле иде. Тиз арада бу әсәрне мәктәп укытучылары тарих дәресләрендә өстәмә материал рәвешендә куллана башлады. Безгә аз таныш булган фактлар «Татарстан тарихыннан хикәяләр» дип аталган һәм ул елларда бик популяр мәктәп дәреслегенә дә кертеп җибәрелде.

Вахит Имамовны коеп куйган язучы сыйфатында гына түгел, тарихчы буларак та таный башладылар. Аны якыннанрак белүче каләмдәшләре һич тә гаҗәпләнмәде мона. Эшли торган заман килде, совет чорындагы кебек яңа фикерләргә киртә куючылар юк хәзер. Татар тарихында «ак таплар» күп — билгеле факт. Галимнәребез ул тапларны бетерергә ашкынып тормый. Нишлисең, үзенә тырышып карарга туры киләчәк. Һәм Вахит әнә шул «яшерелгән» тарихны — татарларның үз дәүләтчелеген торгызуга юнәлдерелгән милли-азатлык көрәшенә караган тарихны! — архивлардан эзли башлый. Мәскәү, Казан, Уфа, Оренбург, Уральск һәм башка шәһәрләрнең архивларында казынып, моңа кадәр галимнәр кулы тимәгән йөзләгән, меңләгән документлар таба. Шул чорга караган фәнни әдәбиятны җентекләп өйрәнә. Җитмәсә әле халык арасында таралган легенда-риваятьләрне җыеп бара, тел гыйлеменең ономастика (топонимика) һәм этимология дигән тармаклары белән тирән кызыксына. Әйе, Вахит Имамов беренчел чыганаклар белән эш итәргә ярата.

Күпьеллык хезмәтнең нәтиҗәсе язучының Пугачёв явы һәм анда катнашкан батыр бабаларыбыз язмышына багышланган «Сәет батыр» *(Чаллы: «КамАЗ», 1994, 512 б.)* һәм «Татар яугирләре» *(Казан: Мәгариф, 2003, 355 б.)* исемле күләмле әсәрләрендә бәян ителде. Беренчесенең тиражы — 90 мең данә! Ул китапны кулга алып укый башлагач туган тәэсирләремне, шатлану катыш шаккатуларымны әле һаман да хәтерлим. Мин генә шулай һушым китеп кабул итмәгәнмендер дип уйлыйм «Сәет батыр»ны. Никадәр яңалык алып килде ул укучыга?! Аксакал тарихчыбыз Сәлам Алишев китабын[1] да шулай сөенеп каршы алган идек заманында. «Каһарман бабайлар» (1976) китабында ул безгә Бәхтияр Канкаев, Мәсәгут Гомәрев, Каранай Моратов кебек герой-шәхесләребезне ачты. Әмма барыбер соңгы елларга кадәр Пугачёв яуларын без элеккечә, изелгән урыс крестьяннарының алпавытларга каршы сугышы рәвешендә генә күз алдына китерә идек. Алишевтан соң бу тема белән кызыксынучы булмады, XVIII йөз һәм аннан элгәрерәк чор тарихын өйрәнүчеләр аз, чөнки күбесенең тешләре үтми. Ә менә Вахит Имамов булдырды, югыйсә, фәнни дәрәҗәсе дә юк. Пугачёв отрядларында сугышучыларның яртысыннан артыграгы татарлар булган! Башкортларның Салават Юлае дәрәҗәсендәге татар каһарманнары, полковниклар, бригадирлар да берәү генә түгел, дистәләгән. Вахит моны документлар белән раслады.

Мин беләм: урта мәктәпнең тарих укытучылары бу китапларны дәреслеккә өстәмә уку ярдәмлеге рәвешендә дә, сыйныфтан тыш чаралар үткәргәндә дә бик теләп куллана. Матур һәм аңлаешлы тел белән язылган алар. Вахит Имамов әсәрләрен югары уку йорты студентлары — булачак тарихчылар да өйрәнә. Елмаеп-көлеп дигәндәй, үземнең мөгаллимлек тормышымнан бер кызыклы фактны искә төшереп

[1] Аның 1973 елда Татарстан китап нәшриятында чыккан «Татары Среднего Поволжья в пугачёвском восстании» исемле китабын күз алдында тотам.

үтим әле: өч-дүрт ел элек чыгарылыш курс студентының (дөрес, ул читтән торып белем алучы укытучы ханым иде) мина рецензияләргә биргән диплом эшендә ярылып яткан плагиатлык галәмәтләре күреп, «дөрес» билге куя алмыйча, авыр хәлдә калган идем. Бер бүлеген «Сәет батыр» китабындагы «Татарлар Пугачёв явында» исемле очерктан күчереп алынган мәгълүматлар белән тутырган да, авторын күрсәтмичә генә, фикерләрен үзенеке итеп тәкъдим иткән. Болай ярамаганлыгын аңлаттым, әлбәттә, әмма язучы өчен, ни генә димә, күнелле факт — файдаланалар ич хезмәтләреннән!

Ярый, хуш, хәзер инде Вахит Имамовның минем карашка иң уңышлы әсәрләреннән саналган «Казан дастаны» (2005) һәм «Утлы дала» *(2001, беренче китап; 2012, беренче һәм икенче китаплар)* тарихи романнарына күз салыйк. Алар язучының элгәреге әсәрләреннән нык аерылып тора. Сурәтләнгән вакыйгалар X-XIII йөзләргә, борынгы бабаларыбызның монгол яуларына кадәрге чорларына карый. «Утлы дала»ның элегрәк чыккан беренче китабына тотынырга куркып тордым. Әлбәттә инде, әсәрне тәнкыйтьче сыйфатында анализларга да атлыгып тормадым. Эш шунда ки, мина, археолог буларак, гомерем буе халкыбызның урта гасырларга караган бик тә катлаулы чорларын өйрәнергә туры килде. Болгар фәне дөньясында бүгенге көндә билгеле булган барлык язма чыганакларны беләм. Алай гына түгел, Вахит Имамов романнарында сурәтләнгән төп вакыйгаларның урыннарын — Биләр, Сувар, Җүкәтау, Алабуга, Казан, Кирмәнише калаларның барысын да җентекләп, казып-чокып өйрәндем. Кыскасы, без икебез дә бер үк чорны тасвирлыйбыз-өйрәнәбез, белгәннәребезне укучыга җиткерергә ашкынабыз: мин — галим буларак, фәнни хезмәтләремдә, Вахит дус — язучы буларак, «Казан дастаны»нда һәм «Утлы дала»да. Шул чор турында инде калыплашып өлгергән үз карашым бар, язучының — үзенеке. Менә шул карашлар, фән теле белән әйткәндә, концепцияләр, бер-берсенә тәнгәл килерме, Вахит Имамов дигән язучының ошбу әсәре канәгатьсезлек хисләре тудырмасмы, күнелемне кайтармасмы дигән сораулар мине гел борчып торды.

Әлеге әсәрләргә шикләнебрәк тотынуымның тагын бер сәбәбе бар иде. Ул — Нурихан Фәттах феномены. Яратам мин ул язучыны. Аның «Итил суы ака торур», «Сызгыра торган уклар» романнары, «Кол Гали» трагедиясе — классик әсәрләр. Тарихи чынбарлык (без белгән күләмдә) ул әсәрләрдә дөрес чагылдырылган, сәнгатьчә эшләнешләре ягыннан тел-теш тидергесез. Нурихан Фәттахтан соң килгән татар язучыларының тарихи жанрда иҗат ителгән әсәрләренә бәяне, ихтыярсыздан, мин әнә шул эталонны күз алдында тотып бирәм.

Вахит Имамов әсәрләре шул эталонга ни дәрәҗәдә туры килә? Хәзер инде курыкмыйча әйтә алам: тарихи вакыйгаларны, шул вакыйгаларда катнашучы персонажларны фәнни дөреслеккә туры китереп сәнгатьчә сурәтләү дәрәҗәсе ягыннан Вахит Имамов әсәрләре иң югары бәягә лаек!

«Утлы дала» романы турында язып чыккан идем инде *(«Мәйдан», 2002, №6, 193-199 б.; 2012, №8, 59-64 б.)*. Макталды да, тәнкыйть сүзләре дә әйтелде. Кабатлап тормыйм. Бәям шундый иде: «Титаник эш эшләнгән! Киң панорамалы, тарихи роман жанрының иң югары таләпләренә туры килерлек, укучыбыз күптән көткән һәм аңа бик кирәкле әсәр язылган».

«Казан дастаны» турында да бер-ике сүз әйтәсем килә. Вахит Имамов, әсәрен язарга утырганчы, эшне һәрвакыттагыча чыганаклардан башлый. Тарихи роман авторларының барысы да шулай эшли торгандыр дип беләм. Әнә, Нурихан Фәттах, романында тасвирланасы вакыйгаларны документлардан өйрәнә-өйрәнә, чын галим булып китә язды заманында. Вахит та шул чамада дип беләм (кандидатлык диссертациясе булса да якла инде ичмасам, дип үгетләүчеләр күп булган, ишетүемчә). Һәрхәлдә урыс елъязмаларын яттан белә кебек ул. Хәтта безнең археология материаллары белән дә таныш. Нәтиҗәдә, язган әсәре без белгән

чынбарлык кысаларыннан чыкмый. Чыганаклардан таныш тарихи вакыйгаларны, чамасын белеп кенә, уйлап чыгарылган мажаралы сюжетлар белән баета: бер укый башласаң, аерылып булмый китабыннан. «Казан дастаны»нда, мина калса, автор әнә шул мажаралы сюжетлар белән артык мавыга кебек. Китапны мин гадәттә кулга карандаш алып укыйм. Үземә кирәк урыннарны тамгалар белән билгеләп барам, кырга кыска гына итеп үз фикеремне дә язып куйгалыйм кайчакта. «Казан дастаны» битләрендә минем «ышандырмый» дигән репликам, сорау билгеләре «Утлы дала»га караганда күбрәк. Мондый гына нәрсәләргә укучы игътибар итми гадәттә. Шулай кирәктер дә, бәлки. Әмма кайбер принципиаль характердагы вакыйгалар турында сүз барганда, автор фантазиясенә артык ирек бирелмичә, тарихи дөреслектән ерак китмәскә тырышырга кирәк. Мәсәлән, Елантауда Казанга нигез салу күренеше. Язучы аны 985 елда Болгар иленә яу чапкан Киев кенәзе Владимир белән Ибраһим хан арасында солых килешүе төзелү вакыйгасына бәйләгән. Ибраһим хан булачак каланың беренче казыгын кага:

– Меньяшәр кала булырга язсын инде берүк!

– Уртак кала булсын! — дип, чак-чак кына ишетелерлек итеп пышылдады бер як читтә турсаеп торган кенәз.

Бу эпизодны тарихи дөреслеккә туры килә дип булмый инде. Казанны без Елантауда (Казансу елгасы тамагында) түгел, хәзерге Кремль калкулыгында нигезләнгән дип расладык ич. Һәм 985 елда түгел, унберенче йөз башында. Ә инде бу мөһим вакыйгага болгарларны таларга килгән урыс кенәзен китереп кушуны аңлый да, аңлата да алмыйм.

Әйтергә теләгән тагын бер фикерем бар. Вахит Имамовның тарихи романнарын укып, болгар бабаларыбызның өч гасырдан артык вакытка сыйган чын тарихын өйрәнергә була. Дәреслекләр, фәнни хезмәтләр укыгандагы кебек үз-үзеңне мәҗбүр итеп түгел, ә язучының матур тел белән язылган, югары сәнгать кануннарына туры килә торган талантлы әсәрләрен укудан ләззәт алып. Кызганыч, мәктәп балаларын ул китапларны укудан тыярга мәҗбүрләр. Сәбәбен китап битләренә карандашым белән төртеп куйган сүзләрдән аңларга була: «Эротика!», «+16». Бу нәрсәләр белән артык мавыгуны заман шаукымы дип аңларгадыр инде. Кирәк микән?

Вахит Имамов — беркемгә дә охшамаган һәм охшарга да тырышмаган, күп санлы китаплары, иң әүвәл тарихи романнары белән бөтен татар дөньясына танылган олпат язучыбыз. Үзенең 60 яшьлек юбилеен ул иҗатының иң югары ноктасына җитеп каршылый. Шулай да без аннан тагын да саллырак әсәрләр өмет итеп калабыз (иң әйбәт әсәрләрем әле язылмаган, дип әйтергә яраталар ич язучылар). Потенциаль мөмкинлекләре бик зур аның. Исәнлек-саулык һәм яңа иҗат уңышлары теләп калабыз Сиңа, Вахит дус!

**Фаяз ХУҖИН,**
*Татарстан Фәннәр академиясе мөхбир әгъзасы,*
*тарих фәннәре докторы*

Фирдәвес Гарипова

# АВЫЛЛАРЫБЫЗ ТАРИХЫ

### Нөнәгәр

Нөнәгәр авылы Балтач районында, район үзәгеннән — 34, тимер юл станциясе Шәмәрдәннән — 46, Малмыж шәһәреннән 23 чакрым ераклыкта урнашкан.

Өлкәннәр сөйләвенә караганда, Нөнәгәр авылы моннан 450-500 еллар элек барлыкка килгән. Авыл табигатьнең матур бер җиренә утырган. Авыл янышнан Кугубор елгасы ага. Аргы ягында кин болын, аннан соң биек булмаган таулар башлана.

Авыл башта Нуринер дип йөртелгән икән, соңыннан гына Нөнәгәр дип үзгәргән. Авылның исеме марицадан алынган, ул исем авылның урнашкан урынына карап бирелгән. Нуринер «уйсу җир» дигәнне аңлата. Авылга иң беренче булып марилар килеп Сәлия суы буйлап уң якка утырганнар. Тора-бара Кугубор суының уң як ярына татарлар килеп урнашкан.

Революциягә кадәр авылда күпчелек крестьяннар ярлы булган, салам түбәле, җимерелергә торган йортларда яшәгәннәр. Хуҗалыкларда сыерлар аз булган, күпчелеге кәҗә һәм сарык асраган. Халыкның имана җирен сөрергә атлары да булмаган.

Авылда 1917 елда яшьләр оешмасы төзелгән, дип сөйлиләр. 1918 елда авылга укытучы килә. Яшь активистлар арасында алты хатын-кыз була: Сара Сабитова, Мәдинә Галиева, Хәтимә Гайнетдинова, Мәйсәвәр Шәрипова, Хәбибә Шакирова, Гыйльми Фәхретдиновалар.

Авылдан акларга каршы сугышка Гариф Шакиров, Фәрит Гайнетдинов, Фәтхелкадыйр Гарипов китә. Фәтхелкадыйр Гарипов Мәскәүдә В.И.Ленинны күрә. 1930 елларда Фәтхелкадыйр абзый авыл советы башкарма комитеты рәисе булып эшли. 1969 елда ул каты авырудан соң вафат була.

30 нчы еллар — авылда күмәк хуҗалык төзү өчен көрәш еллары. 1931-1932 елларда Нөнәгәрдә күмәк хуҗалык оеша башлый. Башта колхозга җиде хуҗалык кына керә. Колхозга керүдән куркып, берничә хуҗалык күрше Малмыж өязенең Гражданка авылына күчеп китә. Әкренләп хуҗалыклар күмәкләшә бара. Авылда ике колхоз оеша.

Түбән очтагылар «Крестьянская газета» исемендәге колхоз төзиләр. Аның рәисе итеп Нургали Әүхәдиев сайлана. Югары очта Вахитов исемендәге икенче колхоз оешып, аның рәисе итеп Сәет Гатин билгеләнә. Беренче елларны бу колхозларның житештергән продукциясе дә, үстергән икмәге дә искитәрлек булмый, чөнки авылда җир эшкәртү өчен атлар да санаулы гына калган.

1934 елда колхозга беренче машина — «полуторка» кайтаралар. Аның шоферы Мөбарәк Нуриев була. 1934 елда шулай ук беренче трактор да кайта. Ана Гыйльметдин Нәбиевне утырталар. Шушындый техникага ия булган колхоз алга бара башлый.

1935 елда хуҗалыклар бөтенләе белән күмәкләшеп бетә. Ләкин иген уңышы башка колхозларныкына караганда түбәнрәк була әле. Бер гектардан 6-7 центнердан артмый.

Колхоз оешуның акрын баруы һәм уңышның түбән булуына тагын бер сәбәп бар:

---

*Дәвамы. Башы 2006 елның 6 нчы санында.*

1928 елның 15 маенда, колхоз оешыр алдыннан, авылда бик көчле янгын була. Бу янгын вакытында күп хуҗалыкларның йортлары кара күмергә әйләнә. Таза каралты-куралар санаулы гына кала. Шуннан соң авыл халкына тернәкләнеп китү авырга туры килә.

Өлкәннәр сөйләвенә караганда, авыл кешеләре кыр эшләреннән бушаган вакытларында сезонлы эшкә, шахталарга китә торган булган.

1941 елда сугышларның куркынычы һәм зуры — Ватан сугышы башлана. Колхоз атларын һәм ике машинаны сугышка алалар. Авылның 160 тан артык ир-егете фронтка китә. Сугыш елларында колхозны Җәләй Жамалиев житәкли. Колхозда тракторда эшләргә дә кеше юк. Озак уйлаганнан соң, бу эшкә Гайшә Кәлимуллина белән Сәйдә Сиражиева алына. Күп авырлыклар белән очрашса да, авылның хатын-кызлары, карт-корылары тырышлыгы белән колхоз өстән төшкән планны үтәп бара.

Ватан сугышында авылның 94 кешесе һәлак була. Кайбер гаиләләр дүртәр кешесен югалта. Сугышка китүчеләрнең 65е генә кире әйләнеп кайта.

1946 елда, ике хуҗалык берләшеп, «Волга» колхозы төзелә. Аның рәисе итеп шушы авылдан Хажи Гайнуллин сайлана. Колхоз район өчен орлык хәзерләүгә алына. Анда сарык, сыер фермалары да була. Сугыштан соң колхозны аякка бастыру бик күп көч сорый. Күп эш кул көче белән башкарыла. Савылган сөтне чиләк-көянтә белән жиде чакрымдагы Смәел авылына илтәләр.

1961 елдан соң «Волга» колхозы белән Рим Зарипов житәкчелек итә. Колхозның икътисады, мәдәнияте күзгә күренеп үсә, ул районда алдынгылар рәтенә чыга.

1968 елда, ВЛКСМның 50 еллык юбилеен каршылаганда, колхоз игенчелек һәм терлекчелек өлкәсендә югары уңышларга ирешә. Һәр гектардан 16-18 центнер икмәк ала. Шуна да 1968 елдан башлап «ВЛКСМның 50 еллыгы» дип йөртелә башлый.

1972-1975 елларда колхозда бик зур терлекчелек комплексы төзелә.

1980 елдан башлап колхоз белән Наил Салихов житәкчелек итә. Колхозда жылы гараж, ремонт остаханәсе, агач остаханәсе, тегермән, амбар, такта яру цехы һ.б. төзелә. Хәзерге көндә авылда мәдәният йорты, мәктәп, кибетләр, балалар бакчасы, медпункт, элемтә үзәге эшли.

Авыл халкы үзәкләштерелгән газ яга, юлларга асфальт түшәлгән. 1998 елда ике катлы балалар бакчасы ачыла, элемтә бүлеге өчен бина төзелә.

Авыл тирә-юнендә елга-инешләр, чишмә-кизләүләр, тау-үрләр, сазлык-күлләрнең атамалары: Нөнәгәр суы, Тирән елга, Акман суы, Пыжан инеше, Пыжмара суы, Читәнле инеш, Сәлия инеше, Зәрәки инеше, Зират инеше һ.б.; Бирге чишмә, Урта чишмә, Баһави чишмәсе, Галләм чишмәсе, Камәр чишмәсе, Лотфулла чишмәсе, Сәлия чишмәсе һ.б. Экспедиция дәфтәремә Хәлиулла күле, Мулла сазы, Акман тавы, Әшир тавы, Байтирәк тавы, Кубыр тавы, Үзәл тавы, Дүрт сука буе, Алты сука буе, Акман басуы, Читәнле елга басуы, Бозау киртә басуы атамалары теркәлгән. Авыл янында Шәкерт зираты дип йөртелгән кабер бар. Габделкәрим исемле шәкертне мәдрәсәдә кыйнаганнар һәм ул үлгәч, суга агызганнар. Язгы ташу вакытында мәет су белән авылга агып килгән. Аны табылган урыныннан якын гына болынлыкка күмгәннәр. Ул кабер койма белән әйләндереп алынган.

Авылдан зыялы кешеләр дә шактый чыккан. Шуларның берсе Фәрзетдин Гыймади улы Гыймадиев — сугыш һәм мәгариф ветераны. «Ватан сугышы» ордены һәм «Сугышчан батырлык өчен» медале белән бүләкләнгән. Аның педагогик эшчәнлеге дә югары бәяләнә. Ул житәкләгән Балтач урта мәктәбе озак еллар районда гына түгел, республикада да алдынгылар рәтендә була. 1960 елда ул «Намуслы хезмәт өчен» медале һәм 1976 елда «Почёт билгесе» ордены белән бүләкләнә. 1960 елда аңа «Халык мәгарифе отличнигы» һәм «РСФСРның атказанган укытучысы» дигән мактаулы исемнәр бирелә.

Авылда тагын режиссёр, артистка Кәшифә Жамалетдин кызы Тумашева, галим, химия фәннәре докторы Габделбәр Гарифжан улы Гарифжанов һ.б. туып үсә.

*Дәвамы киләсе саннарда*



*Әлеге әсәрне* ***Руслан РӘҮПОВ*** *2012 елны, 11нче сыйныфта укыганда язган. Ягъни Сарман районының Азалак мәктәбендә белем алганда. Үзе хикәя дисә дә, бәянга (повесть) тартым әсәр бу. Барып чыкканмы ул? Тулаем укып бетергәч, уңай һәм кимчелекле якларын күрсәтик, мәктәптәгечә билге дә куйыйк әле, кадерле «җилкәнчеләребез».*

# БУЛГАНДА – КАДЕРЕН БЕЛ, ЮГАЛТКАЧ – ЕЛАМА

БӘЯН

## Пролог

Ай, шат та иде соң бүген Илнар! Моның кадәр сөенгәне юк иде бугай аның. Көне буена авызы ерык, кәефе турында сүз дә була алмый. Әлбәттә, шәп!

Илнар наушникларын колакларына киеп, ялтырап торган мотоциклына утырды да сөйгәненә шатлыклы хәбәрне әйтергә ашыкты. Көн кызу булганлыктан, өстендә футболка гына иде.

Көйгә кушылып җырлый-җырлый барды ул юлда. Өенә кайта торган урам буйлап барганда, юл уртасына җыелган халыкка да бик игътибар итмәде, чөнки кәефе шәп иде. Ләкин шунда аны полиция хезмәткәре туктатты:

— Күрмисеңме әллә, кая чабасың?

— Миңа бу урам буенча үтәргә кирәк иде, — диде Илнар, елмаеп.

— Монда авария булды, юллар ябык. Әйләнеп икенче урамнан бар, — дип, кулларын болгый-болгый аңлатты аңа әлеге хезмәткәр.

— Ярар, — дип җавап кайтарды да Илнар, вокзалга икенче юлдан китте.

Кичке җиденче ярты. Илнар Казан вокзалы янында туктады. Вокзал буйлап йөргәндә ике танышын очратты. Танышларын гына дип тә әйтеп булмый инде, төркемдәшләрен дисәм, дөресрәк булыр.

— Сәлам, — дип сүз башлады Илнар.

Аның каршында берсе ябыграк, икенчесе тазарак ике кыз басып тора иде.

— Сәлам, Илнар, — дип җавап кайтарды алар, Илнарны күрүгә сөенеп.

— Син монда нишлисең? Алсуны көтәсеңме? — дип сорау бирде ябыграгы.

— Һәрвакыттагыча, — дип елмайды Илнар.

— Әгәр дә син миңа өйләнгән булсаң, монда кеше көтеп утырмаган булыр идең, — диде тазасы, шаяртып.

Илнар югалып калмады, җавабын кайтарды.

— Әгәр Алсу ун минут эчендә килмәсә, без шушы Казанның берәр ЗАГСына кереп язылышырбыз.

— Вәт алдакчы, — дип көлде кыз.

Алар һәрберсе үз юллары белән китеп бардылар.

Илнар вокзалның тиешле бүлегенә килде дә Алсуны көтәргә утырды. Ун минут үтте, унбиш. Ярты сәгать, бер сәгать. Ә Алсу һаман юк.

Илнарның кәефе китте. Ул кесәсеннән телефонын алып, Алсуның әшенә шалтыратырга уйлады.

— Эльвира, — дип дәште Илнар, — Алсу һаман да эштәме әле ул?

— Ә ул күптән китте инде, — дип җавап кайтарды Эльвира.

— Кая киткәнен әйтмәдеме соң? — дип борчылып сорады Илнар.

— Юк, әйтмәде. Ул синең белән түгелмени? — дип аптырады кыз.

— Ә, ярар, рәхмәт, — дип Илнар телефонны тыгып куярга ашыкты һәм вокзал буенча чабып китте.

## БЕРЕНЧЕ БҮЛЕК

### Ике ел элек

— Китабыңны яп та ашарга утыр! — диде Алсуга әнисе.

— Әни, әгәр дә мин имтиханны бирә алмасам, үзең сүгеп утырачаксың бит, — диде Алсу.

— Сүгеп кенәме соң әле? Синең укуың өчен әтиеңнең ничә сум түләгәнен бер мин генә беләм шул!

— Әни, җитте инде! — диде Алсуның апасы Алинә. — Алсуны гел сүгеп утырасың!

— Тагын нәрсә кала соң? Нишләп ашамыйсың син? — диде әнисе Алсуга.

— Әни, күрәсеңме ничаклы май бу коймакта? — диде Алсу, коймакларга төртеп күрсәтеп.

— Нишләп, Зөлфия ашаган бит әле! — диде дә әнисе кухняга кереп китте.

— Зөлфия! Зөлфия! Зөлфия! Ул бит безнең башлыгыбыз! Һәрвакыт Зөлфияне генә күрәсең! — дип артыннан әйтеп калды Алсу.

Алинә Алсуга китапларын бирде дә:

— Әни, аның бүген имтихан бирәсе бар бит, — диде. Алар җыена башладылар. Алсу белән Алинә чыгып китәргә әзерләнгәндә, әнисе:

— Син бит врач! Үзеңне кайгырта да белмисең, — диде, Алсуның кулына талисман тагып. — Әгәр дә мин чирләсәм, апаң янына алып барма, — дип шаяртты ул Алинәгә карап. — Кызмы бу, әллә ялкынмы?

— Сау бул, әни, — диде Алсу, аның битеннән үбеп.

Алсу белән Алинә әниләре тагын нидер әйткәнче чыгып сызу ягын карадылар.

***

— Айгөл, кызым, бигрәк матурсың! — диде Илнарның әтисе, оныгын кулына алып. — Кил, бер яратыйм әле үзеңне, — дип битеннән үбә башлады.

— Мыекларың кытыклый! — диде оныгы, боргаланып. Айгөл, Илнарның кергәнен күреп, кычкырып җибәрде:

— Абый!

Илнар елмайды да:

— Сәлам, Айгөл, һәм пока, — дип, кулын болгады.

Илнар тиз генә өеннән чыгып китте дә укырга барырга дип вокзалга ашыкты. Юлда дусларын куып тотты да, бергә поездга кереп утырдылар. Поезд кузгалды. Икенче яктан аларның каршысына килгән поездның бер вагонында Илнар бик чибәр кызны күреп алды. Күзен шул кыздан ала алмады. Теге кыз да аны шәйләгән иде.

Менә поездлар арасы ерагайганнан-ерагая барды. Илнар поезд күздән югалганчы ул яктан күзен ала алмады.

Дәресләре тиз үтте бүген аларның. Ул дусларына шул кызны эзләп табарга теләвен белдерде. Ә дусларыннан бер кыз:

— Дускаем, син аның исемен дә, адресын да белмисең. Ә үзең аны бер миллион халык яшәгән шәһәрдә табарга телисең, — диде.

— Казанда барлыгы бер миллион кеше. Аларның ничәсе хатын-кыз?

— Илле проценты, — дип җавап бирде шул ук кыз. — Ягъни ярты миллион.

— Шул ярты миллионның ничәсе вузда укый ала? — диде Илнар, профессионаллар кебек сөйләшеп.

— Бер ун проценты, — диде бер дусты.

— Юк, кимрәк, — дип куйды теге кыз.

— Ярар, ун дип алыйк, — диде Илнар. — Ничә була?

— Илле мең.

— Ә шул илле меңнең ничәсе медицина буенча укый ала? — Дуслары, ухылдап:

— Әәә... ул врачмыни? — диде. — Бер процент дип уйла.

— һәм ничә кеше була? — дип, елмаеп сорады Илнар.

— Биш йөз.

— Шул биш йөзнең ничәсе поездда йөри?

— Автобус, такси, мотоциклларны алып атсак — бер процент, — диде теге кыз. — Ягъни, биш.

— Менә шул биш кыз арасыннан аны эзләп табу авырмыни инде ул? — диде Илнар көлеп.

— Шулай булгач, эзләп кара.

Менә алар вокзалга килеп җиттеләр һәм поездга утырдылар. Илнарга бер дусты:

— Илнар, Илнар, әнә ул кыз, — дип, каршыдагы поездга төртеп күрсәтте.

Илнар да кызны күреп алган иде инде.

— Ул да сине күрде, — диде теге егет.

Ул кыз, ягъни Алсу, Илнарга күренмәс өчен, икенче бер кыз артына басты. Ләкин Илнар Алсуны барыбер күрде, аңа елмаеп карап тора бирде. Ничек кенә тырышмасын, Алсу кача алмады. Шулчак поездлар кузгалды. Илнарларныкы — бер якка, Алсуларныкы — икенче якка. Илнар күздән югалгач, Алсу:

— Вәт карап катты, ә, — дип, дус кызларын көлдереп алды. Поезд тиз кайтты. Ярты сәгать дигәндә Алсу өендә иде инде. Ашады, эчте, ял итте, ятырга әзерләнде.

Йокы алдыннан Алинә Алсу бүлмәсенә керде.

— Минемчә, син гашыйк булгансың, — диде ул, елмаеп.

— Минем уемда андый нәрсә юк әле, — дип җитди генә җавап кайтарды Алсу.

— Синең йөзеңә үк язылган.

— Нәрсә? Минем, нәрсә, башым киткәнме әллә?

— Минемчә, синең эчеңдә бер очкын кабынган.

Алсу бернәрсә дип тә җавап бирмәде. Йоклаганга сабышып, бүгенге очрашуны уйлап ятты.

***

Менә икенче көнне дә дәресләр тәмамланды. Алсу поездга утырган иде инде. Поезд кузгалыр вакыт җиткәч, ул күзе белән Илнарны эзләде, тик егет күренмәде.

— Юк ул, күренми, — диде дус кызы качып торган Алсуга. — Әйдә, тиз генә чык.

— Бәлки, ул вагон өстендәдер. Сиңа җырлар җырлыйдыр, — дип шаяртты икенче кыз.
— Бигрәк кызык, — диде иптәше. — Ул булмаган арада тизрәк чыгып кал.
— Карагыз! Карагыз! Менә ул, — диде икенче кыз.
Кызыл футболка, кара күзлек кигән Илнар юл кырыенда дуслары белән басып тора иде. Алар Алсуны күреп алдылар. Алсудан дусты:
— Син чыгарга җыенмыйсыңмыни? — дип сорады. Алсу башын селкеде. Шул вакыт поезд кузгалды.
Илнар Алсуның исемен белмәсә дә, кайда яшәгәнен, аның адресын җиңел генә эзләп тапты. Ул институттан кайткач, көн саен аның өй тирәсен бер әйләнмәсә күңеле булмый. Ничә көн Алсуның өе янында таптанмасын, аны очрата алмый иде. Ләкин бүген Илнар аның кер элгән вакытына тап булды. Туктап, мотоциклын сүндерде дә Алсуның һәр хәрәкәтен күзәтеп торды. Шулчак Илнарның каршына эштән кайтып килүче Алия — Алсуның апасы очрады.
— Сәлам, — диде Алия.
Илнар аны күргәч каушап калды. Күзлеген салды да исәнләште.
— Кемне эзлисең? — дип сорады Алия.
— Нәрсә? Беркемне дә, — дип ялганлады ул, елмаеп.
— Кер элеп торган кызны түгелме? — дип, белгән кыяфәт чыгарып әйтте Алия.
Илнар дәшмәде, тагын бер кат елмайды гына.
— Ә аның исемен беләсеңме соң?
Илнар башын гына селкеде.
— Ә сызгыра беләсеңме? — ике бармагын авызына тыгып ышылдап күрсәтте Алия. — Менә болай.
Бу юлы да Илнар башын селкеде.
— Син тәртипле кешегә охшагансың, — дип елмайды Алия, Илнар да шул елмаюга кушылды. — Әзрәк кенә тавышланып ал әле.
— Нәрсә? — дип сорады Илнар, аңламыйча.
— Мотоциклыңны кабыз!
Илнар шундук мотоциклын кабызды да берничә тапкыр газына басты. Мотоцикл каты тавыш чыгара башлады. Бу тавышны Алсу ишетеп, борылып карады. Алия белән Илнарны күреп алды һәм эшеннән туктап:
— Алия! — дип кычкырып җибәрде.
— Менә, күрдеңме? — диде Алия Илнарга. — Дөрес эшләдең.
— Алия, нишлисең син анда? — дип, кулларын болгый-болгый кычкырды Алсу.
— Киләм! Менә бу кешегә юлны гына күрсәтмәкче идем, — диде Алия.
— Рәхмәт, — дип кушылды Илнар.
Алия борылды да өйләренә юнәлде.

***

Илнар бүген дә аларның өе янына килде. Ләкин бүген Илнар Алсуны түгел, ә Алсу Илнарны көтеп тора иде.
Илнар мотоциклы белән Алсу янына килеп туктагач, Алсу шундук сүз башлады.
— Синең исемең ничек?
— Илнар, — дип, мотоциклыннан төште егет.
— Син укуыңнан качып, кызлар артыннан чабасыңмы? — дип тавышын күтәребрәк әйтте Алсу. — Синең әтиеңнең акчасы күптер инде, шулай юкка вакыт әрәм итәрлек булгач.
— Әйе, ул да шулай дип әйтә, — дип бүлдерергә тырышты аны Илнар.
— Имтиханнарыңның ничәсен бирдең? — дип сорады Алсу.
— Бөтенесен дә бирдем, — дип елмайды Илнар. — Ләкин соңгысын бирә алмам шул инде.

Алсу да елмаюын яшереп тормады. Кинәт кенә борылып китеп барганда, Илнар:

— Әй! — дип кычкырды. Алсу аңа таба борылды. — Тагын бер кат елмай әле, — диде. — Үтенәм синнән.

Алсу елмайган килеш кире борылып өенә кереп китте. Кызны күпме көтсә дә, ул чыкмады. Илнар өенә кайтып китәргә мәҗбүр булды.

Бер сәгать тә үтмәде, Алсулар өендә телефон шалтырады. Телефонны әтисе алды:

— Тыңлыйм.

Телефонның икенче башында Илнарның сеңлесе сөйләшә иде. Нәрсә дип җавап бирергә кирәк икәнен Илнар үзе әйтеп торды.

— Алсуны чакырыгыз әле, дип әйт, — диде Илнар. Сеңлесе аның сүзләрен кабатлады.

— Ә кем соң бу? — дип сорады Алсуның әтисе.

— Мин — Гөлнар, — дип җавап бирде Илнарның сеңлесе.

— Нинди Гөлнар?

Нинди Гөлнар?, — диде абыйсына кызчык.

— «Мин дус кызының сеңлесе» дип әйт, — диде Илнар.

— Мин дус кызының сеңлесе дип әйт, — дип шул ук сүзләрне кабатлады Гөлнар.

— Син нәрсә? Мин әйткәннәрне генә әйт дип әйттем бит! — дип пышылдады Илнар.

— Син нәрсә? Мин әйткәннәрне генә әйт дип әйттем бит! — дип кабатлады Гөлнар.

Алсуның әтисе түзмәде, кызның үзен чакырырга булды. Гөлнар телефонны Илнарга бирде дә:

— Син миңа нәрсәдер бирермен диген идең, — дип, кулын сузды Гөлнарга.

Илнар Алсуга йөз сум акча бирде. Гөлнар шундук чыгып сызды. Алсу трубканы алды да, "Тыңлыйм!", дип дәште.

— Алсу...

— Син?! — дип шаккатты Алсу. — Минем номерны каян беләсең син?!

— Иртәгә безнең өйдә бәйрәм. Сәгать унга килә аласыңмы? — дип, аңа җавап бирмичә сорады Илнар.

— Мин? — дип аптырады Алсу. — Нишләп?

— Ничек инде? Мин синең бик матур җырлаганыңны беләм.

— Шуннан нәрсә?

— Мин бит сине клубка чакырмыйм, өйгә, — дип җавап бирде Илнар.

Шул вакытта икенче якта Гөлнар, аның бабасы, ягъни Илнарның әтисе бергә аның сөйләшкәнен тыңлап торалар иде. Бабасы Гөлнарга тагын йөз сум акча төртте, ягъни Илнарның кем белән, нәрсә турында сөйләшкәнен белергә теләде.

— Нишләп әле мин синең янга килергә тиеш? — дип сорады Алсу.

— Ярар, син килмәсәң, мин сиңа килермен, — диде Илнар.

— Син чынлап та акылдан шашкансың икән, — дип көлде Алсу.

— Мин синең аркада акылдан шаштым, сине сагынып акылдан шаштым, — дип җавап бирде Илнар. — Психбольницаның адресын язып куй, — дип, үзенең адресын әйтергә тотынды. — Ике йөз алтмыш өченче йорт...

— Тыңла әле, — дип бүлдерергә теләде аны Алсу. Ләкин Илнар дәвам итте.

— Тажи Гыйззәт урамы. Өй кырыенда бер кибет бар. Шуны әйләнеп үтәргә кирәк. Аннары мәчетне күрерсең. Шуның кырыенда безнең йорт. — Язып куйдыңмы?

— Илнар! — дип кычкырды Алсу. Ләкин Илнар трубкасын куйган иде инде.

***

Шулай да Алсу Илнарларга барырга булды. Бүген Илнарның әнисенең туган көне икән. Аларның өендә кеше күп иде. Әнисе ягыннан, әтисе ягыннан туган-тумачалар җыелган. Илнар, Алсуның матур җырлавын белгәч, аны әнисе каршында җырлатмакчы, берочтан кунак та итмәкче булды. Алсу искиткеч матур итеп җырлады. Тавышы бик шәп яңгырады.

Әлбәттә, Алсу белән кызыксынучылар да булды. Кем ул? Кайсы яктан?

— Кем ул кыз? — дип сорады Илнардан әтисе. Илнар да югалып калмады:

— Ә ул кызга мин өйләнмәкче булам.

— Син чынлап та аңа өйләнмәкче буласыңмы? — дип әнисе дә кушылды.

— Әлбәттә! Туй көне билгеле түгел әле, ләкин син иң беренчеләрдән булып белерсең, — дип җавап бирде Илнар.

Бу хәбәр бер минут эчендә бөтен өйгә таралды, һәммәсе аңлады: Илнар тиздән өйләнә.

Кич җитәрәк Алсу кайтырга уйлады. Илнар аны озата китте. Поездда кайтканда, тынлыкны бозып, сүзне Алсу башлады.

— Нишләп син туй турында әллә нәрсәләр сөйләдең?

— Мин бит син миңа чыгасың дип түгел, ә мин сиңа өйләнәм дип кенә әйттем, — дип җавап бирде Илнар.

— Ә миннән сорадыңмы соң?

— Нишләп? Минем әти-әни синең әти-әниеңнән сорарга тиеш түгелмени? Әгәр дә телисең икән, мин синнән сорый алам. Син миңа...

— Юк, — дип шундук җавабын кайтарды Алсу.

— Ярар, иртәгә әти-әнине сезгә җибәрермен. Башта алар танышсыннар, сөйләшсеннәр.

— Нишләп әле мин сиңа чыгарга тиеш ди?

— Чөнки... — Илнар аңа якынрак килде. — Әйтимме? — Илнар Алсуның кулыннан тотты да аны үзенәрәк тартты.

— Чөнки мин сине яратам, — диде Илнар.

— Ә нәрсә соң ул? — дип сорау бирде Алсу.

— Нәрсә? — Илнар аптырап калды. — Яратам... ягъни яратам.

— Ә нәрсә соң ул «яратам»? — Алсу Илнарга елышты.

— Ягъни яратам. Ягъни синең өчен бар нәрсәне дә эшли алам.

Алсу юлга карады да:

— Минем өчен поездан сикерә аласыңмы? — дип, егетнең күзенә бакты.

— Әйе, әлбәттә! — дип көлде Илнар.

— Менә поездан сикергәч тә сиңа кияүгә чыгармын, — дип тыныч кына әйтте Алсу һәм кире урынына басты.

Менә алар кайтып та җиттеләр. Алсуны апасы каршы алган иде. Караңгы бит. Сүзне Алия башлады.

— Сиңа ошыймы ул, юкмы?

— Хәзер минем госэкзаменнарым. Миңа бик ныклап әзерләнергә кирәк, — дип тыныч кына сөйләште Алсу.

— Әйт инде, ошыймы ул, юкмы? — дип Алия аны сораулары белән туйдыра ук башлады.

— Кара әле, — дип бүлдерде Алсу. — Башта син кияүгә чыгарга тиеш, аннары гына мин.

Алия җавап бирмәде.

***

Өйләренә кайтып керү белән алар, әти-әниләренең карта уйнап утырганын күрделәр дә, үзләре дә аларга килеп кушылдылар. Берничә минуттан өйдәге тынлыкны Алия бозды.

— Әти, әти, — диде ул, — әгәр дә безгә бер бай гаиләдән кул сорарга килсәләр, сез нишләр идегез?

Ата-аналары аптырап калдылар. Алсу бигрәк тә. Алия дәвам итте.

— Кул сорарга килсәләр дип әйткән идем, — дип җөмләсен дә бетерә алмады Алия, аны Алсу туктатты.

— Җитте инде, Алия!

Алсу шундук торды да:

— Ярар, минем имтиханга әзерләнәсем бар, — дип, икенче бүлмәгә чыгып китте.

— Тиздән безгә бер гаилә киләчәк, — диде Алия, әтисенә карап.

— Кем? — дип сорады әтисе.

— Ну... Миңа түгел инде, Алсуга, — дип аңлатты Алия. Шул вакытта әнисе торып икенче бүлмәгә атлады.

— Кемнәр соң алар? — диде әтисе.

— Нindидер адвокат, һәм аның улы Илнар.

— Миңа бер кеше дә бернәрсә дә әйтмәде, — диде әтисе аптырап. — Алар болай гына килә аламыни?

— Менә... мин... сиңа шуны әйтәм дә инде, — дип җавап бирде Алия. Әнисе Алсу бүлмәсенә керде дә, шундук тавышын күтәреп:

— Беләсеңме, кызым, син укысын дип без соңгы акчаларыбызны да кызганмадык. Шуның өчен дип без сине институтка җибәрдекме әллә?

— Кияүгә чыгарга җыенмыйм бит әле мин, әни! — дип бүлдерде Алсу. — Мин беркемне дә чакырмадым. Ул егет үзе минем арттан йөри бит! Нишли алам соң инде?

Аның кәефе төшкән иде.

— Синең арттан йөрерлек булгач, берәр нәрсә эшләп ташлагансың инде! Егет болай гына кыз кешене күзәтеп йөри аламыни ул?!

Алсу җавап бирмәде. Соң булгангамы, аның башы бик каты авырта иде.

Менә икенче көн дә килеп җитте. Алсулар шәһәр читендә яшиләр. Өйләре яңа түгел, бүлмәләре дә заманча җиһазланмаган. Иртән үк, чит ил машинасына утырып, Алсуларга Илнарның әти-әнисе килеп төште. Ярлы район икәнен шундук күреп алдылар алар. Алсуларның өенә килеп, ишек шакыдылар. Ишекне Алсуның әнисе ачты. Матур итеп елмайды, яхшы булып күренергә, алардан ким булмаска тырышты:

—Ерегез, исәнмесез!

— Звоногыгыз ватылган бугай, шуңа ишек шакырга гына туры килде инде, — диде Илнарның әтисе.

Әти-әниләр диванга утырыштылар.

— Өйне табу авыр булмагандыр бит? — дип кызыксынып сорады Алсуның әтисе.

— Әзрәк йөрергә туры килде инде. Нишләп сез мондый районда яшисез? Бар өйләр дә бер-берсенә охшаган, — дип көлүен яшермәде «кодасы».

— Ул шаярырга ярата инде, — диде егетнең әнисе, иренә төрттереп. Алсуның әтисе кызлары кергәнен күрде дә, елмаеп, үзләре янына дәште:

— Керегез, кызлар.

Керделәр инде. Алсу да, Алия дә матур, яңа күлмәк кигәннәр, икесе дә чибәрләр.

— Менә болар минем кызларым, — диде әтисе.

Кызлар аларның каршына барып утырдылар, әдәпле генә исәнләштеләр.

— Алар бик матур җырлыйлар, — дип мактанды әнисе.

— Әйе, Алсу бездә дә җырлап алды инде, — диде Илнарның әнисе, елмаеп.

— Менә балаларыбыз сөйләшеп тә куйган инде, — диде егетнең әтисе.

— Илнар нинди малай соң ул? — дип сорады Алсуның әтисе. — Кызым бар дип әйтер дип көтмәгәнсездәдер?

— Байлыкта үстергәч. Илнардан берни дә көтмим инде мин. Белмәссең аны. Иртәгә урамнан тагын берәр нәрсә алып килсә, ни дим инде мин аңа?

Алсуның әтисе, аны туктатып, болай диде:

— Сез нәрсә, мин кызларымны урамга чыгарып аткан дип уйлыйсызмы? ! Безнең кебек гади кешеләр белән сөйләшә белмисез икән!

— Сез икенче нәрсәне уйлагансыз. Мин моны күз алдында тотып әйтмәгән идем, — дип акланды Илнарның әтисе.

— Бернәрсә дә аңлатуыгызны сорамыйм! — дип дәвам итте кызның әтисе. — Мин сезгә беркайчан да кызымны бирмәячәкмен!

— Бу хәлләр килеп чыкканга без гаепләме әллә? — диде дә урыныннан торды Илнарның әтисе.

Тиз генә җыендылар да чыгып та киттеләр. Шул вакытта Алсуның әнисе кызына бик зәһәр карап торды. Алсу ни дип әйтергә дә белмәде. Кырыс иде шул аның әнисе.

***

— Алсу! Алсу, тукта әле! Нәрсә булды? — дигән тавышка борылып караса, Алсу Илнарны күреп алды.

Боларның институттан кайткан вакытлары иде.

— Нәрсә булган, шул булган инде, — дип җавап кайтарды Алсу аңа. — Моны туктатсаң яхшы булыр иде.

— Минем мәхәббәт берни дә аңлатмыймыни? — дип аптырады Илнар.

— Син мине кайчаннан бирле беләсең соң? 20 атнамы?! Ә алар мине 20 ел буе үстерделәр. Синең өчен мин әти-әнине ташлый алмыйм.

Илнарның кәефе бик нык төште.

— Алсу, синең өчен мин барысына да әзер.

— Бүген син минем өчен барысына да әзер. Ә иртәгә башка кыз өчен мине ташламаячаксың дип кем сүз бирә ала? — дип, Алсу атлавын дәвам итте.

— Алсу, бер генә минут, — диде Илнар. — Нишләп безгә шулкадәр ашыгырга соң әле? Әз генә булса да вакыт бардыр бит. Бер атна. Ун көн.

— Бер атна эчендә нәрсә үзгәрә ала инде?

— Алсу, бер атна эчендә күп нәрсә үзгәрергә мөмкин, аңла шуны!

— Тыңла әле, Илнар, — дип кырт кисте Алсу. — Юк, сигез-ун көн эчендә берни дә үзгәрә алмый!

— Ә мин бер мизгелдә дә бөтен нәрсә үзгәрә ала дип ишеткән идем, — дип кәефсез генә җавап бирде Илнар.

— Шушы вакыт эчендә бернәрсә дә үзгәрмәде бит.

— Син мине бер дә исеңә төшермәдеңме? — дип, дымлы күзләре белән Алсуга бакты Илнар.

Җавапка Алсу башын гына селкеде.

— Юк, сәбәп булмады.

— Тагын бер мәртәбә уйла әле, — дип, йөзенә мескен кыяфәт чыгарды Илнар.

— Уйладым инде.

— Ярар, — диде Илнар, аңа кулын сузып. — Сау бул — Алсу аның кулын кысты һәм:

— Сау бул, — диде. —Йөзеңнән елмаю китмәсен, — дип тә өстәде.

— Елмаю... күз яшьләре аша... — дип әйтте Илнар.

Алсу борылды да үз юлы белән китеп барды. Илнар бик озак аның артыннан карап калды.

*Дәвамы киләсе саннарда*

## Сиңа килдем бүген кабаттан

*Бүген сиңа килдем, җанны тыеп,*
*Бар көчемне җыеп кабаттан.*
*Битәрләмә мине, очрамады*
*Синең кебек өзелеп яраткан.*

*Гафу сорыйм, соңлап булса да мин,*
*Кичерә күр сөю хакына.*
*Яшь күңел ул иләс–миләс була,*
*Ялган бәхет эзләп талпына.*

*Кадереңне белми читкә киттем,*
*Сакламадым изге хисләрне.*
*Күпме генә вакыт үтсә дә, мин*
*Оныта алмыйм уртак кичләрне.*

*Бүген кабат синең янга килдем,*
*Карарга да куркам күзеңә.*
*Мин тудырган сагыш ята анда,*
*Беләсең бит моны үзең дә.*

*Чак–чак тыеп торам яшьләремне,*
*Их,капланып сиңа еларга!*
*Күңелемнән һаман кабатлыймын:*
*Үпкәләмә үткән елларга.*

*Минсез генә үтеп китсәләр дә,*
*Алар җанда уелып калырлар.*
*Тик туасы көннәр күңелеңә*
*Мәңге сүнмәс шатлык салырлар.*

*Минем йөрәк һаман сызлый әле*
*Тормыш биргән ныклы сабактан.*
*Гафу сорап килдем бүген сиңа,*
*Гаебемне танып кабаттан.*

Сиринә **МӨХӘММӘТҖАНОВА,**
*Балык Бистәсе районы*

---

*Хикәя яза аласызмы?*

# ИКЕ ХӘСӘН ХИКӘЯСЕ

**— Исәнмесез! Хуҗалар өйдәме? — дип сөрән салды Хәсән, зур урыс капканы ачып, ишегалдына аяк басуга.**

**— Исәнме, абый, сиңа кем кирәк?..**

**Хәсән «дерт» итеп китте. Аның каршында тач үзенә охшаган, зур башлы, зур колаклы, җиде-сигез яшьләр тирәсендәге бер малай басып тора иде.**

— Миңа Ләйсәнә кирәк иде. Ул синең әниең түгелме? Миңа аны күрергә кирәк! Эштәме? Озак көтәргә туры килмәс микән?

— Әйе! Минем әнием — Ләйсәнә исемле, ә минем исемем — Хәсән! Әниемне кичә генә больницага салдылар, сукыр эчәге шартлаган. Әнием терелгәнче мин әбием белән генә яшәп торам. Тик ул да бүген иртән Чаллыга,

әниемнең хәлен белергә дип киткән иде. Тиз генә кайтам дисә дә, озак торды. Кайтмый да кайтмый! Әбием пешереп калдырган ботканы да, йомырканы да ашап бетердем. Ул да бүген кайтып җитмәсә, иртәгә мин нәрсә ашармын икән, белмим. Әбием миңа өйдән чыгып йөрмәскә кушкан иде. Әнием дә, әбием дә булмагач, өйдә үземә генә бик күңелсез шул! Минем урамга чыгуым турында әбигә әйтмәссең, яме, абый!

— Ярар! Килештек! Бир бишне!

Үзенең зур учына малайның нәни кулы килеп керүгә, бөтен тәне буйлап ниндидер рәхәт дулкын узып китүен тойды Хәсән. Мондый рәхәтлекне аның әлегә кадәр беркайчан да татыганы булмаган иде. «Улым!» — дип кычкырасы килә, ләкин ярамый, баланы куркытуың бар!

— Абый! Синең исемең ничек соң? — дип кызыксынды бала.

— Мин дә Хәсән исемле идем шул, акыллым!

— Бөтен Хәсәннәр дә бер-берсенә охшаган булалармы, абый? Син бит миңа бик охшагансың, сакалыңны гына кырмагансың.

— Хәсән исеме — «чибәр, матур, күркәм» дигән мәгънәгә ия. Шуңа күрә, бәлки, шулай бер-беребезгә бик охшаганбыздыр?!

Шушы мизгелдә Ләйсәнә кайтып керсә, олы Хәсән аның табанына егылырга да әзер иде.

— Абый! Син бүген бездә генә йоклап кала алмыйсыңмы? Әбием кайтып җитмәсә, мин өйдә берүзем генә кунарга куркырмын. Минем синең белән җитәкләшеп Азатлар торган өй янына барып киләсем килә, урамның теге башында, мәктәп янында яши ул Азат исемле малай. Ул миннән һаман: «Синең әтиең юк!» — дип көлә. Син бер генә көнгә булса да минем әтием булып тор әле! Мин начар малай түгел! Әниемне борчымас өчен, Азатның бу сүзен әниемә әйтмәдем дә.

— Җитәкләп түгел, җилкәмә атландырып Азатлар өе янына алып барыйммы соң сине? Әйдә, мин — чабыш ат — аргамак булам, ә син атны тотып баручы — сабантуй батыры бул! Килештекме? Бир бишне!

Бу мизгелдә ике Хәсән дә үзләрен күкнең җиденче катында дип хис иткәннәрдер: икесенең дә күзләреннән нур көлтәсе сибелә иде...

**Флёра МӘРДӘНОВА**

---

## Халык әйтсә, хак әйтә

*Бер өйдә ике кыз:*
*Берсе энә, берсе без.*

*Билеңне кысып кына кыз булып булмый.*

*Әдәпле кыз сәдәпле.*

*Кызлар бүрәнә ярыгындагы таракан ботыннан да көләләр.*

*Кызлар киенгәнче, кысыр сыер бозаулар.*

*Егет җиле белән йөрер.*

*Егет чак – эчмичә исерек чак.*

***

ТР Президенты Рөстәм Миннеханов ТР Фәннәр академиясе президиумы әгъзаларын раслады.

1 февральдә имзаланган документ буенча, ТР Фәннәр академиясе президиумы составына 15 кеше керде. Алар арасында ТР Премьер-министр урынбасары — мәгариф һәм фән министры Э.Фәттахов, «Татнефтехиминвест-холдинг» ААҖ генераль директоры Р.Яруллин, «Идея» инновацион-житештерү технопаркы» ААҖ генераль директоры С.Юшко, баш геолог — «Татнефть» ААҖ генераль директоры урынбасары Р.Хисамов, ТР Дәүләт Советының Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Р.Вәлиев, ТР авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары И.Габдрахманов, ТР мәдәният министры урынбасары Г.Нигъмәтуллина, ТР сәнәгать һәм сәүдә министры урынбасары И.Мингалиев бар.

Шулай ук президиум составына А.Гыйльметдинов (Казан илкүләм техник тикшеренү университеты-КАИ), И.Гафуров (Казан (Идел буе) федераль университеты), Г.Дьяконов (Казан илкүләм технологик тикшеренү университеты); К.Салихов (Россия Фәннәр академиясенең Е.Завойский исемендәге Казан физика-техника институты), М.Сафиуллин (ТР Фәннәр академиясенең Перспектив икътисади тикшеренүләр үзәге) керде.

Моннан тыш президиум составында «ТАИФ» ААҖ генераль директоры урынбасары В.Пресняков, Россия Фәннәр академиясенең Казан фәнни үзәге президиумы рәисе О.Синяшин кала.

Герман Дьяконов һәм Кев Салихов ТР Фәннәр академиясенең вице-президентлары булды.

***

4 февральдә Мәскәүдә ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин Федераль Җыен каршындагы Россия Федерациясенең Закон чыгаручылар советы президиумының быелгы беренче утырышында катнашты. Ул мәдәният өлкәсендә дәүләт сәясәтен камилләштерү буенча аерым тәкъдимнәр кертте.

Утырышта Россия Федерациясендә мәдәният сәясәтенең өстенлекле юнәлешләре һәм аны законнар белән тәэмин итүне камилләштерү турындагы төп мәсьәлә буенча фикер алышу булды. Бу темага багышланган доклад белән РФ мәдәният министры Владимир Мединский чыгыш ясады. Ул РФ Мәдәният министрлыгы эшчәнлеге турында сөйләде.

ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин мәдәният турында закон кабул итүнең төбәкләр үсеше өчен мөһим мәсьәлә булуын билгеләп үтте. «Мәдәният турындагы закон бик кирәк һәм төбәкләр, Россиянең аерым субъектлары мәдәнияте һәм милләтләр төрлелеген исәпкә алып, аны эшләүдә катнашырга әзер», — диде ул.

***

21 гыйнвар көнне Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең чираттагы утырышы булды.

Быел Язучылар берлеге оешуга 80 ел тула. Идарә әлеге вакыйганы апрель аенда узачак «Казан — төрки дөнья башкаласы» елы кысаларында үткәрәчәкләре турында әйтте, юбилейның программасын, аны оештыру комиссиясе исемлеген раслады. Юбилей уңаеннан Миргазиян Юныс белән Фоат Садриев — «Татарстанның халык язучысы», Зиннур Мансуров «Татарстанның халык шагыйре» дигән мактаулы исемгә тәкъдим ителде.

Утырышта шулай ук Түбән Кама шәһәрендә Татарстан Язучылар берлегенең бүлекчәсен булдыру зарурлыгы турында да җитди сөйләшү булды. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы һәм Язучылар берлегенең әдәби премияләренә кандидатлар тәкъдим ителде. «Йолдызлар төстән язганда» дигән повесть һәм хикәяләр (Татарстан китап нәшрияты, 2013), Г.Исхакый иҗатын фәнни яктан өйрәнгән «Әдәби бәйләнешләр яктылыгында» («Гарт» нәшрияты, 2002) җыентыклары һәм иҗтимагый эшчәнлеге өчен Р.Рахман — Г.Исхакый, «Еллар кәрваны» (Татарстан китап нәшрияты, 2011) шигырьләр җыентыгы өчен Фирүзә Җамалетдинова — Һ.Такташ, «Язмышның туган көне»: повестьлар, хикәяләр, парчалар, әкиятләр җыентыгы («Ихлас» нәшрияты, 2012) өчен Галимҗан Гыйльманов — Ф.Хөсни, «Гасырлар арасында уйланулар» җыентыгы (Татарстан китап нәшрияты, 2010) өчен Ха-

тыйп Миннегулов Ж.Вәлиди исемендәге премиягә тәкъдим ителде.

«Йөрәгемдә шаулый карурман» («Рухият» нәшрияты, 2001), «Күз нурларым» (Татарстан китап нәшрияты, 2002), «Башкаемда дөнья исәпләре» (Татарстан китап нәшрияты, 2007) шигырьләр һәм поэмалар җыентыклары өчен шагыйрә Флёра Гыйззәтуллина, «Утлы дала» китабы (Татарстан китап нәшрияты, 2012) өчен Вахит Имамов 2014 елда Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә тәкъдим ителде.

Утырышта прозаик Кәрим Кара һәм шагыйрә Екатерина Аничкина Татарстан Язучылар берлегенә әгъза итеп кабул ителде.

***

5 гыйнвар көнне Мәскәү Татар мәдәният үзәгендә Мәскәү Татар милли-мәдәни мохтарияте төбәк иҗтимагый оешмасының хисап-сайлау конференциясе булды. Делегатлар оешманың яңа рәисен һәм мохтарият советы әгъзаларын сайлады.

Оешманың эшчәнлеге хакында Рәсим Акчурин хисап ясады. Ул исә күп еллар дәвамында Мәскәү шәһәре татар мохтариятенә рәислек итеп, яңа эшкә көчүе һәм вакыт тарлыгы сәбәпле, биләгән вазифасыннан азат итүне сорады. Рәсим Акчуринның зур тәҗрибәсе, Мәскәү татарларын берләштерүдәге, татар теле һәм мәдәнияте сакланышындагы өлеше зур булуны исәпкә алып, аны әлеге оешманың шәрәфле президенты итеп сайладылар.

Конференциядә Мәскәү Татар миллимәдәни мохтариятенең яңа Уставы кабул ителде.

Әлеге региональ иҗтимагый оешманың рәислегенә 2 кандидат тәкъдим ителгән иде: ТРның РФдәге элеккеге тулы вәкаләтле вәкиле Назыйф Мириханов һәм «Татарский мир» федераль газетасының баш мөхәррире Ринат Мөхәммәдиев.

Конференция делегатлары, ачык тавыш бирү юлы белән, оешманың яңа рәисе итеп язучы-галим Р.Мөхәммәдиевне билгеләде, мохтарият советы составының яңа составы сайланды һәм анда Мәскәү яшьләре дә керде.

***

5 февраль көнне «Казан утлары» журналы редакциясенең идарә утырышы булды.

2014 елга «Казан утлары» журналының үсеш перспективалары турында баш мөхәррир Илфак Ибраһимов чыгыш ясады.

Конкурслар үткәрүнең әһәмияте, тәрҗемәләрнең кирәк булуына тукталганнан соң, ул дәвам итеп: «Журналыбызның популярлыгын арттыруда, һәрвакыттагыча, аның иҗтимагый-сәяси юнәлештәге язмалары да зур роль уйный... Бу уңайдан милли сәясәтчеләребез, милли философларыбыз, акыл ияләренең язмаларын урнаштыру, «түгәрәк өстәл»ләр, әңгәмәләр үткәрүне һәр сан өчен махсус оештырачакбыз», — диде.

Равил Фәйзуллин журналның тиражын югалтмаска, укучылар санын арттыру буенча тагын да ныграк эшләргә кирәклеген билгеләп үтте.

Идарә әгъзалары журналның үсеш перспективаларын тагын бер кат уртага салып сөйләште, утырыш нәтиҗәле узды.

7 февраль көнне «Гасырлар авазы — Эхо веков» журналының баш редакторы, ТР Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсенең элекке җитәкчесе, тарих фәннәре докторы, фән һәм техника өлкәсендә ТР Дәүләт премиясе лауреаты, ТР Журналистлар берлеге һәм Язучылар берлеге әгъзасы **Дамир Рәүф улы Шәрәфетдинов** 74 нче яшендә вафат булды.

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* Табигатьтә яз.

*Тышлыкның дүртенче битендә:* «Зәңгәр шәл» (К.Тинчурин) спектакленнән күренеш. 2011 ел.

## Яңа китаплар




**Клара Булатова.** Сәяхәтнамәләр: Шигырьләр. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2013. – 127 б. Тиражы – 2000 данә.

Әлеге китабына язган кереш сүзендә шагыйрә, «Сәяхәтнамәләр» җыентыгының ничек дөньяга килү тарихын сурәтләп: «Үткән гасырда көндәлекләргә теркәлеп калган вакыйгаларны күздән кичереп утырам, көндәлекләрне мин 1958-1959 еллардан бирле шигырь белән алып барганмын, әле дә шулай. Үземнең озын гына кыска гомеремне йомгаклап килгәндә, сәяхәтләр вакытында иҗат ителгән шигырьләремне укучылар игътибарына тапшыру зарар итмәс дип уйлыйм», – дип яза. Китап белән танышып чыккач, сәяхәтләрнең, дөнья күрүнең иҗат кешесе өчен кирәкле гамәл булуын шагыйрәнең ихлас, матур шигырьләре аша да тоясың.




**Фәнис Яруллин.** Хәтер төпләрендә утлы күмер (көндәлекләр). – ГУП «ИПК» «Чувашия», 2013. – 584 б. Тиражы – 4000 данә.

2013 елның җәендә язучы һәм шагыйрь Фәнис Яруллинның көндәлекләре китап булып басылып чыкты. Әлеге китапны ул үзе әзерләп, кереш сүзен дә үзе язып калдырган.

Киң катлам укучыларга тәкъдим ителә торган бу китапка авторның аерым шәхесләргә, тормышка, дөньяда барган вакыйгаларга карата үз кичерешләрен, үз уй-фикерләрен чагылдырган көндәлекләре тупланган.

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)